# казан утлары

5
МАЙ-1974

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**5**

МАЙ
1974

## Бу санда

**С. ХӘКИМ. Дәверләр капкасы.** Поэма . . . . 3
**Х. ТУФАН. Багышлаулар дәфтәреннән.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 9
**Х. КАМАЛОВ. Һәркемнең гомере бер генә.** Роман . . . . . . . . . . . . . . . . 13

ДУСЛАР ҖЫРЫ

**Ш. БИККОЛ. Фаҗигадән туган дүрт җыр.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 77

Э. МӨЭМИНОВАГА 50 ЯШЬ

**Э. МӨЭМИНОВА. Туган илем минем.** Шигырьләр. 80

ОЧЕРКЛАР

**КамАЗ елъязмасы** . . . . . . . . . . . . 84
**М. МАЛИКОВА. Күлләр үзәге Самотлор** . . . . 87

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

**С. СӨЛӘЙМАНОВА. Әс-сәлями, Суфият!** . . . 99

ИСТӘЛЕКЛӘР, ОЧРАШУЛАР

**Л. БАДЫЙКШАН. Ерак дингездә** . . . . . . . 117

Х. ЯРМИГӘ 70 ЯШЬ

**И. НАДИРОВ. Татар совет фольклористикасының аксакалы** . . . . . . . . . . . . . . . 131

СССР ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНӘ 250 ЕЛ

**А. ӘХМӘДУЛЛИН. Олы фән юлында** . . . . . 135

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**С. РӘИМОВА. Г. Ибраһимовның бер хикәясе турында** . . . . . . . . . . . . . . . . 140

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

С. ШӘЙДУЛЛИН. Хикмәт инкарь итүдә генәме! . 142

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ VIII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Л. ЮДКЕВИЧ. Татарстанда яшәүче рус язучылары иҗаты . . . . . . . . . . . . . . . 152
Т. ГАЛИУЛЛИН. Буыннар һәм язмышлар . . . . 157

КИТАП КҮЗӘТҮ

И. АХУНҖАНОВ, В. ЗЕЛЕНКОВ. Паустовскийның гуманизмы . . . . . . . . . . . . . . 176
Р. ШИРИЯЗДАНОВ. Сибелә чәчәк җилләр искәндә . . . . . . . . . . . . . . . . 179

Безнең календарь . . . . . . . . . . . . . 181

«ЧАЯН» БҮЛЕГЕ

Татарстан язучыларының стена газетасы «Тынгысыз каләм» бездә кунакта . . . . . . . . . 183

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

*Редакциянең адресы: Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казан, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: **Гариф Ахунов**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 7/II-1974 ел. Басарга кул куелды 10/IV-1974 ел. ПФ 09007. Кәгазь форматы 70×108 1/16, Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8), Тираж 89.000 экз. Заказ Ю-26. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 12.

© «Казан утлары», 1974 ел.

## Сибгат Хәким

# ДӘВЕРЛӘР КАПКАСЫ

ПОЭМА

Бар шагыйрьләр җирдә купкан чакта,
Юл биргәндә бар да туктап чатта,
Бик аз гына шунда, бик аз гына,
КамАЗ белән бары намаз гына
Рифмалашмый калган заманда,
Мин дә йөрдем, йөрдем КамАЗда.
Сәлам биреп горур ил картына,
Кереп иске Чаллы зиратына,
Кереп рәттән шунда ЗАГСка
(Үтте яшьлек, яшьлек аз, кыска),
Теләп бәхет безнең Чулпаннарга,
Гашыйк булып Чулпан — чор — таңнарга,
Теләп саулык өйдә хатыннарга
Һәм буйсынып сухой законнарга,
Туктап, карап мин һәр ун адымда,
Йөрдем иркен Җәлил урамында.
Йортлар, йортлар, бардыр канатлары,
Мин канатлы йортлар тарафдары,
Канатлары озын (җәлләрлек тә),
Китәрләр күк очып зәңгәрлеккә.
Егетләре Вазыйх Мәүлековның
Гөмбәзенә үрләгәндә күкнең,
Урал аша түгел, урам аша
(Кранлаша заман, кранлаша)
Сөйләшкәндә Казан белән Уфа,
Сүзләренә илһам куша-куша,
Һәм рәхмәтләр әйтеп Ереванга
Яңа йортлар буйлап йөрдем анда.
Һәр халык үз төсен, хисен салып,
Йортларыңны синең китсен салып.
Ул йортларда кичен ут алынса,
Калка Мәскәү кинәт, калка Уфа.

Йөрдем июнь эссесендә шул чак
Заманга тиң сүзгә-җырга сусап.
Чаллы кызы, яшь кенә бер кыздан:
— Сеңлем, дидем, каян мондый тузан?
— Тузаннан мин үзем җик күрәм,
Йөрәгенә җирнең җиттеләр...
Аерды да бөтен чүп-чарын,
Болгатты да Болгар туфрагын.

КамАЗ данлы дала туфрагын,
Бодай үскән кара туфрагын
Өйде бергә... Чаллы чал булды,
Тарихының өстен салдырды.
Алмыйм дигән кебек артыгын,
Шушы дигән кебек алтының,
Тау ясады... Басты алыплар...
Җырым, мине шунда алып бар.
Тау ясады... Чаллы туфрагы,
Гасырларның җанлы туфрагы;
Чаллы, чалгы, печән өсте чагы,
Арышларның, камышларның шавы,
Эзе-юлы анда һәр дәвернең,
Керәшен моңы анда Гәрдәленең,
Ниндидер бер моңсу урталык,
Шул язмышта озак буталып,
Гомер иткән Яңа Гәрдәле,
Туры тота бүген гәүдәне.
Күп болганган Болгар туфрагы,
Күп моңнардан торган туфрагы,
Кара туфрак коры дары күк,
Миллион күзләр миңа карый күк,
Күпме сугыш, күпме дау булган,
Ята сулап тынган давыллар...
Ята сулап шул җир... Тукланырга
Икмәк биргән, халкы, туфрагына
һәйкәл кебек тора элеватор:
Синме «Батыр» монда, минме батыр?
Югалды дип юкка уынма,
Ул туфракны шул ук урынга
Сипте КамАЗ, шул ук урынга —
Киләчәккә, яңа буынга.
Бу җирләрнең төтен, тузаны
Хәтерләтте миңа Дуганы...

Бар нигезләр кубарылган чакта,
Каләм әле кулларымда чакта,
Горурланып эчтән, көнләп эчтән,
Җәлил буйлап, көньяк-көнбатыштан
Төштем таңда, Кама суыра кебек,
Барам мин дә гүя шунда кереп.
Кама бөек, көчле ихтыяры,
Уйларымның яры — ике яры.
Ике яры — ике кысасы,
Хисләремне шунда кысасы.
Юк бер кайда тыныч урын җирдә,
Тыныч түгел бүген мин дә, син дә,
Әллә җомга аңа, әллә шимбә,
Язмышыннан хафаланып Шилнә
Корыч заводлары арасында
Тарихына таба ага ул да.
Качып-посып кына юлга чыккан,
Алдында тау-киртә ком-балчыктан,
Тузгып җирдә бөтен ком очканда,
Башын төрткән бетон корпусларга,
Котылырга теләп йөз бәладән,
Озын тимер кебек өзгәләнгән.

Бульдозерлар атлый аның аша,
Бала-чага аста чупылдаша.
Ике туган — ике бәләкәчкә:
Шилнә белән безнең Мәләкәскә,
Кочаклашып юлда, юк, үлмәскә,
Үз уйларым белән мин бәхәстә

Төштем таңда, уйда алачыклар,
Уйда яшьлек, уйда алан, чыклар,
Тугайларда һаман минем чапкыр,
Ялларына мин тотынып чаптым,
Болын буйлап, Ык тамагы буйлап,
Сызылып аткан Ык таңнары буйлап,
Белми йокы, белми көн-төннәрен,
Кудым монда мин ат көтүләрен,
Тыңлап кырда җилнең улауларын,
Тыңлап тавышын арба-олауларның,
Буйларыннан Кама, Иделнең
Елларны мин монда өердем.
Чапкан печән исе, дегет исе,
Искә төште кинәт бөтенесе...
Өерләре белән ат-гасырлар
Агылдылар КамАЗ капкасыннан.

Искә төште бар да, чагыштырам,
Үткәннәрем карый сагыш белән,
Идел. Ачлык... Суда чабаклар...
Чабаклар күк кипкән яңаклар.
Тиф тә ачлык. Арган ил йөзенә —
Моннан торып Арал диңгезенә
Ленин салган аваз бу ярларда —
Кама яры — калын диварларда
Калган яңгырап: Арал, балыкчылар!
Коткарыгыз, сезгә барлык чорлар
Укыр рәхмәт, диңгез илне бага,
Коткарыгыз, сигез миллион бала
Һәлак була... Санаусыз күп эшләр...
Һәлак була сабан сөрер кешеләр,
Белүчеләр серен, җирнең уен,
Җиде миллион алар, җиде миллион...
Идел сезгә игенләтә түләр,
Киләчәктә икеләтә түләр...
Дымы белән диңгез-аралларның
Ачлык, тифтән исән калганнарның
Балалары, арчып кар базларын,
Сала җирнең бүген КамАЗларын.
Карый алар КамАЗ түбәсеннән,
Шул биеклек хәтта түбән сыман.
Бурычларым түләп мин Аралга,
КамАЗ буйлап атлыйм бүген алга,
Атлыйм алга, читкә чөяр төсле
Мине яшьлек, таза, чибәр, көчле.
Без башкарган эшне башкаруын
Беләм, ләкин бүтән, башка буын.

Минем буын төсе? Төсләр, төсләр...
Днепрогэслар, сугыш һәм Ржевлар...

Тугры булып биргән антларыма,
Җитмеш өченең февраль-мартларында,
Җыена торгач, бу көн бер җитте дип,
Без сугышкан син шул Ржевмы дип,
Базарда ат күреп гашыйк булган.
Карап төсен, озак басып торган
Сәер кеше сыман, тирән сердә
Утырган тын йортлар тирәсендә
Мин әйләндем, төсләр җиргә сеңә,
Саклый бу җир солдат төймәсен дә,
Яңа буын ләкин ача барды,
Ачкан кебек иске акчаларны.
Ржев. Идел. Карлар ярма-ярма,
Бөтен якты Идел ярларында,
Анда тормыш, үткән, бүгенгесе,
Ул кайда юк минем буын төсе,
Җил ашаган, кырыс карашлылар,
Яланнарда калын кар астыннан,
Карый һәйкәл, фоторәсемнәрдән,
Кая гына алар чәчелмәгән!
Мин КамАЗда гүя төштем эзләп,
Шул буынның ерак төсен эзләп.
Батырлыкның заман барсын хуплар,
Корчагиннар купты, Матросовлар,
Купты дотлар... Юл-туплары белән,
Фронтлары-Волховлары белән,
Кар-давыллы сугыш чоры белән,
Моабитның кара шомы белән
Купты Җәлил, бергә кушылдылар,
Барсы-барсы менә шушы еллар
Булды миңа кабат кайткан сыман,
Агылдылар КамАЗ капкасыннан.

Масштабы чорның, бөтен эше,
Бөтен рухы чорның, омтылышы
Алар рухы белән кушылганда,
Ашкындырган чакта эшем алга,
Очраштырды заман, Гәрдәле
Тәрәзәдән алып пәрдәне,
Әйләнгәндә үзе фундаментка,
Җыенганда үзе шунда утта
Кайнатырга безнең көн өчен
Иң шәп корыч — КамАЗ корычын,
Таң яктысы уйнап ярларда,
Чагылганда «Пресс-рам»нарда,
Чор яктысын җыйган рамнарга
Сихерләнеп карап барганда,
Очраштырды... Тын таңнарда күрәм,
Ак шәһәрдә томаннарда күрәм,
Йортлар торгыз, ташка ташны сыла!
Әйлән, әверел КамАЗ ташчысына.
Хыял, хыял, нинди ләззәтле син,
Азатлыкны җырла, хезмәтне син.
Без көн саен искә алганнарның
Һәм сугышта исән калганнарның
Балалары, үтәп наказларны,
Сала бүген гигант КамАЗларны.

КамАЗ — җавап. КамАЗ киң адымнар,
Кайда яшьлек — анда «Гренада»лар,
Кайда яшьлек — анда романтика,
Бу урынны безнең заман тиккә
Сайламаган, Кама — җирәбә,
Биек урын, йөзгә җил бәрә...
Улы-кызы якут, калмык, финнең,
Бу КамАЗда бөтен ягы җирнең
Очраша күк, җиңел атларга,
Татарча сүз катып хантларга,
Төштем бергә, минем алдан барган
Гагаузлар белән молдаваннар
Күптән таныш, артта калды эзләр;
Молдавия, дала, гагаузлар...
Төштем Кама ярларына табан,
Сәлам сиңа, авар, табасаран,
Рәсүлләргә, Кайсыннарга сәлам,
Гасырларга калсын, әйдә, сәлам!
Төрле телләр-төркемнәргә сәлам,
Яңа буын Тёркиннарга сәлам.
Төштем көйләп шулар уртасында
Үз телемдә, телем утта-суда
Чыныккан тел, бай ул, телем — Чулман,
Яшим җирдә Чулман аккан чордан!

Йөрдем көзен, январенда йөрдем,
Йөрдем, Кама ярларында йөрдем.
Юк салкын җир Чаллы яланы күк,
Җиле тимер чана табаны күк,
Җиле битне ялап ала төсле,
Кары түгел, ялан ага төсле,
Дала җиле (усал, ачы, кисте)
Кисте битне, «РИЗ» дип, «РИЗ» дип исте.
«РИЗ» шыксыз дип миңа кем тукыды?
Бар үз күге аның, үз офыгы,
Тышта январь, буран бәрә йөзгә,
Бер офыктан бер офыкка «РИЗ»да
Очты кошлар... КамАЗ субайларын
Сукты яшьлек, чорны соң аңладым,
Үскән саен КамАЗ, кеше монда
Ни өчендер күбрәк Есенинга
(Җылысы күп, беләм, җылысы күп),
Шул кошларга ныграк елышты күк.

Кем син, ташчы яки янар күзле
Ак шәһәрләр кызы — маляр кызмы,
Героемы безнең китапларның?
Түбәләрен ябып гигантларның,
Төшеп җиргә, кайнар тимер мичкә
Ике кулың куеп, бирелеп хискә,
Сөйләүчеме безгә зәвыкларың,
Кабызучымы мәктәп, зал утларын,
Элек тып-тын яткан чагын уйлап,
Шул бәрәңге бакчалары буйлап,
Бер почмакка кысып дала аен,
Башлап монда КамАЗ трамваен

Йөртүчеме, тәмам төзелеп КамАЗ,
Бәхәс, шау-шу бераз тынып калгач,
Чыгып кырга, куеп җилгә яңак,
Онытылган күк Дугадан соң солдат,
Син торырсың басып, уйда еллар,
Кызларың бар инде, улларың бар,
Син торырсың басып, синең сүзләр:
Бу ак шәһәр, парк, сүзләр — «РИЗ»лар.

Йөрдем янып... Үттең, вакыт, үттең,
Юлда, мәктәбендә «Вахитов»ның
Юандым мин, кайда тукталмадың,
Киләчәкнең чая Тукайларын
Кердем эзләп, алда язлар назлар
Тукайны да бирсә бу КамАЗлар.

Йөрдем янып... Алда кызыл ярлар
Зәңгәр дөнья эченә сузылганнар,
Сузылганнар ерак тау-үрләрем,
Тау-үрләрем — минем тамырларым,
Мендем атлап тарих баскычыннан,
КамАЗ баскычыннан, баш очымнан
Тора үтеп җитез керәшәләр,
Керәшәләр шатлык өләшәләр,
Чаллы исеме гүя ярдан чыкты,
Дөньяга ул чыңлап-яңрап чыкты,
Хәтерләтте очкан керәшәне,
Шушы ярда аның киләчәге.
Урманнары буйлап Илбактының —
Киләчәге буйлап ил бәхетенең
Гизде уем... Карап сокланырга
Мендем таңда Кама сыртларына,
Рәхмәт сезгә, көн дә мине көткән,
Яшәртүче яңа биеклекләр!

1974

## Хәсән Туфан

# БАГЫШЛАУЛАР ДӘФТӘРЕННӘН

### Абыйлар бар иде

Давыллы юллардан, түбәннән
Тауларга юнәлгән елларда,
Даһилар шикелле гадиләр,
Абыйлар бар иде дөньяда.

Тыныч та, гамьсез дә идек без:
Юлны бит абыйлар күзәтә.
Без — яшьләр читкәрәк юнәлсәк,
Өлкәннәр кыйбланы күрсәтә...

Йолдызлар шикелле уяулар,
Утлары урамга сирпелә.
Киңәшләр кирәксә, төнлә дә
Классик ишеккә — чирт кенә...

Инде без — үзебез Аксакал,
Инде без — үзебез олылар:
Һай, авыр миссия икән ул
Олылар диярлек булулар...

...Әле дә, әле дә, Абыйлар,
Юлларда бураннар, төннәр бар,
Сезнең дәү кулларга баш куеп,
Киңәшләр сорыйсы көннәр бар!..

Кайда сез, Галимҗан,
Әмирхан абыйлар...

1972

### Тарас Шевченко

Аю кебек итеп бәйләп куеп
Монархия арбаларына,
Юксылларның яңа пәйгамбәрен
Илтә конвой дала ягына.

Шушы күренеш белән император
Халыкларны алдан өркетә:

Кем, янәсе, безгә тел тидерсә,
Аны да нәкъ шундый көн көтә!..

Чувашчадан маричага күчеп,
Маричадан татар теленә,
Калмыкларга, казакъларга табан
Идел буйлап хәбәр йөгерә.

Чуваш, татар, руслар һәм марилар
Күзләренә аның карыйлар,
Карыйлар да, ымлап хәбәрләшеп,
Туганнары итеп таныйлар.

Һәрбер күздә
Серле сорау яна:
Нишләргә соң безгә, нишләргә?
Кул-аякны ничек чишәргә дә
Төрмәләрен ничек ишәргә?..

Юк, алла да, беркем белми әле
Киләчәктәниләр буласын,
Бу сорауга җавап бирүченең
Сембер каласында туасын.

Үтеп бара Тарас
Аны күреп калган
Күп милләтле, олы, тын юлдан.
Бу яктагы илләр язмышы да
Украина белән бертуган...

...Аю йөрткән кебек бәйләп куеп
Монархия арбаларына,
Шевченконы алып бара конвой
Казакъ халкы далаларына.

1967

## Баязит Бикбайга

Туфан абый!
...Тагын өстәлде бер киртләч
Гомернең тирәгенә...

Баязит Бикбай

Килде дә керде күңелгә
Фәлсәфә шигъри моңың,
Еракта калган гомернең
Сәламе кебек булып.

Юк, сөрән түгел, Баязит,
Синең бу шигъри нида,
Яшәүгә оран булып ул
Тоела, кустым [1], миңа.

Яралы, ләкин шулай да
Накаллы безнең күңел.
Бүтәне безгә гомернең —
Сүрәне кирәк түгел.

1968

[1] Кустым (башкортча) — энем.

## Педер Хузангайга

Гомер юлын, Хузангай,
Иртә тәмам итмә син:
Бу дөньядан, туганкай,
Миннән алда китмә син! —

Бик күңелсез булыр бит
Синсез калган елларым:
— Кайда минем Педер? — дип,
Җылар минем җырларым...

Һәр вакытта — аек син,
Һәр вакытта — нормада,
Һәр вакытта лаек син
Иң нормальный формага.

Димәк, барлык юлларда
Була сиңа таянып:
Син — зилзилә купса да,
Аумый торган таяныч!

Хөрмәт белән баш иям,
Сәламнәр бирә-бирә,
Сине тапкан, үстергән
Бөек чуваш Иленә!

1966

## Гамзат ич—безнең рәсүл

Мостай Кәримнең 50 еллык
юбилеенда нәни бер шаяру

Кыямәт көндә әгәр дә
Якага ябышып ходай:
— Син, дисә, җирдә чагыңда,
Мостайда, теге табында
Хәрәмне каптың бугай?!

Әйтермен аңа:
— Бу чорда
Шәригать бүтәнчә шул:
Мөхәммәт түгел бит инде,
Гамзат бит безнең рәсүл!

Ә безнең рәсүл шәрабны
Хәрәмгә санамый бит,
Рәсүлең кушканны, ходай,
Үтәми ярамый бит!

Бәс, тотыйк, сират күпердән
Чыгарлык итеп кенә.
Арыслан дигән киекне
Тотарлык итеп кенә!

Тостлар бит — алар асылда
Хәерле дога гына:
Дудин да каршы түгелдер,
Мөгаен, моңа гына.

Замана шундый кичәгә
Даталар бирә торсын,
Бердәнбер кичә түгел бу,
Меңнән-бер кичә булсын!

1969

## Хәерле көн

Татар театрына

Гаҗәп түгел, Илем,
Тамашаны,
Театрны яратуларың:
Олимпиаданың бер төре бит
Демократик сабан туйларың!

Тумышыңнан килгән сыйфатың ул
Тамашаны сөю гадәтең.
Алкышларың аша канат кага
Театрга тирән рәхмәтең.

Бүген тагын агылып килерсең син,
Бәйрәм хисен китереп залларга,
Үткән көннәр эзен карый-карый
Киләчәгең төсен барларга.

Көтә сине — актер классиклар,
Көтә сине — яңа талантлар,
Академик сәнгать түшәмеңне
Күтәрешкән рухи атлантлар
Көтә сине.

Һәр сезонда
Канат каксын, әйдә,
Сәнгатеңә олы, дәү рәхмәт.
Хәерле юл сиңа, хәерле көн,
Аншлаглы, тулы мәхәббәт!

## Хисам Камалов

# ҺӘРКЕМНЕҢ ГОМЕРЕ БЕР ГЕНӘ

РОМАН

**12**



Фира алар яңа позициягә урнашкан көнне килеп төште. Алексей батареяда түгел иде. Фира аны көтеп тора алмады, санбатка урнашасы бар иде. Анда Фираны тыенкы гына каршыладылар. Баш врач Семен Израилович Долкарт — биек маңгайлы, чәчләре агарган кеше — шактый кырыс күренә иде. Фира, бик күп башлыклар каршында йөз суы түгеп гадәтләнгәнгә, аңа исе китмичә генә карады. Семен Израилович Фираның тәҗрибәсе турында сорашты. Фираның ФАШны тәмамлаганнан соң санчастьларда һәм госпитальләрдә эшләвеннән башка казанышлары юк иде.

— Сезгә кече лейтенант должносте бирә алмыйм, сез үзегез дә риза булмассыз,— диде Семен Израилович бик җитди төстә.

— Әйе, шулай...— диде Фира, ни әйтергә белмичә.

Баш врач хаклы иде. Әлбәттә, хәзердән үк хирург булырга ул үзе дә теләмәс иде.

— Өйрәнерсез, аннары...— Семен Израилович сүзен әйтеп бетермәде, хәер, нәрсә әйтәсе аңлашыла иде.— Ә хәзер урнашыгыз. Иртәгәдән эшкә тотынырсыз.

Шул вакыт палаткага ниндидер полковник килеп керде. Фирага тиз генә чыгып китәргә уңайлы булды. Шунда ук ул Алексей янына барырга уйлады, ләкин нигәдер элекке дәрте сүрелеп, кыюлыгы бетеп калган кебек булды. «Ә ул мине ничек каршылар?» Фира үзенең Алексейга язган хатларыннан оялып куйды. «Ирем янына барам», дип әйттем, һаман шулай җавап бирдем. Ә нигә моны Алексейга язарга иде?! Эх, мин юләр баш! Мин аңа үзем бәйләнәм кебек килеп чыккан бит! Мин аны үзем яулап алам кебек булган. Аһ, ничек мин алдан берни дә исәпләмәгәнмен?! Бөтенләй горурлыгымны җуйганмын икән. Болай мин Алексей алдында артык очсыз зат булып чыгам түгелме соң? Ул минем беренче баламны кабул итеп алучы, минем дөньяда беренче күргән газапларымны уртаклашучы. Әмма бу әле аңа дәрәҗәмне җуеп асылынырга хокук бирми...»

---

Ахыры. Башы 3, 4 саннарда.

Башта ул бала табунын авырлыгыннан бөтен ирләрне каһәрләде, аларга шундый нәфрәт туды аңарда, үзенең ире Рәшиткә булган бөтен яратулары кисеп төшерелгән кебек булды, аңа карата фәкать ачу гына калды. Башта бөтен үчле әрнүләрен Рәшиттән күрде, барча газаплары өчен аны гаепләде, ана киявгә чыгуына үкенеп бетә алмады. Аннары авыртулар үткәч, газаплар беткәч, әнисе янында улын әйбәт кенә үстерә башлагач, малаеның күзләрен күреп, чиксез сөенә башлады. Бу кечкенә, көчсез, әмма гаҗәп тере малай аның бөтен күңелен, вөҗүден биләде. Аның каткан күңелен йомшатты, газапларын оныттырды, җанына укмашкан катлы-катлы ачу бозларын эретте. Маратның күзендә иренең йөз чалымнарын күреп, аны искә төшерә, аны сагына, юксына, аның «гаепләрен» ярлыкый иде. Монда аның ни гаебе бар? Ул бит хезмәттәге кеше, үзе дә, мескенем, әллә нинди газаплар күреп бетергәндер инде! Исән микән соң ул? Малае шулай матур гына үсеп килгәндә, Рәшит гел исәндер кебек тоела иде. Малае акылын җуеп вафат булгач, Фира тагы бөтенесеннән өмет өзде. Аның бөтен нәрсәсе шул малай белән бергә үлде дигән фикергә килгән чаклары булды. Үзен бөтен нәрсәдән мәхрүм ителгән кебек тойды. Һаман бер кызык мәкаль исенә килә иде: ихтыярсыз ачу — тол, монсуланусыз күңел — тол, тугрылыксыз сөю — тол, ирсез хатын — тол. Менә шуларның барысы да аңарда бар хәзер. Кайчагында Фира чыгып булмаслык караңгылык эчендә кала, шунда өзгәләнә, ләкин күңел офыгында тагы өмет чаткылары үзенең көчсез генә нурларын чагылдыра, тагы өмет күбәләге терелеп, баш очында зәгыйфь канатлары белән җилпенеп, тагы Фирага тереклек бирә, тормыш ярына тартып чыгара. Аны яшәү ярына тартып чыгаручы бу өмет — Алексей иде. Нишләп соң әле бу кешегә шул чаклы бәйләнде? Һәрбер кеше икенче кешегә бәйләнуы белән я аны бәхетле итә, я аның бәхетсезлегенә сәбәпче була. Һәр кеше үзенең икенче кешегә булган мәхәббәте белән ул кешене пакьли, сафландыра, яки аны пычрата, тапландыра. Фира үзенең авыр язмышын Алексей җилкәсенә салырга ниятләмәсә дә, шулай килеп чыгуы бар. Менә ул ничә айлар буе аңа таба ашкынды, юл әрчеп, аңа таба күпме газаплар аша үтеп килде, горурлыгын җиңеп һаман аның янына ыргылды. Хәзер менә ишек төбенә килеп җиткәч, Фираны шик-шөбһә тетрәтә башлады. Нилектән булыр бу? Алексей янына баруны ният итеп куйды да, алдына-артына карамады, һаман тынгысыз тамчы кебек бер «ташны» чокыды, һәм теләгенә ирешергә бер адым калгач... җанына ничектер чиксез күп шик тулды. Әллә ияле кешене, әрсезләнеп, иясе кулыннан тартып алган сыманрак төсмере куркытамы? Алексейның «ияләре» ничек икән соң? Фираның вөҗданы мәхәббәттә һәм бүтән шундый шәхси мөнәсәбәтләрдә кеше өлешенә керүдән тайчына иде.

Ничектер гомернең омтылышлы кисәгендә кеше бер йолдызга бөтен җаны-тәне белән атлыга, ләкин йолдызны күргәч, аңа орынгач, ул аңардан канәгать булмый, бизенә. Фира да бу минутта шундыйрак хисләр кичерә иде. Ул Алексейны күбрәк хыялы белән яратты, чөнки өч ел буе аны һаман хыялында тотты. Хыял белән сөю шул бөтен сөюләрдән көчле һәм эчкерсез, ахры, шуңа күрә ул еш кына бизүләргә, чәлпәрәмә килүләргә дучар була... Килүен килде, әмма хәзер нишләргә? Чигенергә соң инде, юк, күзне йомарга да әрсезлек чоңгылына ташланырга...

Фира үзенә күрсәтелгән палаткада бераз ял итмәкче булып поход караватына урын хәстәрләде. Аны биредәге кызлар бик шат каршыладылар. Семен Израиловичның бик кырыс кеше булуын, ләкин гаделлеген сөйләделәр.

— Безне монашкалар итеп тотмакчы була! — дип шаяртып әйтеп куйды бер сестра кыз.

— Безнең янга егетләр килгәнне җаны күтәрә алмый. Бу Семен Израиловичның просто авыруы, тагы ни әйтим? — дип, икенче кыз тегесенең сүзен куәтләде.

— Сиңа, Таня, ярамый да, син — донор, ә миңа ярый.

— Дуслашырга да ярамыймы?

— Донорлык вазифасына кергәндә биргән распискаң нәрсә? Анда әйтелгән: егетләр белән мөнәсәбәткә кермәскә, авыру ияртмәскә.— әгәр шул шартларны үтәмәсәң...— Кыз хәйләкәр елмаеп Фирага карады.

— Дуслашмаска дип мин расписка бирмәдем,— диде Таня, саргылт бал төсле матур чәчләрен рәтләп.

— Бар нәрсә дә дуслыктан башлана, җаным! Әй, Таня, фәрештә булып кыланма инде!

— Мин фәрештә, фәрештә, менә кара, канатлар да чыга башлады бугай үземә! — дип, Таня көмеш тавышы белән көлеп куйды, кулларын канат итеп җилпеп-җилпеп алды.

— Таня, син бик нык үзгәрдең, сизәсеңме, син йөз сиксән градуска үзгәрдең, чын,— диде берсе житди тавыш белән.— Шул кара мыеклы капитан сине җилкетә, чын!

— Ул минем кулымнан тотарга да кыймый, беләсең килсә...

Таня үзе сөйләнә, үзе һаман кечкенә көзгесе каршында чәчен рәтләп маташа. Әле туздыра, әле бер җиргә өя, әле тарагы белән икенче якка тарый, әле кедрәләр ясау өчен төйнәп куя...

Шул вакыт Фираны чакырып алдылар. Ул әле урнашу өчен тагы берничә кешегә күренергә тиеш иде. Бу юлы аны бүлек мөдире дәшкән иде. Ягымлы гына хатын икән. Киң маңгайлы, коңгырт чәчле, купшылыкны өнәмәве, пөхтәлекне яратуы бөтен килеш-килбәтеннән сизелеп тора иде. Ул сөйләшүне, аңлашуны бик төгәл һәм кыска тотты. Аның яныннан чыкканда, караса, ком сипкән тар сукмакта Алексей көтеп тора.

Фира шунда ук аны танып алды, кинәт тез буыннарының хәлсезләнүен тойды. Йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Очрашу болай кинәт булыр дип исәпләмәгән иде. Фира нишләргә белмәде, Алексей аңа арты белән тора иде, ул әле Фираны күрми, шуңа Фира, әллә урман эченә кереп качыйммы, дип уйлап алды. Ул, Алексей минем турыда начар уйлар инде, дип курка иде. Килеп җиткәннән бирле аның мин-минлеге җәберләнә, газаплана иде. Алексейга булган тойгылары да бер сүнә, бер кабына. Соңгы минутта ул аны ярата алмас шикелле тоелып китте. Алексей белән бергә кичергән газаплар артык күп һәм авыр иде, әрнүле иде. Менә шул тетрәүле кичерешләр йөрәктән һәм акылдан һаман җуелмый, тойгыларга киртә булып тора шикелле. Алексейны күрү белән йөрәк шул газапларны кинәт тагы терелткән кебек итте, һәм Фира үзенең хыялында булган яратуларының челпәрәмә килеп коелып төшүен аңлагандай булды. Ник килдем? Мин аны яратып килдем бит! Ул булмаса, мин бәлки инде дөньяда да булмаган булыр идем. Ул минем гомеремне саклап калды. Минем өчен мең тәрле кыенлык күрде бит! Гаҗәп, үзеңнең гомереңне саклап калган кешене яратып булмас шикелле тоела! Аның белән тәмуг эчендә күргән газаплар артык зур, башка да, күңелгә дә сыймаслык. Алар бер-берсен артык нык белделәр. Бер-берсенә алар хәзер кызык булмаслар, ни генә эшләсәң дә, бергә кичергән газапларга килеп бәрелерсең. Бергә күргән бәхетсезлекләр, бәлаләр кешеләрне бер-берсенә беркетә, дуслаштыра, дип әйтәләр. Юк, кайбер кешеләрне дуслаштырмый, бер-берсенә беркетми, ә аеруы да мөмкин микәнни?.. Фира, аска караган килеш, Алексейга таба атлады, үзе шундый уйлар кичерә, аяклары аңа таба атласа да, уйлары кирегә качмакчы була иде. Ләкин кинәт Алексей борылып карады һәм:

— Фира! — дип кычкырып җибәрде.

Шушы тавыш үзенең көче һәм сагышлы-әрнүле булуы белән бөтен шикләрне, икеләнүләрне күңелдән сыпырып ташлагандай итте. Фираның аяклары тышаулагандай булды, бер урында таптана кебек тоелды. Алексейга таба ыргыла, ниндидер көч, дөресрәге, ниндидер көчсезлек аны тота, җибәрми шикелле иде. Көчкә-көчкә генә Алексей янына килеп житте, егылып житәр чиктә аның күкрәгенә капланды. Икесе дә кинәт сүзсез калдылар. Алексей хискә бирелүчән кеше булмаса да, йөзен читкә борды. Күзен яшь пәрдәсе каплаганын сизде. Ә Фираның күзләре коры иде, ул гаҗәпсенеп һәм ышанмыйча карап тора, Алексейның күзләреннән, йөзеннән нәрсәдер эзли, ниндидер серне ачарга теләп азаплана иде. Беренче сүзләрен әйтү авыр булды, чөнки, билгеле булганча, мөлдерәмә тулган шешәне кинәт әйләндереп авызы белән түбән тотсаң, суы акмый, болар белән дә шундый ук хәл килеп чыкты. Аннары кинәт икесе берьюлы сөйләшә башладылар. Арага өелгән кичерешләрдән һәм алып ташлап булмый торган нәрсәләрдән Фира һаман курка иде. Ул фронтка килде, канлы сугышта кешеләргә әз булса да үзенең көче белән булышырга ашыкты, ә менә Алексейның кулын тоткач, аңарда хатын-кызлык эгоизмы нык кына үзен сиздереп куйды. Алексейның бик тә үз итеп каршы алуы бәлки шундый хисне уяткандыр?

— Әһ, Фира, инде сине бүтән күрә алмам дигән идем! — дип, Алексей аңа сөеп карады.

Алар сары ком җәйгән юлдан әкрен генә атладылар.

— Мине юләр түгел диген, кая хәтле килдем бит!

Фира Алексейны күзәтте. Әйе, ул үзгәргән, урта яшьтәге ирләр төсе кергән аңа, ә өч ел моннан элек ул егетләр кебек иде, маңгаенда, битендә җыерчыкның эзе дә юк иде.

— Килүең минем өчен бик шәп, синең өчен ничек булыр, фронт бит, ут эчендә йөрисең.— Алексей Фираны күзәтә, ул да үзгәргән: тагы да чибәрләнгән, тулыланган, ягымлыланган. Беренче баладан соң хатыннар тагы да матур булып киткәнен Алексей белми иде әле.

— Мин анысын уйлап тормадым да,— диде Фира. Үзе, Алексей минем килүне бик үк өнәп бетермәгән икән, дип уйлап куйды. Ә Алексей аның өчен борчыла иде. Буш сүзләр сөйләп, кешене сүз белән иркәли һәм юата торган гадәте булмаганга, нәрсә уйлаганны туры гына әйтә иде ул.

— Маратны бик җәлләдем, орчык малайны...— диде Алексей, әрнүле тавыш белән чын күңелдән үкенеп.

— Син дә аңа сөт эзләп күпме чаптың, ә? — дип, гаепле елмайды Фира.

Ул баланың ашарга тилмереп елаулары Алексейның әле дә колагыннан китми. Нәни генә җан, ә үзендә күпме тавыш, ашарга сорап һаман аларның бәгырьләренә тиеп торды. Бәбәйләгәннән соң хатынкыз күкрәгендә сөт бетүне ишеткәне булса да, Алексейның күргәне юк иде. Коточкыч снарядлар шартлавы һәм немецның тоташ әзәрлекләве астында көненә ничәмә чакрымнар үттеләр, шундый шартларда сөтең түгел, җилегең кибәр.

Алар Алексейның батареясына кич кенә кайттылар. Алексей старшинаны очратып, кичке аш турында нәрсәдер әйтте, Фираны блиндажга алып керде. Аппаратта Әнвәр утыра иде. Ул аңар старшина янына барырга кушты. Әнвәр тиз генә барысын да алып кайтты, старшина шәм биреп җибәрергә дә онытмаган иде. Комбат Әнвәргә аппараты белән Мурзыев янына күчеп торырга кушты. Егет бик теләп чыгып китте.

Фира белән Алексей төне буе сөйләшеп утырдылар. Алексей Фираны үзендә бик яхшы кунак итәргә уйлады. Табынга барысын да тезде, кыйбатлы әчемлек салып бирде. Ләкин Фира, үзенең дә гаҗәпсенүенә

каршы, эчә алмады. Алексей аңа папирос та тәкъдим итеп карады. Фира анысын да кире какты. Яраткан кешесе белән очрашу аңа хатын-кызлык табигатен бар нечкәлеге белән кире кайтарган иде бугай.

— Ә үзең тартам, эчәм дип язган идең? — диде Алексей, аңа сынный карап.

— Әй, минем сүзгә ышансаң! Кеше үз өстенә ни генә әйтмәс! — дип, Фира көлеп, Алексейга йотылып карады.

— Шулай да килүең көтмәгәндә булды, алдан хәбәр дә итмәдең.

— Кинәт кенә фронтка алдылар. Мәскәүдә Унынчы армиягә билгеләгәч, каршы килмәдем. Ә бирегә сезнең дивизионны сорадым. Әллә син...

— Юк, юк, Фира, ничек алай уйлый аласың? Мин сине үзем дә чакырып китерердәй булдым. Никтер курәсем килде.

— Әйдә юат инде, юат,— диде Фира кыюланып.

— Үкенми торгансың бит?

— Үкенәм дә, үкенмим дә, әллә ничек буталдым.

— Әһә, алайса, барысы да миннән тора,— дип, Алексей көлеп, аның кулын тотты, ике учына кысып торды. Фира исә Алексейның элеккегедән бик нык үзгә булуын сизде.

Иртән ул Фираны госпитальгә озата барды. Ләкин баш врач Семен Израилович, Алексейны үзен генә чакырып алып, бик нык ачуланды.

— Дошманны кыйныйсы урында, санчастьны кымтырыклыйсыз, егет! Минем уемча, сез аның ире түгел!

— Юк, мин аның ире, законный...

— Суга сәнәк белән язган законмы?!

Врач бик ачулы иде, тик Алексей кәефен төшермәде. «Берәр җае чыгар әле»,— дип уйлады ул. Аңарга каршы әйтүдән фәтва күрмәде, мондый чакта дәшмәүдән дә яхшысы юк. Ул бик күтәренке рухта, Фира белән бергә булу шатлыгын мондый тиргәүләр генә җуя алмаслык иде. Алексей гаепле һәм шатлыклы хәлдә батареяга кайтты һәм шуннан ук күзәтү пунктына китте.

Икенче төнне Алексей тагы алгы сызыктан кайтты, Фира янына санбатка барды. Аларның күрешкән саен сөйләшеп сүзләре бетми иде. Ничектер шулай килеп чыкты: берникадәр вакыттан соң алар бергә тора башладылар. Үз ихтыярларыннан көчлерәк булган тойгылар аларны бер-берсенең кочагына ташлады. Семен Израиловичның «суга сәнәк белән язган законмы» дигән ишарәсе чынга әйләнде.

Полк штабыннан инспектор киләсе икән, шуңа бүген комбатны алгы сызыктан чакыртып алдылар.

— Минем анда кызыклы күзәтүләр барые, инспектор белән син генә йөрерсең инде,— дип, Алексей Ваһаповка карады.

Ваһаповның йөзе ничектер моңсу иде, әллә ничек ягымлы гына моңсу. Алексей аның: чын күңелдән әйтми бит бу, дип уйлавын шәйләгәндәй булды. Чинлылар белән аралашырга ярату Ваһаповның йомшак ягы иде.

— Беләсең, өйрәтүләрең бер дә яратмыйм,— дип көлеп куйды комбат.— Мин передовойда шулардан качып ятам.

— Кара сакалың кая барсаң да калмый инде,— дип, Ваһапов та көлеп җибәрде.

— Берәр борычлы сүз ычкындырмагаем дип куркам,— диде Алексей, самими беркатлылык белән. Ваһапов белә: кайчак Алексей тупатуры дә начальникка берәр ярамый торган сүз әйтеп ташлый һәм шуның өчен соңыннан замполит белән икесенә дә күңелсезлекләр килеп чыккалый иде.





РЕСПУБЛИКАНСКАЯ

— Ә син тәнне тыярга өйрән,— диде Ваһапов, тагы елмаеп. Аның йөзендәге вак-төяк җыерчыклар каядыр югалды, ул яшәргән кебек булып китте.

— Тыеп булмый бит, нәләт! Кешенең тәне — үзенең дошманы дигәннәр, дөрес шул,— диде Алексей да елмаеп.

— Пустяк,— дип, Ваһапов шунда ук җитдиләнеп китте, бу сөйләшү ничектер аның күңеленә ятмый иде бугай.

— Мин тәнемне тыя ала торган кеше булсам, күптән полковник була идем инде,— диде Алексей көр күңелләнеп. Ул үзенең карьерасындагы уңышсызлыкларны тәненнән күрә һәм шуңарга күңеле булып, шатланып, кәефе күтәрелгән шикелле сөйләшә иде.

— Юкны сөйләмә инде,— Ваһапов һаман җитди, ул комбатның шулай үзенең ахмаклыкларына шатланган сыман каравына ничектер күнегә алмый.

— Фактлар китеримме, берничәсе синең күз алдында булды,— диде комбат.

— Кирәкмәс! Нәрсәгә?

— Ә, менә шул шул,— дип, комбат уйланып калды. Аннары сүзне икенчегә бору өчен әйтте: — Әй, бу кеше дигәнең мәзәк тә нәрсә инде. Үзенә-үзе менә шундый сугышлар, үтерешләр уйлап чыгара.

— Исәпләсәң, баш китәрлек шул.

— Нәрсә котырта кешене шундый эшләргә? — диде комбат уйчанланып. Аның әлеге шаянлыкларының эзе чыраеннан бөтенләй югалды. Ул фәлсәфәне үзе дә яратмый иде. Фәлсәфәгә эш эшләргә теләмәүче кешеләрнең үзләренең эшлисе килмәүләрен аклар өчен тел озайтулары дип кенә карый, яисә куркып позициясен ташлап качкан кешенең фрицны һәм аерым хәлләрне сәбәп итеп, акланырга тырышуы шикелле мәгънәсез әйбер дип саный иде. Әмма Ваһапов фикерләренә һәр вакыт колак сала ул. Чөнки замполит күп укый, аның сүзендә тирән мәгънә була.

— Легендамы, чын хәлдерме, борынгы заманда да шулай тыныч кына яшәүче кабиләләргә бәла-каза китереп торучы бер халык булган, менә шушы фрицлар шикелле ерткыч халык, илбасар, ди. Кешеләрне бер дә тиккә шулай үтергәннәр, балаларын суйганнар, кыскасы, бөтен ерткычлыкны кылганнар, нәкъ фрицлар шикелле...— Ваһапов сүзен өзеп торды, чөнки җир кинәт дерт итте, немецлар еракка ата торган орудиедән атарга тотындылар.— Менә шул,— дип сөйләп китте Ваһапов,— бик ерткыч халык булган, ләкин шунысы кызык, тыныч яшәргә омтылучы халыклар аларны кырып бетергәннәр. Бу бәлки берничә йөз ел дәвам иткәндер, ләкин ул халыкның бер генә вәкиле дә дөнья йөзендә юк, ди, хәзер.

— Ә фрицлар? — дип, комбат аның сүзен бүлдерде.

— Фрицлар — бүтән. Тегеләрнең бер кешесе дә калмаган, ди. Шуннан соң гына халыклар бераз тынычланып яшәгәннәр, имеш.

— Алар фрицларның борынгы бабаларыдыр әле.

— Юк, һич юк,— дип каршы төште аңа Ваһапов.— Соң бит немецлар 14 нче елгы сугышта да болай әшәке булмаганнар. Аларны фашизм ерткыч иттергән.

— Фашистлар фрицның йомшак җирен беләләр, шуна басым ясыйлар, аннары куркыталар, кеше бит ул куркак. Куркудан ул барысын да эшләргә мәҗбүр. Алар кешенең ерткычлык инстинктларын тәрәкъкый иттерәләр. Дөнья каршында аларның хыянәте шунда! — Ваһапов тынып калды, аның йөзе бик кайгылы иде, ул үзенең фикерләренең хаклыгыннан борчыла иде булса кирәк.

— Власть зур көч шул,— диде комбат, Ваһаповның фикерләрен дәвам иттергән шикелле.— Власть куша, аны уйсыз, сүзсез солдат үти. Әгәр үтәмәсә, аның үзен... Менә бөтен хикмәт шунда.

— Ерткычлык кешедә менә шулай барлыкка килә.

— Да,— дип сузып торды комбат бу җайсыз, читен мәсьәләнең мәгънәсенә төшенә башлаган кебек.— Ләкин фрицның үз шәхесенең дә әһәмияте бар. Кеше бит курчак түгел, үзен шулай ерткычка әйләндерергә ирек бирмәскә тиеш.

— Нишли алсын ул! Әллә ана фикер йөртергә бирәләр дисеңме? Әнә Тельманны нәрсәләр генә эшләтеп бетермәделәр? Ахырда ябып куйдылар...

Алар чыкканда, каршыга майор чинындагы полк инспекторы килә иде. Ул туктап фуражкасын салды, тирен җиңләтеп торды, командирлар белән исәнләшкәндә аны тагы киеп куйды. Ул хәлне дә сорашып тормады, шунда ук позицияләрне карарга теләвен белдерде. Комбат белән замполит аны озата бардылар. Комбат, ана орудие расчетында бары икешәр яки өчәр сугышчы гына калганын аңлатып, кешеләр сорады, пополнение кирәк диде. Инспектор моны бер дә ошатмады.

— Ул эш минем карамакта түгел. Мин кечкенә кеше, әнә полк командиры белән сөйләшегез! — дип кырт кисте.

Менә беренче орудие янына килделәр. Инспектор орудиене бик җентекләп карады. Окопларга, снаряд ящиклары чокырына, бруствергa күз төшергәч, аның йөзе тагын да чытыкланды. Ул эсселектән фуражкасын салды, ялт иткән, кырган башындагы тирләрен сөртте, маңгай тиресе гармун күреге шикелле әле җыерылып, әле язылып хәрәкәтләнеп торды.

— Комбат, орудие чистартылмаган, бусы — бер, бруствер дөрес түгел,— ике; янадан казыгыз, орудиегә маневрировать итеп атарга запас урын юк,— өч. Хәзер үк барысын да эшләргә! — дип, ул чытык йөзе белән бер кырыйда снарядлар чистартып горучы коручы белән ташучыга карады.

Аның күрсәтмәләре, әлбәттә, дөрес иде. Ул, шуны тойган кебек, тагы башка кимчелекләрне дә комбат белән замполитның борынына төртә-төртә күрсәтте. Ул хаклы, шуна күрә комбат ана каршы төшеп бер сүз дә әйтмәде, акланырга да тырышмады. Аның һәрбер күрсәтмәсенә:

— Дөрес, дөрес, төзәтербез! — дип, кыска-кыска гына җаваплар биреп барды.

Инспектор расчетны коручы сержант Нусовны һәм ташучы Үтәшне чакырып китерде.

— Орудие к бою! — дип команда бирде. Атыла торган квадратны, аннан прицельне әйтте.

Тегеләр шалт-шолт барысын да төгәл үтәп тордылар. Прицельне сулга, уңга күчертте. Болары да төгәл эшләнде. Инспекторның бик күңеле килде.

— Молодцы! — диде солдатларга карап. Аның йөзе бераз яктырып киткән кебек булды.

Ләкин икенче орудиегә килү белән ул тагы кырысланды, йөзендәге нур сүнде. Ул тагы бик нык бәйләнә башлады. Биредә дә пушканың маневр ясап атуы өчен урын әзерләнмәгән, аннары ышыкланыр урын да казылмаган, өч-дүрт кешегә бер кечкенә, тәбәнәк кенә, үрмәләп йөрешле генә блиндаж казыганнар да шуның белән канәгатьләнгәннәр.

— Комбат, нәрсә карыйсыз сез? Сез кайда?

— Мин передовойда, НПда.

— Ә замполит нәрсә карый? — дип, ул Ваһаповка таба борылды. Карта уйныйсыздыр әле! Сезгә Ватан ышанып тора, ә сез? — Аның ачудан төкерекләре чәчелеп китте. Инспектор тагы расчетны команда белән эшләтеп карады, ләкин монда расчет осечка бирде. Алар

буссольдән прицельне дөрес үк алып бетерә алмадылар. Инспекторның моңа бик кәефе кырылды.

— Замполит, комдивка әйтегез, мин сезгә шелтә белдерәм.

— Есть әйтергә! — диде Ваһапов һәм солдатлар алдында аңа бик оят булып китте. Орудие командиры акланырга маташып карады. Комбат исә өлкән сержант үзбәк Нурмановның бераз каушап калганын аңлап алды. Ул барысын да яхшы белә иде.

— Комбат, матчасть белән шөгыльләнергә! Комдивка әйтегез, мин сезгә шелтә белдерәм!

— Есть әйтергә!

Мондый чакта шулай итүдән башка чара юк, әйе, тәртип бераз йомшаган. Шактыйдан оборонада яту да, яңалар өстәлеп тору да, командирларның таләпчән булмавы да, солдатны җәлләве дә булгандыр. Алексейны менә шул нәрсә уйландыра иде: нигә мин солдатларга, яки үземә буйсынган кешеләргә каты була алмыйм? Аңа да сәләт кирәк, мөгаен, ә шул булмаса нишләргә соң?..

— Сезнең хуҗалык шушы гынамы? — диде инспектор, пушкаларны карап бетергәч.— Разведчиклар кайда?

Тагы фуражкасын киде, командирларга шелтә белдергәндә ул һәр вакыт төгәл формада булырга ярата иде. Күрсәтмәләрен әйтеп бетергәч, фуражкасын сала һәм тирләгән, аксыл кавын кебек башын сөртергә тотына.

— Әнә тегендә,— диде комбат, алгы сызык ягына күрсәтеп.— Разведка шунда күзәтү эшләре алып бара.

— Әйдә, киттек,— диде инспектор бик кырыс кына.

— Иптәш майор, замполитка биредә калырга рөхсәт итегез,— диде комбат, кулын козырегына куеп.

— Нигә шундый формальность! — Ул бик гади, самими кыяфәткә керде, аның йөзендә баягы кебек яктылык тагы пәйда булды.

— Иптәш майор, сезгә каска кияргә кирәк булачак. Ваһапов, бир касканны,— дип, Алексей иптәшләрчә елмайды. Ваһапов майорга үзенең каскасын салып бирде дә батареяга таба китеп барды.

— Анда бераз куркынычрак,— диде Алексей, кузгалып.

— Исәп куркыныч артына ышыкланырга идеме? — дип, инспектор аңа иярде.

— Юк.— Алексей бүтән сүз әйтмәде, үзе эчтән уйлап куйды: алгы сызыкка барудан бер дә шүрләп тормады, димәк, инспектор тыловик түгел, тиз аңлашып булачак.

— Беләм, беләм,— диде инспектор, янаган төслерәк итеп.

Көндезләрен алгы сызыкка бару шактый куркыныч иде, ләкин бик елгыр һәм хәйләкәр, эт каешына әйләнгән булсаң, сират күпереннән үтүе әллә ни кыен да түгел...

Алар, бүтән ләм-мим сөйләшмичә, урман ышыклыгыннан бераз бардылар. Урман бетте. Алда чокыррак җир, кинәт сукмак түбәнгә төшеп китә, менә шул төштән бик тиз йөгереп үтәргә кирәк. Бу немец тоташ ата торган «коридор» иде. Комбат шуны майорга аңлатты. Майор исә игътибарсыз гына тыңлады. Башта комбат нык кына иелеп, урталай сынып «коридор»ны тиз генә йөгереп узды. Теге якка яр астына төшеп ышыкланды. Аңа шунда ук аттылар, «тью-тью» итеп пулялар сызгырып узды. Кайсылары, шартлый торган пулялар, үләннәргә тиеп, аның сабакларын, яфракларын кыеп төшерде. Инспектор моны күреп торды, нәрсәгәдер бераз туктабрак, кыюлыгы җитмичәрәк калган кебек булды. Менә ул иелеп, хәтта куллары белән җирне тырмаштыра-тырмаштыра йөгереп, комбат янына килеп ауды. Аңа тагы да ныграк аттылар. Киеренкелектән аның иреннәре күгәреп чыккан

иде. Ул арада фриц рота миномeтыннан яудырырга тотынды. Күренеп тора: боларны шәйләп алдылар, шайтаннар. Бер мина якында ук яр өстендә шартлады, ярчыклары боларның каскаларына чарт-чорт килеп бәрелгәләде. Инспектор ничектер бер сүз дә эндәшмәде. Хәер, эндәшергә вакыт та юк. Авызыңны ачарга өлгермисең, өскә яудыра башлый, башыңны тизрәк җиргә яшерәсең. Менә ату бераз тынды. Майорның иреннәре сәер генә кысылды:

— Комбат, син мине үтерергә алып килдеңме? — диде ул, бик йомшак кына. Аның тавышында киная бар иде, ул елмайган шикелле булды.

— Хәзинәдә бары — шушы,— диде комбат ни әйтергә белмичә, майорның сүзләренә артык игътибар итмәстән.

Комбат өчен бу атулар бик гадәти, кычыткан чагуы кебек бер гади нәрсә, шуңа күрә ул курку дигәнне кичерми дә, тоймый да иде.

— Комбат, мине акылга утыртмакчы буласыңмы? Ә-ә, аңладым мин сине!

— Һич юк, иптәш майор, сез бит үзегез барырга теләдегез.

— Ник атмый торган җирдән алып бармадың? — диде майор җитди итеп, чырае бик борчулы иде.

— Бүтән юл юк бит,— диде комбат, үзен нигәдер гаепле сизеп. Ул майорның болай җитди тавышка күчүен аңлап бетермәде.— Бармыйк, алайса,— дип өстәде һәм майорның йөзенә туры карады.

Теге, нәрсәгәдер эчтән үз-үзе белән көрәшкән кеше кебек, һаман карарсыз кыяфәт белән йөзен комбаттан читкә бора иде.

— Шулай җайлырак,— диде ул, үрмәләп барганда лайга буялган кулларын сөт кебек ак кульяулыгы белән сөртә-сөртә.

Аларга «коридор» аша фәкать түш белән генә кире шуып чыгарга мөмкин иде. Комбат бик чос кына, чыпчык тотарга барган мәче кебек, «коридор»ны шуып узды. Ату булмады диярлек. Ниндидер узгынчы пулялар гына яр кырыен сыдырып уздылар, үләннәргә тиеп, шырпы сызган тавыш чыгардылар. Менә мыш-мыш килеп майор да үрмәләп бу якка чыкты. Аның чиста гимнастеркасы нык кына таушалган, орден планкалары каядыр эләгеп, йолкынып калган иде, ул күкрәк турын кулы белән капшап торды Майорның йөзе фикерләрен җыя алмыйча торган кешенеке кебек иде. Ул, хәле бетеп, ышыкка чыккач, тагы фуражкасын салды, димәк, тәнкыйтьләргә җыенмый икән әле. Тәнкыйтьләү алдыннан ул фуражкасын кия, иреннәрен кыса. Хәзер исә майор эченнән генә фикер йөртә, баш вата шикелле. Ул үзенең үлән сүленнән юешләнгән тезләренә карады, ничектер аның өс-башы комбатныкына караганда ныграк пычранган иде.

— Менә шулай, иптәш майор, фриц бик нахалланды, аны тизрәк куасы иде,— диде комбат, акланырга теләгән тавыш белән.

— Беләбез, беләбез.— Майорның тавышыннан аның бераз кимсенгәнлеге сизелеп калды.

— Әнә бит ул үзен һаман чүкеч итеп сизә, ә безне сандал итә, безнең башка чүкеч булып чүкеп кенә тора! — Комбат менә үзегез дә күрдегез, безне дә аңлагыз дигән мәгънә белән тегеңә карады.

Майор кашларын гына җыерып куйды. Майорның исәбе бик нык эшли башлады, ахры, ул тәмам тынып барды. Комбат аңа тупларның ату сыйфаты түбән булуы хакында да зарланды. Бу сүз майорны бик кызыксындырды, ул, туктап, фуражкасын салды һәм планшетын ачып, шунда нәрсәдер язып алды.

— Менә, ичмаса, шул хакта сөйләшик,— диде ул, ягымлы гына. Тавышында мин беләмлек чагылып киткәндәй булды, чынлап та аның шул мәсьәләләр буенча яхшы белгеч булуы ихтимал. Ни әйтсәң дә

инспектор буш кеше түгел, уйлана торган, борчылып яши торган кешегә охшый иде. Алар, батареяга кайтып житеп, Ваһапов блиндажына керделәр.

— Иптәш майор, чәй эчәсезме? — Комбат ничек итеп булса да аның күңелен табарга тырыша иде. Ләкин ничек якын килергә бу кешегә? Бик кирәкле кеше бит, шайтан, аның белән дус булу бер дә зыян итмәс иде. Бераз ялагайлана белсәң дә, ичмаса, ярап куяр иде, юк бит, булдыра алмый, үзенне үзең өзгәләп ташлыйсыңмыни?

— Юк, рәхмәт! Ну-ка, миңа телефонны бир әле!

Майор телефонны алу белән үзен тагы бүтәннәрдән өстенрәк итеп сизде. Аның шул халәтен күз явы очкыннары да тарата иде. Тегендә, алгы сызыкка якынлашканда һәм үрмәләп ату «коридорын» узганда, ул үзен комбат белән тигез тотты, шаян сүзләр сөйләнде, демократларча ым белән сүгенде, тылгарак кайта башлагач, аның үз өстенлеген күрсәтү хасияте тагы тышка бәреп чыккандай булды.

— Миңа унжиденчене бир, әйе, унжиденчене,— диде ул телефонга, боеручан тавыш белән.— Мин сезне тавышыгыздан таныдым,— диде телефонда хатын-кыз тавышы.— Хәзер ялгыйм.— Телефон трофейный, шуңа күрә бөтен сүз кырыйдагыларга да ишетелә иде.

— Телефонда унжиденче,— диделәр.

— Мин — уналты, урыннан доложить итәм. Сигездә бөтенесе дә бик яхшы,— диде майор.— Бөтенесе дә тәртиптә. Мин алгы сызыкта да инструктаж үткәрдем.

— «Тел» дә алып кайтмыйсыңмы? — диде унжиденче шаяртып.

— Анысын пока монда калдырдым әле,— диде майор. Аның елмаюы йөзенә җәелде.— Барысы да әйбәт, кайтырга рөхсәт итегез! — Майор һаман да елмаюын баса алмады.

— Рөхсәт, рөхсәт! — диде унжиденче һәм трубканы куйды.

Майор тагы нәрсәдер шаяртмакчы иде бугай, телефон өзелгәч, нәүмизләнебрәк торды. Ләкин аның елмаюы йөзеннән барыбер тиз генә китмәде.

Комбат, майорның сүзләрен ишеткәч, кинәт аңа ышанмас булды. Нәрсәгә ул барысы да яхшы дип әйтте? Нигә алай ялганлый? Капитан шушы уйлары белән мәшгуль булып торганда, майор китәргә җыенды.

— Комбат, мин сезне табармын әле, хушыгыз! — диде ул һәм блиндаждан җиңел генә өскә күтәрелде. Комбат аны озата чыкты. Бераз киткәч, майор кул бирде һәм шуннан ары озатма дигән шикелле кулы белән ымлады. Ул бик шат, аның күңеле бик күтәренке иде. Комбат майорның таучык артындагы «вилли»сенә утырып китүен карап торды.

## 13

...Егерме көнләп вакыт узды. Соңгы атнаны көне-төне алгы сызыкта күзәтүдә ятып, Алексей дошман турында күп материал туплады. Шуны һәм ут ноктaларын штабка житкерү өчен, бүген иртән батареяга кайтты. Фираны күреп булмасмы дигән өмете дә бар иде.

Үзе урынына Мирхасны калдырды, ә телефонда — Тәкәнәев. Әнвәрне үзе белән алды.

Биредә яңалыклар шактый иде. Расчетка яңа пополнение килгән.

— Артиллеристлармы? — дип кызыксынды комбат.

— Юк, яңа азат ителгән җирләрдән.

— Ну, ничек?

— Туң агачлар. Менә матчасть өйрәтәбез.

— Дөрес.— Комбат, сүзне беткәнгә санап, урыныннан кузгалды, фуфайкасын салды.

Сөенчалин шул арада чыгып китте. Тагы кемнәрдер килде, аннары старшина кереп, сугышчыларны мунча керту мәсьәләсен кинәште. Армейский күчмә мунчага тиз генә чират житәрлек түгел, шуңа күрә үзебезгә әмәлләргә туры киләчәк. Комбат, аңа кинәш, күрсәтмәләрен биреп, чыгарып җибәрде. Үзе кырынырга әзерләнде. Әнвәр, почмактагы сәндерә кебек җиргә менеп, йокларга ятты. Ләкин күзенә йокы кермәде.

Комбат авыз эченнән ниндидер көй шыншый-шыншый кырынды, юынды. Одеколон сөртте. Фира килгәннән бирле үзенең кыяфәтенә игътибар итә башлады, ахрысы.

Кинәт кояш кебек ялтырап Фира килеп керде. Санинструктор кече лейтенант киемендә иде. Хатын тагы да матурланган, яшәргән кебек күренә. Комбат аны инсафлы гына, шатланып, нурланып каршы алды. Фираның күзләреннән Алексейны чиксез ярату сирпелә иде. Алексей Фираның йөзендә саргылт тут эзләре күреп, аны кызганып куйды.

— Тагы хина эчтеңме? — дип төбәлде комбат аңа, йомшак тавыш белән.

— Тагы.

— Моңа чик куярга кирәк, Фира, болай син үзеңне тереләй үтерәсең.

— Чик куй.

— Син үзеңне үзең кулга алырга тиеш!

— Ул синнән тора, Алексей.

— Ничек миннән тора? — дип сорап куйды Алексей тагы да йомшак һәм ягымлы тавыш белән. Хатын-кызлар белән сөйләшкәндә аның тавышы тагы да йомшаклана, ниндидер бер рәхәт, юл куя торган тавышка әйләнә иде.

— Синнән, Алеша, синнән,— дип кабатлады Фира.

— Бүген каласыңмы? Фира, зинһар дим!

— Юк, уйлама да!

— Фира, мине кимсетмә инде!

— Шул хакта гына хыялланган идем,— диде хатын, үзенең нәрсәгәдер хаклы һәм дәгъвалы икәнен аңлатырга тырышып.

— Фира, я инде, үтермә инде мине? Синең өчен генә передовойдан кайттым.

— Ә, шулаймы? — дип, Фира тыныч кына көлеп куйды. Аның көмеш тавышы тагы да ягымлы иде.

— Сиңа ни булды, Фира? — диде комбат, һаман да шул иркәли торган тавыш белән.

— Нәрсә булсын, берни дә булмады,— дип, хатын тагы көлде.

— Ә нигә шул чаклы шырпылы син бүген?

— Аны син үзеңнән сора.

— Ничек үземнән, аңламыйм, Фира?

— Алайса, аңлатып бирим: ни өчен керпе шулай тоташ энәләр белән капланган, ә?

Шул арада, шалтор-шолтыр котелоклар күтәреп, телефонда утыручы иртәнге аш алырга чыгып китте. Телефон трубкасын ул бер кырыйга куйган, ахры. Ул китү белән кемдер шалтырата башлады. «Алло, алло-о» дигән тавышы гына блиндажны яңгырата иде. Алексей белән Фира теге баштарак, ишек катындарак иде, шуңа күрә телефон шалтыраганны әллә ишетмәделәр, әллә ишетергә теләмәделәр, алар урыннарыннан кузгалмадылар, фәкать Алексей гына кырынган суларын түгеп керде бугай. Бераз тынлыктан соң, ул шаярулы итеп әйтте:

— Керпе дисең, әх-хе-хе?

— Син биолог, үзең дә бик яхшы беләсең. Әйт менә, ни өчен?

— Икебез дә яхшы белгән нәрсәне әйтеп тормыйлар. Мин аңламыйм, Фира.

— Син әйт, син әйт, Алеша! — Фираның тавышы яратулы, шаян иде.

— Ну, дошманнарыннан саклану өчен шулай энәләр белән капланган.

— Аның дошманнары кемнәр, син әйт, зинһар,— дип ялварулы тавыш белән сорады кече лейтенант.

— Ну, минемчә, керпенең беренче дошманы төлке.

— Төлкеләрдән саклану өчен ул шулай тоташ энәләр белән капланган. Әйе! — диде Фира бик җитди һәм бераз боеграк тавыш белән.

— Димәк, син дә энәләр белән капланырга булдың?

— Сезнең белән ихтыярсыздан шулай булырга туры килә.

— Димәк, шулай, Фира?

— Нигә, без дә кеше ләбаса,— диде Фира, томса гына итеп.

— Синең кешелегенә хилафлык китергәнем юк дип уйлыйм.— Алексей, Фира янына утырып, аны кочаклап алды. — Кил әле, минем йомшак керпем! Керпе баласына йомшагым дип әйтә икән...

— Алеша, әнә телефон шалтырый, бар алып тыңла.— Фира Алексейның күкрәгенә ике кулын терәп аны артка этә, ә теге аны биленнән ычкындырмый иде. Шул чакта элемтәченең кайтып килүе ишетелде һәм Алексей Фираны ычкындырып җибәрде.

— Бүген кал инде, сиңа әйтәсе сүзләрем бар,— диде ул шыпырт кына.

— Юк, булмый,— диде Фира. Ләкин үзе тагы көмеш тавыш белән көлеп куйды. Димәк, кала инде. Ул һәр вакыт шулай калмыйм, юк, ди, ә үзе кала. Алексей, аны яхшы белгәнгә, ахры, бүтән төпченеп тормады.

— Мин хәзер дивизион штабына барам, ә син кая? — диде ул, сүзне тәгәлләргә теләп.

— Мин алтынчыга, аннан дүртенчегә,— диде Фира.

— Дүртенчегә барма инде, Фира. Яле, миңа вәгъдә бир, бармыйсыңмы?

— Әһә,— диде Фира.— Димәк, синең гөнаһларыңны анда беләләр, шуңардан куркасыңмы?

— Мине анда дошман күрүче бар, Фира. Унынчыны бергә бетергән идек, һаман үчле.

— Ни сәбәптән, әгәр хәрби сер булмаса?

— Бик кинәле адәм. Безне Айкилдиев белән дә бәрелештерде,— диде комбат. Шунда ук алар чыгып киттеләр. Бераз баргач сукмаклар аерылды, аларның икесенә ике якка иде.

Алексейның эшләре күп иде бүген. Алар дивизионы беркетелгән пехотачылар белән сөйләшәсе бар. Батальон командиры шактый сак кеше. Алексей телефон аша киңәш-табыш итеп караган иде, ләкин командир теге якка да, бу якка да өзеп бер сүз әйтмәде. Эш шунда иде: биредә тагы позицияләр бик тә алама...

Мостафин янында икенче батарея командиры утыра иде.

— Иртәгә төнлә «Шайтан биеклегенә» сугыш разведкасы җибәрелә. Ул-бу була калса, безнең сул фланг сак торырга тиеш! — диде Мостафин. Бу ниятне ул хупламый шикелле иде.

— Маңгайдан бәреп керергә, ай-һай!..— диде Алексей.

Икенче батарея командиры дәшмәде.

— Уйланылгандыр, күрәсең,— дип, Мостафин эчендәген яшерергә теләде.

— Кемнендер герой аласы киләдер,— дип, Алексей югарыдагыларны күз алдында тотып әйтте.

— Штурмовикларны җибәрмәкчеләр...— Мостафин сүзен әйтеп бетермәде, ахры, үзе дә Алексей әйткәнне уртаклаша, булыр.

Кайтканда Алексей: әле дә без ул «Шайтан биеклеге» итәгендә түгел дип, эчтән генә сөенеп куйды. Ул каһәрләнгән җирдә Алексей байтак чәч агартты. Бикиев шунда һәлак булды, тагы күпме бер дигән егетләр баш салды?! «Шайтан биеклеге»ннән алар азат итәсе Опочка шәһәренә иң кыска юл. Өстәге командирларны шул кыҗратадыр...

Менә Фираның да килүе зур бәхет. Рәхмәт аңа! Тик үзем генә нәрсәдер... Хатын-кыз белән мөнәсәбәткә керми торып, үзеңнең нинди икәнеңне белмисең, диләр иде, хак, ахрысы. Минем аркада бит агу — хина эчә. Ник килгәненә үкенә булыр, мескенем.

Аннары икенче батарея командиры исенә килде: ничек шулай үз фикерен бер дә әйтми түзә ала? Дәшмәү белән, әлбәттә, югары үрләячәк. Чөнки ни уйлаганын әйтеп сала торган кешене беркем дә баш итеп куймый инде...

Әнвәр аягыннан тартканга уянып китте. Каршында Тәкәнәев басып тора иде. Блиндажда ут юк, карбит лампа да газы бетеп сүнгән иде, ахры.

— Линия өзелде,— диде Тәкәнәев, караңгыда аның ак тешләре елтырап китте. Линияне ялгарга Әнвәр барыр дип өмет итеп дәшми торды ул.

— Кем чираты? — дип сорады Әнвәр.

Өйләдән соң, әле яктыда, Әнвәр бер ялгап кайткан иде инде, кем чираты икәнен белсә дә, юри сорады ул, чөнки Тәкәнәевнең линиягә барасы килмәгәнен аңлап алды.

— Ну, минеке,— диде теге, ачуын яшерә алмыйчарак.

Әнвәр нардан төшеп, аппарат янына барып утырды, караңгыга күзе иялешә төшкән иде инде. Ул, трубканы алып, аны элмәгеннән башына эләктереп куйды. Тәкәнәев, запас аппаратны шалтор-шолтыр иттереп, сүлпән генә кыяфәттә линиягә чыгып китте.

Алгы сызыктан комбат элегрәк бик сирәк кайта иде, хәзер шактый ешлады. Кайткан саен ул Фираны үз янына дәшә, кайбер төнне бөтенләй йокламыйча төннәр буе сөйләшеп чыгалар. Фира ничектер чуар күңеллерәк хатын иде, бүген бертөрлерәк булса, икенче көнне бөтенләй алыштырып куйган шикелле була иде.

Бераздан плащ-палатка кыштырдаганы ишетелде, нәрсәдер нардан идәнгә шап итеп төште. Комбат торып маташа икән.

— Ут юкмыни? Кем анда? — диде комбат, Әнвәр торган якка йөзен борып.

— Юк шул, иптәш комбат,— диде Әнвәр.

— Малайка, синмени?

— Старшинага барып, лампа алып килимме?

— Бар,— диде комбат, үзе нарга утырып аягына ыштыр урый, киенә иде.

Әнвәр тиз генә старшина блиндажына йөгерде. Шактый чабарга туры килде. Җәйге төн, шундый җылы. Йолдызлар карбит шикелле елык-елык килеп яналар. Каядыр аткан тавышлар бик сәер булып ишетелә. Зәңгәр төннең гаять зур шешә зәңгәр вазасын кинәт чәлпәрәмә китереп ваткан кебек, снаряд шартлый. Тавышы яңгырап, үзәкне өзеп, җанны чукып ала.

Старшина нәрсәдер кабул итә иде, машиналар, солдатлар мәш килә, нинди-дер ящикларны, төкләрне каядыр алып китәләр. Старшинаның вакыты юк иде.

— Әнә, минекен алып тор,— диде ул. Үзе тагы шөгыленә чумды. Әнвәр, лампа эләктереп, чапты гына. Ул кайтып кергәндә, комбат киенгән иде инде. Фира да торып маташа. Әнвәр утны яндырып җибәрде, бик төтенли башлагач, пәке боравы белән филтәсен рәтләде. Әле һаман элемтә юк, шуңа күрә тынычы иде.

— Әйдә, тизрәк, Фира, мин соңга калам, — диде комбат. Ул тагы күзәтү пунктына барырга тиеш иде, ахры.

— Элемтә булмыйча әле!

— Хәзер булыр, — диде комбат сузыбрак һәм бик ышанган кебек.

Ул арада Фира үзенең сумкасын ачты, плащ-палатка пәрдәне ычкындырып алып, аны нарга җәйде дә шуңа ашамлыклар куйды. Комбат юынып керде, Аннары башта үк фляганы ачып, сыңар рюмкага гына шәраб агызды, бер кулына колбаса кисәге тотып, аны тиз генә эчеп җибәрде. Фира Алексейны кыстады, аның ашаганын бик яратып, сокланып карап утырды, ә үзе әз-әз генә капкалый иде.

Ул Әнвәрне дә ничектер кече итеп, якын күрә, аның алдында комбат белән булган мөнәсәбәтләрен дә яшерми, тик эчкерсез тыйнаклыгын, күркәмлеген бервакытта да җуймый иде.

— Әнвәр, кил, син дә утыр, — диде Фира татарчалатып.

Комбат аның Әнвәр белән татарча сөйләшүенә бер дә ачуланмый. Батареяга беренче килгәч тә, комбат Әнвәргә татарча сөйләшмәскә приказ бирде. Шигырь китаплары табып, шигырьләр ятларга мәҗбүр итте. Вакыты булганда комбат үзе, ә күбрәк Фира Әнвәрне русчага өйрәтәләр. Бу аларга ничектер бер кызык эш иде. Исәпләнгән, уйланылган рәвештә түгел, әйбәт булырга тырышу өчен дә түгел, аларның табигый хәлләре, характерлары шулай иде. Фира Әнвәрнең тартынучан икәнен белә, шуңа күрә аңа бер кисәк колбаса һәм ипи китереп бирде. Комбат флягадан салып бирмәкче булса да, хатын аны туктатты.

— Эчәргә өлгерер әле, ул бик яшь, — диде.

Алексей бер сүз дә әйтмәде. Чыннан да Әнвәр эчми, әле кайвакыт һөҗүм алларыннан үзенә тиешле сырецны да бүтәннәргә бирә. Аларның шундый әшәке, сасы, ачы нәрсәне яратып эчүләренә ул бик аптырый. Нәрсәсе бар инде аның?

— Карале, аша инде! — дип, Фира һаман комбатны кыстый. Ул Алексейга чиксез бирелгәнлек рәхәтлеге белән тулышкан, күзләре, иреннәре, хәтта һәрбер бармакларына чаклы мәхәббәт нуры чәчеп тора иде.

— Фира, нишләп үзең ашамыйсың? — ди комбат, аңа бик яратып карап. Аның тавышында шундый кечелеклелек, олылау, кичектер кызгану яңгырый.

— Монда килгәннән бирле тазарам да тазарам, чүпрә салган камыр кебек күперәм гел, — ди Фира һәм комбатның күзләренә мөлаем карап, шаркылдап көлә. — Юанаеп китсәм, яратмый башларсың тагы.

— Һи, әйттең сүз, — ди комбат шаяртып. — Яратып кына торып буламыни?

— Яратмыйча торып буламыни диген! — Фира тагы шаркылдап куйды.

— Әйе,— диде Алексей, нәрсәдер уйлап җитдиләнде, кашлары ничектер өскәрәк күтәрелде, борын өстендә ике кашы тоташкан җире бүлтәебрәк китте.— Кешеләрне ярату дөньяда иң авыр нәрсә.

— Ә бер кешене генә ярату авыр түгел инде! Аңа гына урының бардыр?

— Юк, мин ул хакта әйтмим, өскә җаваплылык алуны әйтәм.

— Гади генә яратырга да яратырга.

— Ул ярату булмый, инстинкт кына.

— Юк, аңламыйм, син кеше сүзен әйтәсең, — диде Фира, комбатның

кулыннан тартып. — Минемчә, сиңа кешеләрне ярату дөньяда иң җиңеле.

— Мин яратам, әйтик, ә алар яратмый дип йөриләр. Буламы шулай, ә?

— Ә син ул турыдамы? — диде Фира, гаепле кеше кебек. Ул моны үзенә ишарә дип атлады.— Әллә сине ярат дип борчыйммы?

— Кара, син гел үзеңә аласың, Фира.— Алексей, шаярып, аның җилкәсенә учын куеп алды.

— Мин фронтка килгәндә синең белән болай булырмын дип төшемә дә кермәгән иде.

— Әллә инде үкенә дә башладың?

— Дәгъвама ачуың килә, әйеме?

— Дәгъва җитдилек галәмәте.

— Син уйлый торгансың: үз иренең язмышы билгесез була торып, миннән дә тайчанмады, диясеңдер? — Фираның тавышы бик моңсу иде.— Миңа да киртә иде ул. Әмма киртәне син җимердең.

— Намус пристубымы бу синең?

— Әллә...

— Сине түбәнсетә торган уйның башыма да килгәне юк, Фира.

— Нинди эгоистландым мин, ә? Просто үземә-үзем күңел болгандыргыч була башладым.— Фира риясыз көлгән итте, ул чынлап та рияны белми, Алексейны гаепләү вөҗүдендә дә юк иде.

— Мине гаепләсәң, Фира, гаебемне таныйм. — Алексей аны вөҗдан газабы кичерә дигән нәтиҗәгә килде.

— Гаебең тиз таный торганнарны өнәмим, Алексей.

— Андыйлар гаепне дә ансат кына эшли, дисеңме?

— Син алай түгел.

— Киртәне җимердең диюең ничектер күңелемә тиде.

— Юк, үзем гаепле, Алексей.

— Үткәннәр синең тормышыңа киртә булырга тиеш түгел. Шуның белән килешәсеңме?

— Хәзер инде килешәм, хәтта сиңа мең-мең рәхмәт дим.

— Гаепне үз өстеңә генә алсаң, мине кимсетәсең, Фира.

— Алайса, илле процентка син гаепле, калган иллесенә — мин.

— Икебез дә гаеплеме?

— Юк, икебез дә гаепсез?!

— Нәкъ пәйгамбәр хөкеме кебек. — Алексей кинәт, әллә сөенечтән, әллә болай көлеп җибәрде.

— Хатын-кыз хөкеме — дөньяда иң гадел хөкем. — Фира да чиксез шатланып көләргә тотынды.

— Әйтмә дә.

— Чын-чын! Эш башын хатыннар кулына бирсәләр, бернинди сугыш булмас иде.

— Ә? Юк, барыбер булыр иде.

Фира җавап бирмәде, Алексейның сүзләрен тыңламады да бугай, үз уйларына йотылган, карашы да бирсдә түгел иде.

— Безне кичә төнлә бик каты бомбага тоттылар, ишеткәнсеңдер, — диде Фира, кинәт уянып киткәндәй.

— Үлүчеләр булдымы?

— Бәхеткә каршы, юк!

— Алайса, әйбәт.

— Ә мин шундый курыктым, Алеша, аңлыйсыңмы?

— Әй, минем куркак куяным, йомшак куяным,— диде комбат, Фираның битенә учын тидереп. Аның күзләре шатлык белән тулып, нур ташый кебек иде.

— Чын, курыктым, бөтен үзәгемне суырып алган кебек булды.

— Инде күнегергә вакыт, югыйсә.

— Булмый, ахры, миннән.
— Мин сиңа әйтәм бит, тылга кит дим, миңа бер малай тап дим.
— Ә мин сине ташлап китәргә куркам.
— Миңа ни булсын, чудачка син.
— Юк, Алеша, алай итә алмыйм әле.

Хәтәр караңгы төн. Сәгать унберләрдә безнең уң фланг «Шайтан биеклеге»нә ата башлады. Корым шикелле куе караңгыда алтышар «Катюша»ның берьюлы залп бирүе коточкыч тәэсир итә иде.

Аның өстәвенә гаубицалар дәррәү дөпелдәтәләр, дошман позициясен тетәләр. Яшенле куркыныч төн хәтергә төшә. Тик бу тагы да куркынычрак. «Катюша»лар атканда җанны суыра торган әллә нинди бер аваз чыгаралар. Немец ягында бер тере җан да калмагандыр, дип уйлыйсың.

Әнвәрләр урнашкан төштән шактый уңда һәм түбәндә булганга «Катюша»ларның караңгы төнне ярган ут ташкыннары әйбәт күренә һәм йөрәкләргә көч, дәрт өсти иде.

— Баш тегермәне тотынды, — ди Шилов, гвардия минометларының уты белән горурланып.

— Нигә фриц бер дә атмый? — дип сорый Әнвәр, гаҗәпсенеп.

Янда басып торган Мирхас аңлата:

— Дотларга поскан, ату тынгач та чыгар. Алар хәйләкәр! — Тавышыннан фрицны тиз генә алдый алмассың дигән мәгънә аңлашыла.

— Дотны «Катюша» җимерә алмый шул, — дип, Шилов моңа бик пошынган сыман, ияге белән биеклек ягына ымлый.

Безнең орудиеләр кинәт атудан туктады. Бер минуттан немец пулеметының «ток-ток-ток» иткәне ишетелде.

— Ах, заразы! — дип, Мирхас теш арасыннан ысылдап куйды.

Безнең пехота алга күтәрелгән булса кирәк, немецның тагы бер пулеметы телгә килде. Солдатлар корал тавышларыннан һөҗүмнең ничек баруын абайлап тордылар.

Сәгать икеләрдә күктәге болытлар таралып яктыра башлады. Ике яктан да атышлар сыегайды.

Яктыргач күрделәр: «Шайтан биеклеге», кыегы янып кара күмергә әйләнгән гигант бер йортны хәтерләтеп, каралып тора иде. Андагы барча урман, куак, җирләр янып көл булганнар иде.

Иртән яңа хәбәрләр килде: безнекеләр биеклеккә үтә алмаганнар, байтак кеше югалтканнар. Пехота бер-ике дотка бәреп керсә дә, аннан таута — немецларга таба ут ачарга мөмкин булмаган. Дотлар болайга таба гына атарга җайланган бит.

Чындырмы, юктырмы: әлеге уңышсызлык өчен югарыда кемнедер урыныннан алганнар, имеш, дип ишетте Алексей. Ләкин бу фаҗига җитәкчеләргә күп кенә акыл да биргәндер. Дотлы ныгытмалар булган төштән прорыв ясар өчен бүтәнчәрәк тактика кулланырга кирәк. Дошман оборонасының тоташ ныгытмалы булуы мөмкин түгел. Һөҗүм өчен ныгытмасыз җирне табу мөһим.

Алексей ул «Шайтан биеклеге» янында булмавына тагы бер кат сөенде. Алар хәзер урнашкан тирә шулай да бераз рәхимлерәк шикелле. Немец алар алдындагы ике үркәчле тауЧыкка урнашкан. Алай биек түгел, шактый сөзәк. Тауҗыкның кечерәген солдатлар «Кыз» дип, зуррагын «Хатын» дип йөртәләр. Шулай да немец фашист инде, биектәрәк утыруыннан файдалана, пехотага бер дә көн күрсәтми. Снайперлары саксызракларны чүкеп кенә тора.

Батареяда матчасть өйрәнеп яталар. Сөенчалин хәрәкәт итә торган танкка ничек атарга һәм тидерергә өйрәтә. Ара ераклыгын төгәл чамалау хәлиткеч нәрсә икән.

— Баш белән чутла, анда сиңа кәгазь-каләм юк, — дип кычкыра Сөенчалин томанаракларга, кат-кат эшләтә.

«Молодец!» — дип сөенде Алексей, аларны күзәтеп торгач.

Мушков «Тигр»ларның макетын ясаган, шулар мисалында ничек итеп «йомшак җирләренә» атарга өйрәтә.

— Маңгайга бәреп, «Тигр»ны алып булмый. Факт! Тәгәрмәч чылбырын һәм жалюзын чамаларга кала.

— Алды белән килгәндә арттагы частена ничек тидерәсең? — дип сорый сугышчы.

— Хәйләлә, маневр яса. Баш котелогыңны эшләт!..

Фронт сызыгы тирәсендәге һәрбер хәрәкәт тиздән зур һөҗүм башланачагын белгертеп тора иде. Төне буе мотор тавышлары гөрелди. Артиллериянең барча калибрлары китерелә. Ә минометлар әүр агачлар яки биеклек ышыгына тар гына мәйданчыкка урнашалар. Алар тау артында торып икенче тау артын утка тота алалар.

Ак чиркәүдәге эвакгоспитальдән аерым итеп чыршы урманы эченә яңа санбат кордылар. Оборонада яткан чорда комсостав һәм рядовойлар өчен анда ял йорты иде. Алдынгы сугышчылар һәм командирлар өчәр-дүртәр көн ял итеп кайталар иде.

Яким Зиновьевич Сергейны тылга җибәрттермәде, терелгәнче үз күз алдымда булсын, диде. Егетне чын күңелдән үз итүен ул яшерми иде. Яким Зиновьевичның яратуының серен белергә йөдәүчеләр: Сергей — аның тәрбиягә алган малае, имеш, дигән сүзләр дә чыгардылар. Чөнки бу кырыс кешенең разведчикны аталарча яратуы күпләргә аңлашылмый һәм сәер тоела иде. Чынында исә ул Сергейны батырлыгына һәм фидакарьлегенә сокланып ярата иде. Аларны бары фронт очраштырган, сугыш эшләре бергә бәйләгән иде.

Санбатның баш врачы Нунау майорның үтенечен кире какмады. Сергейның хәлен җиңеләйтү өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләде. Римманы махсус рәвештә дигәндәй егетне карарга куйды.

Һөҗүмнең кичектергесез башланачагын белгертә торган тагы бер билге: штаблардагы барлык политработниклар аңлату эшләре өчен алгы сызыкка килделәр. Траншеяларда, окопларда, орудие расчетларында әңгәмә алып баручы инструктор яки агитаторны очратырга була иде. Һөҗүм бөтен фронт белән булачак икән.

Һөҗүм башланасын солдат халкы үзенең алтынчы тойгысы белән алдан сизде. Сугышчыларның йөзләрендә киеренкелек, үз эченә йотылганлык күренә. Бигрәк тә алгы траншеядагы Тукташев солдатлары уйчан һәм шул ук вакытта канәгать кыяфәттә иделәр. Берәүләре кайсы якка булса да үзгәреш булыр, я җиңел яраланып, тылга китәрмен дип өметләнә, икенчеләре шушы һөҗүмнән исән-имин чыксак, бәлки сугыш та бетеп куяр, туган җирләргә кайтырбыз дип хыяллана. Авыр уйларны куу өчен шаяртталар:

— Иптәш капитан, «орденнар эшләргә» барабызмы? — дип, сары мыеклы сугышчы Алексейга елмаеп карый.

— Бәлки герой да булырсың, ә? — ди аңа Алексей.

— Белмәссең, шайтан ничек кенә шаяртмый!

— Герой булганчы башыңны салырсың, — диде шаярырга яратмаучы икенче бер сугышчы. — Ул «Кыз» биеклеге бетоннан койган ди бит! — Сугышчы тозлап-борычлап сүгенеп калды.

Оборонада ятканда да «Кыз» һәм «Хатын» биеклекләре сугышчыларның канына күп тоз салды. Фриц шул биеклектән торып, баш күтәрергә дә бирми, тәмәке тарта башласаң, төтенен шәйләп алып, атарга тотына иде.

— «Кыз»ын алсаң, «ана»сы үзеннән-үзе бирелә инде аның!..

— «Кыз»ы бит крепость кебек, шайтан алгыры!

— Крепость җимерергә рәтең бармы соң? — диде кайсыдыр. «крепость» сүзенә конкрет бер мәгънә биреп. Үзе ютәлли-ютәлли көлә башлады.

— Ай-һай, җае узганнарны берни белән дә җимерә алмыйсың, ди.

— Ә мин кырыкта булсам да, ул эшне үз җаваплылыгыма ала алам. Шулай, брат! — дип, хәйләле елмайды сүзне башлаган сугышчы һәм траншеяның теге башынарак атлады. Командирлар блиндажга кереп киттеләр. Сугышчылар янына чиста, ыспай гына гәүдәле бер сержант килеп сөйләшә башлады.

— «Кыз дагы немец траншеясына беренче бәреп керүчеләргә Кызыл Йолдыз ордены биреләчәк, икенчеләргә Дан ордены!

— «Кыз»ның итәгенә барып җиткәч, анысы җаен табар идек әле.

— Юк, сержант, чын әйтәсеңме?!

— Әнә, замполит аңлатты, җир йотсын менә! Син политзанятиегә кермәдеңмени, Артюков, ә?

— Мин постта идем, иптәш сержант.

— Шул шул, юбкалар турында күп лыгырдыйсың!

— Ну, лейтенант, «Кыз»ны турыдан гына алып булырмы? — диде Алексей, Тукташевның йөзенә якын ук килеп.

— Шикләнәм, иптәш комбат, тимер-бетон дотлар, икенче маннергейм!

— Шикләнүең әйбәт, лейтенант! — диде Алексей һәм блиндаж бусагасына утырып картасын алдына җәйде. — Һе, «Кыз»ны тактикасыз гына кулга төшереп булмас кебек күренә бит әле.

— Бик капризный, яман!

— Берәр йомшак җире юкмы соң, шуннан эләктерергә?

— Бер дә әйтә алмыйм, иптәш капитан, капшап карамадык түгел инде.

— Ничек тә берәр җаен табасы иде бит.

— Әгәр төнлә һөҗүм итсәк, иптәш капитан?

— Теге башкорт ягындагы кыз урлау шикелле дип әйтмәкче буласыңмы, ә? — дип көлде капитан һәм хәйләкәр генә итеп Тукташевка карап куйды. — Сездә, татарларда да, ул йола бар бугай. Тукта, ә син үзең кыз урлаганың бармы соң?

— Бар, — диде Тукташев һәм күңелсезләнүе кинәт йөзенә чыкты.

Алексей «урлаган өчен моны утыртканар, ахры» дип уйлады, үзе кызыксынып төпченә бирде.

— Аның өчен статья бирәләр түгелме?

— Була андый хәлләр, — диде Тукташев, шулай ук кинәт җанланып. Олы йөзе нурланып, эчтән яктырып китте. — Урлау бит берничә төрле була. Кыз үзе урларга куша, яки кушмаса да, шуны тели...

— Ә синең ничек, үзе теләдемени? — дип, Алексей елмаеп, яратып лейтенантка карады.

— Үзе,— диде лейтенант һәм тирән дип көрсенеп куйды.

— Азагы ничек булып бетте соң?

— Бик яхшы булды, әле бетмәде.

— Романтичный йола инде, — диде Алексей.

— Гомергә онытылмый торган әйбер. Без унике көн генә торып калдык.

— Сразы алдыларммыни?

— Беренче көнне үк, җыенга, район үзәгенә барган җирдән! — Тукташев башын аскарак иде, күзен читкәрәк алды, аның йөзендә сагыну, үкенү шәүләләре чагылды һәм ул эчке уйларына нокта куйган кебек кулын селтәде дә йөзен тагы капитанга таба борды.

Шул вакыт Тәкәнәев килеп, Алексейны телефонга чакырды. Алар иелеп кенә чыгып, бик нык бөгелеп, күзәтү пунктына таба атладылар.

Немец барыбер хәрәкәтне шәйләде, снайперлары берничә тапкыр атып карады. Пулялар үләннәргә тиеп, вак кына кургаш кисәкләре булып вакланалар, яфракларны кыеп төшерәләр, үлән сүле битләргә чәчри иде.
Телефонда хуҗа үзе иде.
— Мин синең хуҗалыкта, кайта аласыңмы? — диде Мостафин, тыныч тавыш белән.
— Ярты сәгатьтән булырмын! — дип, Алексей трубканы куйды һәм, разведчик Мирхасны күзәтергә калдырып, үзе кайтырга чыкты. Ниндидер гадәти булмаган хәл, ахры, дип уйлады ул, куаклар арасыннан яшеренеп атлаганда. Әллә яңа снарядлар китерделәр микән, ниндидер секретный әйбер, «Тигр»ларга каршы ата торган реактив корал дип сөйләгәннәр иде...
Ул кайтып төшкәндә, Мостафин блиндаж ишеге төбендә тора иде.
— Алексей, синең фикерең кирәк, — дип, кул бирде ул аңа.
Алар эчкә уздылар, анда пехота командирлары да бар иде. Мостафин эшнең асылын аңлатып бирде:
— Командирлар дотларны тиз алып булмас дип шикләнәләр, гомуми һөҗүм хәрәкәтеннән артка калудан куркалар, шуңа күрә биеклеккә төнлә, искәрмәстән бәреп керергә әйтәләр. — Мостафинның бу фикерне хуплаганлыгы тавышыннан сизелеп тора иде.
— Ә безнең бурыч? — диде Ваһапов. Аның пехотачылар ниятенә бик үк кушыласы килми иде.
— Артиллерияне безнең арттан ук алып менәргә һәм безне ут белән ышыкларга, — диде батальон командиры.
Ишектә Тукташев күренде. Алгы сызыкта Алексейга бу фикерне башта ул әйткән иде. Аңарда бу уй немецны озак өйрәнгәннән соң туган булса кирәк.
— Әгәр уңышлы чыкса, югалту да аз булыр, — диде Алексей.
— Ә нинди нигез бар? — дип, бу омтылышка Ваһапов гаярьлек итеп кенә карады.
— Тәвәккәлләргә һәм биеклекне алырга! — диде Мостафин приказ биргән кебек. Аннары разведка мәгълүматлары турында сөйләп китте. Нәкъ төнге унберләрдә немец частьлары алмашынырга тиеш икән. Бу яңалык барысының да ышанычын кинәт арттырып куйды.
— Алайса, ярый, — диде Ваһапов.
— Бер җайлы урын бар, тик минадан әрчергә кирәк, — дип, Тукташев картадан шул җирне күрсәтте.
— Ә сезнеңчә? — дип сорады Мостафин, батальон командирларына таба борылып.
— Без шул вариантка тукталдык. Тик орудиеләрне ничек менгерергә, анда тирән чокырлар бар бит.
— Бөтен көчне куячакбыз, — диде Алексей. — Уратыбрак юл булырга тиеш.
— Хәерле сәгатьтә, алайса. — Мостафин мәсьәлә аңлашылган, килешенгән санап шулай диде. Пехотачылар кузгалып уйчан кыяфәт белән чыгып киттеләр. Мостафин да аларга иярде. Озата чыгучы Алексейны туктатып:
— Рәхмәтеңне әйт, сиңа ике яңа орудие бирдек, — диде.
— Рәхмәт, иптәш майор. — Алексей тыйнак кына аның кулын кысты.
Комдив шунда ук китеп барды.
Кичкә таба «Кыз» биеклегенә төнлә бәреп керергә дигән приказ килде. Алексей кайсы орудиеләргә пехота артыннан калышмый кузгалырга, кайсыларына урында калып, ут нокталарына атарга әйтеп, боерып йөрде. Аннары эшләрне Ваһаповка тапшырып, үзе алгы сызыкка — Тукташев янына китте.
— Хәерле юлга! — диде ул үз-үзенә.
Лейтенант аны бик моңсу каршы алды.

— Нәрсә, уйландырамы? — диде Алексей, аңарда дусты Бикиев чаткылары күреп. Тукташевның риясыз кеше икәненә көннән-көн күбрәк ышана бара иде ул.

— Уйламаска тырышам. Артык күп уйлау ул барыбер берни уйламау кебек файдасыз! — Тукташев төнге һөҗүм турында идея әйтүенә үкенгән шикелле иде. Ул, үзенең начар уйларын куып җибәргәндәй, кулын селтәде һәм мелт-мелт килеп янган ут янындагы картасына иелде. Аның аксыл йөзен йокламаудан тирән сызыклар телгәләгән иде.

Төнге уннарда саперлар сул як флангтагы һөҗүм коридорын миналардан әрчеп кайттылар.

— Фрицның кәефе ниндирәк, бик тынычсызланмыйлармы? — дип сорады Тукташев, утырган килеш черем итүеннән кинәт уянып.

— Кабер кебек тыныч! — диде сержант.

Тукташев шикләнеп куйды, биредә фрицның берәр хәйләсе ятмыймы? Аннары ул взвод командирларын җыйды, соңгы хәзерлекне тикшерде.

— Кем беренче барырга тели? — дип, Тукташев взвод командирларының йөзенә карады. Ул эченнән Калмыков тәвәккәлләр дип көтте, ләкин теге дәшмичә күзләрен аскарак төбәп утыра бирде. Менә уй нишләтә, уй безгә зарарлы, тәвәккәлләргә уй комачаулый, дигән фикер килде рота командирының башына, Калмыковка карап торганнан соң.

— Миңа рөхсәт итегез! — диде кызыл чырайлы, сары чәчле сержант Колчин.

Тукташев эченнән: «Молодец!» дип куйды, күп уйламау нинди әйбәт! Колчин ротада яңа кеше, бер дә аралашырга яратмый, аңардан бер сүзне тартып алу өчен дә түземсезләнеп көтәргә кирәк. Кара, теле ничек ачылган. Юк, беренче булып үземә барырга кирәк, дигән карарга килде Тукташев.

— Башта бер дотны алам да сезгә хәбәр итәм, аннары сез дә кузгалырсыз, — дип сөйләнде Колчин. Оборонада ятканда су кебек тыныч холыклы бу егетне хәзер бөтенләй танырлык түгел иде.

— Юк, юк, — диде Тукташев ихлас күңелдән. Үзе кинәт кенә тынып калды, иякләре кыймылдап куйды. Ул траншея буйлап китте һәм сугышчыларына тагы бер мәртәбә приказны аңлатты, шуның белән сугышчыларының тупланганлыгын, ышанычларын арттырырга уйлады. Яраланган очракта кычкырмаска, түзәргә кирәклеген һәрберсенә тукып чыкты.

Кузгалгач, Колчин взводы кызурак шуышып шактый тиз алга китте. Калмыков та җәһәт кыймылдады. Тукташевка бу хәлне башта үзе уйлаганча итәргә мөмкин түгел иде инде. Аның солдатлары нәрсәгәдер әкрен шуыштылар. Биредә инде команда кычкырып булмый, алар җае белән хәрәкәт итәргә туры килә иде.

Ракетачы лейтенант, боерганча, һаман шул яшькелт ракеталарын, ягъни оборонада ятканда саклык өчен кулланыла торган ракеталарын, билгеле бер ара белән һавага чөеп торды.

Хәзер июль азаклары, төн караңгы иде. Ракета чыжылдап өскә күтәрелә, тирә-юньне яктыртып ала да аннары күз яше кебек мөлдерәп җиргә төшеп сүнә. Кеше гомере кебек, дип уйлады Алексей траншеяга сөялгән килеш. Җаңга билгесезлектән пошаман тулган — тын алуы авыр...

Колчин взводына немец траншеясына чаклы түш белән шуышып диярлек барырга туры килде. Ул искәрмәстән генә «маңгай» ягыннан һөҗүм итте. Калмыков ерганак буенча менеп, сул фланг өзелгән җирдән бәреп керде.

Колчин траншеяга сикереп төшкәндә, бер фриц шәүләсен шәйләп алды: немец җиргә бөгелеп нәрсәдер эшли иде, аннары турайды да туптуры Колчинга таба килә башлады. Сержант, автомат тәтесенә бармагын куйган килеш, стенага сыенып, шып булды. Берничә адым кала фриц кычкырып җибәрде һәм кулындагы атарга әзерләгән ракетаны

туры Колчинга юнәлтте. Ракета хәтәр чыжылдап, аның сул җиненә тиде дә кинәт киеменә ут кабынды. Сержант янган көе фрицка ташланды. Фриц таза һәм көчле иде. Колчинны читкә ыргытты да яңадан аның өстенә атылды. Колчин күз ачып йомган арада автомат тәтесенә басты, фриц, чайкалып, тар траншея кырына тотынды һәм үзенең өстенә зур кантар балчыклар ишеп төшерде.

Автомат тырылдаган тавышлар яңгырады, барысы да буталып бетте, немец бик тиз сизенеп алды һәм каты рәвештә каршылык күрсәтә башлады. Фрицлар дотларга кереп бикләнделәр.

Колчин траншея борылышындагы дот ишегенә атты, аңа каршы көчле ату белән җавап кайтардылар. Ул бер борылышка ышыкланып калды, юкса, беткән иде. Кинәт сул беләгенең ачыта башлавын тойды, караса, гимнастеркасы пыскып яна, шул тәнен пешерә икән, тиз генә өстен салып ыргытты, шәрә тән калып, автоматын алгарак тоткан килеш, дот тирәсендәгеләр янына килде. Сугышчылар дотны камап алып, «Гансик, Гитлер капут!» — дип кычкыралар. Моңа каршы тегеләр ут белән җавап бирәләр иде.

— Гранаталар! — дип кычкырды Колчин. Аксыл ишеккә берничә граната очты. Фрицлар барыбер ут белән җавап кайтардылар.

— Сержант, плен алыргамы?

— Нинди плен!.. — диде Колчин ачулы тавыш белән. — Бередә икәү калыгыз, бүтәннәр теге дотка!

— Төнлеге монда, Дима!

— Хәзер, хәзер, — диде тегесе үз нәүбәтендә.

— Тукталмагыз, шайтаннар! — дип, сержант йөгереп китте, караңгыда аксылланып шәрә гәүдәсе күренеп калды. Аның артыннан траншеяның уң флангысына таба сугышчылар ябырылды. Әмма кинәт немец автоматының уты типчеп-типчеп куйды. Кемдер бик авыр лапылдап җиргә егылды, кайсыдыр бик каты итеп, үлем ачысы белән кычкырды да тынып калды. Колчин траншеяга чүгәләде, бер сугышчыга төрткәләп:

— Артына төш! — дип боерды.

Тегендәрәк безнекеләр нигәдер «Ура-а!» кычкырдылар, бередәгеләр дә шуңа кушылдылар, шактый гына тәэсир итәрлек тавыш чыкты. Фрицлар да каушап акырыша башладылар. Аларның элемтәләрен өзәргә кирәк дигән уй белән Колчин урыныннан торды һәм траншея буенча йөгерде, ләкин чыбыкларны күрә алмады. Кемдер яраланып карганатиргәнә ярдәм сорый, ярсулы гасабиланып алланы сүгә иде...

Шушындый болгавыр чакта Тукташев килеп җитте. Аның белән пушкаларга урын, расчетка блиндаж хәстәрләү өчен разведчик Мирхас һәм Шилов та килде. Бу гаярь егетләр кискен бәрелешләрне, фриц белән күзгә-күз очрашуны тагын тансыклаганнар иде. Шунда ук, һөҗүм дулкынына бирелеп, эшкә тотындылар.

Лейтенант берничә сугышчы белән немецларның икенче траншеяларына һөҗүм итте. Бередә дотлар юк, тар гына ячейкалар лабиринт бормаларына уелып эшләнгән иде. Шулай лабиринт буенча коточкыч атыш китте. Мирхас белән Шилов шунда могҗиза күрсәттеләр. Күп кенә сугышчылар атып та тидерә алмыйлар, үзләре я яраланып, яки үлеп калалар иде. Ә Шилов белән Мирхас бер пуляларын да бушка җибәрмиләр. Бүтәннәр шәйләп өлгергәнче, кай арададыр күреп алып, фрицны тончыктыралар. Алар төзәп тә тормый, кулларын гына юнәлтәләр, фриц шунда ук авып төшә иде. Әйе, шушындый өч-дүрт солдат бөтен ротаны алыштыра алыр иде дип хыялланды Тукташев.

Кинәт Мирхас артына әйләнеп атып җибәрде. Тукташев фрицның ике кулын югары күтәреп авып төшүен күрде. «Әллә минем артымда да күзе бармы?» дип уйлады Тукташев. Мирхас үзенең парабеллумын нечкә чылбыр белән бил каешына эләктергән иде. Ул тиз генә аны ычкындырып алды да бер немецны эзәрләп каядыр чапты.

Сугышчылар тегендәрәк тагы бер дотны чолгап алып, шаулаша башладылар. Моржа тишегеннән граната төшерделәр, бик каты шартлау булды. Инде дөмеккәннәрдер дип бер сугышчы ишеккә таба атылды, көтмәгәндә ишектә ут сызыгы пәйда булды, сугышчы йөзтүбән авып төште. Кемдер акырып куйды. Тагы моржа тишегеннән ике лимонка тондырдылар. Көчсез шартлау ишетелде. Янә бер сугышчы тагын ишек турыннан өстән төшеп, ишеккә аягы белән типмәкче булган иде, кинәт кул пулеметы утыннан киселеп ауды.

— Танк гранаталары! — дип кычкырды Тукташев, һәм аңар кемдер авыр чукмарбаш кебек граната тоттырды.

Тукташев сул кулы белән (ул сулагай иде) тегене ишек астына томырды. Каты шартлау ишекне җимерде, ләкин пулеметтан ату тукталмады. Шул арада Мирхас җайлы позиция сайлап өлгәләде дә:

— Үзем алам, барыгыз! — дип кычкырды.

Тукташев, сугышчыларына кычкыра-кычкыра, фрицларны әзәрлекләргә ашыктырды. Алар киткәч, бераз тын калган шикелле булды. Мирхас ишектән күзен алмады, көтте, кемнең күпмегә түземлеге җитәр? Ниһаять, ишектә квадрат каска пәйда булды, ул ата-ата чыкты. Пулялары выжылдап Мирхасның колак яныннан гына узды. Аның кулы корал авырлыгын сизмичә үзеннән-үзе күтәрелде дә тәтене тартты. Фриц ишек яңагына аркасы белән сыланып, җиргә чүкте.

Мирхас, бу блиндаж дотны комбат өчен әйбәт булыр дип ниятләп, ишеккә таба бара башлады. Кинәт чокырдан тагы бер фриц калкынды. Разведчик туктап калды. Инде шактый якты иде. Фриц Мирхасны күрде һәм аңа атып җибәрде, ләкин тидерә алмады. Мирхас, бер дә каушамыйча, салкын канлылык белән немецның кулына атты, тегенең пистолеты бармакларыннан ычкынып, җиргә тәгәрәде, үзе урталай бөгелеп, башы артка китте.

Мирхас кәефләнеп блиндажга атлады. Үлгән фриц гәүдәләре яныннан үткәндә, кинәт якында гына аткан тавыш аны җиргә екты. Юк, ул яраланмаган иде, кинәт куркынычтан саклану инстинкты аны җиргә аварга мәҗбүр итте. Әйе, анда яралы гансик бар, дип сизеп алды Мирхас. Яткан килеш лимонкага запал куеп, ишеккә томырды. Аннары эчкә атлады, чыннан да дот өчендә зәңгәр мундирлы бер фриц аунап ята иде, икенчесенең күн итек дагасы чагыла икән, күзләр ялтыравы дип уйлый язды... Әйбәт НП булачак бу.

«Яктырганчы тупларны менгерә алмасалар, безгә капут», — дип уйлады Тукташев бер блиндажда ныгырга исәпләп. Ә машиналар нигәдер күренми. Калмыковтан элемтәче килде, сул флангны фрицлардан тазарта икән. «Кыз»ны алдык, шампанскийларыңны җыеп, тизрәк туена кил дип, комбатка хәбәр саласы килде Тукташевның. Әйе, хәзер чынлап та «туй» башланачак. «Шампанскийлар» дип ул тупларны күз алдында тотты. Алардан башка бирелә үлем туе тантана итәчәк!

Шул чак машина гөрелтесе ишетелде, ул ике орудие өстерәп менгән, ә өченчесен берничә расчет бер булып китерә иде. Аларны Мирхас белән Шилов каршы алдылар.

Алексей блиндажга керде генә — чигенеп барган фриц, аңына килеп, минометтан котырган ут ачты. Авыр снарядлар җирне коточкыч актарырга тотынды. Машинага фугасный снаряд тиде, кауый урынына һавага очырды. Кичә генә госпитальдән кайткан шофер Мулла, ике кулы белән башын тотып, траншеяга ауды, кузовта ике яралы бар иде дип, кычкырып үкерергә тотынды.

Тукташев, артиллеристлар килгәнен ишетеп, тизрәк Алексей янына хәл белергә ашыкты.

— Туй башланды! — диде ул, өстендәге балчыкларны кага-кага ишектән кергәндә.

— Яралылар төялгән машинаны бетерде! — дип, Алексей үзенең калтыранган тавышын сиздермәс өчен сүзен өзде. Тукташев йөзендәге җиңүдән булган шатлык чаткылары кинәт сүнде.

— Артподготовка ничәдә? — дип, ул томырылып комбатка карады.

— Сигездә.

— Әх, аңа чаклы чыдап булса, — диде Тукташев, үкенүле-кызганулы тавыш белән.

— Элемтә булса, сорар идек, — дип, комбат Шиловка таба борылды.

Әнвәр чыбыкны китереп житкермәгән икән әле. Шилов ниндидер трофей кораллар белән мәш килеп утыра иде, шуңа комбатның ачуы да кузгалгандай булды.

Немец бер тере җан калдырмаслык итеп, бөтен җирне снаряд, мина белән тетә. Сугышчылар ярчык яңгыры астында орудиеләрне урнаштыралар. Шул мәхшәрдә могҗиза белән исән калган кебек, элемтә катушкасы өстерәп Әнвәр килеп керде. Чыбыкны тизрәк аппаратка ялгадылар, ләкин... элемтә өзелгән иде.

— Шилов, живо! — диде комбат.

Теге исә блиндаж бусагасында бер минут туктап торды да чиксез күп үлем ярчыклары эченә ташланды. Кешеләр тынып калды, авыр снарядлар якында гына төшеп шартлый, әмма немецларның блиндажлары бик шәп, сугышчыларның әле исән булулары фәкать шуңардан гына иде. Тукташев бер тыныш арасында чыгып, тагы пулеметларның урнашуын, сугышчыларын барлады. Үлүчеләр күп түгел иде әле.

Бераздан Шилов линияне таба алмый кире кайтты. Линияне снарядлар тураклап бетергән булып чыкты. Комбат нишләргә белмичә гасабиланып алды. Запас ике катушка чыбык алып, Әнвәр белән Шилов тагы мәхшәр эченә киттеләр. Аппаратта Мирхас калды. Радист тагы рация белән штабны ала алмый, дулкынына төшә алмый, анда пароль алышынган иде булса кирәк.

Мина шартлауларыннан качарга итеп, чаба-чаба, Әнвәр чыбыкны гел снаряд чокырлары өстеннән суза. Бу атылган урыннарга кабат атмаслар дигән өмет белән эшли. Шилов моны өнәми. Әнвәр байтак баргач, бер чокырга чыбыкны тартып, аппаратына күеп караган иде, алар сузып өлгергәнче, элемтә өзелгән булып чыкты. Нишләргә?

— Давай, үзәннән, — дип кычкырды Шилов.

— Һөҗүмгә танклар шуннан киләчәк, линиянең эзе дә калмаячак!

— Әй, анарчы әле?! Ярар, син линия буенча кире кит, өзеген ялга, мин сузуны дәвам итәм, батареяга кадәр,— диде Шилов.

Әнвәр чокырдан атылып чыгып, чыбыкны тоткан килеш икенче чокырга сикереп төште, аннан өченчесенә... Бер төштә чыбыкны ялгады, өзекләрне бер-берсенә китерде, теш белән керешләрен сыдырып алды, тимер чыбыкларны бергә ялгап, ишеп куйды. Тимер чыбык очлары бармагын канатып бетергәнне дә сизмәде. Күзәтү пунктына кайтып, тагы шунда ук линиягә чыгып китте, элемтә булмыйча торып, комбат күзенә күренү коточкыч оят иде.

Шилов исән-сау батареяга кадәр элемтәне суза алды. Анда Baһапов бөтен элемтәчеләрне линиягә чыгарды. Шиловны, Тәкәнәевне «урталык» ясап, линияне ике якка да тәэмин итеп торырга боерды. Шилов тагы чыгып чапты... Немец утны көчәйткәннән-көчәйтә. «Хатын» биеклегеннән торып бик каты ата иде.

Менә алгы сызыкта кинәт аппарат җанланды, Мирхас трубканы комбатка бирде.

— Нишләп соңгаралар, синдә хәлләр ничек? — дип кычкырды комбат. Теге: «Әйбәт», — дип җавап кайтарды.

— Тизрәк артподготовка башлагыз, немец атакага килә.

— Хәзер башлыйбыз, — дип кычкырды Мостафин.

Ваһапов телефонны аның линиясенә тоташтырган икән. Алексей комдивка тагы нәрсәдер әйтергә теләп авызын гына ачкан иде, элемтә өзелде. Ул ачудан трубканы атып бәрде.

Алексей, элемтә юклыктан кая керер урын тапмыйча, Тукташев янына барды. Анда бер немецтан сорау алып маташалар иде. Бер сержант ярыйсы гына немецча сукалый икән, фриц елмайган килеш аңа караган. Болай үзе ягымлы гына күренә бит, ә эчләре тулы ерткычлык дип уйлап куйды Алексей. Фриц, аяу сорап, һаман сөйләнә:

— Арбайт, арбайт. Рус хитри, рус хитри, зелены ракета, зелены ракета... Пушка не будил, пушка наен, наен...

Сержант аңлатып бирә:

— Яшел ракета чөеп торып, безне хәйләләдегез, ди. Пушкалардан атып безне уятмадыгыз, шуңа күрә без алдандык, ди.

Ә фриц һаман калтырана-калтырана сөйләнә иде.

— Рус хитри, рус хитри. Их бин арбайтер, — дип күкрәгенә суга-суга телләнә. — Но пасаран, Испания, салют!

Сержант тагы аның сүзләрен үзе аңлаганча тәрҗемә итә:

— Мин эшче, ди, Испаниядә булдым, ди.

— Әкият сөйли ул, — диде Тукташев һәм ниндидер эш белән тиз генә чыгып китте.

— Үтермәсеннәр дип ялагайлана!

— Испаниядә булганнарны Гитлер концлагерьларга озатып бетергән.

Ә фриц һаман башын лакейларча ия, күкрәгенә учы белән тиеп-тиеп ала: мин эшче, мин эшче дип тәкърарлый.

Тукташев кереп, кемгәдер, нәрсәдер эшләргә боерды.

— Барыгыз да цепькә! — дип кычкырды.

Сугышчылар блиндаждан чыга башладылар.

Тукташев Алексейга таба борылды.

— Фриц атака башлар төсле, — диде. — Артподготовка кая, нишләп сузалар, аналарын сатыйм!..— Аның әрнешкән тавышы Алексейның йөрәгенә барып тиде. Ләкин рота командирының ачуын китермәс өчен, тынычландыру сүзләре әйтмәде. Тизрәк чыгып китте.

Немецлар бернинди дә тереклек калдырмаслык итеп рәхимсез аталар иде. Алексей блиндаж янына җайлаган стереотрубага ябышты, ләкин берни күрергә өлгерә алмады, маңгаена бәргән ударлан кинәт чалкан барып төште. Стереотрубага зур ярчык тиеп ваткан иде, ә Алексейга зарары тимәде, бары күз чокыры һәм маңгае бик каты кабарып, күгәреп чыкты.

Кемдер яраланды, ул:

— Туганнар, ташламагыз, туганнар, ташламагыз! — дип кычкыра башлады.

Аны блиндажга алып керделәр. Санитар сугышчыны чишендереп, ярасын эзләп маташты, аннары кул селтәде, яралының авыз кырыйларында кызыл күбек өрелә башлаган иде. Тагы телефон җанланды, тик комбат трубканы алганчы, ул яңадан өзелде. Линиядә Әнвәр белән Шилов, ак күбеккә төшеп, чыбык буенча чапкалап йөрделәр...

Немец атакага килер дип торганда гына, безнең туплар ата башлады. Алексейның эченә җылы керде. Немецның котырынып атуы бераз басылып торган кебек булды. «Катюша»лардан атылган ут «күпере» фрицларга барып тоташты. Ә Ваһапов калган орудиеләрне һаман алып килми дә килми. Бая тынычрак вакытта мөмкин иде, хәзер мөмкин булмаячак.

— Иптәш комбат, телефон! — дип кычкырып, Әнвәр траншеядан абына-сөртенә Алексей каршына килеп чыкты.

— Черняев биредә кала, бүтән орудиеләр сиңа китте, — диде Ваһапов батарея тылыннан.
— Штабның пароле?
— «Тигр»! Алексей, бар радистка, парольне әйт дип, кулы белән Әнвәргә ишарәләде. Әнвәр блиндажның икенче башындагы радист янына чапты. Ул кире әйләнеп килгәндә элемтә өзелгән иде инде. Ишектә орудие командирлары күренде. Алексей бу хәлгә чиксез шатланып, кычкырып куйды. Әнвәр тагын линия буенча йөгереп киткәндә, комбат, командирларны җилкәләреннән кага-кага, яңа позициягә ашыктырды.
Дивизион туплары һәм гаубицалар утны дошманның икенче, өченче траншеяларына юнәлттеләр. Немецлар тарафы, балчык һәм төтен корымы белән күмелеп, күренмәс булды. Анда бер тере җан әсәре калмастыр шикелле иде.
Ярты сәгать буе дошман ягын теткән ут өермәсе, гүләү кинәт тынып калды. Яшел ракета күккә чөелде. Атакага сигнал иде бу. Тукташев үзенең сугышчыларын күтәрде. Алар бөгелә-сыгыла алга омтылдылар. Әмма немец пулеметлары кинәт телгә килде. Каян атканнарын да чамаларга мөмкин түгел иде. Пехота ятарга мәҗбүр булды. Яраланганнар сүгенә-сүгенә кире траншеяга шуыштылар.
Алексей белән Мирхас бергәләп ут ноктaларын барларга керештеләр. Комбат тиз генә прицельне билгеләде. Аннары, ату кайсы орудиегә кулайрак булуын әйтеп, Мирхасны чаптырды. Нусов орудиесе белән ике пулеметны тончыктырдылар, әмма немец тагы яңа «оядан» ата башлады. Монысының урынын билгеләү ансат булмады. Мушков орудиесенә комбат үзе килде, подрамниктан карап, прицельне куйды. Дүрт снаряд аттылар. Шундук орудиене бүтән төшкәрәк күчерделәр. Бер минуттан орудие булган җиргә зур миномет снарядлары килеп төште. Барысы да гаҗәпкә калып, баш селкеп куйдылар.
Кинәт: «Танклар!» — дигән ачы аваз колакларны ярды. Алексей биноклен күзенә китерде. Кечкенә калкулык артыннан дошман танклары чыгып килә иде. Ул сигезне санады. Тизрәк орудиеләрне танкка каршы әзерләргә дип, траншея буйлап чабып китте. Сөенчалинга, Мушковка кычкырып узды.
Сөенчалин бераз каушабрак калган иде. Танк үзенең тавышы белән гүя нервыларны тартып, тәгәрмәченә урый. Менә шушы көтеп тору минуты җанны суыра.
Танкларны якынрак җибәрергә кирәк. Шул вакыт пехота белән рәттән урнашкан кырык бишле орудиеләр ата башлады. Безнең позициягә дә снарядлар төшә иде. Сөенчалин бер чокырга дикъкать итте. Бу — кырык бишле снаряды, дошман танкысына бәрелгән дә, рикошет ясап, биреге килеп ярылган иде.
Танклар якынлаша бирә, кырык бишле орудиеләрнең атуын бар дип тә белмиләр. Сөенчалин күзе белән подрамник окулярына ябышты, танкның сурәтен тотты, куллары маховикны бора иде. Менә ул танкның чылбырына төзәде һәм рычаг элмәген тартты. Снаряд барып житмичәрәк ярылды. Нәрсә бу?! Тагы танкны мушкага алды, аңа гына ышанмыйча, бинокленнән карады.
— Готово? Ну, тиз кыймылда! — дип, коручы Порошинга кычкырды.
Теге исә ташучыны кыздырды.
— Готово! — Сөенчалин рычагны тартты.
Снаряд выжт итеп очып китте. Танкның янында гына шартлады. Зарарладымы? Юк, имансыз, һаман үрмәли әле.
— Подкалибрный! — дип кычкырды Сөенчалин.
Порошин тиз генә казенникка снаряд томырды. Сөенчалин подрамникта танкның зур гәүдәсен тапты да тәгәрмәченә төзәп атты.

— Аха-ха-а! — дип, ят бер тавыш белән акырып җибәрүен үзе дә сизми калды. Ул танкның чылбыры өзелеп, бер якка янтаюын күреп алды. Шунда ук янтыгына тагы бер подкалибрныйны җибәрделәр. Танктан төтен күтәрелде. Шул чак кырыйда гына ике мина шартлады. Сизгер Порошин ату белән мавыгып киткән лейтенантка:

— Иптәш лейтенант, окопка! — дип кычкырды.

Үзе, подрамникны алып, чокырга сикерде. Сөенчалин окопка мәтәлеп төште генә, нәкъ шул минут лафеттан ерак түгел генә өченче мина ярылды. Лейтенант үзенең чак кына үлми калуын күрде, ярчыклар орудиене каезлап-каезлап алганнар иде, Порошинның уңганлыгына иман китерде. Ләкин тагы бер танкның орудиегә таба килүен күреп, алар чокырдан сикереп чыктылар. Порошин прицельне урынына куйды. Подрамникка күзен текәү белән, ямьсез акырып җибәрде. Зур танк хәтәр булып, боларны изәргә җыенган кебек килә иде. Кауша-маска, каушамаска дип, Сөенчалин үзен-үзе кулга алырга тырышты.

— Готово! — дип кычкырды Порошин.

Сөенчалин атып җибәрде, ләкин снаряд танкның нәкъ артында балчык өермәсе күтәрде. Әллә каушадыммы, авызын корт чаккыры дип, Сөенчалин каты сүгенде. Шул аңа көч биргән кебек булды. Тиз генә тагы бер снаряд аттылар. Танк тибрәлеп киткәндәй итте, көпшәсендә ялкын чагылды. Ул каядыр ата иде. Әмма тәгәрмәче өзелгәнен белмичә, кинәт алга омтылырга дигәндә, арты белән болайга борылды да куйды. Бер минуттан, кайсы орудие снарядыннандыр, кара төтенгә күмелде.

— Иптәш лейтенант, окопка! — дип кычкырды Порошин.

Баш очыннан гына снаряд сызгырып узды. Окопка посарга гына өлгерделәр, кырыйда гына снаряд шартлады, боларны балчык, таш белән күмеп ташлады. Әмма исән калдылар. Орудиенең накатнигын зарарлаганын күрделәр. Кай арада Порошин чокырдан чыккандыр, боларны да берәм-берәм тартып алды. Тик кинәт тагы җиргә аудылар, немец пулеметтан атты. «Әллә үттеләрме?» — дип, Сөенчалин әсселесуыклы булып китте. Порошинга карады. Ул инде сизеп тә, күреп тә өлгергән, лейтенантны:

— Самоходкадан ата! — дип тынычландырды.

— Ах, паразит! — Сөенчалин җимерелгән танкларга ышыкланган самоходканы күреп алды. Шул орудиеләргә туры атып сафтан чыгара булыр... Тик аны пушка белән алып булмаячак. Нишләргә? Мең төрле уй яшен тизлеге белән башында чуалды. Соңгару — үлем булачак!

— Алкишев, ике граната ал, самоходканы җимер! — дип, Сөенчалин фаҗигале тавыш белән кычкырды.

Теге солдат шунда ук әзерләнде, әмма китә алмыйча тоткарланды, нидер көткән кебек тоелды. Сөенчалин тагы: «Ну!» дип кычкыргач кына, бруствердан үрмәләп, алга шуышты. Болар тын да алмый күзәттеләр. Алкишев снаряд чокырларына төшеп югалып торды, аннары тагы күренде. Йөз метрлар шуышкач, цельгә шактый якынайгач, аңа самоходкадан ата башладылар.

— Танклар ышыгыннан барырга иде, әх! — дип, Сөенчалин өзгәләнде, сүгенде.

Менә кинәт Алкишевның гимнастеркасыннан әз генә төтен күтәрелгәне күренде.

— Яндыргыч пуля, бетте, бетте! — Сөенчалин кулларын бутый-бутый елаган кебек үкереп куйды. Йодрыгы белән җиргә бәрде, башын төйгечләде, гимнастерка изүен аерып төшерде. Ә самоходкадан һаман пулемет ата, баш күтәрергә дә бирми иде. Сөенчалин, яшьләрен агызган килеш, күзләрен сөртә-сөртә, Порошинга карады. Күзеннән аккан яшь белән битенә балчык буялып беткән иде. Порошин шунда ук барысын да аңлады. Хәзер аңа чират иде. Ул кинәт әллә нишләп, агарып китте,

йөзеннән каны качты, иреннәре калтырады. Тик үзен кулга алды, йөзендә гаепле елмаю галәмәте чагылды. Үзе тиз-тиз генә граната һәм яндыргыч шешә хәстәрләде, әзер булса да, нигәдер юанып, нидер көтте. Аннары сүзсез караш белән Сөенчалинга төбәлеп торды. Сөенчалин карашын читкәрәк алды. Порошин өметсез тавыш белән:

— Иптәш лейтенант, өйгә хат язарсыз! — диде.

Сөенчалин, аның күзе белән очрашудан куркып, Порошин сузган блокнотын алды да кесәсенә тыкты. Икесенең дә мәлҗерәп калуы аңа бик җирәнгеч тоелды. Порошин күзләр очрашуын көтеп, бер минут торды да, түземлеге төкәнеп, алга шуышты. Сөенчалин орудие артына үрмәләп килеп, подрамниктан күзәтмәкче булды, бәлки тагы танк киләдер дип шикләнде. Көтмәгәндә, якында гына каты шартлауны тәне белән тойды, колагына нидер бик нык бәргән кебек сизде. Ул егылды, тик аңа кинәт бик җиңел булып китте. Авыз эчендә тозлы сыекча җыелуын тойды, яраландым бугай, дигән уй миен яндырып узды. «Порошин!» — дип кычкырмакчы иде, канына тончыкты. Күзләрен ниндидер кара, авыр тимер пәрдә каплаган, күз кабакларын һич күтәрә алмый да алмый...

Кинәт беренче орудие янына бер кулы яраланган пехота лейтенанты килеп чыкты. Әллә Мушков күземә күренәме дип, Михеев аңа төбәлде. Орудие яныдарак фугасный шартлагач, алар командирларын җуйганнар иде, гарасат эчендә нишләгәнен белә алмадылар.

— Туганнар, ярдәм итегез, танклар! — дип, еламсырап ялына лейтенант. Михеев җанланып китте, тиз генә прицельгә карап, танкны мушкага алды. Әйе, бу тагы безгә таба килә!

— Үтәш, подкалибрный! — дип кычкыра Михеев. Әхәлсезләнгән лейтенант, сошникка яткан килеш:

— Туганнар, коткарыгыз,— дип ялвара иде.

Михеев бер минут түзәп торды, аннары рычагны басты. Снаряд ничектер танкның астында диярлек шартлады, дөресе, танк шартлау өстенә үзе килеп кергәндәй булды. Михеев танкның зарарлануына ышанмады, тагы мушкага алып, көтте. Кибән хәтле танк туктап калган иде. Икенче карауга аңардан төтен чыга башлады. Бүтән орудиеләр тагы ике танкны җимерткәч, калганнары чигенеп, тау артына күмелделәр. Яралы лейтенант, боларга мең рәхмәт укый-укый, китеп барды. Михеев белән Үтәш исләренә килеп, Мушковның чынлап та юк икәнен хәзер генә зиһеннәрен җыеп аңладылар.

— Үтәш, командир кая? — дип кычкырды Михеев, чөнки аның колагы тонган, ишетми иде.

— Мин син беләсең дип торам!

Алар икәүләп зур бомба чокыры кырыена килделәр, ярыннан төшеп, җыелып торган газлы, кара-кучкыл суга текәлделәр...

Бу сәгатьтә яраланган Мушковны санитарлар санбатка алып баралар иде инде. Башта аны бәйләделәр, аягына жгут салдылар. Менә бүтән яралылар белән бергә, аларны атлы арбага төяп, тылга чыгаралар. Бу тирәне немец еракка ата торган туплардан тетә, шуңа күрә кучер атны чыбыркылап куа, арба бер сикәлтәдән икенчесенә сикерә. Яралылар үләргә житеп сүгенәләр, кычкыралар:

— Әй, кучер, алаша, үтерәсең бит!

— Терелэй суясың, фашист!

— Ах, ах, ах, тукта, тукта!

— Түзегез, җан кисәкләрем! Түзегез, җан кисәкләрем! — дип юаткан була кучер, үзе һаман атларын куа. Яралыларның сикәлтәдән эчләре актарыла. Мушков тешен кысып түзеп бара, янындагы — аларны юатырга тырыша.

Урман кырыена житкәч, кучер атны әкренәйтте, бераздан яшел палаткалар күренде. Барысы җиңел сулап, тизрәк газаптан котылуны өмет итте. Ләкин санбат яралылар белән тулган булып чыкты, аларны кабул итмәделәр. Тагы арбада шалтырарга, авыртудан телләрне чәйнәп канатып бетерергә туры килде.

— Тфү! Мин үләм, туганнар! — диде кайсыдыр.

— Түз, әнә, күренеп кенә тора!

Чынлап та бераз баргач, ак җәймәләр элгән җир пәйда булды. Бу кыр госпитале иде. Кучер, атны туктатып, сикереп төште. Өй кырыенда ак халатлы солдат тора иде. Ул кулларын болгый башлады.

— Урын юк, ары үтегез! — диде солдат юан тавыш белән.

— Әй, ефрейтор булма, урын бар! — Кучер яралыларга төшәргә булыша башлады.

— Юк, диләр сиңа, мин ефрейтор түгел, сержант.

— Ә ефрейтор кебек сөйләшәсең. Кабул ит яралыларны!

— Син русча аңлыйсыңмы, юк, диләр, сиңа!

— Телләнмә, кабул ит! И капут махер!

— Госпиталь тулган! — дип, теге һаман үзенекен туглады.

— Симергән дуңгыз, кабул ит! — дип, кучер кычкырып җибәрде һәм, кызышып, иңеннән карабинын суырып алды да күккә төбәп ата башлады: гөрс! гөрс! гөрс!

Өйнең теге башында ишек ачылды һәм китель өстенә ак халат элгән, чәчен артка тараган бер кеше болар янына йөгереп килеп тә житте.

— Нәрсә бар, нәрсә бар? — дип, куркынган тавыш белән кучерга кычкырды ул.

— Әнә яралылар үлеп ята, ә сезнең бу сасы көзән кабул итми! — дип, кучер теге солдатка ымлады.

— Хәзер үк барысын да кабул итәргә! — дип, әче тавыш белән кычкырды кительле.

Теге санитар шунда ук юкка чыгып торды да носилкалар һәм тагы берничә санитар алып килде. Алар яралыларны арбадан бушатырга керештеләр. Кучер, кәефле мыгырдана-мыгырдана, иркенләп тәмәке суырды.

Алексей Нусов орудиесе янына килеп житкәндә, каты атыш бара иде. Сержант, жиргә тезләнеп, нәрсәдер эшләп маташа иде.

— Нигә атмыйсың? Танклар килә, анаңны сатыйм!..— дип, куркыныч тавыш белән кычкырды комбат.

— Әнә, барысы да яраланды! — дип, Нусов чокырга күрсәтте.

— Әйдә, кор!!

Алексей кабалана-кабалана прицельгә ябышты. Нусовны ашыкмавы өчен өзгәләп ташлыйсы килде. Бер танкны мушкага алып, рычагны тартты. Снарядның кайда, ничек шартлавын күрә алмады. Танк болай таба хәрәкәт итә иде, көпшәсе очында ялкын чаткысы күренде. Алексей тагы бер снаряд атты, әмма танк һаман бирешмәде.

— Подкалибрный! — дип акырды комбат.

— Андый снаряд алырга өлгермәдек, иптәш комбат.

Нусовның ахмакланган сыман йөзен күреп, Алексей сугып җибәрүдән көчкә тыелып калды. Ә танк һаман шуыша. Бераз атмый торырга, көтәргә кирәк! Танк сулгарак борылмасмы дип өметләнде Алексей. Кинәт траншеяда Әнвәр күренде.

— Иптәш комбат, телефонга, штабтан! — диде ул ничектер шатлыклы итеп. Ләкин Алексейның куркыныч йөзен шәйләп кинәт шым булды.

— Нинди хрен, штаб!.. Әнә танк килә, Фазлыев, булыш!

Кинәт төтен эченнән танкның куркыныч зур гәүдәсе килеп чыкты, ул инде берничә метрда гына иде, аның клепкалар пунктиры белән шадраланган борты күзгә чалынып китте. Нусов баскан урынында нигәдер тыпырчына, тешләре шак-шок килә, нишләргә белми, йөгергәндәге кебек итеп таптана. Танк туп-туры орудие өстенә ажгырып килә. Алексей, нәрсә уйларга да белмичә, шулай ук каушамаска тырышып, өсләренә килә торган кара, зур үлемне бөтен тәне белән тоя... Комбатның шулай курыкмый танкны көтеп торуын күргәч, бүтәннәр дә үзләрен ышанычлы тоталар, куркып, чигенергә уйламыйлар, паникага бирелмиләр. «Паника ул командирдан башлана»,— дип уйлый Алексей. «Менә хәзер барысы да хәл ителәчәк! Менә-менә, шайтан алгыры, нигә шул чаклы әкрен килә!..» Орудие алдында яңгыр сулары ерган зуррак кына канау шикелле нәрсә бар иде. Танк шуны чykканда буксовать итеп, хәтәр гүли башлады, ул бер як чылбырында гына әйләнеп корпусы белән сулга таба борылды, бер як чылбыры өскә калыкса да, арты белән тегеләйгә авыша иде, шул чак Нусов беренче граната томырды, танкны коточкыч шартлау һәм төтен сарды, ләкин аның моторы һаман эшли иде әле, бортындагы пулемет атарга тотынды. Алексей җайлабрак тагы бер граната ыргытты, артына чамалабрак җибәрде. Әнвәр дә гранаталар томырды. Бер мәл бөтен нәрсә әллә нинди кара, ябышкак төтен эчендә калды. Танк та күренмәс булды. Нусов тагы бер граната атарга кулын күтәрде. Аның йөзе шундый ачылган, хәтта җыерчыклары язылган, үзе ничектер елмайган кебек иде. Нусов гранатасын атарга өлгердеме, юкмы, шул чак каты шартлау ишетте Алексей һәм шунда ук аңын югалтты. Аның өстенә ниндидер авыр нәрсә ишелеп төште, ахрысы, күкрәген нәрсәдер хәтәр кыса, ул кыскан нәрсәне үзеннән алып, умырып атмакчы, ләкин кулларын урыныннан кузгата алмый. Ул каядыр, гүя клеткага утырып шахта төбенә, түбәнгә төшә дә төшә. Бу шахтаның төбе юк микәнни? Шахта төбендә һава юк, менә шуңа минем тыным бетә икән, бу нинди төпсез шахта соң? Ул һаман караңгы базга төшә дә төшә. Ә кулларны кем бәйләп куйган, кулларны бәйләп төшерәләр микәнни? Нишләп бу базның бөтен җире дә караңгы, нишләп бу җәһәннәм базының төбе юк? Күкрәкне нәрсәдер бик әшәке итеп тырный, төшкәндә боз кырыйларына тән сыдырылып канаган шикелле...

Нәкъ шул вакыт «Кыз» биеклеге итәгеннән безнең танклар килеп чыктылар. Немецларның пехотасы артка чигенә башлады, исән калган танклары да кире якка борылды. «Хатын» биеклегенә атака ясаучы танклар артыннан Тукташев үзенең сугышчыларын күтәрде.

Немецлар юлга пулеметчылар калдырып чигенәләр. Алар, нәкъ харакирилар шикелле, безнекеләрне тоткарлап торалар. Бер шундый немец пулеметчысын ала алмый озак маташтылар. Тукташев аны әйләнеп үтеп, тылына төшәргә кушты һәм шунда ике сугышчыны җибәрде. Теге фриц үткен булып чыкты, аларны шунда ук яралады. Солдатлар, канга батып, ул җирдән көчкә чыктылар. Тукташев үзе тәвәккәлләде. Ул куркуның нәрсә икәнен дә оныткан, бүген әллә ничә үлемнән калып, ничектер үзенең үлмәслегенә ышанган кебек иде. «Эх, гомер — кара күмер!» — диярга ярата иде ул. Немец хәйләкәр, димәк, аңардан да хәйләкәррәк булырга кирәк. Тукташев яңадан ике сугышчыга пулеметчының дикъкатен башка җиргә юнәлдерергә боерып, үзе бер ерганак чокырыннан, кue үлән эченнән тегеңә таба үрмәләде. Безнен сугышчылар фрицның сул флангысынарак төшеп ата башладылар. Немец үзенең утын шуларга юнәлтте. Тукташев ерганак буенча түбә башына чаклы менеп, фриц яткан окоп турысы белән тигезләште. Ләкин аның үзен һаман шәйли алмады. Аңа табарак чамалап шуышты, шул чак кына тегенең каскасы кыймылдап куюыннан искәреп алды. Әһә! Монда икән! Яткан килеш пистолетын алып төзәде, ләкин үзенең каушаганлыгын, йөрәгенең чиксез еш типкәнлеген кулының калтыравыннан сизеп, туктап

калды. Тынычланырга кирәк! Бер минуттан үзен кулга алды һәм тегеңә атып җибәрде. Аңа тиюе дә бу юлы әһәмиятле түгел, фрицка үзеннең биредә икәнеңне белгертү бик мөһим...

Теге шунда ук борылып карады бугай, каскасыннан шулай беленде. Тукташев шул минутта аңа тагы атты. Бу юлы фриц шактый борсаланды, борчылды, атышның каян булуын чамаларга маташты, бераз күтәрелә төшеп, артына борылып карады. Тукташев аның йөзен күреп калды, ләкин тиз генә ата алмады, ә немец атарга өлгерде. Тукташев цельне бераз түбәнгәрәк алып атты, шул чак: «А-а-а-а!» — дигән карлыккан аваз килде. Тукташев, ахры, тигердем дип, күтәрелеп караган гына иде, кинәт каскасына бәрелгән пулядан башын түбән төшерде. Вәт шайтан: яраландым, үлдем дип хәйләли.

Тукташев чак кына шуңа гомерен корбан итми калды. Ярый — сабак булыр. Ул песи кебек үрмәләп, кулына иркенләп төзәргә мөмкинлек бирде. Фриц каскасының бер кырые күренә иде, ул аскарак төбәп чакмага басты. Фриц җавап бирмәде, тавышы да ишетелмәде, әллә дөмектеме дигән уй башыннан йөгереп узды. Яшел үләннәр, куаклар арасыннан яшел касканы аерып булмый, озак чекерәеп караганга күз әлҗемәлҗе килә иде. Тукташев үрелеп караудан чак тыелып торды. Биредә чыдамлылык хәл итә. Берничә минут шулай түзеп тордылар, кем беренче булып нервысын җуяр? Тукташев кыймылдап куйды, немец шунда ук селкенгән үләннәргә төбәп атып җибәрде. Пуля Тукташевның беләген яралады. Беләкне утлы чыбык кебек пешереп, каны акканы беленде. Бәхеткә, әле сул кул итен генә яралаган. Тиз генә пакет алып, аны бәйләп куйды. Немец пулеметтан атарга керешә. Гаҗизләнгән Тукташев аңа таба берничә метр шуышып барды. Граната алды, аның запалын кесәдән чыгарганчы бик озак вакыт узган кебек тоелды. Ниһаять, гранатаны яткан көе бөтен көченә аңа таба томырды. Шартлау көтелмәгәнчә булды, ахры, фриц кинәт үзенең окобын ташлап, чигенү ягына йөгерә башлады. Тукташев шунда ук аңа атып җибәрде, теге алга таба мәтәлеп барып төште, ләкин бер минуттан парабеллум белән Тукташевка атарга тотынды.

Тукташевның үлеп су эчәсе килә иде, нишләргә? Берәр сазлы җир дә юк, ичмаса. Нишләп безнекеләр килми икән, инде пулемет атмый бит! Юк, тегендәрәк тагы бер фриц пулеметчысы ата бугай. Флангысына төшәргә иде!

Тукташев пистолетына яңа обойма куйды. Кем кемне җиңәр?! Тормышта да шул мәсьәлә аның алдына килеп баскалады, ул чакта Тукташев җиңәргә тырышмады, тавыш кына булмасын дип җиңелүче булып калырга риза була иде. Хәзер аның бу дошманны бик җиңәсе килә. Эх, ничек итеп? Ул үзенең көче бетә баруын сизде. Әһә, немец янындагы үләннәр кыймылдады, Тукташев шул җиргә төбәп тагын атты. Немецның ухылдаганы ишетелде, юк, бусы провокация түгел иде. Лейтенант аның эчен яралаган иде. Тукташев та ухылдады. Нигә безнекеләр килми? — дигән сорау миен бораулады. Күзне тозлы тир ачыттыра, Тукташев аны бәйләгән беләге белән сөртеп-сөртеп ала иде.

Ниндидер бер мизгелдә фриц янындагы үләннәр тагы селкенеп китте, караса, аңа таба туп-туры олы бер кызыл чырай чекерәйгән иде. Фриц та Тукташевны күреп алды, бер секунд эчендә аларның күзләре очрашкан кебек булды. Ара утыз-утыз биш метрдан ким түгел иде. Тукташев аңсыз рәвештә пистолетының мушкасын күзенә тигезләде, фрицның да кулы күтәрелгәне күренде. Тукташев чакманы басты, ләкин шул вакыт кинәт нидер булды, маңгаена нәрсәнеңдер бик каты итеп сукканын сизде, аннары берни дә тоя алмады. Ул хәйләләп калмакчы булган якты дөнья йөзе аның өчен мәңгегә югалды...

Михеев солдатлар белән килеп җиткәндә, Тукташев үлгән, кулы пистолетын тоткан көе катып калган иде. Берничә метрлар арырак

немецның да үле гәүдәсе аунап ята, каскасы башыннан тәгәрәп төшкән, чигәсеннән пуля кергән жиргә кан оешып, кара нокта булып тора. Фриц гәүдәсеннән әшәке одеколон исе анкый, чыдап торышлы түгел иде. Михеев аны күн итегенең башы белән төртеп әйләндерде дә Тәкәнаевкә документларын алырга кушты...



## 14

Немецларның оборонасы тузгытылды. Алар чигенү юлында төтен шашкалары яндырып калдыралар иде. Төтен пәрдәсе буйдан-буйга бөтен офыкка эленде. Бу зур чигенү билгесе иде. «Хатын» биеклегенә пехота бәреп кергәч, фрицлар каршылык күрсәтүне бөтенләй туктаттылар. Төтен пәрдәсе артына яшеренеп, алар авыр коммуникацияләрен күчерәләр. Әмма безнең самолетлар тынгы бирмиләр, эзәрлекләп, баш очларына пулеметтан ут яудыралар иде.

Ләкин һөҗүм вакытында немецларның өч самоходкасы ничектер безнең тылга үтеп чыккан. Алар ак чиркәүгә урнашкан армия госпитале янына барып җиткәннәр.

Семен Израилович белән Фира бер яралыга операция ясарга әзерләнәләр иде. Менә сестра яралының йөзенә ике катлы марля каплады. Семен Израилович яралыга сораулар бирә, яралы җавап кайтара:

— Тәмәке тартасыңмы?

— Тартам.

— Аракы эчәсеңме?

— Булса, эчәм.

— Берьюлы күпме эчә аласың?

— Алты йөз грамм, кайчак артыграк.

Бу диалог сестра өчен мөһим, ул наркоз дозасын билгеләү өчен кирәк. Аракы эчкән кешене аз доза гына йоклата алмый, аңа күбрәк бирергә туры килә.

Сестра наркоз сыекчасын яралының борын турына марляга тамыза башлады. Марляның шул төше куе сары төскә керде.

— Сулагыз,— диде сестра яралыга, аннары бер минуттан тагы дәште: — Санагыз!

Яралы:

— Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...— дип санарга кереште һәм санаудан туктап, йоклап китте.

Врачлар, сестралар кинәт хәрәкәткә килеп, кулларына тиз-тиз инструментлар алдылар. Семен Израилович, тизрәк булырга кирәк дип, Фирага ымлады. Яралының тәненә үткен пычак килеп керде... Кетмәгәндә кинәт ут сүнде, икенче минутта биек тәрәзә пыялалары коелып төште, стена җимерелеп, кемнедер яралады, ул кеше коточкыч тавыш белән кычкырып җибәрде. Караңгыда буталыш, кычкырыш китте. Семен Израиловичның каты тавышы ишетелде:

— Каушамаска, немец кукурузниклары налеты! — ди ул. Ләкин бомба шартлаган тавышлар ишетелмәде. Кемдер, движоктагы механикмы, астан кычкырды:

— Безне немец танклары чолгап алды?! — Ул кесә фонаре белән яктыртып, Семен Израилович янына килде һәм тыны бетеп, төсе-өне китеп, шул фаҗигале сүзләрне кабатлады.

Чиркәүнең гыйбадәт кыла торган залында яралылар хәтсез иде, алар өстенә тәрәзә рамнары, стена ватыклары җимерелеп төшә башлады. Яралылар бик каты сүгенеп кычкырыналар. Семен Израилович нишләргә белми, әле монда, әле тегендә барып сугыла иде. Ул:

— Барыгыз да подвалга, яралыларны подвалга! — дип боерык бирде дә, Фира янына килеп, таяныч эзләгән кебек аңа тотынды.

— Фира Касимовна, ничек итеп булса да берәр частька хәбәр итәргә кирәк!
— Ә биредән ничек ычкынырга?
— Элемтәне өзгәннәр. Движокны ваттылар,— диде механик фаҗигале тавыш белән.
— Ә частьлар кайда соң? — дип төбәлде Фирага икенче хирург. Әллә аның комбат белән булган мөнәсәбәтеннән чыгып шулай сорыйлар инде?
— Механик, берәр чыгу юлы тап! — дип үтенде Семен Израилович, аның иреннәре калтырый, тешләре тешкә бәрелә бугай, тавышыннан шул сизелә иде.
— Каберлеккә чыга торган арткы юл бар бугай.
— Соң?! Мин яралылар белән калам! — Семен Израилович Фираның беләгеннән кысып, механик белән бар, дип ымлады.
— Әйдә, киттек! — дип кычкырды Фира кырыс кына. Механик кесә фонаре белән юлны яктыртты. Фира аның артыннан йөгерде.
Алар бәрелә-сугыла әллә нинди тар баскычлардан үттеләр. Механик уңган, җитез егет булып чыкты. Абынырлык, бәрелерлек әйберләр очраганда Фираны кисәтә-кисәтә атлады. Лычкылдап суланып торган стеналарга ышкыла-ышкыла шактый бардылар, бик озак вакыт үткән кебек тоелды. Алар, өскә алып менә торган баскычка килеп җитеп, тыңланып калдылар. Якында гына немецның чигенгәндә ата торган зур снаряды шартлады. Механик кабаланмый гына баскычтан менде, бераздан ишекне тибеп ачты, тышта әле караңгылы-яктылы, шулай да әйберләрне ачык күреп була. Әмма якында гына самоходкаларның мотор тавышлары ишетелеп тора иде. Кайсы якка юнәлергә? Фрицлар күрмәсләрме?
Фира механикның җиңеннән тартып, кирәкле тарафны күрсәтте. Теге исә, башта мин йөгереп узыйм, аннары син дип, куллары белән аңлатты. Һәм, иелеп, муенын җыерган хәлдә йөгереп тә китте. Кинәт немец автоматы тырылдап алды, егет нәрсәгәдер абынган шикелле, алга сөрлегеп, кабер ташлары артына барып төште. Фира күренү секторыннан читкә, каберлек эченә ыргылды, кабер ташларына, агачларга ышыкланды. Егет болай гына егылгандыр, немец утыннан ычкынырга җай көтеп ятадыр, килеп җитәр, дип чапты да чапты... Итәкләре кайдадыр эләгеп умырыла, аяклары бәрелә, суела, ләкин ул аны тоймый иде.
Бу вакытта немецлар чиркәүне ватарга, җимерергә керештеләр. Тәрәзәләргә гранаталар томыралар, котырган ерткычларча, ишекләрне каерып, залга уздылар, анда госпиталь әсбапларын вата-кыра кинәнәләр иде. Бөтен җирне туздырып, актарып йөрделәр. Подвалның тимер ишегенә гранаталар ыргытып ваттырып карадылар, әмма ишекләр берничә кат тимердән эшләнгән булганга, анда үтә алмадылар. Ахырда стенаны граната белән шартлатып, подвалга самоходкаларының янган газ төтене торбаларын тоташтырдылар. Шулай итеп яралыларны агулап үтерергә ниятләделәр.
Подвалдагылар башта моның нинди мәкер икәнен белмәделәр. Семен Израилович та чарасыз калды, башы чатнап юеш идәнгә ауды. Тазарак яралылар миңкеп, үз-үзләрен белештерми кычкырыша, ыңгыраша башладылар. Кайбер җегәрлерәкләре урыннарыннан торып, тилергән кеше кебек, хәтәр тавышлар чыгарып, бүтәннәрне таптап, изеп йөрделәр. Аларның коточкыч булып акайган күзләре караңгыда үлем урагы шикелле ялтыратып китә иде. Кайберләре җан ачысы белән бер-берсенә ташлана, берсен-берсе йолыккалый, каядыр омтыла, ачы аваз чыгарып, хәлдән таеп ава да тынып кала. Кемдер ялвара:
— Сестра, сестра, үлә-ә-әм...
— Иптәш врач, мине ташлама, мине ташлама!..
— Иптәш, иптәш, без кая барабыз? — дип кайсыдыр саташа.

Бермәл подвал эче тоташ ыңгырашуга күмелә. Хәллерәк ике врач ишекне ачмакчы булып бикләрен ычкындырырга маташалар иде. Күп азаплана торгач, беренче кат ишек ачылды, берсе хәлдән таеп, ишек тоткасына ябышып тынып калды. Икенчесе дә көче бетеп идәнгә чүгәләде. Тагы ыңгырашу, үрсәләнү авазлары ишетелеп куйды, аннары бер минутка үлем тынлыгы урнашкан кебек булды. Бераздан соң әлеге врачлар исләренә килеп, бикне тагы каерырга тотындылар, ә үзләре, әйдә, атсыннар, сволочьлар, дип кычкырыналар иде.

...Ваһапов батареяның калган орудиеләре һәм хуҗалыгы белән Грехово авылына барырга приказ алды. Алгы сызыктагы орудиеләр дә шунда очрашырга һәм икенче эшелонга чыгарга тиешләр. Машиналарга төялеп китәргә торганда, Фираның төссез-өнсез кыяфәттә килеп егылуы барысының да башына суккан кебек тәэсир итте. Җитмәсә, комбатның хәле дә билгесез иде.

— Алексей Егорыч кайда? — диде ул, чирәмгә ауган җиреннән башын калкытып.

Ваһапов шомланып калды, Алексейның югалуын әйтсә, хәтәр генә булачак. Фира көчкә тынын җыеп:

— Ак чиркәүдәге госпитальне немец танклары чолгады, тизрәк коткарыгыз! — диде.

— Ничек?! Немецлар чигенә бит!

— Самоходкалар...— Фираның тыны кысылды.

— Әһә, тылга үтә алганнар! — диде Черняев.

Ваһапов шунда ук боерык бирергә тотынды.

— Барча расчетлар минем белән! — дип кычкырды ул.

Шофер Фираны кабинкага утыртты, барысы да китәргә әзер иде. Старшина, Ваһапов машинасына барып, нәрсәдер әйтте дә таптанып торды. Ваһапов аңа хуҗалык белән әлеге хуторга барырга, шунда батареяга кушылырга әйтте, һәм машиналар кузгалып киттеләр.

Ярты сәгатьтән ак чиркәүгә якынлашып, орудиеләрне позициягә урнаштырдылар. Окоплар казыган арада ак чиркәү ягыннан болайга таба якынлашып килгән мотор тавышлары ишетелде. Сугышчылар сагаеп калдылар. Ерак түгел куаклар арасыннан аксыл төстәге самоходка көпшәсе күренде. Ваһапов кинәт кычкырып, орудиегә ташланды. Черняев сулдарак иде, ул элегрәк шәйләп өлгергән, танкны прицельгә алып, маховикны борып маташа иде. Менә ул кулын алга таба төшерде, атучы рычагны басты. Снаряд танк янында гына шартлады. Танк туктап калды.

Ваһапов, орудие калканына ябышып прицельне төгәлләгәч, сугышчыга:

— Рычагны тарт! — дип кычкырды. Аларның снаряды танк арты-нарак төште. Бераз чиркәнчек алган кебек булдылар. Шоферлар һәм Фира снаряд ташырга керештеләр.

Ваһапов яңадан төзәде һәм башняга атудан мәгънә юк дип, танкның янтыгын чамалады. Инде каушавын җиңеп тынычланырга һәм төгәл төзәргә өлгергән Черняев та шулай итә булса кирәк. Аның икенче снаряды танкның сул ягында гына балчыкны актарды. Шул чак самоходка атарга тотынды, снарядлар җан өзгеч тавыш белән сызгырып баш очыннан гына уздылар, аз гына арттарак шартладылар. Икенчесен безгә туры тидерәчәк, дип уйлады Ваһапов һәм орудиене куак артына ыкү җиргәрәк күчерергә боерып, үзе дә тәгәрмәчләренә тотынды. Икенче танк та ата башлады. Орудиене бер егерме адымга янгарак күчереп кенә өлгерделәр, нәкъ иске урынга снаряд килеп төште. Беребез дә калмый иде бит, дигән уй Ваһаповның миен кисеп үтте. Ничек төгәл бәрә, чукынган!..

Черняев расчеты да, орудиене күчереп, бер залп бирде. Ләкин танкларга болай мәгънәсез атып файда чыкмаслыгын Ваһапов сизеп алды һәм бер минутка атуны туктатты. Әллә гранаталар белән шуышып барыргамы? Шулай уйлап, ул танкның берәр якка борылуын көтте. Әмма танк урыныннан кузгалмады. Черняев тагы үзенең расчетын җигеп орудиесен күчерде, ул танкның ян ягынарак чыкты. Тиз-тиз прицельне рәтләп атып җибәрде. Тидерә алмады, снаряд арырак очты. Иртәнге һава салкынча һәм дымлы иде, моны дистанцияне алганда исәпләргә кирәк. Бер минуттан икенче снаряд танкның кырыенда ук шартлады. Әллә зарарландымы?

Ваһапов икенче танкка ата, ләкин һичничек ала алмый, снарядлар аның башнясына бәрелеп, рикошет ясап янга китәләр иде. Нишләргә? Танкның аксыл сыны һаман кукраеп, үчекләп тора. Тагы орудиене күчереп маташканда, янда гына гөрс! итеп снаряд шартлады. Сугышчылар җиргә аудылар. Ваһапов балчык тулган күзен тырмап ачканда, бер сугышчының аягы тубыгыннан яраланган, икенчесе күн итеге-ние белән өзеп ыргытылган иде. Кунычы эченнән торбадан аккан кебек кан ага башлады. Фира чабып килеп кабалана-кабалана аны бәйләргә тотынды, бераз исенә килә башлаган сугышчыны тынычландыру өчендерме:

— Куркыныч түгел, исән калуыңа сөен,— дип сөйләнде.

Шул вакыт танк кузгалганы күренде. Черняев аның түбәрәк урынга житүен прицельгә карап көтеп торды да тәгәрмәч чылбырына атып җибәрде. Бу юлы ату уңышлы чыкты. Танк урынында зырылдап бер якка түнкәйде, тик әнә шунда да пулеметтан сиптерүен туктатмады.

Ваһапов сугышчылар белән орудиене күчереп маташканда икенче танкның да китеп барганын шәйләде. Тиз генә лафетларны җиргә кададылар. Ваһапов бик хасиятләп төзәде, аннары замок янына тезләнгән сугышчыга: «Рычагны тарт!» — дип кычкырды. Их! Снаряд барып житмичә шартлады. Прицельне җайлап, тиз генә тагы бер яндыргычны аттылар. Көтмәгәндә танктан кара төтен күтәрелде. Кемдер:

— Люктан чыгалар! — дип акырып куйды. Автомат очередьлары сызылып, типчеп-типчеп үтте. «Ура» кычкырган авазлар яңгырады,— нindидер часть солдатлары ярдәмгә килгәннәр бугай. Автоматларын алга юнәлтеп, танк янына таба омтылмакчылар иде, әмма ятарга мәҗбүр булдылар. Чөнки самоходкалар пулеметлардан бик каты хәнҗәр-ут ачтылар.

— Стой! — дигән команда ишетелде.

Моны Ваһапов кычкырды. Ул, танкны граната белән генә шартлатырга мөмкин, дигән фикергә килгән иде. Барысы да җиргә сыендылар. Немец болай гына бирелмәячәк. Яна торган самоходка немецлары да чыгып, икенче танкка сыенганнар булса кирәк.

Черняев Мурзыевны граната белән танкны шартлатырга җибәрергә ниятләде. Булдыра алырмы, дигән шик белән икеләнеп торды да, бар, дип кулы белән ишарә ясады.

Ваһапов Мурзыевны туктатып, өйрәтеп, киңәш биреп маташты.

— Замполит, алай булмый, аны тоткарламагыз,— дип кычкырды Черняев.

— Нигә булмасын?

— Турыга барып ни тоҗырасың?

— Мин дә турыга дип әйтмим.

— Иптәш капитан, миңа рөхсәт итегез! — дип, яңа пополнениегә килгән, әле Ваһапов танырга да өлгермәгән бер сугышчы басып тора иде.

— Рөхсәт, бар!

Сугышчы Мурзыев артыннан чапты һәм бераз баргач куакларга күмелде.

— Ну, нигә, иптәш капитан? — Черняев тагы бер сугышчы җибәргәнгә каршы килеп, Ваһаповка ачуын белгертте.
— Икәү кыюрак булырлар.
— Немец тизрәк күреп алыр, шул гына.
— Юк, син, Черняев, ялгышасың.
Черняев сүз кайтармады. Көтәләр... бер минут, ике минут... Мурзыев инде танкка якын булырга тиеш, ләкин шартлау юк та юк. Үзем генә барасы калган икән, дип уйлап куйды Черняев. Кинәт шул вакыт тагы «Ура-а-а» яңгырады. Самоходка пулеметы атудан туктады. Ваһапов нишләргә белмичә Черняевка карады, үзе беренче булып хәлне аңларга һәм карар кабул итеп боерык бирергә тели иде. Тик өлгерә алмый калды, ә Черняев әнә барысын әллә каян белеп тә алган.
— Киттек, теге танк пленда,— диде Черняев һәм сугышчыларны үз артыннан ияртеп чиркәүгә таба китте. Уйсулыктан күтәрелү белән барысы да күрделәр: аксыл-сары танк, ә тирәсендә — солдатлар.
Мурзыев белән теге сугышчы танк башнясына менеп басканнар да нәрсәдер кычкыралар. Мөгаен, танк эчендәге немецлар бирелергә теләмиләрдер. Сугышчылар немецча сүзләр кыстырып сүгенәләр, шатланып киләнәләр.
— Сез җимердегезме теге танкны? — диде бер лейтенант, Ваһапов каршысына килеп.
— Без, ә нәрсә булган? — диде Ваһапов, берни аңламыйча, шундый каты арыганлыгын хәзер генә тоеп.
Ниһаять, күп тавышлана торгач, люк ачылды, немецлар кулларын күтәреп танктан чыктылар, шунда ук аларны урап та алдылар.
— Кайсы часть? — дип, лейтенант һаман сораша бирде.
Ваһапов җавап кайтарды да үзе дә кызыксынып:
— Дүртенче самоходка кая? — дип сорады.
— Анысы качкан бугай,— диде лейтенант, һәм аны кемнәрдер чакырып алып киттеләр.
Черняев Мурзыев белән теге сугышчыны кыздыра, нигә шартлатмадыгыз, дип тиргәп тора иде.
— Граната атарга пехота комачаулады,— диде Мурзыев гаепле кеше шикелле. Черняев кулын гына селекте.
Ваһапов тизрәк машиналарга утырырга, орудиеләрне тагарга боерык бирде.
Ике сугышчы теге яралыны күтәреп госпитальгә илтеп маташа иде. Аның битләре эчкә баткан, күз тирәләре көеп чыккан иде. Ваһапов аны таныш врачларга күрсәтергә һәм шуның белән аның хәлен җиңеләйтергә ниятләп госпитальгә таба атлады.
Шул вакыт чәче-башы тузган Фира күренде. Ул коткаручылар белән бергә подвалда агуланган яралыларга ярдәм күрсәтә икән.
— Кайберләрендә өмет тә калмаган,— ди Фира, күзләреннән яшьләре агып төшкән, сүзләре дә пыскып кына чыга иде.
— Агулаганнар, ерткычлар,— дип кычкырды кемдер.
Берничә врач һәм сестраның хәлсезләнгән гәүдәләрен алып чыктылар. Ярдәмгә килгән врачлар аларга укол кадыйлар, нашатырь спирте иснәтеп, палаталарга озаталар.
Фира, Ваһаповның китәргә итүен күреп, җилкәсенә барып тотынды.
— Алексей кайда соң? — дип, аның йөзенә текәлде.
Ваһапов ни әйтергә белми аптырап, каушап кала язды, ләкин үзен шунда ук кулга алды:
— Ул алдагы частьлар беләндер.
— Син аны тәгаен күрдеңме?
Ваһапов комбатның һөҗүм вакытында югалуы хакында белгән иде, ләкин аңарга бер дә ышанасы килмәде. Алексей Нусов орудиесендә

булган, яннарына зур снаряд төшеп шартлаганнан соң аны таба алмаганнар. Фираның йөзенә карагач, шул хакта әйтергә теле бармады.

— Күрдем, исән-сау,— диде Ваһапов һәм сүзе ышандырырлык булсын өчен Фираның җилкәсеннән какты.

Фира тынычланган кебек булды. Ваһапов аның белән дусларча саубуллашты да госпитальга кереп китте. Ул әйләнеп чыкканда, машиналар, орудиеләрне тагып, аны көтеп торалар иде. Алар юлга кузгалдылар.

...Римма һөҗүм вакытында сортировочныйда яралыларны бәйләп, беренче ярдәм күрсәтеп, алны-ялны белмәде. Яралылар шактый күп иде. Авыр хәлдәгеләрен шофер белән машинага төяп тылга илтеште. Шулай тылга билгеләнгән яралыны алырга кергәч, Римма, палатка идәнендә комбат гәүдәсен танып, шаккатып калды. Баш врачка чабып барып, комбатка хәзер үк ярдәм күрсәтүне үтенде. Баш врач Алексейның таныш кешесе иде, шунда ук үзе килеп карады, укол кадады.

— Куркыныч юк, ул бераз гына контужен бугай,— диде. Римма Алексей яныннан китмәде, әллә ничә кат, беләзегеннән тамырын табып, пульсен санады. Бераздан комбат күзен ачты һәм үзе өстенә иелгән матур йөзне, кара күзләрне күреп, әкрен генә торып утырды.

— Хатантаева, мин кайда? — дип кычкырды ул, ләкин үзенең тавышын ишетмәде.

— Алексей Егорыч, сез санбатта.— Римма аны йомшак кына итеп урынына кире яткырмакчы булды. Комбатның торырга азаплануын күреп, аның контужен булуын һәм ятарга кирәклеген аңлатты.

Комбат Римманың сүзләрен ишетеп җиткермәде, урыныннан торып басты, башы бик нык чатнап авырта, муены һич тә борылмый, катып калган иде. Нәрсә булды миңа? Ә батарея кайда? Мин ничек бирегә эләктем? Әһә, бервакыт каядыр түбәнгә очып төшеп барам кебек булган иде. Мине бирегә шушы кыз алып килде микәнни? Мин бит яраланмаган, тап-таза. Ник ул мине санбатка алып килгән? Миннән башка анда ничшләп беттеләр икән? Хәтерендә: Тукташев солдатлары атакага күтәрелделәр, ул Нусовка цельне ераккарак алырга әйтеп, Сөенчалин орудиесенә барырга теләгән иде. Ә аннан соң нәрсә булды? Юк, хәтерли алмый. Нәрсәдер башына бик авыр әйбер белән китереп суккан шикелле булды бугай...

Римма нәрсә әйтергә, ни кыларга белми гаҗизләнгәндә, баш врач тагы килде һәм аларны үзе янына алып керде.

— Коля, нәрсә булды, ник мин биредә? — диде Алексей ялварып.

Врач аны чишендереп карады. Ахырда кат-кат уң як муен тамырын баскалады, Алексей җилкәсен җыерды, сискәнде, шул төше бик каты авырта иде. Врач шаркылдап көлеп җибәрде.

— Йокы артериясенә арыган ярчыкмы, ташмы тигән, шул сине саңгыраулаткан, һушыңнан яздырган.

— Мин ишетмим, Коля, ишетмим, кычкырыбрак әйт,— дип акырды Алексей, колагы ишетмәгән кешенең ни өчен кычкырып сөйләшүен сизеп.

— Римма, капитанга өч доза кофеин, тизрәк! — дип боерды баш врач.— Алеша, хәзер барысы да рәтләнер.

Алексей һаман башын селкеп утыра, мине бирегә кем китерде икән, дип хәтерен җигеп азаплана... Римма аңа дару эчерде, аннары врач конус микстура белән спирт бирде дә ашыгып чыгып китте. Чынлап та, бу врачлар могҗиза тудыручылар бугай, бераздан Алексей кеше кыяфәтенә кереп, шактый үк ишетә дә башлады.

— Мине син китердеңме, Хатантаева? — Алексей, һаман ишетмәм дип куркып, кызның авызына карады.

— Юк, мин түгел. Мин күргәндә сез бередә ята идегез,— диде Римма, йөзенә гаҗәпләнү билгеләре чыкты.

Шул чак тәэсирле һәм шатлыклы кыяфәт белән баш врач каяндыр кайтып керде:

— Безгә алга күчәргә приказ, безнекеләр Опочканы алганнар, дошман туктаусыз чигенә,— диде ул, капитанның җилкәсенә кулын куеп.

— Коля, мине кем китерде?

— Ә-ә, миңа старшина сөйләп торды, сине ике яшь кенә пехотачы китергән. Командирны коткарабыз, ут эченнән алып чыгабыз, дигән булып, үзләре ут эченнән тизрәк шылу ягын караганнар. Ул аларны бик каты ачуланган.

— Комбатны яраланган дип белгәннәрдер? — Римма аптыраулы тавыш белән әйтте.

Алексей бер сүз дә дәшмәде, аның башында әле һаман «тәртип» урнашып җитмәгән иде бугай. Ул арада баш врачны дәшеп алдылар. Алексей, хәзер үк батареяга китәргә кирәк, дигән карарга килде.

— Югалтулар күпме? — дип Риммага текәлде.

Кыз берничә яралыны әйтте, алар орудие расчетыннан иде. Туры наводкага куймасалар, югалту әзрәк булган булыр иде дип уйлап алды Алексей.

— Тәк,— дип, Алексей торып басты.— Тизрәк батареяга! Кая безнең машина?

— Нунау, мөгаен, батареяга хәбәр иткәндер. Көтәргә кирәк.

— Юк, көтеп ятарга мөмкин түгел.

Алексей, китәргә ниятләп, ишеккә таба атлады, баш врачтан машина алып булыр микән дип уйлады. Әмма палатка ишеге кыштырдады да бусагада кинәт бер сугышчы калкып чыкты:

— Мулла, синме? — Алексей үз күзләренә ышанмыйча торды.

— Сезне алырга килдем, Алексей Егорыч...

— Яралангансың дип торам, безнекеләр кайда?

— Немец элдерә генә, пехота да куып җитә алмый. Безгә Опочканы чыккач, тупланырга приказ. Замполит шулай әйтте.

— Киттек, ну, молодец, ну, рәхмәт,— ди-ди Алексей шатлыгыннан өтәләнде генә. Чыкканда Риммага таба борылып караса, кыз өстәлгә башын салган килеш йоклап киткән иде. Алексей аңа кулын селтәде.

Алар машинага утырдылар. Бу вакытта таң атып килә, офыкка тасма-тасма кызгылт пәрдәләр эленгән иде...

Бераздан санбат та юлга җыена башлады. Барча яралыларны тыл госпитальләренә озатып бетерделәр. Ләкин Яким Зиновьевич Сергейны тагы алып калды. Тиздән аңа орден кайтырга тиеш икән, егетне шуның белән сөендерергә телиме, әллә бүтән сәбәп бармы, тик майорның Сергейдан аерыласы килми иде. Ул аны тәҗрибәле врачлардан каратты, тик егетнең ярасы бөердә бик тирән, пулясы да эре калибрлы булган. Шуңадырмы, бер дә хәле алга бармый шикелле.

Ә Сергей үзе рухы белән һич тә бирешми әле. Ярам төзәлгәч, Яким Зиновьевич мине офицер итә, туган шәһәремә яшьләр белән очрашырга җибәрә, аннары немец тылына разведкага барырсың, ди. Хәзер мине анда бик көтәләр инде, әнигә дә әйткәннәрдер, ә мин бирәдә «кызынып ятам», дип сестраларга һаман сөйләнә ул.

Менә Сергейны йомшак носилкага яткырып, бөркәүле машинага куйдылар. Санбат Опочка шәһәрен узып китеп, бер елга буендагы урманга барып урнашырга тиеш иде.

Римма аның янына утырып барды. Егетнең күзләре зураеп, монсуланып калган, ә күз кырыйлары сызык кебек көеп тора иде.

— Римма, син мине каһәрләдең инде, ә? — диде ул ягымлы тавыш белән. Кыз нәрсә әйтергә дә белмәде, чөнки Сергей, синең рәнҗешең төште, дигән кебегрәк итеп аңа карап алды.

— Юк, ник инде алай дисең?!
— Мин бит син уйлаганча ук начар кеше түгел, Римма.
— Беләм. Һич тә сине алай дип исәпләмәдем.
— Теге чакта ничек алама килеп чыкты бит...
— Үткән — беткән инде, Сережа!
— Мин сине шулай үземә караткмакчы идем, Римма, чын. Сиңа тилереп гашыйк булдым. Ә син аңларга да теләмәдең.
— Гашыйк булу бит, Сережа, үтә торган нәрсә, өермә кебек, бер котырына да үтә ул.
— Минеке үтмәде, һаман давыл кебек көчәя барды.
— Үткән булыр иде, сабырлык кирәк шул!
— Кая инде, бирәдә бер нәрсәне дә иртәгә калдырасы килми.
— Юк, Сережа, үзең дигәнчә генә булып булмый ул.
— Ай-ай, Римма, горур да син.
— Горурлык начар икәнен дә беләсең, ә холыкны үзгәртеп булмый.
— Үзгәртергә кирәкми дә. Горур кеше үз намусы белән сделкага керми, түбәнлек белән килешми.
— Ләкин үзенә генә кыен була.
— Зур эшләрне бары горур кешеләр эшли, дип әйтә Яким Зиновьевич.
— Горур булу коточкыч авыр. Гомер буе бернигә дә ирешә алмавың мөмкин.
— Үзенә күрә горур булу да рәхәттер, Римма?
— Юк, юк.
— Ә бит синең шулай горур булуың, бирелмәвең минем җенемне ирештерде, котыртты.
— Мин синең кырыслыгыңнан һәм катгыйлыгыңнан бик курыктым.
— Әй, Римма, бер кечкенә тәҗрибәмне сиңа әйтим: кырыс кешеләр тугрылыклы булалар.
— Шулайдыр бәлки. Синең турыда әйбәт сөйләмәделәр.
— Ышанам,— диде Сергей, көчсез тавыш белән.— Көнчеләр бар иде. Кеше нинди кешене ярата? Үзенә баш игән, үзенә буйсынганны...

## 15

Юл буенда җимерелгән немец орудиеләре, яндырылган самоходкалар күренеп китә. Ташлап калдырылган йөк машиналары һәм тягачлар түнтәеп ята. Күктә безнең бомбардировщиклар чигенүче дошманны бомбага тотып кире кайталар. Юлларда тузан коточкыч өермә шикелле күтәрелә. Көннәр коры һәм эссе. Радиаторлар пар атып бара.

Ниндидер таш юлга керделәр. Бераздан юлның ике ягыннан тезелеп киткән, пөхтә итеп эшләнгән складлар күренде. Аларның ишекләре ачык, эчләре буш, ләкин кузов бөркәнчеге артыннан карап баручы солдатларның барыбер күзләре яна. Аларның шул складларда актарынасылары, казынасылары килә. Кинәт Тәкәнәевнең күзенә бикле ишекле бер склад чалынды. Ул шунда ук машинаның кабинкасын йодрыгы белән төяртә кереште. Машина юлдан читкәрәк кереп туктады. Шофер ачуланган булып кабинкадан сузылды, ник туктаганны белсә дә, юри җикереп кузовтагыларга кычкырды:
— Сез нәрсә, әллә терәлдеме?
— Әйе, терәлде! — дип җитди генә әйтеп куйды берсе, машинадан сикереп төшеп.

Кабинкада утырган Ваһапов алдында шул сәбәпне сылтау итеп, барысы да складка ябырылды. Ишектәге йозак солдатның һәрнәрсәне ачарга омтылу дәртен йөзләтә арттырды. Миналанган булуы мөмкин дип тә шикләнү юк, ишекне шунда ук ачтылар да кереп тә киттеләр.

Бу продукт склады булып чыкты, ләкин ул шактый бушаган иде инде. «Изге» пехотачылар, күмүчеләр аны бик матур чистартканнар. Шулай да ике-өч ящик вино һәм ике тартма консерва банкалары бар иде. Шоколадлы әрҗәләр дә табылды. Шунда ук машинага алып килеп төяделәр һәм юлга кузгалдылар. Хәзер инде иркенләп ачарга, тикшерергә була.

— Ром, егетләр, ром! — дип кычкырды Никишин, шешәләрне карап һәм, шунда ук ачып, кружкаларга бүлде.

Икенчеләре консерваны ачтылар һәм сүгенеп куйдылар. Анда аксыл сыр массасы иде. Ашап карыйлар — авызга сылана, ләкин ром белән юдыртып җибәрә башлагач, ярады тагын.

— Нимчураның ашау ягы такырайган,— дип куйды кемдер консервадагы сырны яратмыйча.

— Сыр тыгынганга язваны белми алар, хәйләкәрләр!

— Аларда хәзер тамак кайгысы түгел, җан кайгысы!

— Артларына нашатырь кыстырганнармыни, элдерәләр генә!

— Нашатырьдан да болайрак иманнарын укыттык, ә?

— Әйдә, сал, сал, салма авыз.

— Күбрәк булмасмы?

— Әйдә, сал, теге дөньяда салдырмаслар! — Черняевның башына йөгерде, ахры, күңеллеләнеп китте, үзе гел елмая да елмая, авызы, аның ирегенә буйсынмыйча, үзеннән-үзе җәелә. Ул шундый яхшырды, үзенең намуслы кеше булуын сөйләргә тотынды.

— Мин төз ату буенча беркемне дә алга чыгармыйм, шулай бит, юлдаш, ә? Мин солдатны бервакытта да кимсеттермим, әх!

— Дөрес, дөрес, сержант, әйдә, тот әле,— Тәкәнәев аңа, ром салып, кружкасын сузды. Черняевның авызы һаман ерыла гына, колакларына житә. Ул кружканы иреннәренә китереп бик оста чөнкәйкеп куйды. Шуннан соң тагы да яхшыланып китте. Тәкәнәевне кочаклап алды.

— Мин татарларны яратам, батыр халык ул. Минем үземнең дә әни ягыннан ерак бабам татар булган, әйе, әйе! Ышанмыйсынмы? Әби мине яратканда һәрвакыт, их, татар күзләре, дип миңа әйтә иде. Әбекәй, кайда, кайда син? Тәкәнәев, мин сине үземә расчетка алам, яме? — дип, Черняев тынып уйга калды. Тәкәнәев батыраеп һәм рухланып татарча җыр җырлап җибәрде:

Кай якларга илтә икән
Без барасы олы юл?
Бәлки инде очрашмабыз,
Якын дустым, бәхил бул!
Хуш авылым, сау бул, китәм синнән,
Бик күп михнәтләр чиктем мин синдә:
Өзелде үзәгем,
Кимсенде күңелем,
Әрнеде йөрәгем чамасыз.

Кемдер зарлы тавыш белән сөйләнде, йөрәктән чыккан сүзләр яңгырады:

— Бер рәхәт тә күрмәдем дөньяда, юлдашлар...

— Хатын-кыз сине бәхетсез иткән,— дип, сугышчының биографиясен белгән танышларыннан берәү әйтеп куйды.

— Бәхет ул кешенең үзеннән генә тора.

— Юк, тормыш шартларын да инкарь итмә, гөлием!

— Язмыш кушканча йөри кеше,— диде Тәкәнәев, тагы кружкаларга салды, теге зарлы солдатка да өстәде.

Бу нәрсәне ул ярата иде булса кирәк, бик шәпләп тагы эчеп куйды һәм кинәт айнып киткәндәй булды, исереклеге бөтенләй калмады. Эчкән саен ул айный гына барды. Җанлылыгын җуймаган әңгәмәгә бүтән катнашмады.

— Сал, көндә оҗмах булмый!
— Хәерле булсын, оҗмахын да, тәмугын да күрдек.
— Юк, әле тәмугны күргәнең юк.
— Һе, немец бомбить итү — тәмугтан да хәтәр!
— Тәмугны татымаган — оҗмахның кадерен белмәс, ди!

Машина шәһәр урамына барып керде. Барысы да кузовның артына ябырылдылар. Опочка шәһәре! Тәрәзәләре ватылган ике катлы йортлар, бомбадан җимерелгән өй почмаклары, янгыннан корымланып калган стеналар. Каяндыр куе төтен күтәрелә. Мазут сөреме тузан белән бергә катышып тешләргә сылана, керфекләргә утырып, күзне йомдыра.

Әнә бер колонна хатын-кыз тротуар буйлап баралар. Барысы да эш чалбарыннан, аякларында кирза ботинкалар. Һәммәсе дә көрәктер, кәйләдер күтәргәннәр. Колонна: «Москва моя, могучая, ты самая любимая!» дип җырлап бара. Шәһәр бүген биш-алты сәгать элек кенә азат ителде, шул арада безнең тәртипләр урнашып та өлгергән. Хатын-кызлар нindидер җимерекләрне чистартырга баралар. Һәр тере кеше тизрәк җиңү өчен үз көчен бирергә ашыга.

Шәһәрне чыккач — күпер. Тимер юл күперен шундый каты шартлаткан немец, бередән тиз генә кичү ясамаслык иткән. Ә агач күперне бөтенләй чырага әйләндереп калдырган. Безнең саперлар пантон салып та өлгергәннәр. Пантон янында тагы бер төркем хатын-кыз юлны бозган бомба чокырына тачкалар белән балчык ташыйлар. Безнең сәрхүшләнгән солдатлар шаярып, аларга кычкыралар, банкалы сырлар ыргыталар.

— Мин әнә теге кызыл косынкалысын алыр идем,— дип шаяртып куя арадан берсе.
— Мин теге кубанка кигәнен.
— Мин зәңгәр чалбарлысын, әх!..
— Әй, авыз белән кош тотучы кырчыннар.
— Икенче эшелонга чыккач, хутордагы яшьрәк солдатка бер дә артык булмас иде, ә?
— Кызлар диген!..
— Юк, кызлар кызык түгел, кызлар егетләргә, ә безгә бирәр яшь тол какрас!..

Юл икегә аерыла: сулга һәм уңга китә иде. Ваһапов машинаны туктатып төште дә регулировщик кыздан юлны сорап менде. Уңга киткәне — Себеж шәһәренә бара. Ә боларга — сулга, Латвия чиге ягына таба хәрәкәт итәргә боерылган. Кайдадыр чиккә илтә торган иске таш юл булырга тиеш. Батарея шул төштә тупланырга, пополнение алырга тиеш.

Машина тузанлы юллардан элдерде, салам түбәле авыллар, сазлыклар, хуторлар артта калды.

Немец икенче көнне Себеж шәһәрен дә калдырды. Ләкин Латвия белән элекке Россия чигендәге борынгы крепостьларга кереп урнашып, фронтның бу кисәгендә безнекеләрне кызу тизлек белән алга барудан туктатты.

Дивизион белән батарея икенче көнне иртәнгә генә тупланып бетте. Әлегә дивизион, җанлы көч белән тулыландырылганчы, алгы линиягә куелмаячак дигән гөман бар, шуңа күрә бер урман кырына урнашырга дигән боерык килде.

Алексей үзен теге дөньядан кайткан бер кеше кебек итеп сизде. Ул исән калган бөтен солдатлар белән исәнләшеп, сөенеченнән нишләргә белмичә йөрде. Яшәүнең һәр минуты бик кадерле тоелды. Көн яктысының һәр чаткысы чиксез бәхет, чиксез байлык булып күренде. Төнлә ылыслы һәм яфраклы агачлардан корган шалашта да йоклый алмады, йоклап шундый җан күтәренкелеген, җан куанычын җуясы, сүрелдерәсе

килмәде. Ул Фираны көтә иде. Ләкин хатын нигәдер озаклады. Алексей аны каршы барып алды. Фираның күңеле бик төшенке иде. Өченче көнге фаҗигадән һаман айнып китә алмый изалана иде. Шулай да шалашта Алексей хатынның күңелендәге чи яра әрнүен үзенең шатлыгы, сөенече белән, иркәләүләре белән бетергәндәй итте.

— Фира, очрашмаган булсак, нинди зур югалту булыр иде, ә? — дип пышылдый Алексей аны үбә-үбә.— Рәхмәт сиңа!

— Сиңа да рәхмәт,— дип, Фира да пышылдый.— Мин синең белән бер кичтә йөз еллык рәхәт кичерәм.

— Мин дә шулай, Фира! Синең белән миңа да әйбәт! Сугыш та юк, үтереш тә юк кебек тоела башлый.— Алексей тыела алмый, тагы үбәргә, яратырга тотына.— Мин синнән һич туя алмам, Фира! Сине гел янымда гына тотар идем! Әх!

— Әнисен бәбисенә калдыр, син генә түгел бит!..

— Чын әйтәсеңме, Фира,— дип, Алексей шатлыгыннан торып ук утыра, шалаш ачыгыннан төшкән ай яктысында хатынының ялангач аяклары яктырып китә.

— Исәпләвем дөрес булса, чын! — диде Фира ышандырырлык тавыш белән һәм ашыгып киенә башлады. Китәргә вакыт иде.

— Алайса, сиңа биредән ычкынырга кирәк, элек әйткәнемчә, Фира.

— Әйе, юләрем, син әйткәнчә, ләкин берәр айдан.

— Иртәгә язылышырга барыйк, Фира, болай ярамас!

— Рәхмәт, Алексей, шул сүзне синнән көткән идем,— диде Фира, чиксез шатланып.

Алексей уйга калды. Әмма уйлары куанычлы да, борчулы да иде. Ул Фираны кайгыртты. Бирелә миңа да, аңа да төрле хәл булуы мөмкин. Татлы төш кебек кыска гына шушы бергә булган чорда Фира аның тормышына көч һәм иман өстәп торды, аңардан берни кызганмады. Аек акыл белән ул үзенең үлү ихтималын да күз алдына китереп карады, ләкин аңа һич кенә дә ышанмый иде. Үзен-үзе сынап, әллә ышанаммы дип тә уйлый. Юк, ул күңеленнән үлемгә бер тамчы да ышанмый иде, үзенә-үзе шуны икърар итте.

Алар озак аерыла алмадылар.

— Мин синең өчен куркам, Алексей,— диде Фира, яктырып барган офыкка таба карап. Аннары, борылып, күзләрен Алексейга төби, аның эчендәге тәшвишне сизенгән кебек була.

— Беләм, әй, миңа пычагым булсынмыни?

— Алай димә, Алексей... Төшемдә сине күрдем, ялангач көе күрдем, ә бу әйбәт түгел.

— Син төшләргә, хорафатларга ышанмыйсың бугай бит.

— Бер дә ышанмый идем, менә шуңардан соң, синең өчен куркуданмы, кайчак ышанып та куям.

— Син хәзер күбрәк тоясың, күбрәк уйлыйсың, Фира. Уйлама, уйлау начар ул. Кешене уй бетерә.

— Мин бирелән китсәм, син нишләрсең? Берәр әрсезе сине үзенә каратып куйса?— дип шаркылдап көлде Фира.

— Синең урыныңны кем били алыр икән, Фира? Андый хәл мөмкин булмас,— диде Алексей чын, җитди тавыш белән. Ул уйчанланып калды.— Юк, юк, мөмкин түгел ул! Минем беркем белән дә үземне болай хис иткәнем юк иде.

Фира аны өзелеп тыңлый, һәрбер сүзен йотып бара. Аның һәрбер сүзе бал шикелле. Ул Алексейны шул чаклы якын күреп ярата, һәр сулышы белән аны үзенә суырып алыр иде, һәр йотымы белән аны үзенә йотар иде...

Алар көчкә аерылыштылар. Алексей бүген иртән дивизион буенча дежурлыкны кабул итеп алды. Ул дивизион хуҗалыкларын, кухняларны дежур солдат белән бергә карап йөрде. Төрле урыннарда тәртип

кайгыртып, төрле күрсәтмәләр бирде. Кайсы җитешсезлекләрне бетерү өчен штабка, бүтән бүлекләргә чабарга туры килде.

Кичен Мостафин үзе аны чәй эчәргә чакырды. Ул Алексейны һаман якын итә, үзенә белгертмичә, аңа ташланучылардан комбатны аралаган чаклары да була, чөнки аны чын сугышчы дип белә һәм ышана иде...

...Әнвәр контузия алып, санбатка эләксә дә, колагы ишетә башлагач, тизрәк батареяга кайту ягын карады. Немецның яңа «вал тер»ын кулга төшергән иде, шуңардан атып карарга кымырҗыды. Ахырда Риммага ялынды, аңа батареяга кайтып китәргә чынлап та кыз булышты.

Батареяда кайбер иптәшләре юк иде, Ваһапов үлем язулары, хатхәбәр язып утыра. Йөзе бик күңелсез иде, Әнвәрнең күренүенә ул сөенгән кебек булды.

— Алтынчы батареяда синең якташың Минзәлә русы — разведчик бар, беләсеңдер. Ул сине үзенә сорап йөри. Барасыңмы? — диде Ваһапов, бу эшне өнәмәгән сыманрак.

— Юк, бармыйм,— диде Әнвәр.

Ваһапов шуның белән сүзне беттегә санап, кәгазьләренә иелде. Әнвәрне, иптәшләре күреп, шалашка алып керделәр...

Икенче көнне аны кухняга аш алырга җибәрделәр. Барган юлындагы тапталмаган үлән, чәчәкләр аның фикерен әллә кайларга алып киттеләр. Авылда печән өстенең иң кызган чагы инде хәзер. Бикәнәй болынына печәнгә төштеләр микән әле? Беренче пакусны кем сала икән? Өмә иткәннәрдер, мөгаен. Алдан кем йөри икән? Колхозның иң оста чабучысы Әфтәх карттыр инде. Әнвәр аның артыннан үткен чалгы белән төшеп, картны кара тиргә батыра иде. Чыдамлыгы беткәч, карт, әйдә, син алга чык, кара керәшен, дип әйтә иде.

Шулай уйларына йотылып бара Әнвәр. Кухня Латвия чигенә таба үтә торган таш юлдан урман эченә кереп урнашкан икән. Юлның икенче ягында немецлар аэродромы, зур, өсте бөркәүле аэродром — ангар. Кара, нинди оядан чыгып безне бомбага тотып ятканнар?

Әнвәр кухнядан бер термос тутырып әйбәт токмачлы аш алды, второйны зур бер котелокка салдырды. Рая, повар кыз, үзе генә иде. Әнвәр аны белә: соры күзле, курнос борынлы, ләкин борынны шактый югары тота торган нәрсә. Башта аның чалбар киеп йөрүен өнәмәде Әнвәр. Сазлыкта басып торган озын аяклы челән кебек дип исенә төшерә иде. Рая исә Әнвәрне нигәдер ярата, үз итә, ул аңа кухняга барган саен барын да өеп җибәрә, ашның да куесын бирә иде... Ә теге казакъ малайлары Үтәш яки Мурзыев барса, ашыңның шыр су гына булуын көт тә тор... Үзара гына сизелеп тә, әле башкаларга таралмаган бер сер иде бу. Ләкин бу сернең шулай сер булуы әйбәт иде булса кирәк, бишенче батарея элемтәчеләре һәм разведчиклары һәр вакыт Әнвәрне кухняга җибәрәләр. Башта, Үтәшләр алып кайтканда, нигә аш сыек дип Раяга бәйләнеп карадылар, әмма барыбер бер мәгънә дә чыгара алмадылар. Кыз, әнә өлкән повардан сорагыз, гына диде. Тегеләр шып булдылар. Өлкән повар шайтан кебек тешле бер нәрсә, ишетмәгәнеңне ишетерсең, күрмәгәнеңне күрерсең, аның белән бәйләнмәвең хәерле. «Әһә, сез кунакка килдек дип белдегезме әллә, солдат шулпасы куе булмый ул,— ди, крокодилныкы кебек тешләрен ыржайтып һәм санап китә көнгә солдат башына ничә грамм концентрат, ничә грамм май тиеш икәнлеген, шулай тезә, тезә — авызыңны ачып тик тыңлап торасың...

Шуңа күрә Үтәшләр кухняга барып бернәрсә дә тожыра алмыйлар иде. Әнвәр инде бу якка бик чос, үзенең чибәрлеге белән Раяны эретә дә ташлый дип сөйлиләр кайбер шук телләр. Бәлки бу дөрестер дә. Рая, Әнвәрне күргәч, үзгәреп китә, кинәт каушап кала иде. Бүген

ничектер үзен кулга алып өлгерде, алай итмәде. Сөйләнеп, аны бераз юандырып тотты.

— Нигә синең исемең Әнвәр? — дип сүз кушты кыз.— Пушок мыегынны яратам мин синең, Әнвәр! — дип, кыз күкрәкләрен селкетеп көлеп куйды. Кашыгын тиз генә киштәгә элде дә, Әнвәр янына килеп, бармагы белән егетнең ирен өстендә әле яңа гына матур булып үсеп килгән кара мыегын сыпырып алды. Әнвәр моны сизми дә калды, аның да йөзендә шаяру төсе ялтырый иде.

— Әй, башка җиремне яратмагач, мыек белән генә булмый,— диде ул.

Кыз тагы да ныграк шаркылдады, тагы әрсез генә тырпаеп торган күкрәкләрен селкетеп, рәхәтләнеп, чын күңелдән көлде. Әнвәр, русчаны вата-сындыра гына белүенә карамастан, бу әчкерсез рус кызын көлдерә алуына күңеле булып, шактый авырайган термосны җилкәсенә эләктерде дә кайтырга чыкты. Ә кыз, көлеп, аның артыннан карап калды.

Русча өйрәнү ягыннан егет хәзер шактый алдырды. Чөнки элемтә эше үзе шуны мәҗбүр итә иде. Телефонда сөйләшкәндә оялмыйча шушы буең-сының белән аңламыйм дип тормассың бит инде! Көн саен кычкырып русча шигырь укый. Бервакыт аны шундый чакта күреп алып, штаб кешесе сораша башлады. Акцентын бетерү өчен, малайка, син авызыңа вак таш тутырып укы,— диде. Һәм борынгы Грециядә булган бер ораторның әкәмәтен сөйләп китте. Әнвәр башта бу миннән көлә бугай дип уйлады. Ләкин соңыннан, уйлап-уйлап карагач, шулай кирәктер, штабист белмичә әйтмәс, дигән нәтиҗә ясады. Вак ташлар табып, аларны әйбәтләп юды, кешегә күрсәтмичә генә авызына тутырып укый торган булды. Кешеләр килеп сораша башласа, авызында ни дисә:

— Лампочи,— дип кенә җавап бирә иде.

Ләкин бу ташлар аның авызын тәмам эштән чыгара язды, аңкаулары тырналып, канап бетте. Әнвәр авызын саклап калыр өчен, конфет кабып укырга булды. Биш-алты чакрым тылда «Военторг» эшли иде. Кеше тәмәке алырга бара, үзенә тигән генә җитми, ә менә Әнвәр тәмәке дигән нәрсәдән мәхрүм булганлыктан, арзанлы конфетка да риза. Конфет белән эш шактый яхшырды. Ул үзенең русча өйрәнүен үзе үк сизә башлады...

Әнвәр термосның кайнарлыгын аркасында тоеп, әкрен генә, җай гына атлап кайта.

Ул, кайтырга турырак юлны сайлап, әлеге немец аэродромын аркылы үтеп китәргә уйлады, моннан батареяга юл якынрак, ашны кайнар көе малайларга тизрәк кайтарып җиткерергә кирәк. Немец, шайтан, аэродромны шәп төзегән. Тигез асфальт, түбәсен калын тимер-бетон белән япкан. Юан таш колонналар, кочагың җитмәс, шундый юан, биек баганалар. Самолетлар төшә дә шуның астына кереп китә, шунда ышыклана. Өстән самолетларны күрү түгел, бернинди нәмәрсәне сизә дә алмассың. «Безнең пленныйлардан эшләткәннәрдер әле»,— дип уйлады Әнвәр. Колонналарны узып кына киткән иде, кинәт артында шартлау тавышы ишетте һәм колагы яныннан бер пуляның выжт итүенә сискәнеп китте. Шул хәлдәнме, әллә инстинкт шулай иттердеме: аның аягы кинәт чокырга туры килеп, каймалгандай булды, һәм ул җиргә барып төште. Шул арада тагы бер пуля выжт итеп үтеп китте. Әнвәр башын җилкәсеннән салган термос артына яшерде, ә котелок белән ботка шалтырап бер читкә тәгәрәде. Нәрсә булыр бу? Бер минутта башына мең төрле уй ябырылды. Тылда калган берәр немецмы әллә дип, Әнвәр тиз генә пистолетын алды, сакланырга әзерләнде. Ул термос артына яткан килеш күзәтә, бөтен тәне дерелди, калтыранган куллары капшанып патронның ничә икәнен саный иде. Тукта, ничек тә каушамаска кирәк. Үз-үзен кулга алырга тырышса да, һаман тынычлана

алмый гына. Ичмаса, берәрсе күренми дә бит! Менә шундый минутта дошманга булган нәфрәт көче кешене бер йодрыкка туплый, аңа тагы үз-үзен саклау инстинкты да килеп кушыла. Бераздан инде Әнвәр чирканчык алган шикелле булды, каушавын җиңеп, аек фикер йөртә башлады. Куллары да дерелдәүдән туктаган иде. Биш патроны бар икән әле, шуңа бик нык сөенде һәм көче арткан кебек булды. Эх, граната да булса. Иртән елгага төшкәч, балык аулап, ник әрәм итте икән! Термос артыннан башын чыгарырга куркып, Әнвәр шулай уйлый иде. Дөресрәге, үзе түгел, ә уйлар үзләре бер-бер артлы өерелеп киләләр. Кинәт немец тагы атып җибәрде. Пуля термоска тиеп, рикошет белән читкә китте, асфальтны шытырдатканы ишетелеп калды. Тәмам исенә килеп, хәлгә яраша башлаган Әнвәр немецның бер колонна артына посып атканын абайлап алды. Нишләргә? Юк, болай ятарга һич тә ярамый! Ләкин беркая кузгалырга да мөмкин түгел иде. Неужели шулай үләрмен? Ә немец бит ул төз ата... Әнвәр иң кырый колоннага барып ышыкланырга карар итте, термосны башы белән этеп алга таба шуыштырды, шул рәвешчә бер баганага якынайды.

Немец атты, ләкин пуля тагы термоска тиде, Әнвәрне зарарламады. Әллә немецлар икәү микән дип, кинәт югалып кала язды Әнвәр. Яшен тизлеге белән колонна артына посты. Немец тагын атты — тидерә алмады. Төз атучылардан түгел булса кирәк, дип уйлады Әнвәр. Әмма колонна артында яту да кинәт куркыныч булып тоелды: капылт өскә ташлануы бар. Аннары — беттең! Юк, болай ярамый! Ничек тә берешмәскә, вакытны сузарга, миңа бүтән чара калмаган, дигән уй башында бөтерелде. Колоннага сыенып, әкрен генә торып басты, пистолетын җайлап тотты. Хәзер инде Әнвәр үзен кулга алды бугай, үзендә көч һәм кыюлык сизгән кебек булды.

Күз тигезлеге җирдән, баганага ябышкан көе, әз генә башын чыгарып карамакчы итте Әнвәр. «Нишләп бу фриц биредә калган?» — дигән уй һаман тынгылык бирмәде. Кинәт немец якыннан гына атты, пуля гимнастеркасының иң-җилкә турын умырып ташлады. Яраладымы әллә? Юк, тәнгә эләкмәгән. Әнвәрнең кинәт бик нык үче кузгалды. Акылның автоматик кушуы буенча, ул колонна төбенә иелде, шуннан күзәтә башлады. Менә немецның фуражка козырегы күренде, пистолеты үзеннән-үзе шуңа таба юнәлде. Әмма тирләгән бармаклар тәтене тартырга ашыкмады: фрицның башы әле күренми иде. Ләкин шунда ук немец сак кына тагы башын чыгарырга итә иде. Ул һаман да Әнвәрне күз тигезлегеннән эзли, аска таба искәрми. Әнвәр бу юлы да атмады. Немец куркыныч юк икән дип белсә, башын күбрәк күрсәтәчәк. Менә кинәт фрицның йөзе күренде, җәһәт кенә юкка да чыкты, Әнвәр тәтене баса алмый калды. Озынча, төк баскан саргылт чырайлы немец. Ул менә тагы, башын кыюрак чыгарып, күзәтә башлады. Әнвәр астан, багана төбеннән, атып җибәрде. Фриц баганасы янынан ниндидер карамчык очкан кебек күренде. Әмма тавыш-тын чыкмады, димәк, тимәгән. Әнвәр үзенең сулышы кысылганын тойды, күкрәк турысына ниндидер каты нәрсә килеп төелде. Сулышны дөрес алмаган, эчтәге курку шулай иткән, тидерә алмавының да сәбәбе шул. Иркен сулап, бераз үзен тынычландырырга тырышып, атарга әзерләнде. Әмма фриц башын күрсәтми, әллә берәр хәйлә мәтәштереп ятамы? Нишләргә? Әллә, үрмәләп, аңа якынаергамы? Ә ул шуны гына көтеп торадыр, үзеңне мишень итеп бер дә куясы килми, ә соң нишләргә? Көтәргә, сабыр итәргә?! Колоннадан әз генә тайпылдың исә, беттем дип бел.

Дикъкать җегәре төкәнгәндә, немецның бер җилкәсе күренде, Әнвәр атып җибәрде. Тимәде, әлбәттә. Юкка гына аттым, дип үкенде ул. Бераз көтәргә кирәк иде, әх, бөтен уңышсызлык шул түземлек җитмәүдән. Бәхеткә каршы, Әнвәр артында тавышлар ишетте, караса: ике солдат каядыр үтеп бара.

— Әй, Иван,— дип кычкырды Әнвәр фаҗигале тавыш белән,— колонна артында бер фриц, фриц...

Шуны раслаган кебек, немец боларга атты. Тегеләр, исләренә килеп, җиргә яттылар һәм колоннага таба шуыша башладылар. Немец колонна артына посты, күренми. Солдатларның берсе нигәдер кинәт «ура-а!» дип кычкырып җибәрде, болар белешмәстән шуңа кушылдылар. Ярыйсы гына тавыш чыкты. Немец, кинәт колоннасын ташлап, ангарның эченә таба икенче колонна артына ыргылды. Әнвәр чакмасын тартты. Немец чайкалып китте, акырып җибәрде, тик шул минутта ук колоннага посты. Әнвәр торып басты һәм алдагы колоннага йөгереп барды. Немец атмады. Әллә патроны беттеме? Хәзер аны барып алырга мөмкиндер бәлки. Юк, ул болай гына бирелмәс. Әнвәр тагы икенче колоннага күчте. Немецның авыр ухылдаганы ишетелде. Әһә, юк, бу хәйлә түгел иде бугай. Әнвәр тагы да кыюлана төште, теге солдатлар алдында да үзен күрсәтәсе килдеме, әллә кызып киттеме, якынрак колоннага күчте. Немец кинәт аның каршына күтәрелмәкче булды, финкасы ялтырап китте, Әнвәр пистолетының чакмасын тартып өлгерде, теге чалкан авып төште. Ул тере иде әле, күзләре кызыл кара тутырган кечкенә шар кебек иде. Теге солдатлар килеп җиткәнче, ул үлде, финкасы асфальтка чартлап бәрелде.

— Собака, ничек бирелә калган ул? — диде солдат, фрицның пистолетына үрелеп.

— Исереп аугандыр да өч көннән уянгандыр,— дип, икенче солдат аптырап карап торды.

— Шәп корал! — диде беренче солдат, пистолетны кулында селеккәләп.

Алар сүзсез генә үзләренең юлларына таба китеп бардылар.

Әнвәр кинәт үзенең бөтен тәне манма тир икәнен тойды, термосын исенә төшерде, аны көтеп торуларын, шактый озак вакыт узуын уйлап, эче жу итеп китте. Тизрәк термосны эзләп тапты, ул җиңеләйгән сыман тоелды. Котелоктагы ботка асфальтка түгелгән иде. Әнвәр кулын гына селтәде, второйга махан пешерербез әле, дип уйлап термосын күтәргән иде, аннан аш шулпасы агуына аптырап калды. Тегенең пулясы термосны берничә җиреннән тишкән иде...

Кайту белән малайлар шаярта башладылар. Телгә дисәң, аларның теленә шайтан төкергән инде.

— Ай-ай, малай, киттең дә баттың, бик тәмле җиргә юлыктың, ахры, син, ә? Авыз-борының майланган, күрәм.

— Раяның ак кулларыннан тиз генә ычкынып булмый шул, димә...

— Кочагы бик кайнар, ахры, тәмам егетне мәлҗерәткән бит.

— Поварихаларга эләксәң, арт саныңны көчкә сөйрәп котылырсың.

— Әнә ич битләрен, кулларын тырнап, күлмәкләрен ертып бетергән нани... бик наян нәрсә булып чыкты ул...

Шулай сөйләнә-сөйләнә барысы да термоска ябырылдылар, котелоклар, кашыклар шалтырады, кайсы савытын чайкый, кайсы блиндаждан капчыгын алып чыгып маташа. Ләкин термосны ачып карасалар, анда аш яртылаш кына калган, ботка котелогы бөтенләй күренми иде.

Әнвәр лафет янында башын ике кулы белән учлап, түбән карап утырган да бер сүз дәшми. Ул әле исенә килеп җитә алмаган кебек иде.

— Ә ботка кая?

— Монда аш та аз күренә әле.

— Әллә Рая Әнвәргә развод биргәнме?

— Нәрсәдер бар!

Сугышчылар ашны зур чүмеч белән котелокларга бүлә башладылар.

— Әнвәр туеп кайткан, аңар бүлмәсәң дә ярый.

— Тимәгез әле шунар, егетләр, әнә башын да күтәрә алмый бит.

— Әй, яшь чакта була торган хәл, нигә исегез китте.

Шилов, нәрсәдер сизенеп, Әнвәр янына килде.

— Нәрсә, «вальтер»га күчтеңмени? — дип, аның сул янтыгына ымлады.— Каяле? — Шилов яңа корал күрсә, аны тотып, тикшермичә тынычланмый иде.

Әнвәр, кулларын башыннан көчкә генә кубарып, аңа «вальтер»ын сузды.

— Әһә, кайнар,— диде Шилов кулына алу белән.— Атышлы уйнадыңмы?

— Юк.— Әнвәрнең бик ачуы килгән иде, тавышы көчкә генә чыкты.

— Дуэльдә атышкандыр,— дип шаяртты берсе, чирәмгә кырын ятып ашаган килеш.

— Әйе, дуэльдә.— Әнвәр үчекләүгә үчекләү белән җавап кайтарырга булды.

— Я, я, шаяртма. Ничә метрдан ничәне алып була? — Шилов пистолетның маркасын карады. Шул чак Үтәш кычкырып җибәрде. Ул кашыгында нәрсәдер күтәреп килә иде.

— Менә аштан пуля чыкты, пуля-я!

— Кит әле, әкәмәт!

— Әллә котырдыңмы?

— Әнә кара.

Җыйнаулашып пуляны тотып карый-карый шаулашып алдылар. Соңыннан барысы да күзләрен Әнвәргә төбәделәр. Ул су сорады. Аны голт-голт итеп эчкәч, иптәшләренә эшнең ничек булганын көчкә сөйләп бирде. Термосның тишелгәнен берәү дә шәйләмәгән икән әле, аны да карарга тотындылар, ике җиреннән тишек табылды. Актара торгач, аштан тагы бер пуля килеп чыкты. Һәммәсе дә гаҗәпкә калып тордылар.

— Каушап кала яздым,— диде ул, нигәдер үзен шул йомшаклыгы өчен гаепле санап.

...Мостафин, чәен эчә-эчә, Алексейга немецның чигенүеннән зур нәтиҗәгә килүен, сугышның тиздән бетәчәген гөман кылып сөйләде. Алексей исә немецның Латвиядә зур каршылык күрсәтәчәген, чигенергә теләмәячәген таныклаган кебек әйтте, сугышның тиз генә бетәчәгенә ышанмады.

— Җанлы көче дә азаеп бара,— диде Мостафин. Аның күзләре монсуланып, яңагындагы мускуллары кыймылдап куйды.

— Безнең пленныйларны безгә каршы әзерләгән, ди бит.

— Алар белән ерак китә алмас ул. Соң, уйлап кара, үз братына каршы ничек атсын инде? Йөздән берсе атуы мөмкин,— диде Мостафин.

— Кешене белеп булмый шул,— диде Алексей. Аннары ул Фира белән булган мөнәсәбәтен сөйләде.

— Димәк, сугыш беткәч, туры Казанга? Якташ булырсың, әә? Безнең Ык буйларына, мина кунакка, әә?

— Хыял күптән тыныч тормышны уйлап кинәнә дә бит!

— Хыял белән чын арасы һаман якыная, Алексей!

Комбатны чакырып алдылар. Әле дежур вакыты бетмәгән иде. Ике солдат белән тагы батареяларны карап йөрделәр. Көн өйләдән узган икән инде. Кая барсаң да бу сирәк урманлы җирдә солдатлар, машиналар, орудиеләр. Әнә еракка ата торган озын көпшәле бер авыр тупны дизель тракторы каядыр өстерәп бара.

— Иптәш капитан,— дип туктатты Алексейны янәшәдән баручы дежур.— Әнә безнең якка элек немецка әләккән әсирләр чыккан...— Зәңгәр немец киеме кигән утызлап кеше болай таба килә иде.

— Күтик әле, иптәш капитан, танышлар очрамасмы? — диде икенче дежур.

Алексейга да кызык тоелды, үз илләренә каршы барырга әзерләнгән кешеләрнең кыяфәтләрен генә булса да күрәсе килде. Шундый хыянәткә үзләре теләп риза булмаганнардыр, әлбәттә, кая инде! Әллә кайберәүләре, безгә ике дөнья — бер, уртасы камыр, дип карадылар микән? Юк, булмас, туган җир кадерле, канга сеңгән бит инде ул...

Колонна якынайды, зәңгәр немец киеме кигән бу кешеләр ничектер барыбер дошман кебек булып тәэсир итте. Тик аларның мескен йөзләрен күргәч, кызгану хисе дә уяна иде.

Бик алҗыган күренәләр. Әллә шуна, конвойчылар, гадәттәгегә каршы килеп, аларны привалга туктаттылар. Барысы да шунда ук җиргә утырдылар һәм безнең солдатларга күзләрен төбәделәр. Алексейның дежурлары һәрберсенең диярлек туган җирен сорашып чыктылар, тик якташларын тапмадылар. Әмма Алексейга ничектер бер таныш йөз чалымы очраган кебек булды. Хәтерен күпме җигеп караса да, аның кем икәнен, ничек, кайда күргәнен һич исенә төшерә алмады. Бик таныш йөз шикелле үзе, шайтан. Алексей һаман шул әсиргә текәлеп торды, теге дә капитанның аны күзәткәнен сизде, йөзен бормады, туп-туры чекерәеп карады. Карашлар очрашып чарпалашты. Әсирнең карашы, аяу көткән сымак, билгесез өмет белән мөлдерәмә тулы иде. Юк, ахры, ул берәр охшаш кешене генә хәтерләткәндер. Алексей, җанга авыр йөк шикелле караштан тизрәк котылырга теләгәндәй, күзләрен читкә алып, китү ягына борылды, дежурлар да аңа иярде. Ләкин берике атлау белән Алексейның миенә ток суккан кебек, кинәт фикере ачыкланды. Ул әсиргә таба кире кызу-кызу атлап китте.

— Син Таминдаровмы? — дип кычкырды аңа.

Әсир кинәт урыныннан торган кебек итте, нишләргә белмичә каушап калды.

— Юк, әйе,— дип авыз эченнән мыгырданды, ләкин шунда ук йөзендә өмет чаткылары очкынланды.

Шул вакыт аларга кузгалырга команда булды. Әсир авызына килгән сүзне әйтә алмый калды бугай. Теге ачык җавап бирмәгәч, Алексей бераз таркауланыбрак китте, сәер бер икеләнү белән нишләргә белми аптырап торды. Бер фикер икенче фикергә каршы килде, язгы бозлар берсе берсенә төртелеп, юлларын тыгылдырган шикелле, уйлары тоткарланды. Ул арада тегеләрне алып китеп баралар иде инде. Әйе, шик юк, бу Фираның элеккеге ире Таминдаров булырга кирәк. Тик хәтерем ялгышуы да мөмкин бит! Юк, мин ул кешене еш күрә идем, ялгышу булырга тиеш түгел.

Аның башына хәзер үк Фирага әйтергә, аңа ирен күрергә булышырга кирәк диган уй килде. Станциягә чаклы әле ерак, аларны җәяү илтәләр, машина белән куып җитәргә була. Әллә үзем генә барып, начальниклар белән сөйләшергәме? Аның язмышын бераз җиңеләйтеп булмас идеме икән? Юк, Фирага хәзер үк барып әйтергә кирәк.

Тагы бер минуттан күңеленә бүтән уйлар килә: Фирага хәзер һич тә дулкынланырга ярамый. Бәлки Фираның аны күрәсе дә килми торгандыр? Киселгән икмәк бит инде ул. Ә Фира аны кисмәгән булса? Юк, хәзер үк әйтергә, Фира үзе барысын да хәл итсен! Ләкин шушы чаклы катлаулы йөкне аның өстенә генә, аның җилкәсенә генә аударырга омтылу минем тарафтан егетлек булырмы соң? Биредә син дә катышкан бит! Фира үзе теләсә нишләсен дип әйтергә ничек җөрьәт итәсең? Димәк, син аны түгел, үзеңне генә яратасың. Барысын да Фирага гына

калдырсаң, син чын эгоист, үз өстеңнән бәлане бүтәннәргә генә шудырырга торучы пустяк кеше. Үзе хәл итсен, имеш. Ул бит асылда синең хатының...

Ничек болай килеп чыкты соң бу? Фира белән мөнәсәбәтнең шулай катлаулану ихтималы булуы Алексейның башына килеп тә карамаган иде. Ул яратудан тәмам сукырайган кебек йөргән. Нинди ахмак мин, ә бит чынында Фирадан башка үземне күз алдына да китерә алмыйм. Юк, ире турында әйтеп тормаска, аның күңеленә артык чүпләр төямәскә кирәк...

Алексей кисәк кенә Фираны югалтудан куркып куйды. Аңа ул хәзер бигрәк тә үз, чиксез якын, кадерле тоелды. Мәхшәр эчендә аны яшәтүче тылсымлы көч кебек иде ул.

Шулай да Алексей Фира янына барырга булды. Солдатларына тиешле объектларны күзәтергә боерып, үзе госпитальгә юнәлде. Госпиталь бер хутордагы өч-дүрт йортка урнашкан, янында тагын озын яшел палаткалар да бар иде.

Фираның буш вакыты туры килде. Ул Алексейны күрү белән атылып чыкты.

— Әллә берәр ашыгыч нәрсә булдымы? — дип, Фира аңа төбәлеп карады. Күзләреннән Алексейның уйларын белергә өйрәнеп килә иде.

— Вакыт чыкты да килдем менә.

— Булган-булган,— дип көлә-көлә бармак янады Фира.— Нигә төсең үзгәргән?

Миндәге үзгәрешне ничек сизде ул дип шаккатты Алексей һәм шуңа яратып карап торды. Фира Алексейга ныграк текәлде һәм, йөзендәге елмаюлары сүнеп, аның беләгенә ике куллап тотынды.

— Нәрсә булды, Алексей, әйт инде! — дип ялварды хатын. Алексейга берәр күңелсезлек булгандыр дигән уйдан коты алынды.

— Нидән инде бу шөбһә? — Алексей эчендәген яшерергә тырышып, чыраена бирни дә юк, дигән билгеләр чыгаргандай итте. Ләкин бу риялылыгы белән Фираны тынычландыра алмады.

«Әйтергәме, әллә әйтмәскәме?» — дип Алексей тагы икеләнде.

Фираның Алексейны беткәнче үзенеке итәсе килә иде. Ләкин кырыс шартлар аркасында үз дигәнен итә алмый, шуңа эче пошып гасабилана иде. Күңеле хәлләр белән санашырга теләми азапланса да, акылы белән Фира барысын да тигезләргә омтыла. Ул һаман Алексей турында кайгыра, аның күңел почмагында кемгәдер бүтәнгә урын калгандыр дип курыккан чаклары күп була. Шуңа күрә кайчак Алексейны рухи саранлыкта гаепләп тә куйгалый. Алексей исә, хатыннар шулай була торгандыр инде дип, Фираны артык гаепләми. Фира үзенең дәгъвачыл булуын үзе дә яратмый, әмма Алексей күңеленә үзенең генә хуҗа буласы килү теләге аның ихтыярына буйсынмый иде.

— Нәрсәдер миннән яшермәкче буласың,— диде Фира, үпкәчән тавыш белән һәм аска карап уйланып бара башлады. Бу минутта ул үзенең көчсезлеген сизгән кебек булды.

Алексей Фираның эчкерсезлеген тойды. Ничек аңар дөресен әйтмәскә мөмкин? Бу фәкать үз-үзең каршында оят һәм уңайсыз булачак.

Алар урман эченәрәк атладылар.

— Иреңнең фотосы синдә юкмы?

— Нигә? — Фира, шикле кабаланып Алексейга караган көе, сумкасын актарды һәм бер рәсем чыгарды.— Нәрсә булды, ник? — дип, ешеш кабатлады.

— Мин Таминдаровны күрдем,— диде Алексей фотога бик төбәлеп карап торганнан соң. Фира кинәт туктады һәм хакмы, әллә сынар өчен генә әйтәме, дип Алексейның карашыннан чынын белергә теләде. Ул

коелып төшмәде, шулай да аның куллары калтыранганын Алексей сизеп барды.

— Фира, син артык борчылма,— диде ул, әмма Фира аның сүзләрен ишетмәде.

— Ничек, Рәшитнеме, әллә ул исән? — дип, Фира Алексейның беләген авырттырырлык итеп кысты. Аның тавышы бик аптыраулы һәм гаҗиз иде. Алексейга уңайсыз булып китте. Ник әйткәненә үкенеп куйды.

— Теге яктан безгә чыккан әсирләр арасында иде.— Алексей бу юлы үзе гаепле кеше кебек күрсенеп куйды, чыраен кайгы шәүләләре күмде.

Фира да уйга чумды.

— Ни булыр инде ул мескенгә, исән икән, ә? Без аны... барыбыз да шуңа ышанган идек.— Фира үзенең сүзләре ясалма чыккан кебек сиздеде сүзен әйтеп бетермәде. Ул Рәшитне ихлас күңелдән кызганды.

— Аны күрәсең килсә, машина белән куып житәргә була,— диде Алексей, Фираның рухи халәтен аңларга һәм уртаклашырга теләп.

— Нәрсәгә? — диде Фира ачынулы рәвештә.

Алексей аның бу тавышыннан җаны тетрәнүен белде. Әммә көенечен тышка чыгармавына, вөҗданлы булып кыланмавына сокланды.

Бераз тынып торганнан соң Фира әйтте:

— Киң күңеллелек күрсәтмәкчесеңме? — Аның тавышы ачулы шикелле иде.

— Син аны яратасыңдыр бит?

— Белмим, Алексей, син барысын да күмден, үзеңә яулап бетердең. Миңа элеккегедән бернинди дә аваз ишетелмәс булды.

— Беренче ярату гомергә саклана, диләр.

— Кемдә — беренче, кемдә — икенче. Минем беренчесе булмаган да кебек... Гомумән, мин бик оятсызландым, ахры, әйеме?

— Я инде, үзеңне тиргәмә, ул мине тиргәгән кебек барыбер...

Фира Алексейның сул беләген ычкындырып, уңын тотты, алар кайту ягына таба борылдылар.

— Алеша, син Рәшит хакында беркемгә дә әйтмә, яме! — дип үтенде хатын.

— Әлбәттә.

— Ничек ул шулай булган?

— Әйе, егет кызганыч. Күрәсең, язмыш.

— Эх, без нишли алабыз соң?

— Бик начар фал,— диде Алексей. Үзе эчтән: күрмәгән булсам, тыныч була иде, аны танырга шайтан котыртты, ахры, дип уйлады.

Аерылганда, Фира аның бүген кич тә килүен үтенеп, елмайды. Алексей сүзсез аңлап, вәгъдә бирде, кызу-кызу атлап частена кайтып китте. Фира аның артыннан моңсу гына карап калды, ул китәр дә кабат килә алмас кебек тоелды.

Адәм баласы берне сагышлар, язмыш икенчене багышлар, ди. Төнлә батареяга пополнение китерделәр, ә таң алдыннан алгы сызыкка күчәргә приказ булды. Алексей ул кичне Фира янына бара алмады.

Сергей Айкилдиев әле һаман ярадан савыга алмыйча ята иде.

— Римма, мин үләм инде,— диде ул бер көнне.

— Сөйләмә юкны, Сережа,— дип, Римма аны юатмакчы булды, теге кулын гына селтәде. Чөнки ул үз хәлен яхшырак белә, «хөкем» ителгәнен тоя иде. Сергей үзенең вак-төяк әйберләрен аманәт итеп кызга бирде, Карталы шәһәрендә яшәүче әнисенә җибәрүен үтенде.

— Юк, юк,— диде Римма.

Сергейның бүген кәефе әйбәтрәк шикелле иде, бераз гына хәле җайланды исә, ул мәзәк кенә сөйләнә башлый.

— Мин сине яраттым, ә син — юк. Күңелемдә синә әллә нинди үч бар. Әллә сине җиңә алмау үче микән? — ди.

— Әгәр җиңсәң, Сергей, син мине яратмаган булыр идең,— дип елмая Римма, аның сүзләрен чынга алмыйча.

— Бер ирешкәнне икенче тапкыр ныгытырга иде исәп.

— Юк, Сережа, ул синең төшенә генә кергән.

— Баш имәвең мине үчләндерде.

— Менә терел әле, терел.— Римма Сергей сүзләренең асылына әһәмият итми, бары авыруның ибенә килергә генә тырыша иде.

— Юатыр өчен генә әйтәсең.— Сергей, Римманың күзләренә текәлеп, анда нәрсәдер шәйләде бугай.— Ялганлама, ярар, бетте инде.

— Эх, сез, ирләр! — дип, Римма урыныннан торды. Ул морфий уколы әзерли башлады. Ампуланың очын нечкә кайчы белән китеп алды да сыекчаны шприцка суыртты.

— Гозеремне үтәрсеңме?

— Әллә ышанмыйсың?

— Нигәдер ышана алмыйм, ышанасым килә дә соң.

— Тәмам өметеңне өзгәнмен икән.— Римма үпкәләмәде, бу сүзләрнең бернинди дә реаль мәгънәсе булмаган кебек, әллә ни борчылмады. Ул егетнең беләгенә морфий уколы кадады да приборларын күтәреп чыгып китте.

Сергей шунда ук изрәп йоклап китте, каядыр рәхәт дулкында йөзеп барган шикелле булды. Яким Зиновьевичның килгәнен томан аша гына күрде, ләкин сөйләшә алмады.

Яким Зиновьевич баш врач янына бик бетерешкән, кайгылы кыяфәттә килеп керде.

— Семен Израилович, егетне йолып калырга иде,— диде Яким Зиновьевич карлыккан тавыш белән.

— Бар өмет яшьлек рухында инде.

— Организмга булышырга кирәк.

— Кулдан килгәннең барысын да эшлибез.

— Минем балаларым булмады, Семен Израилович, булмас та, мин Сергейны улым кебек яраттым.— Майор врачка туры карамас өчен башын читкә борды. Врач барыбер мине аңламас, дип уйлады ул.

Врач аның чырае суырылып калудан, күз кабакларының шешенкеләнүеннән борчылуының ихласлыгына шикләнмәде. Фронт тудырган гаҗәеп дуслык, туганлык турында уйлады ул.

— Аңлыйм, аңлыйм,— диде врач.

Ә Яким Зиновьевич урындыкта башын күтәрә алмый утыра бирде.

— Тәгаен нинди чара күрергә мөмкин? — дип, майор урыныннан калкынды, өмет иткән күзләре белән врачка төбәлде.

— Беренче группа кан кирәк.

— Ничек табарга була?

— Бу соңгы чара инде: мин Хатантаевага әйткән идем, ул үзе авырып киткән бугай.

— Авырса да инде, дусты өчен...

— Бирмим дип тә әйтмәде ул үзе, белмим тагы...— диде врач серле һәм ике төрле аңларга урын калдыра торган тавыш белән.

— Кан булыр, анысын үзем ышандырам,— диде Яким Зиновьевич.

— Болай булгач, өмет зурая.

— Новокаин китермәделәрме?

— Китерделәр, бик зур рәхмәт.

— Зинһар, тырыша күрегез инде...

Яким Зиновьевич әкрен генә чыгып китте. Ул урман сукмагыннан кайтып килүче Римманы күреп үзе янына чакырды. Алар агачлар күләгәсеннән атладылар.

— Сережаның хәле начар икән,— диде Яким Зиновьевич. Римма ни дип әйтергә белмичә торгач, тагы өстәде:— Бер дә өмет юкмыни?

— Бөтенләй өметсез димәс идем,— диде кыз.

— Мин үземнең канны бирергә иткән идем, группасы туры килми, ди Семен Израилович.

— Яким Зиновьевич, мин ана кан кирәк дип белмәдем, сез нәрсәгәдер ишарә ясыйсыз,— диде Римма ничектер куркынган һәм уңайсызланган кебек. Ул кинәт йөзенә кызыллык йөгерүен сизде, майорга карамаска тырышты. «Әллә Сергей минем салкынлыгымны сизеп, майорга шикаять иттеме?» дигән уй миеннән йөгереп узды. Яким Зиновьевич нидер уйланып дәшми барды да кызга якты чырай белән карап әйтте:

— Әллә Сергей сине кимсеттеме?

— Юк,— диде кыз ничектер ышанычсыз гына.

Яким Зиновьевич исә кимсеткән икән дип уйлады.

— Яшь чагында, бер-береңне нығрак белергә теләгәндә, була инде ул, Римма. Ә Сергейның күңеле шундый әйбәт аның.

— Беләм, беләм,— диде кыз.

— Әх, гаярьлеге бар иде аның. Терелсә, аны да, сине дә бик әйбәт урнаштырыр идем,— диде Яким Зиновьевич, ышанычлы, катгый итеп.

— Сугыш бетсә, анысы...

— Сергейга үпкәләмә инде, Римма?!

— Һич тә, Яким Зиновьевич!

— Син минем нәрсә әйтергә теләгәнне, димәк, аңладың?

— Әйе,— диде Римма, һаман ныграк оялып.

— Алайса, килештек.— Яким Зиновьевич шулай әйтергә генә өлгерде, нинди дер связной килеп, аны каядыр чакыруларын әйтте. Майор күзләре белән кызга ышанганлыгын белдереп елмайды да тиз-тиз атлап китеп барды.

Сергейга кич белән Римма биргән ике йөз илле грамм канны җибәрделәр. Иртәнгә хәле яхшырган кебек булды. Римма тагы ике йөз илле грамм кан бирде. Әмма Сергейның хәле кинәт кенә начарлана башлады. Врачлар, нинди генә әмәл кулланып карасалар да, ул кабат рәткә килмәде...

Римма Сергей белән танышкан, сөйләшкән чакларын исенә төшереп ятты. Римманың шуңа бик кәефе киткән иде: кызлар аңа Сергей үзенең «җиңүе» белән мактанган дип җиткерделәр.

— Безнең арада берни дә булмады,— диде Римма.

— Яшермә,— дип җанга тукынырга теләүчеләр дә табылды. Римма барысын да кире какты.

Шулай инде, егет белән кыз арасында ни булганын беркем дә, беркайчан да төгәл генә белә алмый... Алар мөнәсәбәтен берәр төрле гөман итәргә маташсаң, тик үзең генә ахмак булып каласың...

Берничә көннән Сергей үлде. Яким Зиновьевич аның кабере янында бик картайган кыяфәттә, озак кына китә алмыйча басып торды.

«... Менә җирдә тагы бер кабер калкып чыкты! Ә күңелдә? — дип яза Римма көндәлегенә.— Күңелдә нинди дер бушлык? Юк. Сергейның үлеме миңа нык тәэсир итмәде. Мин үлемгә дә күнегә барам бугай! Бу — әшәкелек. Тик Сергейның миңа ышанмыйча китүе күңелне тырнап алды. Мин шулай ук ышанычсыз кебек микәнни? Нигә мин кешене тиз генә ярата алмыйм, тиз генә кешедән үземне яраттыра алмыйм? Миңа ир-ат халкы ничектер миннән аласы әйберләре бар, аласы хакы бар шикелле итеп карый. Кайберләре хатын-кызны түбәнсетергә, түбән итеп күрергә яраталар. Алар безне әз генә «очсызлансак» та, кылансак

та бик каты хөкем итәләр, безне нинди генә пычрак сүзләр белән атамыйлар!..

Минем хатын-кыз янында бер тапкыр булган кеше белән дуслашасым килми...

Сөенчалин әйбәт кеше иде, ләкин аның белән ара өзелде, ул һаман миңа ышанмый, биредә ятканда да шуны тукыды. Мин моңа бик үкенәм. Ара өзелгәч, миңа ул тагы да ошый башлады. Аның килүен теләп йөрдем. Ул килмәде. Үзем барырга горурлыгым аяк чала, җибәрми. Асылда әллә шул горурлык кешене бәхетсез итәме? Ә характерны ничек үзгәртергә? Әнә Раяның бар эшләре әйбәт, мөнәсәбәтләре дә җайлы, минем кешеләр белән ара ничектер киеренке, тартынкы, әз генә тайпылдыңмы — шартлап өзелергә тора? Мин, ахры, әйбәт кыз түгел, характерым да әйбәт түгел, бүген мин кешене яратам, ә иртәгә яратмый башлыйм, яки киресенчә. Ник?

Яким Зиновьевич мине укырга китәргә өнди. Мин риза булдым. Кайчан хәбәр килер? Китәм, барысын да яңадан башларга кирәк. Үзеңне «очсызламаска» кирәк, әмма үземә артык зур бәя дә куярга ярамый...»

Римма көндәлегенә үзенең кайгыларын сызгалап утырганда кинәт Сөенчалин килеп керде.

— Ничек син болай бер ялгызың? — дип, яратулы караш белән кызга төбәлде ул.— Урлап китсәләр?..

— Син килеп коткарырсың әле,— диде Римма, шаяруны дәвам иттерәсе килеп. Сөенчалин өстәлгә шешә белән берничә плитка шоколад куйды.

— Коткара алмасам, ә?

— Мин үзем дә тиз генә ак флагымны күтәрмәячәкмен,— дип көлде Римма, элеккечә, үзләре арасында бернинди тәмсезләнешү булмаган кебек.

— Алайса, син бик катгый, ә? — диде лейтенант һәм шешәне күн итек табанына бәреп ачты да өстәлдә торган кырлы стаканнарга эчемлек агызды. Стаканның берсен Риммага тоттырды, кыз башта ялындырды, аннары барыбер алды: «Ярар, мин биредән китәсе кеше», дип, үзен аклаган булды ул.

— Җиңү өчен! — диде Сөенчалин җитди итеп һәм эчеп җибәрде. Римма да әз генә эчте, авызын эчемлек яндыргангамы, учы белән тамак астын тотты, тынын кысып торды һәм кинәт сулышын тышка өрде.

— Ай-яй,— дип башын селкеде Римма һәм шоколад сындырып капты. Бөтен тәненә кызулык йөгерде.— Яндыра ич бу!..

— Ныграк ян, Римма, яктырак булыр.

— Минем яктым кемгә кирәк? — диде кыз, тәнендә рәхәт кызулык артканын ныграк сизеп.

— Миңа кирәк, Римма.

— «Яктырткычларың» бардыр әле.

— Юк.

— Ай-яй, теге көнне син миңа каты әйттең, син ышанычсыз, дидең.— Римма егет гафу үтенер дип көтте. Тик егет тә горур иде, сүзен кире алмады.

— Яратканга күрә әйттем,— диде.

— Ышанмагач, ничек яратырга мөмкин?

— Үзем яратам, үзем ышанмыйм,— дип, лейтенант кызны кинәт кочып алды, күкрәгенә кысты. Римма әз генә карышкан булды, ул үзе дә егетнең кочуын һәм үбүен көтеп тора иде бугай. Сер белгертми егетнең куенына авып төште, үп дигән кебек күзләрен йомды. Сусаудан тәкате беткән кеше сыман, егет аның иреннәренә ябышты.

— Бирегә керүләре бар! — диде кыз, иреннәрен читкә алып, егетне туктатмакчы булды, тик үз теләгенә ирешә алмады, егет тыны беткәнче үпте. Аннары бераз тын тордылар.

— Синең шәүләң миңа ияреп йөри, Римма, аңлыйсыңмы?

— Аңламыйм. Чын, ничек инде ул?

— Менә барам, син артымнан киләсең кук, мин борылып карыйм — беркем дә юк.

— Мин алай булганын белмим,— диде кыз, аскарак карап, аның күз тирәсенә керфегеннән күләгә төште, битендәге вак кына сипкелләр чиксез ягымлы, сөйкемле булып күренде.

— Син яратмыйсың! — диде егет һәм аның тавышында электкеге ачуланышкан чактагы төсмер ишетелде. Үзенең урынсызрак әйтүен шунда ук сизде һәм төзәтер өчен сүзен дәвам иттерде.— Римма, миңа фотоңны бүләк итче, ә? — Сөенчалин елмаеп, кызның биленнән кочып алды.

Кыз урыныннан торып, чемоданыннан карточкасын чыгарды һәм артына мондый сүзләр язды: «Карагач искә төшерү өчен түгел, искә төшереп карар өчен! Римма». Үзе эчтән егетнең сүзләре турында уйлады: әллә мин аны яратмыйммы икән? Ә үземә яратам шикелле тоелган иде?! Мин, ахры, яратуга сәләтсез бер бәндә! Нишләп соң мине өзелеп ярatканга мин шундый ук тойгы белән җавап бирә алмыйм? Ә миңа аның белән шундый рәхәт, җинел, димәк, мин аны яратам!!

— Мә, сакла. Истәлек итеп!

— Истәлек булып кына калмасын иде, Римма!

— Анысы инде бездән тормый торган нәрсә!

— Бездән тора, Римма. Озакламый сугыш бетә.

— Сугыштан соң нишлисең?

— Иң элек өч тәүлек йоклар идем. Ә чынында, бик укыйсы килә.

— Ә минем юк,— диде Римма. Бу минутта аның бик серле буласы, егет күңелен шуның белән үзенә ябыштырасы килде.

— Нигә?

— Кем белсен.— Римма тагы да серле итеп җилкәләрен җыерды.

— Сиңа алтын тавы вәгъдә итүчеләр бардыр, мөгаен.

— Мин бала-чага түгел лә.

— Шухыр-мухырларыңны башыңнан чыгарып ташла да, әйдә, Римма, бергә укырга, ә? — диде егет хыялчан өмет белән. Ул кызны тагы кысып кочаклады һәм гүя хисләре дулкынына алып, аны үзенең фикерләренә, ихтыярына буйсындырмакчы булды.

Римма, ничектер, үз ихтыярына каршы килеп, егет кочагына ныграк сыенды, чөнки Сергейга булган салкынлыгы өчен эчтән генә үкенә һәм шул инсез тойгылардан тизрәк арынырга тели, хәзер Сөенчалин алдында тагы ышанычсыз булып күренәсе килми, ә чынында исә егетнең ихлас хисләренә кырыслык күрсәтергә базмый иде.

Шул чак шау-шу һәм аяк тавышлары ишетелде. Егет Римманың караватыннан сикереп торды, кыз тиз генә мендәрләрне рәтләде.

— Ә-ә, безнең патшалыкка бүре үтеп кергән,— дип кәлә-кәлә, кызлар килеп керделәр.— Кулларыгызны күтәрегез, сез арестовать ителдегез!

Сөенчалин шунда ук шаярып кулларын күтәргән, бөрешкән, мескенләнгән булды.

— Арестовать итмәгез, җибәрегез, гомер буе сезгә хезмәт итәрмен,— диде егет ялварулы тавыш белән. Кызлар тагы көләргә керештеләр. Берсе өстәлдәге шешәне һәм шоколадларны күрде дә:

— Кызлар, бүренең кучтәнәче дә бар икән, әллә җибәрәбезме? — диде.

— Коткарабыз, коткарабыз,— дип шаулаштылар. Сөенчалин стаканнарга эчемлек салып, кызларга сузды. Алар бик шатланып, чытлык-

ланырга, сөйләшергә тотындылар. Яшь, чибәр лейтенант янында һәрберсе матуррак, акыллырак күренергә, үзенә игътибар иттерергә тырышты. Кызлар, һаман көлешә-көлешә, тост әйткәләгән булып, стаканнарны иреннәренә тигезеп алдылар.

— Римма «бүрене» йөрәгендәге көмеш читлеккә бикләп куйсын өчен!

— Юк, юк, читлек кирәкмәс,— дип кулларын селкеде егет.

— Читлеккә керергә теләмәсәң, башкасы да тәтемәс, гомер буе күке булып яшәрсең.

— Күңелләрнең аңлашуы өчен,— диде сары чәчле, буяган кашлы кыз.

— Ярату һәм тугрылык өчен!

— Ярату өчен димә, ярату тиз бетә ул,— дип, теге кыз егеткә карап алды, аның кашлары сикереп куйды.

— Алайса, бәхет өчен,— дип, икенче кыз һаман стаканын тотып торды. Аның сүзен ишетмәделәр. Ахырда тостсыз гына эчеп куйды.

Сөенчалин күзләре белән Риммага үзенең китәргә тиешлеген аңлатты һәм урыныннан торып, кызлар белән саубуллашты. Римма аны озата чыкты. Егетнең һаман кыз күңеленә тирән эз ясыйсы килә, аны үзенең холкы, теләкләре белән ныграк үзенә бәйлисе килә иде.

— Римма, әйдә, бер-беребезгә хыянәт итмәскә, бер-беребезне алдамаска, антмы? — Егет кызның йөзенә текәлеп карады.

— Кит әле, нәрсәгә ул! — Римма чирканган шикелле кашларын җыерды, йөзен чытты. Сөенчалин шунда аның баядан бирле рияланып кыланганын аңлады. Кызның тавышы да «нинди сабый акыллы син» дип көлгән шикелле иде.

Егет тә бик горур иде, шуңа күрә кызның бу мәнсезлеге аның минминлегенә барып тиде. Ул кимсенгән кыяфәт белән кинәт борылды да кул селтәп китеп барды.

— Тукта әле, тукта әле,— дип, Римма гаҗизләнеп дәште аңа, теге әйләнеп карамады.

## 16

Төнен тревога белән кузгалып, батарея беренче эшелонга чыкты һәм алгы сызыкка барып сугышчан позиция алды. Бәхеткә, батарея туры наводкага куелмады, пехотадан ике чакрым чамасы арткарак урнашты. Немецны тиз генә кузгатып булмас төсле, латышларның элеккеге крепостьлары тактик яктан бик уңай җирдә иде.

Икенче төнне алгы сызыкка барып, пехота траншеяларыннан берничә метр арткарак бер калкурак урынга күзәтү пункты блиндажы казыдылар. Мирхас, Үтәш, Шилов һәм Әнвәр, бер минут ял итмичә, таңга барысын да өлгерттеләр диярлек. Комбат вакчыл кеше түгел, шуңа накатны ике кат кына иттерделәр. Юкса, кайбер командирлар була, биш накатсыз блиндажга аяк та атламыйлар... Урман янда гына иде, немец пычкы тавышы яңгыравын, агач аударганны ишетепме, кул миномётыннан аткалады. Миналар агач ябалдашларына, ботакларга тиеп ярылды, сугышчыларга зыян китермәде.

Таң атканда, Мурзыевны ияртеп, Сөенчалин килде. Лейтенантны комбат үз урынына җибәргән. Мирхасны батареяга чакырганнар. Прорыв өчен орденнар, медальләр кайткан икән.

Сугышчылар:

— Миңа нәрсә? Миңа бармы? — дип кызыксынып лейтенантны сарыдылар.

— Комбатка Кызыл Байрак ордены,— диде Сөенчалин теләмичә генә. Аның ирене сәер бер киная белән өскәрәк күтәрелде.

— Ә сезгә нәрсә? — дип сорады Шилов, аңа туры карап. Лейтенантның ишарәсе аңа ошап җитмәде.
— Дүртенче Дәрәҗә Дан ордены,— диде Сөенчалин ризасыз гына.
— Комбатка Ленин ордены тиеш.
— Тиеш, тиеш, анда беләләр.
Сөенчалин Шилов белән бәхәсләшүдән тыелды, алгы сызыкта сержант аны бик ук тынламый иде, чөнки Шилов сугыш осталыгына бик чос, гаярьлеге белән дә лейтенанттан күп өстен иде.
Сугышчыларга медальләр, орденнар иртәгә кайтасы икән. Комбатның бүләкләнүе аларга чын шатлык китерде. Сөенчалинның комбаттан бераз көнләшкәнлеген дә сизми калмадылар. Сугышчылар белән комбатның мөнәсәбәтендә ара юк иде, шуңа аны барысы да үз итәләр. Сөенчалин исә үзе белән сугышчылар арасында дистанция тота, һәр эшеннән шул сизелеп тора, һәм бу нәрсә аның янындагыларга ошап бетми иде. Сөенчалин, командирга үзен тиешле югарылыкка кую кирәкле, дип саный. Солдат ул команданы ярата, шуңа күнеккән.
Инде яктырып килә, баш калкытырга да мөмкин булмаячак. Әнә берничә снайпер кыз үзләренең яшерен «ояларына» үтеп киттеләр. Алгы сызыкта хәрәкәт бетә, тик снайперның гына дуэле башлана. Кичсез бу тәбедән ычкынып булмый инде.
Көндезгә запас су алып калмаганнар иде. Эсселектән тамак кибә башлады. Шулай да дежурдан бушаганнар йоклыйлар. Сөенчалин белән Мурзыев стереотрубаны күзәтү өчен җайларга керештеләр.
— Ташла, куярга ярамый,— дип ачулана Шилов, ә Сөенчалин аңар үч иткән кебек һаман куярга куша. Аларның ызгышу тавышына Әнвәр уянды. Хикмәт шунда, кояш немец ягыннан төшкәндә стереотрубаны куярга ярамый. Сөенчалин, нурларның чагылу почмагын исбатлап, Шиловны шелтәли.
— Әйдә, куй, күзәтеп кара, бирер ул сиңа! — ди Шилов.
Сөенчалин — мин-минлекле кеше, үзенекен итәсе килә. Тик ниятеннән кире кайта, үзенең ахмаклыгын эчтән таный, сер бирәсе, сүзен аста калдырасы гына килми иде.
— Фазлыев, суга бар! — дип боерык бирде ул бераздан. Көн эссе, су юк, иреннәр сусаудан ярыла, сөйләшкәндә бер-ике сүздән туктарга мәҗбүр буласың.— Фазлыев, су алып кил!
Бу боерыкка Шилов та, Мурзыев та шаккатып калдылар. Блиндаждан чыгу белән немец снайперлары аны теге дөньяга озатачак.
— Ник малайканы алай итәсең, иптәш лейтенант? — диде Мурзыев, урыныннан торып.
«Ул ник мине күралмый икән? — дип уйлады Әнвәр.— Әллә комбат мине һәр вакыт үзе белән алып, ышыклап йөргәнгәме? Алгы сызыкка җибәрмичә, орудиеләр янында калдыргалаганга ачуы киләме?» Әнвәр әкрен генә китәргә әзерләнде. Ләкин блиндаж ишеге төбендә Әнвәрне Мурзыев кулы белән читкә этәрде, каешына ике баклашка тагып, үрмәләп чыгып китте. Сөенчалин көлемсерәбрәк карап торды, Шилов аңардан карашын читкә борды. «Менә шулай үзенең авторитетын бетерә бугай ул»,— дип уйлады Шилов.
Мурзыевны шәйләделәр, ахры, снайперлар ата башлады. Шилов шуңа колак салып утырды, пуляларның выжылдап очуыннан куркынычмы, түгелме икәнен чамалады. Беренче карауга әкрен кыймылдап торган бу казакъның куркыныч уртасында каушамый хәрәкәт итү сәләте бар. Ул бик ышанычлы шуыша, куркынычта ничектер үзен әйбәтрәк, иркенрәк сизә иде шикелле. Юк, бу ясалма гаярьлек түгел, аның табигатендә ниндидер бер чослык бар бугай. Әллә ул курыкмый торган бер гайре табигый кешеме?
Бераздан шуышып блиндаж чокырына Мурзыев килеп төште. Кулында котелок белән су, биләндә баклашкалар иде.

Әллә яраланганмы тагы? Котелок тоткасы буйлап каны агып суга тама иде.

— Ни булды? — дип, Шилов котелокны аның кулыннан алды.

— Сыдырып китте бугай.

Мурзыев баклашканың икесен дә лейтенантка сузды да үзе кесәсеннән бинт чыгарды. Әнвәр аның бармагын әйбәтләп бәйләп куйды. Сугышчылар, йокыдан уянып, котелокны бер-берсенә йөрттеләр. Бер генә йоткан кебек итәләр дә башкаларга бирәләр. Тик котелок Мурзыевка килеп җиткәндә суның юеше генә калган иде. Ул моңа кимсенмәде, эндәшмәде, кысык күзләрен ялтыратып бер карады да бетерде. Берәү булса, пыр тузып китәр иде. Мурзыев дөя кебек түзем, барысын да эчтән тынып кичерергә өйрәнгән. Әнвәр аның сабырлыгына, ачу туплавына соклана һәм үзе дә шулай булырга тырыша иде.

Ниһаять, кич булды. Кич — сәхрә инде, ашарга-эчәргә китерделәр.

Тәкәнәев немец һөҗүме вакытында батырлык күрсәткәне өчен бер атнага ял йортына җибәрелгән иде. Менә ул кайткан да бирегә линия сузып килгән.

Трофейный аппаратны блиндажга куйган Тәкәнәев трубканы Сөенчалинга тоттырды. Теге озак кына комбат белән сөйләште. Комбат бүген дә монда килә алмый икән әле. Аның Әнвәрне батареяга кайтырга боеруын Сөенчалин йөз җыерып кабул итте, бераз әрепләшеп тә алды. Комбат катгый гына әйткәч, лейтенант, ык-мык килеп, трубканы Тәкәнәевкә бирде.

Әнвәрнең Тәкәнәев белән сөйләшәсе килә иде, алар якташлар, аннары Казан турында бик кызыксынган нәрсәләре бар. Тик гәпләшергә һич җай чыкканы юк. Инде тагы булмады. Ул җыенган арада Мирхаска да батареяга кайтырга әйттеләр. Әнвәрнең бераз күңеле күтәрелеп китте, чөнки Мирхас үзенең батырлыгы белән Әнвәрне сокландыра, серле шикелле үзенә тарта иде.

Алар линия буенча, аны тикшерә-тикшерә атладылар. Мирхас Чистай-Ширәмәт төбәгеннән икән, туган җирен сагынып, кызык итеп сөйләп кайтты:

— Безнең күрше Бoҗыр кушаматлы кеше иде. Беркөнне моңа баҗасы кергән. Өстәлдә бер чәкүшкә генә аракы тора икән. Баҗа, гадәтемне беләсең, беренче рюмканы үзем эчәм, дигән Бoҗыр һәм эчеп куйган. Бераз башына киткән тегенең. Тамагы кымырҗый башлаган. Баҗа, дигән Бoҗыр, калганын сиңа салсам, бик әз инде, ни ултара-ни пылтара гына була, шуңа үземә генә салам. Әйдә, миңа начар булсын, дип калганын да эчеп бетереп куйган, ди. Мәзәк кеше иде, бик тапкыр телле, һич тә югалып калмас. Бервакыт Бoҗырдан сораганнар: «Берәр тапкыр синең үз гомереңдә дөрес сөйләгәнең бармы?» — дигәннәр. Теге уйлап-уйлап торган да:— «Әйе» дип әйтсәм, ялган булыр, дигән. Шулай Бoҗырны туганы очраткан да: «Ник бер дә безгә килмисең?» — дигән. Бoҗыр каядыр ашыга икән: «Миңа кирәк нәрсә синдә юк, сиңа кирәк нәрсә миндә юк!» — ди икән.— «Вәт, син кирәк өчен генә йөрисеңмени?» — дип, туганы шелтәле итеп моңа караган. «Әллә син кирәкмәс өчен йөрисең?» — дип, Бoҗыр китеп барган. Тагы бермәлне Бoҗырны председатель чакырткан да эшкә чыкмаган өчен бөтен халык алдында сүгәргә тотынган. Бoҗыр тыңлап торган да әйткән:

— Мондый начар сүзләрне, Кадыйр дус, син әйтмисең миңа, ә синең белгән властең әйтә, чөнки син миндә салып утырганда мине шундый мактаган идең,— ди икән. Председатель нәрсә әйтергә белми шып булган...

Икенче көнне кичтән үк яңгыр яварга тотынды. Эсселектән әлсерәгән җаннар бераз рәхәтләнеп китте, сулыш алуы иркенәйде. Тупчылар

бик шат булып, шаян сүзләр сөйләшеп утырдылар. Комбат яңа килгәннәрне матчасть белән таныштыра, ә Ваһапов халыкара хәл турында әңгәмә уздыра. Безнекеләр Белоруссиядә, Украинада зур һөҗүм алып баралар. Көн саен диярлек калалар азат ителеп тора. Безнең армия немецларны үз ояларына таба һаман саен ныграк кысрыклап бара...

Төнге сәгать унберләрдә элемтә өзелде. Немец болай атмаган да кебек иде бит, дип шикләнде Әнвәр. Шул танклардыр инде, төн булды исә, кирәкмәгән төштән йөреп, бөтен чыбыкны тәгәрмәчләренә урап алып китәләр. Тәкәнәев элемтәне җайсыз җирдән сузган, дигән уй белән Әнвәр линияне кулына тотып чапты. Бераз баргач, иңендәге аппаратка тоташтырып, тыңлап карады, юк, линия үлек иде. Тагы йөгерде. Шактый баргач тагы тикшерде. Яшен яшьнәп бөтен җирне яктыртып куя, аннары күк күкрәргә тотына. Нәкъ караңгы төндә «Катюшалар» аткан кебек картина тасвирлана. Ярты юлга җиткәч, тагы тикшергән иде, линия эшли. Күзәтү пунктында Мурзыев дежурда утыра икән, ул: линиягә Тәкәнәев чыккан иде, шул ялгады, әле үзе кайтып җитмәде, диде. Әнвәр, тынычланып, батареяга кире китте, ләкин ул килеп кергәндә инде линия тагы өзелгән иде. Бу юлы линиягә икенче элемтәче чыкты. Өзек ерак булмаган, ул тиз борылды. Әнвәр Мурзыевтан: «Тәкәнәев кайттымы?» — дип белеште, ләкин теге һаман юк иде әле.

— Әллә берәр хәл булдымы икән?

— Күрше батареяда аның дуслары бар, шунда олаккандыр,— диде Мурзыев үзенә хас исе китмәгәнлек белән. Ләкин Тәкәнәев тагы бер сәгать, ике сәгатьтән соң да кайтмады. Әнвәр моңа бик пошынып, тизрәк комбатка барып әйтте. Яктырып килә иде инде. Алексей Егорыч шунда ук Мирхас белән Әнвәргә линия буенча алгы сызыкка чаклы барырга кушты. Яңгыр туктаган. Аяк асты юеш, үләннәрдә су. Йокламаудан бөтен тәнне өшетә, куырылдыра иде.

Җирне кәҗә мамыгы төсле аксыл томан сарган. Шулай да күз ияләнгәч әйберләр ачык күренә. Мирхас пистолетын кулына тоткан килеш атлый. Мирхас бик ышанычлы, үткен егет, аның үзе артындагы әйберләрне дә сизә торган әллә нинди тойгысы бар. Фронта йөреп тәмам шомарган, пычакка әйләнеп беткән. Цельгә төзәп тормыйча, үзе чабып барган көе ата һәм тидерә.

— Син ник «тел» алырга йөрмисең? — дип сорады Әнвәр. Мирхасның осталыгы турында сөйләгәннәрне күп ишеткәне бар иде аның.

— Мин берүзем генә барырга яратам. Туң башлар белән туры килсәң, харап кына буласың.

— Ә барганың булдымы?

— Һи, без бер обер-лейтенантны алып кайттык.

— Хәзер җибәрмиләрмени?

— Язын полковой разведка белән баргач, засадага эләгеп, бары икебез генә исән чыктык. — Мирхасның дикъкате сак иде. Әнвәргә генә төбәлеп барган төсле тоелса да, урынны чамалап та өлгергән.

— Ярты юлны үттек,— диде ул һәм туктады.

Әнвәр линияне кулына алып, өскә тартып карады, чыбык авыр иде, димәк, өзелмәгән, исән-имин.

— Шалтыратып кара әле, кайтмады микән? — диде Мирхас, шыпырт кына җиргә чүгәләп. Әнвәр аппаратын линиягә тоташтырды, телефонда Шилов иде, Тәкәнәев әле һаман юк икән. «Биредән Мурзыев та эзләргә китте»,— диде йокылы тавыш.

Мирхас торды, пистолеты белән изәп Әнвәрне үзе артыннан иярергә кушты. Алда иңкү җир, ул тегендәрәк ниндидер бер кызгылт ярга тоташкан.

— Әнә ул,— дип кычкырды Мирхас һәм кинәт чабып китте.

Әнвәр әле берни белми, ышанмый. Иң элек күзенә чуар плащ-палат-

ка чалынды, шунда ук бер-берсеннән ерак түгел өч гәүдә аунап ята иде. Мирхас Тәкәнәев гәүдәсен танып алды.

— Карале, нәрсә булган монда? — Ул, аптырап, нинди нәтиҗәгә дә килә алмый йөдәде. Тәкәнәевнең йоклаган кебек тыныч, озынчарак йөзе чалкан киткән, әз генә маңгай туры газап белән җыерылган, яткан көйгә черем итә шикелле. Әнвәрнең буыннары калтырый, гәүдәгә якынаерга куркып, бу көтелмәгән хәлдән ни уйларга белми.

— Ну, биргән бу гансларга! — дип гөрелдәде Мирхас. Әнвәр дә зиһенен җыеп, бу гарасатны аңы белән кабул итәргә тырышты. Ә Мирхас һаман дәртләнеп сөйләнде.

— Беләсеңме, бу тәгаен немец разведкасы, «тел» алырга килгән.

Әнвәр аның сүзенә ышанмады, кибәк очыра дип уйлады.

— Безнең солдатлар ич болар, обмоткалылар.

— Гансиклар, алар еш кына разведкага шулай йөриләр.

Мирхас, Әнвәрнең һаман шикләнүен күреп, бер гәүдәнең бушлатын сыерды.

— Әнә вискоз күлмәк.

Әнвәрнең мондый күлмәккә бет ияләнми икәнен ишеткәне бар иде.

— Әйдә, хәбәр ит! — Мирхаска Тәкәнәевнең үлеме түгел, аның ике немецны тончыктыруы күбрәк тәэсир иткән иде. Ул әле бер, әле икенче гәүдә янына килеп, хәзинәгә юлыккан кеше кебек шулар белән әвәләнде.

— Мин, мин...— диде Әнвәр һаман карарсыз.

— Әй, кәбестә күбәләге, күрмисеңмени? Немец «тел» алырга килгән. Линияне өзгән дә ялгарга баручыны сагалап торган һәм «хоп!» — эләктереп тә алган. Ничек алар безнең тылга үткәннәр диген, менә шунысы аңлашылмый.

Әнвәр линия чыбыгы янына килеп тезләнде дә аппаратны асты, чыбыкның резинын әкрен генә әрчеде, ялгыйм дигәндә тагы туктап калды.

— Ә нигә үлеп яталар? — диде Әнвәр һаман безнең киемдәгеләрнең немец икәнлегенә ышанып бетмичә.

— Тәкәнәев герой, шуңа,— дип ачуланды Мирхас, Әнвәрнең зиһене чамалы булуына гажәпсенеп.— Аның кесәсендә «лимонка» булган, әнә, күрәсеңме, бөтен эчен актарган. Божрасын бик җайлы чакта тартып өлгергән, фрицлар аның ал ягында булганда тарткан! Вәссәлам! Ай-яй, ничек шәп эшләгән! — Әнвәр Тәкәнәев гәүдәсе янына атылып барды, тезләнеп, аның битенә кулын тидерде, чөнки кинәт ул ничектер үлмәгән, тере шикелле булып тоелды. Мирхас батареяга шалтыратты, ул арада Мурзыев та килеп җитте. Инде кояш чыгып килә, томан тарала башлаган, бу куркыныч урын, тизрәк сызарга кирәк иде. Мирхас тегеләрнең документларын эзләде, Мурзыев, чаука каеннар сындырып, носилка әзерләде.

— Бернинди кәгазьләре юк, сәер,— дип сөйләнде Мирхас, мәетләрнең кесәләрен актарып.— Безнең карабиннар белән, паразитлар! Әһә, менә нәрсә аларны сата! — Мирхас портсигар һәм кечкенә блокнот, зажигалка, тагын вак-төяк әйберләр тапты. Боларның немец разведчиклары икәненә аның шөбһәсе калмады.

Тәкәнәевне каен колгаларга салып күтәрделәр. Аның янында аппарат булырга тиеш иде, анысын таба алмадылар.

— Ә теге мәетләрне нишләтергә? — диде Мурзыев, болай калдырырга яхшысынмыйча.

Мирхас кулын гына селкеде...

...Мостафин янына беркөнне көтмәгәндә Галиев килде.

— Галиев абый, ну, ни хәлләр? — дип, майор аны якты йөз белән

каршы алды. Галиев складтан машиналар белән снаряд ташуда эшли иде.

— Әй, Мостафин туган. Өйдән хат алдым. Өч ел югалып торганнан соң, кинәт кенә исән булуыма ышанып житми язалар. Сөенгәннәр, башлары күккә тигән. Ничек болай булуымны кызларым төпченә, уны бетергәннәр. Әх! Нәрсә дип языйм икән, Мостафин туган?

Галиевнең шатлыгы ташый иде, шулай да аның эчендә курку, сагаю утыра. Мостафин аңа битараф жавап бирсә, үзенә кара инде, Галиев абый, дисә, үз намусыңнан сора, дисә, аның салкынаюын күрсәтер иде, ләкин нинди киңәш бирергә язмыш суккалап-типкәләп, изеп-таптап бетергән бу кешегә? Күренеп тора: кешенең мин-минлеге юкка чыккан булган, ә хәзер әнә аруланып килә шикелле.

— Берни дә язмагыз, Галиев абый,— диде Мостафин, уйланып торгач.— Төрле күнелсезлекләр булуы мөмкин.

— Әйе, шулай, бик рәхмәт, туган! Әгәр сез булмасагыз... Аның тавышы кинәт калтырап өзелде, күзләреннән яшьләре тәгәрәде. Бу шатлыктан, туган! — диде ул, ашыга-ашыга һәм күзләрен сөртеп, шунда ук эш кыяфәтенә керде.— Әмма, тузан,— дип, тагы сүзен дәвам иттерде:— теге вакытлар искә төшә дә эчләрем әрнешә хәзер. Күп кенә эшләр миннән торган, ә мин чи дурак булганмын. Мине, туган, алгы сызыкка күчерә алмыйсыңмы дип килүем инде?

— Ярар, Галиев абый,— диде Мостафин, уйларыннан котылу өчен.— Батарея расчетына билгеләргә булыр.

— Рәхмәт, туган! — Галиев капылт урыныннан кузгалды да, Мостафин карарын кире алмасын дип курыккан кебек, тизрәк чыгып китте.

Мостафин Галиевкә ачуы юк икәнен тагы үзенә-үзе икърар итте. Ә ачуы булса, нишләр иде ул? Ачуын кайтарыр идеме? Юк, ачу алмас иде! Аның урынында бүтән кеше — кимсеткән өчен гомер буе ачу саклый торган кеше булса? Ачу кайтарырга жай эзләп кенә йөрсә? Ачу бит йоклый торган тойгы түгел! Ачуның иясе булса ярый, минем очракта ул — Галиев. Ә ачу иясе булмаса, сукыр ачу булса? Ачу бит, яшен кебек, бушанырга жай, сугар нәрсә эзли... «Яшен» иң якын ноктага суга! Сугышта шундый нокта — Ватан...

Мостафин бер төр хыянәтнең башлангычын шундый психологик халәт белән аңлатмакчы булып, уйланып утырды. Аның кызыклы уйларын икенче орудие командиры Черняев бүлдерде. Ул военторгка папирос сатып алырга килгән иде, сугышчы Тәкәнәев турында сөйләргә дип комдив янына кергән. Мирхас фриц разведчикларыннан алган вак-төяк әйберләрне, бигрәк тә язмалар белән тулы блокноты Мостафинга күрсәтергә дип әйткән иде. Черняев кесәсеннән кәгазьләр чыгарып өстәлгә куйды.

— Менә, егет, югалып калмаган! — диде Черняев, бу батырлыкны ничек исемләргә белмичә.

— Ишеттем, таң калырлык хәл бу! — дип, Мостафин урыныннан торды, аның йодрыклары төйнәлгән иде.

— Сугышчылар бу хакта газетага язуны үтенәләр, иптәш майор!

— Рәхмәт! Ул турыда уйладык: листовка чыгарып, бөтен фронтка таратачакбыз. Газетага да язылачак.— Мостафин өстәлдәге кәгазьләргә иелде.

— Әх, жәл, егет жәл! — Мостафинның яңагында бүлтәймәләр беленде. Ни әйтергә белмичә аптырап калды.

— Гел батырлык эшләр төсле түгел иде ул, бик йомшак, тыңлаучан иде! — Черняевның тавышы аптыраулы, кызганулы, хәлне берничек тә үзгәртеп булмаудан гажиз иде.

— Ваһаповка әйт, аерым бүләк документлары әзерләп китерсен.

— Фрицларның хет берсе исән калмаган, сорау алырга шәп булыр иде, ичмаса.

— Ниемә ул? — диде майор.

Черняев моны аңлап җитмәде.

— Күп нәрсә әйтерләр иде.

— Һе, безнең көчләр аларныкыннан берничә мәртәбә артык хәзер,— диде майор, кәгазьләрне актарып. — Безнең алда ни исемле немец часте тора — анысының әһәмияте юк. Тизрәк дөмектерергә — шул гына!

— Кыйнарга кайсы да бер, һе-һе!..

— Нәкъ!

Черняев сөйләшү тәмамланганны аңлады, Тәкәнәевнең кызылармеец книжкасын алып, ишеккә таба борылды. Нәкъ шул минутта майорга шалтыраттылар. Телефоннан сөйләшкәндә аның маңгае бер җыерылды, бер язылды...

...Фира Алексейны көтә иде, ләкин нигәдер ул озаклады. Буш минутларында Фира аны гына уйлый. «Ә Рәшит нигә минем искә төшми, ник мин аны уйламыйм?» — дип, Фира үзен-үзе битәрли, шелтәли. «Бу инде намуссызлык!» дип, үз-үзенә ачуы килә. Ләкин нишләргә? Үз-үзен көчләп уйлый алмый. Ул үзенең намусын да көчләп карый, юк, аны тәмам Алексей биләгән, бөтен төшен ул яулаган, җанында бүтәннәргә һич урын калмаган шикелле. Бу шулай була микәнни? Үткәннәрнең бер дә эзе калмый микәнни? Һәммәсе беренче мәхәббәт, беренче хисләр, беренче төн, беренче кавышу дип үлеп сөйлиләр, ә миңа беренчесе бөтенләй булмаган да кебек. Барысы да икенче очрашу, икенче хисләрдән башланды. Ә беренчесе вакытында мин гүя йокыда булганмын, тәмле йокымны бүлмичә, битараф йоклап яшәгәнмен, ә менә хәзер генә уяндым. Уянып, күзне ачу белән, кояш нурларының нинди матур икәнен беренче күргән кебек булдым. Нинди рәхәт яктылык, нинди рәхәт киңлек! Суларга нинди рәхәт, тәмле һава! Моңарчы күргән газапларым бөтенләй булмаган да кебек тоела.

Фира биредән китәргә кирәк булачагын тоя, чөнки аңарда үзен сиздерә башлаган бүтән җан иясе шуны таләп итә. Ләкин ул һич тә китүенә ышанмый. Ничек ул Алексейдан аерылып китә алсын? Юк, бу мөмкин түгел! Ә бит биредән китү котылгысыз булачак... Юк, юк, ул хакта уйлыйсы килми. Аңардан башка Алексейга да бик авырга туры килер. Ә Алексейдан башка ул япа-ялгыз, ятим шикелле. Алексейга әйткәне дә бар: «Син үзеңне саклабрак йөр, син минем өчен әти дә, әни дә, абый да, апа да», Алексей матур итеп, шатланып көлде генә:

— Каян син барысын да шулай табасың? — диде.

— Тапмыйм, күңелемдә булганны әйтәм.

— Шулайдыр да, сакланып кына йөреп буламыни? — дип, Алексей уйга калып торды, бу сугыштан аның ничек туйганлыгын, сугыш аның хыялларына һәм гамәлләренә ничек аркылы торганлыгын аның гаҗиз карашыннан тоярлык иде.— Характерны үзгәртеп булмый инде, Фира,— дип өстәп куйды ул.

— Син бик юл куючан, Алексей, үзеңә бәла килер дип курыкмыйсың. Командирга катырак булу да әйбәттер.

— Әйдә, бу хакта сүзне бетерик, Фира! — диде Алексей. Ул Фираның мондый дәгъвалары аны үз холкына иплəндерергә тырышудан түгел, ә яратудан икәнен аңлый һәм аңа каты бәрелми иде...

Көтә торгач, Алексей килде. Төрле ашамлыклар тутырып килгән. Фира табын әзерләде.

— Сөенеч бар, Фира, — диде Алексей, консерва ача-ача. Ул Фираны үзгәргән кебек күрде. Аның беленер-беленмәс матур сипкелләре ничектер куерган шикелле, йөзен борчу-хафалану әлпәсе каплый башлаган сыман.

— Нинди? — дип, Фира ягымлы карашын аңа төбәде. Алексейның озынча бите, киң кияге тагы да матур булып тоелды.

— Станциядә яралыларны эшелон белән Казанга озаталар. Син шуларны илтүче врач.

— Ничек? Чынмы? — диде Фира, моңа ышанмыйча. Беренче карашка бу сөенеч кебек, ләкин хатын өчен бирелән китү мөмкин түгел сыман тоела иде әле. Димәк, китәргә?

— Чын, менә бөтен кәгазьләр әзер! — дип, Алексей, шатланып, түш кесәсеннән кәгазьләр чыгарды. Кинәт карашын Фирага туктатып: — Син әллә шатланмыйсыңмы? — диде.

— Шатланам, әлбәттә,— диде Фира, сер бирмәскә тырышып. Һәм иренең бушаган савытына чәй агызды. Алексейның тырышлыгын бәяләмәгән кебек иткәнен сизәргә өлгерде һәм шунда ук елмаеп аның беләгенә асылынды. — Мин шат та, түгел дә... Мин китәм, син каласың... Мин тагы ялгызым?

Алексей аның күпереп торган коңгырт чәчләреннән сыйпады, тәмле исен татыды. Чынында Алексейның аны җибәрәсе килми, шулай да анда тылда Фирага яхшырак булыр, дип инана, аннары үзен хуҗаларча тоеп, булачак тормышны кайгыртасы килә. Чөнки Фира аның халәтен әзгә генә булса да табигый хәленә кайтарган, менә хәзер яңа гамь һәм теләк белән төсмерләнгән вөҗүде шуны таләп итә иде. Ул Фирага биредән китү бик кыен булуын да аңлый.

— Бу иң әйбәт җай, Фира, — диде Алексей.—Просто синең бәхетең!

Фира матур соры күзләре белән бер ноктага текәлеп торды.

— Бәхет, бәхет, о, минем бәхет?! — диде хатын, тирән итеп көрсенеп куйды, үзе дә бу көрсенүен яратмады, көннән-көн үзгәрә баруына ул әле һаман күнегеп җитә алмый иде. Үзен артык нечкәргән, иркәләнә башлаган кебек итеп тоя һәм үзенә-үзе ачуы килә, соңгы көннәрдә Алексейның күңелен шуның белән тырмыйм, бидерәм дип курка һәм үзен нормага китерә алмый эчтән газап чигә иде.

Ашап-эчкәч, Фираның караватына кырын яткан килеш, Алексей төрле планнар корды, алда нилэр буласын, аларны нинди хәлләр көтәсен гөман итеп, шаярып маташты. Фира аның кулын ике учында иркәләп, аны тыңлап утырды.

— Әйе, кайту проблемасы хәл ителде. Беләсеңме, күпме чаптым? Барысын да Мостафин җайлады. Кайтасың, госпитальгә эшкә урнашасың. Миңа бер малай табасың, әйеме? Бел, мин сиңа малай заказать иттем!—дигәч, икесе дә бер-берсенә карап көлештеләр. Фира башын аскарак иеп, беләм, беләм, дип ияген какты. Алексей тынып калды.

— Шуннан? — дип, Фира аның кулыннан тартты.

Алексей ничектер бүтән нәрсә уйлаган кебек, дәшми торды.

— Шулаймы? Сугыш бетә, мин синең яныңа кайтам!

Тагын икесе дә тынып калдылар, чөнки бу хыялның тормышка ашуы өчен чыгып булмаслык үткелләр, кичеп булмаслык диңгезләр, тәмуг кебек утлар бар иде әле... Шул нәрсә хыялның кинәт утын сүндергән кебек итте.

— Алексей, ачуланма тагы, ә бит син тыл армиясенә күчә аласың, әгәр теләсәң? Аягыңдагы яраң һаман төзәлми, эренләп тора, ә?

— Мостафин җибәрми мине, — дип кешегә сылтамакчы булды Алексей, шулай Фираны юатмакчы иде.

Ләкин бу кеше артына посарга, ышыкланырга тырышуның чынлыкка туры килмәгәнен Фира бик яхшы белә. Ул фронтка ашыкканда хәзерге хәлгә төшәрмен дип күз алдына да китермәгән иде, хәтта хыялы белән дә Алексейның хатынына әйләнүенә барып җитә алмаган иде.

— Сине намусың җибәрми, Алексей, — диде Фира.

Икесе дә, бер-берсенең ялганын тоткан кебек, бер-берсенә карап елмаялар, бер-берсен кичерәләр, гафу итәләр. Ир белән хатын шулай

була торгандыр инде ул, дип уйлый Алексей. Бу яңа вазифа, ир вазифасы аңарда әллә нинди фикерләр, ниятләр уята иде.

— Әгәр квартир белән уңайсызлык килеп чыкса, шунда ук миңа хәбәр сал, яме! Безнең полковник Кимбр мине бик ярата. Мәскәү аша гына эш итә ул!

— Шуның яратуыннан файдалан, тыл армиясенә күч, Алексей. — Фираны ни борчыганын Алексей аңлады, үзенең күңеленнән бу мәсьәлә буенча «верховный совет» оештырып алды, юк, мөмкин түгел, дигән фикергә килде. Сәбәпләрен аңлатуны артык санады. Күңелнең бөтен тойгыларын әйтеп бетереп буламыни? Шулай да Фираны тынычландырырга кирәк, болай үзсүзләнергә ярамый, аңа авыр килүе мөмкин дигән нәтиҗәгә туктады.

— Дәгъваң хаклы, Фира, менә прорывтан соң, мин, мөгаен, синеңчә эшләрмен,— диде Алексей. Хатын шунда ук җанланып китте, аның куера башлаган сипкелләре юк шикелле булды, йөзен сөенеч нуры яктыртып җибәрде. Фираның Алексейның шушы карарын аның күңеленә тирәнрәк уйдырасы килде.

— Без бит хәзер үзебез генә түгел, — дип, үрнәп килгән өченче җан иясен дә үз теләге ягына ава башлаган үлчәү тәлинкәсенә салырга җөрьәт итте. Алексей елмайган көе, дәшми генә, Фираны тыңлады. Хатынның тавышы аңа ниндидер бер музыка шикелле тоела иде. Юк, ул аны аңлата алмас иде, ә музыканы шәрехләргә кемнең генә көче җитә? Фираның йөзендә уенчаклык, шаянлык кабынды.

— Син нинди исемнәр яратасың? — дип, Алексейның кулыннан, бармакларыннан тартты.

— Нинди исем? Син татар, мин рус, шулай булгач, интернациональ исем инде, ә?

— Кыз булса, Ландыш, ә малай булса... Әйдә, шобага тотышабыз?— диде Фира һәм кульяулык чыгарып, аны бөтерде. Бер очыннан тотып, Алексейга якын китерде, икенче очын үз бармаклары арасына кыстырды.— Кем башка чыга, шуның яраткан исеме куела.— Алексей көлә-көлә, Фираның мәзәген кабул итте.

— Иң элек яраткан исемнәреңне әйт.

— Альберт, Римма,— дип тезде Алексей.— Ә синең? Артык матур исемнәр кирәкмәс.

Фира бераз уйлаган итте дә:

— Булат, Динә, — диде.

Алар тотыша башладылар, бармакларын берсе өстенә берсен куйдылар. Кульяулык очы кечерәйгәннән-кечерәя барды. Фира бармаклары арасына кыстырганнан әз генә калды, Алексей шырык-шырык килеп үзенең баш чыгуын тантана итте.

— Менә бармакларың белән син яулыкны өскә чөяргә тиеш, әгәр шулай итә алмасаң, мин баш,— дип шыркылдады Фира.

Алексей кульяулык очын бармаклары арасына кысты һәм кульяулыкны өскә чөйде, кульяулык сүтелеп, һавада җәелде дә әкрен генә төшеп китте. Икесе дә шатланып көлештеләр. Шул чак палатка тышында:

— Мөмкинме?—дигән тавыш яңгырады. Штаб элемтәчесе килеп керде, Алексейны штабка чакыруларын әйтеп, тиз генә чыгып та китте.

— Иртәгә таңда кузгаласыз, Фира, мин озатырга килермен. Ну, хәерле! — диде Алексей борчулы һәм киеренке бер тавыш белән. Башына фуражкасын киде. Фира аны муеныннан кочаклап күзләренә текәлеп торды.

— Барысы да әйбәт булыр, Фира, кайгырма!

Хатын аңардан кулларын ычкындырды, ни әйтергә белмичә аптырап калды... Тик Фира исен җыеп өлгергәндә, аның каршында Алексей юк иде инде!

Аны озатырга ул килә алмады. Таң алдыннан машина яралылар белән Фираны ике йөз чакрымдагы станциягә алып китте. Хуш, хуш, Алексей җан!

Ә шул көнне сәгать уннарда безнең һөҗүм башланды. Сул флангта һөҗүм таңнан ук бара иде инде. Чолганыштан куркып, немец бу ныгытылган районнан үзе ычкыныр дип гөман ителгән иде. Тик алдан уйлаганча ук булып чыкмады. Сул флангта фрицлар бик каты каршылык күрсәттеләр. Бирсдә исә безнең пехота, беренче мәртәбә атакага күтәрелеп караса да, алга бара алмады, траншеядан берничә адым китү белән дошманның тернәкләнгән пулемет уты ятарга мәҗбүр итә иде.

Алексей стереотрубадан ут нокталарын күзәтеп, шул урыннарга ату өчен цельләрне кычкыра, Әнвәр телефоннан саннарны батареяга, орудиеләргә китерә. Бөтен орудиеләргә бер квадрат-цель бирелә, димәк, залп белән атарга тиешләр.

— Прицель шул ук, уңгарак 06, огонь! — Алексей немец траншеясы өстендә балчык болыты күтәрелгәнен күрә. Ләкин бу беренче траншея, атканда немец бетон ныгытмаларына ышыкланып тора, ату туктадымы, кире чыгып безнең пехотага ата башлый. Аның пулеметларын нәкъ шуңа күрә берәм-берәм юк итәргә кирәк. Немецлар пулеметларын запас ояларына күчереп йөртәләр.

Тактика таләп иткәнчә, Алексей билгеләнгән цельләргә генә түгел, ихтимал, булганнарына да залп белән һәм сыңарлап аттырды. Нәтиҗәдә бер сәгатьтән соң безнең пехотачылар атакага күтәрелеп, дошманның беренче траншеясына һәм ныгытмалы дотларына бәреп керә алды. Әмма уң яктагылар артта калды. Атакага күтәрелгән пехота нейтраль зонада ятарга дучар булды. Командирлар телефонда талашырга тотындылар. Пехотачылар артиллеристларны гаепләделәр, артиллеристлар пехотаны эттән алып иткә салдылар. Безнең фланглар ачык калды. Шуңа күрә Алексей уңдагы батареяның күзәтү пунктына барды. Тәҗрибәсе җитеп бетмәгән бер яшь комбатка шактый озак булышып азапланды, үзе цельләр күзәтеп, үзе шуларга аттырды. Ниһаять, өйләдән соң немецны урыннан кубардылар. Пехота алга китте, аларның һөҗүмен танклар ныгытты. Кичкә таба немецның бөтен фронт белән чигенүе беленде. Ул, гадәтенчә, юлга арьергардлар куя иде. Пехотачылар шулар белән бәрелешә-бәрелешә алга бардылар. Немец барыбер еракка ата торган авыр туплардан атып торды.

Пехота алга киткәч, безнең орудиеләр утны тирәнгә, немец тылына күчерделәр. Алдан билгеләнгән квадратларга атыш ясадылар.

Кояш офык артында ут шары булып кызарып торган мәлдә, батареяга атуны туктатырга һәм алга күченергә приказ килде. Алексей тәмам хәлдән тайган иде, сугышчылар җыелган арада окоп читенә чыгып утырды. Эх, Фираны озатырга барып булмады, киткәндер инде, дигән уй күңелен чәнчеп алды. Шулай да прорывтан исән-имин чыгуына шатланды, безнең көчнең немецныкыннан күпкә өстен булуын тою шулай ук җанга зур канәгатьлек бирә иде. Хәзер сугыш озакка бармас төсле, тагы бер-ике тапкыр шушындый ут — и немец капут! Юк инде, тылга күчәмме соң! Юк, Фира миңа ачуланмас әле. Гаҗәп мөлаем ихласлыгы белән мин-ташны йомшартып үзенә беркеттерде дә куйды бит. Озатырга килер дип өзелеп көткәндер инде ул, их!..

— Иптәш комбат, телефон! — дип, Әнвәр блиндаж авызына чыгып кычкырды.

Алексей урыныннан торырга гына өлгерде, кинәт күзендә ялкын чагылуын күрде, әмма шул секундтагы каты шартлауны ул ишетә алмады, башына ярчык тиеп аңсыз егылды...

Сугышчылар килеп җиткәндә, ул тынсыз иде инде.

Авыр снаряд төшүен Әнвәр дә күрмәде, аркасына нәрсәнеңдер бик каты сугуын гына тойды, үзенең каядыр атылып мәтәлгәнен чамалады, күз алды бермәл кап-карангы булып торганын ачык хәтерләде.

— Алексей Егорыч?! Иптәш комбат! — дип кычкырды Әнвәр.

— Алексей Егорыч һәлак булды,— дигән тавыш ишетте ул. Аны күтәреп баручылар әйтте, ахры, моны.

— Ничек?! Тукта, тукта!

Ләкин тегеләр, ишетмәгән кебек, каядыр баралар. Тик Әнвәрнең күз алдында тагын бөтен нәрсә изелеп җәелгән шикелле булып, үзләренең рәвешләрен югалттылар.

Ваһапов бөтен батареясы белән бирегә килгәндә комбат Алексей Барановның канлы гәүдәсе плащ-палаткага салынган иде. Старшина алдан өлгергән, барысын да хәстәрләгән. Ваһапов нәрсә уйларга, ни исәпләргә белмичә коты очып карап торды. Кинәт аяк асты җимерелеп, убылып киткән кебек булды. Бу хәлне аның зиһене кабул итә алмый изаланды. Ничек инде бу? Ничек болай килеп чыкты әле? Бик күп үлемнәрне башыннан кичерсә дә, аңа үлемнең моңа кадәр шул чаклы каты китереп сукканы юк иде әле. Ә Мостафинга бу хәбәрне ничек ирештерергә, аңа ничек җавап бирергә? Бөтен фронт буенча алга кузгалган бер минутта бит?! Алмаштырмаслык кешеләр булмый дип әйтәләр дә, юк, дөрес түгел! Алексейны минем җанда кем алыштыра алсын? Ә аның сугышчан дусты һәм хатыны Фирага ничек хәбәр итәргә? Кайтып җиту белән аңардан шатланып, сагынып хат киләчәк!..

Бер минут эчендә башта диңгез дулкыннары кебек, берсен-берсе куып, берсен-берсе ишеп, берсен-берсе бөтереп бик күп фикерләр узды, ми ярларына бәрелеп, һаман кыйнап торды.

Сугышчылар каберне казып бетерделәр. Замполиттан соңгы сүз көткән кебек тынып калдылар.

Кинәт башына төшкән бу кайгыдан Ваһапов барча агитаторлык сәләтен югалтты. Хәрби тәртип шуны таләп итсә дә, ул сөйли алмады. Биредә сүз сөйләү артык иде, сүзләр урынына күз яшьләре генә тамды. Бермәлгә бар нәрсәнең дә асылы, мәгънәсе беткән кебек тоелды. Җирдәге әйберләр, хәрәкәт — барысы кешенең тере булуына нисбәтән рәвештә генә мәгънәгә ия булалар икән. Ваһапов шул хакыйкатьне белде.

Сүзләр көчсез, кабер өстендә автоматтан салют бирүләр көчсез, шыксыз бер талпыну булып тоелды...

Комбатны Латвия белән элекке Россия чигендәге билгесез бер калкулыкка җирләделәр. Ваһапов, дустының кабере югалмасын өчен, аңа иртәгәме, берсекөнгәме килеп чардуган куярга ниятләп, машинага утырды, кабинкада ут яндыртып, картада кабер урынын төгәл билгеләп куйды.

Машиналар дәррәү кузгалдылар, чигенүче дошманны эзәрлекләп барырга, аңа тын алырга бирмәскә кирәк иде...

**Шәриф Биккол,**
башкорт шагыйре

## Фаҗигадән туган дүрт жыр

●

Чили бүген
матәм киеме кигән,
әмма
Чили кәфен кимәгән;
хәсрәт,
үчтән
йөзе кара көйгән,
иллә-мәгәр
башын имәгән!

Гориллалар шаша:
канлы террор
котырынганнан бара котырып.
Корыч пружинадай кысыла Чили
хунта шашынганнан отыры.
Һәр нәрсәнең була
соңгы чиге:
ут дөрләтә нәфрәт очкыны.
Чили — пружина,
кысылыр-кысылыр да,
тоталмаслар аны — ычкыныр!
Гориллалар шаша һаман...
Моннан
ота түгел,
алар отыла:
пружина бит
күпме нык кысылса,
шул тиклем үк көчле атыла!

●

Бар гомерең —
тарих уч төбендә,
халкың күңелендә,
Альенде!

Син барында
дусның
рухы үсте,
палачларның коты алынды.
Син сафларда
килдең
алгы рәттә,
йөзенә-йөз терәп дошманның;
туган Җирең — азат,
аналар — шат,
балалар тук булса,
хушландың.
Соңгы минутларың сукты...

Ә син,
ихтирамын яулап галәмнең,
хунта башын бермәл идертәчәк
көрәш байрагына әйләндең!
Әнә,
Чили бүген
шул байракның
каршысына басып,
баш сала.
...Көрәшчеләр өчен
үлемсезлек
яуда аугач кына башлана...

Бирелмәгән сыман вәхшиләргә
иптәш Карлос,
иптәш Корвалан,
батырларың ант итәләр:
— Чили,
сиңа туры калды һәр балаң!
Кул кушырып түгел,
ут яудырып,
хунта көлен күккә очырып,
тизләтикче
үч кайтарыр көнне —
Азатлыкның яңа таң чорын!
Яттан белә моны һәрберебез,
бу хакыйкать
безгә сер түгел:
ирмен дигән ирләр
тез чүкмиләр,
тез чүктеме,
димәк —
ир түгел!

Баш имәгән кебек вәхшиләргә
иптәш Карлос,
иптәш Корвалан,
көрәш учагына ташлый үзен
бүген, Чили,
синең һәр балаң!

●

Канәферләр,
әнә,
баш калкыта,
сәлам биреп дөнья йөзенә.
Мин аларны
сезнең истәлеккә
утырттым бит үткән көз генә...
Бурлат-кызыл чәчәк атар алар,
тере комач итеп җир өстен;
бу чәчәкләр
хәтерләтеп торыр
ярагыздан аккан кан төсен,
Чили күген иңләп,
бер барыбер
гомерлеккә балкыр таң өчен!

1973—74.
Уфа

# ЭНҖЕ МӨЭМИНОВАГА 50 ЯШЬ



*Каләмдәшебез Энҗе!*

*Гомер уртасына Сез тормыш тәҗрибәсенә баеп, шигъърият белән канатланып килдегез. Алтмышынчы еллар башында татар әдәбиятында хатын-кызлар поэзиясенең яңа битен ачып җибәрүче — Энҗе Мөэминова дисәк, шәт, ялгышмабыз.*

*Хезмәт героикасы белән сугарылган «Әткәм чүкеченең тавышы», туган илгә мәхәббәт, дуслыкка дан җырлаучы «Ефәк яулыгым» поэмасы һәм шул исемдәге беренче китабыгыз белән Сез әдәбиятка үз юлыннан килүче шагыйрә булып танылдыгыз.*

*Тәрбияче, укытучы, җәмәгать эшләрендә актив катнашучы коммунист буларак, тормышта сайлаган юлыгызга Сез иҗатыгызда да турылыклы. Нәниләргә дә, үсмерләргә дә, өлкәннәргә дә әйтер сүзегез бар. «Әниләргә һәм нәниләргә», «Синең өчен язам», «Шигырьләр» — бу китаплар укучыны илгә хезмәт итеп, зур максат белән яшәргә чакыралар.*

*Киләчәктә дә иҗат чишмәгез кипмәсен, тормыштан алган илһам белән укучыларга яңа зур әсәрләр бүләк итегез! Сезгә сәламәтлек, озын гомер һәм тынгысыз иҗат шатлыклары телибез!*

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ,
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕ.

## Туган илем минем

Кулым тисә,
туфрак алтын була.
Тирем тамса,
шыта гөл булып.
Күкрәгемдә туган җылы хисләр
Яңгырыйлар матур җыр булып.
Җиргә бассам,
арта егәрлегем,
Күккә баксам,
иркен тын алам.
Туган илем минем —
газиз җирем,
Мин бәхетле синең бер балаң.

## Ир-егетләр

Ир-егетләр — бөгелмиләр авырлыктан.
Ир-егетләр — үз иленең данын тоткан!
Ир-егетләр — яу тотканда дан казана,
Ир-егетнең җилкәсенә ил таяна.
Һәр эшеннән, торышыннан танып алып,
Ир-егетне Ил агасы итә халык.

## Беләм

Тирләр түгеп эшләп тапкан
Икмәкнең тәмен беләм.
Каннар коеп яулап алган
Тормышның ямен беләм.

Илгә бәхет яулап үлгән
Әткәмнең каберен беләм.
Тормышымда юлдаш булыр
Дусларның кадерен беләм.

## Язмышлар

Авылым!
Һәр адымым минем,
һәрбер эшем
Бәйле синең белән.
Мин бит синең һәрбер куагыңның
исен, төсен беләм.
Гомеремнең иң-иң матур чагы,
авыл, синдә үтте.
Балаларым тәүге сукмакларын
синнән башлап китте.
Шатлыкларым минем, кайгыларым
уртак синең белән.
Мин бит синең һәрбер өлкәнеңне,
сабыеңны беләм.
Мин битараф булып яши алмыйм
алар тавышына.
Минем язмышым да катнашкан бит
алар язмышына.

## Нык нигез

Коммунист-ветеранга

Биек йорт. Күп катлы.
Җемелдәп ут яна.
Иң биек каттагы бер залда
туй бара.
Икенче бүлмәдә бер егет
Туган көн мәҗлесен үткәрә.
Дуслары кул чабып, тәбрикләп,
Ширбәтле бокаллар күтәрә.
Берсендә карт белән бер карчык
Чәй эчә икәүдән-икәүләп.
Берсендә яшь ана нәниен —
Сабыен йоклата иркәләп.
Берсендә дус-ишләр гөрләшә.
Берсендә яшь парлар серләшә...
Кыскасы —
бу нигез ташына
Төялгән шатлыкның барысы да!..

Тик менә,
кайсыдыр бүлмәдә
Бер агай сыкранып йөткерә.
Берсендә бер өлкән апабыз
Сулышы буылып интегә.
Берсендә...
Юк, җитәр хәзергә.
Мин шушы бүлмәдә тукталам...
Бүлмәдә яп-якты ут яна.
Өстәлдә — канәфер чәчәге.
Көмештәй җемелди чәчләре.
Ул — Ленин чордашы.
Большевик.
Шаһите — давыллы елларның.
Сөйлисе сүзләре күп аның!
Ул тели кычкырып дәшәргә
Шатлыктан исергән яшьләргә:
«Бәхетнең кадерен белегез!
Бик кыйммәт түләдек без аңа.
Мин сөйлим, тыңлагыз, килегез!..»
Тик тыны кысылып туктала.
Бүлмәдә яп-якты ут яна...
«...Кичердек без ачлык газабын.
Төрмәләр газабын кичердек.
Татыдык без кулак камчысын,
Сугышлар дәһшәтен —
күп күрдек.
Бүген дә сыкратып алалар
Йөрәктә сакланган яралар...»

Урамда,
таң нуры каршында
Биек йорт —
нык нигез ташында.
Нык нигез күтәргән таш йортны.
Өлкәннәр күтәргән
Күп катлы бәхетне, шатлыкны!
Онытмыйк без шуны.

## Аңладым мин

Минем өчен һәр сөенеч, көенечтән
Әниемнең күзеннән яшь коелуын,
Ачу килеп сукканда да кулларының
Нигә болай йомшак булып тоелуын
Яшь чагымда һич тә аңлый алмадым мин!..

Мәхәббәтне акыл белән кушу өчен
Күпме көч һәм түземлелек кирәклеген,
Тискәрелек, көйсезлекне җиңү өчен
Нинди иркен күңеллелек кирәклеген
Үзем әни булгач кына аңладым мин!

## Хатлардан юллар

Улы яза:
«Борчылма син, әни,
тыныч бул син,
Мине уйлап татлы йокың
бүленмәсен.
Мин бит постта, әни,
һәр чак уяу!
Кулда корал минем,
күңелемдә син...»

Әнисе җавап бирә:
«...Эш белән тиз үтеп китә,
улым, көннәр.
Тик нигәдер озынайды
җәйге төннәр.
Тик нигәдер күбәйделәр
салкын көннәр.
Көз көненең яңгырлары
санын беләм,
Кыш хәтердә бураннары
саны белән.
Үзем өйдә, күңлем белән
тышта шул мин.
Еллар буе синең янда
постта шул мин.
Һәр минутта, һәр секундта
янымда син,—
Минем шундый тынычлыгым
сагында син».

Солдат булган чакта балалар,
Ничек тыныч булсын аналар?!

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**МАЙ, 1973 ЕЛ.**

«Тугызынчы бишьеллыкның дүртенче елында Чаллы шәһәрендә гигант автомобиль заводы — КамАЗ сафка басачак. Яңа, күп йөк сыешлы зур машиналар өчен корыч йөрәкләрне Ярославль мотор төзүчеләре ясый. Хәзер аларның куәтенә, ныклыгына, экономиялегенә сынау бара...

Заводның уку-укыту үзәге автогигантка кадрлар әзерләүдә ярдәм итә. Предприятиенең белгечләре уку классларында һәм турыдан-туры цехларда КамАЗ өчен 500 гә якын квалификацияле эшчеләр әзерләделәр.

Хәзер биш группада Чаллыдан килгән тагын 157 эшче белем ала. Алар биш группада слесарь-монтажчы, слесарь-ремонтчы, электромонтер, станокчы-универсал һөнәрләрен үзләштерәләр.

Кадрлар бүлеге Камадагы автомобиль заводы төзелешенә 59 производство командирын — тәҗрибәле инженерларны һәм техникларны җибәрде. КамАЗда алар группа җитәкчеләре, механиклар, цех энергетиклары, бюро һәм төрле служба начальниклары булып эшләячәк».

**«Северный рабочий». Ярославль.**

«21 майда СССР Министрлар Советы Председателе А. Н. Косыгин Кремльдә Американың күренекле банкиры һәм җәмәгать эшлеклесе Дэвид Рокфеллерны кабул итте. Советлар Союзына ул Мәскәүдә үзе җитәкли торган «Чейз Манхэттен» банкысы илчелеген ачу уңае белән килгән иде.

Эшлекле характерда һәм үзара аңлашу шартларында барган бу әңгәмә вакытында СССР белән АКШ арасындагы экономик элемтәләр мәсьәләсе тикшерелде.

А. Н. Косыгин үзара файдалы шартларда һәр ике илнең зур масштаблы экономик хезмәттәшлегенә Советлар ягының уңай карашын билгеләп үтте. Д. Рокфеллер, үз чиратында, ул җитәкләгән банкның төрле тармаклар буенча экономик хезмәттәшлекне җайга салу эшенә теләктәш булуын белдерде. Бу теләктәшлек, өлешчә, Кама автозаводы өчен Америка җиһазларын җибәрүне финанс белән тәэмин итүдә күренә».

**«Труд». Мәскәү.**

«...Мөнир белән очрашканчы ук, ул җитәкләгән бригаданың ремонт-инструменталь заводында иң яхшылардан саналуын ишеткән идем... Ә бригадир үзе югары класслы монтажчы икән.

Үзеннән-үзе язачак очеркымның герое образы күз алдыма килеп басты. Мин аны зур тормыш, производство тәҗрибәсенә ия булган кеше итеп күзалладым. Яшь белән дә урта яшьләрдә булырга тиеш кебек иде. Аның 23 яшьтә генә булуын белгәч, исем китте. Ничек гаҗәпләнмисең: монтаж эшенең чын остасы, катлаулы эшләр башкарырга сәләтле бригадир Мөнир Шәймөхәммәтовның төзелештәге эш стажы... ике елдан аз гына артык.

Тугызынчы бишьеллыкның иң зур төзелешләреннән берсендә — Кама автомобиль заводында үз урынын тапкан Мөнир Шәймөхәммәтов язмышы бик күпләр өчен уртак. Вазих Мавликов, Галина Филяшина, Нина Отюбина һәм башка бик күпләр төзүче хезмәте шатлыгын иң башлап бирелә татыдылар һәм хәзер КамАЗның данлыклы кешеләре булып әверелделәр».

«Строительная газета» хәбәрчесе Палевский. Мәскәү.

«РИЗны июль аенда тапшырырбыз!» — транспарант бик ерактан ук күренеп тора. Бирелә, ремонт-инструменталь заводы төзелешендә, безнең сатучыларның күбесе эшли. Төзелештә эшләр бик кызу барган кебек үк, безнең дә, сәүдә хезмәткәрләренең дә, эш графигы киеренке. Безнең эш төзүчеләр белән тыгыз бәйләнештә.

Безнең поселокта кибетләр берничә. Кибетләр сатып алучыларга уңайлы рәвештә чиратлашып эшлиләр. Мәсәлән, берсе иртәрәк ачылса, икенчесе соңрак ябыла. Төшке ял вакыты да төрлечә.

Минемчә, шундый бер закончалык бар: сатып алучы турында никадәр кайгыртсаң, аңа яхшы сыйфатлы һәм төрле товарлар тәкъдим итсәң, культуралы хезмәт күрсәтсәң, товар әйләнеше планын үтәүдә кыенлыклар шул кадәр кимрәк була. Узган елны планны 20 процентка арттырып үтәдек, быелның беренче кварталы һәм апрель планнары да арттырып үтәлде.

50 нче магазин сатучысы З. Мәрдәншина».
«Советская торговля». Мәскәү.

«Тугызынчы бишьеллыкның ике елы эчендә КамАЗда 580 миллион сумлык төзү-монтаж эшләре башкарылды.

Бишьеллыкның өченче, хәлиткеч елында КамАЗ төзүчеләре алдында тагы да зуррак бурычлар тора. Аларны уңышлы хәл итү өчен СССР Энергетика һәм электрификация министрлыгы, Монтаж һәм махсус төзү эшләре һәм автомобиль промышленносте министрлыклары бергәләп эшләү планын булдырдылар. Елның төп тематик бурычы анда болай билгеләнгән: комплексның барлык төп производство корпусларын төзү, салкыннар башланганчы 1,3 миллион квадрат метр түбә ябу, кыш айларында биналарны эшкәртү һәм җиһазларны монтажлау».

«Строительная газета». Мәскәү.

«Нью-Йорк таймс», «Вашингтон пост», «Крисчен сайенс монитор», «Балтимор сан», «Чикаго трибюн» кебек танылган газеталарның вәкилләре булган бер төркем журналистлар Кама автозаводы төзелешендә булдылар. Алар төзелеш мәйданнарын карадылар, төп игътибарны кою заводына юнәлттеләр.

«Социалистическая индустрия» хәбәрчесе белән әңгәмәсендә «Нью-Йорк таймс» газетасы хәбәрчесе Теодор Шабад түбәндәгеләрне сөйләде:

— Иң зур тәэсир калдырганы — ул төзелешнең колачы. Мондый зур төзелешне әле минем күргәнем юк иде. Дөрес, төп завод корпусларының әле каркаслары гына калкып чыккан, әмма алар буенча да күп нәрсәләрне төсмерләргә мөмкин.

Мин КамАЗ һәм аның тирәсендәге юлларга игътибар иттем. Һәр тарафка таба киткән юллар ике рәтле. Автомагистральләр кисешкән урыннар аслы-өсле... Мондый уңай юллар Мәскәүдә бар. Әмма, минемчә, андый юллар Советлар Союзының башка шәһәрләрендә очрамый шикелле.

Ә «Крисчен сайенс монитор» газетасы хәбәрчесе болай диде:

— Ә мин торак районнар, төзүчеләр һәм автозавод эшчеләре өчен тудырылган шартлар белән кызыксындым. Бүтән төзелешләрдә ничектер, белмим, әмма монда алар гигант автомобиль комплексын төзү белән бергә гамәлгә ашырыла».

«Социалистическая индустрия» на строительстве
Камского автозавода»

«Тиңсез төзелеш гүли. Аның 100 кв. километрга җәелгән мәйданын тулысынча бары тик күктән-самолеттан гына күреп бетерергә мөмкин. Төрле тармакларда мең төрле исемдәге машиналар эшли. Камадагы бу гигант төзелешнең автопаркы бер рейста 20 мең тонна йөк ташырга сәләтле.

Шәһәр бик тиз күтәрелә. Һәр елны яңа шәһәрдә генә 300 мең метр торак мәйданы — 50—60 күп катлы торак йортлар эксплуатациягә бирелә. Шул ук вакытта кирәгенчә балалар учреждениеләре, сәүдә, көнкүреш предприятиеләре ачыла.

Чаллы урамнары буйлап йөргәндә:

«Бездә һәркем изге теләктә,
Шәһәр сезгә, дуслар, бүләккә»,—

дигән җыр юллары белән язылган плакат күрдек. Дөрес, һәркемгә түгел, әмма бик күпләргә бүләк итәләр алар шәһәрне. «КамАЗны бөтен ил төзи».— дигән канатлы сүзләр һәркемгә билгеле. Һәм бу — сүзләр генә түгел, ә хакыйкать. Яшь төзүчеләрнең фуфайка, эш киемнәре җиңнәренә тегелгән эмблемадан илебездәге барлык шәһәрләрнең исемнәрен укырга мөмкин. Алар арасында безнең якташларыбыз — Брянск егетләре һәм кызлары да күп».

**«Брянский рабочий».**

«Драматурглар — бишьеллыкка» дигән баш астында «Советская культура» газетасы күп кенә драматургларның заман темасын, хәзерге совет чынбарлыгын үз әсәрләрендә ничек гәүдәләндерүләрен чагылдырган чыгышларын бастырып чыгарган. Анда яшь татар драматургы Диас Вәлиев тә «Тормыш бүләк итәм» пьесасын ничек иҗат итүе турында яза. (Бу әсәр илебезнең күп кенә театрларында, шулай ук Мәскәүдәге Ермолова исемендәге театрда уңыш белән бара).

— Минем язучылык биографиям газетада эшләүдән башланды,— ди ул.— Хәзер дә минем язучылык хезмәтем журналистика белән рәттән бара. Пьеса язаммы, проза әсәреме — һәр вакыт тормыш үзе тудырган проблемалар, кешеләр кирәк миңа.

«Дәвам» пьесасының нигезе дә «Смена» журналында КамАЗның беренче төзүчеләре турында басылып чыккан очеркым булды. Публицистика миңа пьеса язарга этәргеч бирде».

**«Советская культура». Мәскәү.**

Мәдинә Маликова

# КҮЛЛӘР ҮЗӘГЕ САМОТЛОР

Самолет, түбәнәеп, соры болытка чумды. Шактый вакыт берни күренмәс булып торды, ниһаять, канатлар астында гаҗәеп манзара пәйда булды: киң офыкларга хәтле көрәнсу-яшел сазлыклар һәм саргайган ябалдашлы каен аралаш кара-кучкыл эрбет урманнары җәелеп ята. Алар боргаланып-сыргаланып, буталып беткән елга-ерымнар белән ергычланганнар, эреле-ваклы күлләр белән чуарланганнар. Әйтерсең лә нindидер бер гыйфрит биниһая зур калагы белән җирне-суны бутап ташлаган да өстән болыт юрганы белән каплап куйган. Күз ялы өчен ник, ичмасам, бер кишәрлек басу булсачы!

Самолет Иделдәй киң елга өстеннән очып узды.

— Обь елгасы!

Офыкта, кара урманнар артында, башкалардан шактый ук зур күл күренде. Аның янында, кемдер кызыл яулык болгагандай, факеллар яна иде.

— Самотлор!

Самотлор хант телендә «Йөрәк-күл» яки «Үзәк-күл» дигән сүз, диләр. Чыннан да, киңлеге 8 чакрымлы, буе 12 чакрымлы бу күл, самолеттан караганда, формасы белән йөрәк сурәтен хәтерләтә икән.

Самотлор еракта, офык сызыгы янында, кала, Төмән шәһәреннән күтәрелеп өч сәгатькә якын очкан АН-24 самолеты җиргә төшә. Аэропорт бинасының түбәсенә «Түбән Варта» дип язылган.

Самолеттан чыгуга, пассажирлар калтыранып куялар: бүген, 1 октябрьда, Төмәндә кояшлы, җылы көн иде, урамда күпләр костюмнан йөриләр иде. Ә монда аэродром янындагы кызыл балчык кантарларын бәс сарган — 10 градус салкын.

Минем тизрәк күлне күрәсем, даны бөтен илгә таралган Самотлорның ярына барып басасым килә иде.

Кырык минут та үтмәгәндер, «газик» машинасы мине Самотлорга илтеп тә җиткерде.

Менә нинди икәнсең син, Самотлор — күлләр үзәге! Өстенә юка боз чыраган соргылт су. Ерак яр буйларындагы урманнар кара челтәр сыман күренә. Су өстеннән иркенләп искән дымлы җил үзәккә үтә.

Күксел болыт, соргылт су, кара урманнар. Я табигать, безнең якларга чутсыз мул биргән төсләреңне бу якларга ник кызгандың син?

Минем белән янәшә бораулау бригадасы бригадиры Виктор Китаев басып тора, ул да күлгә караган. Аның бригадасы Самотлор ятмасының нәкъ үзәгенә скважина бораулый. Вышка күл уртасына ком өеп ясалган мәйданчыкка куелган.

— Озак эшләячәксезме сез монда? — дип сорыйм мин бригадирдан.

— Кыш буе.

Алар шушы мәйданчыктан унсигез скважина бораулаячаклар икән. Вышка үзе рельсларга куелган, аны әз генә күчерәләр дә, кыеклап бораулыйлар. Кечкенә генә мәйданчыктан нефть ятмасының шактый зур мәйданына барып җитәләр.

— Кышын монда салкындыр,— дим мин.

— Урманда егерме градус булса, монда кырыкка җитә.

Ә бит бу якларда салкыннар илле градуска җитә, диләр. Урманда эшләүче бригадаларга ышыграк та, күңеллерәк тә. Андагы түмгәкле сазлыкларда күзен күзне кызыктырып мүк җиләге, нарат җиләге пешә. Анда кыр тавыгы, куян, төлке очрый, кайчак буровойлар тирәсендәге калдык-постык ризыкка ымсынып, аюлар да килеп чыга, дип сөйлиләр. Урманда рәхәт. Ә монда су да җил генә.

— Бигрәк шыксыз урында эшлисез,— дим мин Викторга.— Скважинасы да бик җаваплы, диләр.

Бу буровойның геологик яктан катлаулы булуы турында күп сөйлиләр, күп язалар. Самотлор нефть ятмасының өстендә мендәр булып калын газ катламы ята. Күл уртасы — шул «мендәрнең» иң калын урыны. Зур осталык, зур саклык кирәк монда. Әмма Виктор бер дә ачылып китми:

— Бораулау эше бораулау эше инде ул,— гына ди.

Кызганычка каршы, бригаданың комсоргы Рафат Юсупов вахтада төнлә булган, хәзер кайтып киткән икән. Вышка янында йөрүче бер егетне күреп, Виктор:

— Фәннүр, бире кил әле,— дип чакырды.— Таныш булыгыз: бораулаучы ярдәмчесе Шәйхелисламов.

Фәннүр яшь әле, шулай да даны илгә таралган икән инде. Ул медаль белән бүләкләнгән, «Огонек» журналында аның рәсеме басылып чыккан. Монда Бөре шәһәреннән килгән ул.

Саубуллашканда Виктор кинәт кенә:

— Нишләп әле сез күлне хурладыгыз? — диде.— Бер дә ямьсез түгел ул. Искиткеч матур күл бу! Гаҗәп матур!

Ул, минем сокланачагыма шикләнмәгәндәй, зур ышаныч һәм соклану белән күлне күздән кичерде. Мин исә күлдән бигрәк аның үзенә гаҗәпләнеп карадым. Аның моңарчы битарафлык саклаган йөзе кинәт ачылып китте, күзләре нурланды. Шушы соры күлне чын күңелдән яратканы аның бөтен кыяфәтеннән күренеп, тавышыннан сизелеп тора иде.

Күл ярыннан буровойга хәтле булган арага ком өелеп, дүрт чакрым ярымлы юл салынган. Бетон плиталардан салынган юл күлдән утыз чакрым ераклыктагы шәһәргә илтеп кертә. Юл буе мин кызгылт түмгәкләрне, су күплектән урыны-урыны белән тамырында көйгән урманнарны күзәтеп кайттым. Колагымда һаман Викторның күлне яратып әйткән сүзләре яңгырап торды. «Кай җирен ярата икән ул бу күлнең, бу сазлыкларның? — дип уйладым мин. — Ни өчен ярата икән?»

* * *

Ишекне ачуга таныдым мин Рафатны. Озын буеннан, маңгаена бүселеп төшкән сары чәченнән, елмаюдан чокырланган бит очларыннан таныдым. Аның елмаеп төшкән рәсемнәрен газеталарда күргән идем.

Мин аларга бераз вакытсызрак килеп кердем. Кечкенә бүлмәнең асты өскә килгән. Рафат, аның хатыны Рәйсә һәм өч яшьлек Иркә яңа квартирага күчәргә әзерләнгәннәр икән. Шулай да алар авырсынмадылар. Төнге вахтадан кайтып өс-башын да алыштырырга өлгермәгән Рафат төеннәр арасыннан бер кочак карточкалар да табып алды. Бу аның Берлинда, Яшьләрнең һәм студентларның унынчы бөтен дөнья фестивалендә төшкән рәсемнәре иде. Анда да Рафат рәхәтләнеп, чын күңелдән, эчкерсез елмаеп төшкән.

Фестивальгә ерак юллар илтә. Рафатның бу юлы әле яшүсмер чагында, Татарстаннан көнбатышка «Дуслык» нефть үткәргече төзүчеләр белән очрашкач ук, башлангандыр, мөгаен. Шул чакта ук нефтьнең «сихере» тиеп калган аңа.

— Нефть сихере тигән кеше гомере буе шушы эшкә гашыйк булып кала икән ул, — ди Рафат.

Бирегә дә аны шул сүнмәс мәхәббәт китергән. Бар эш тә җиңел бирелә кебек Рафатка, гомер юлыннан ул елмаеп кына атлый шикелле. Кирәк чакта «әһ» тә димичә уналтышар сәгать вахтада була ул, комсорг эшен дә гөрләтеп, бар кешене мавыктырып алып бара, читтән торып техникумда да укый.

Узган елның көзендә, Советлар Союзы төзелүгә илле ел тулу хөрмәтенә, Самотлорда күп милләтле комсомол бригадасы оештырылган иде. Аңа Әзербәйҗаннан, Украинадан, Төркмәнстаннан, Белоруссиядән, Коми АССРдан яшь нефтьчеләр килде. Бригада составына шулай ук Татарстаннан Вәгыйз Гәрәев, Башкортстаннан Әхәт Сираев, Оренбург өлкәсеннән Исмәгыйл Мөхәммәтгалиев, Томск өлкәсеннән Зөфәр Усманов, Төмән өлкәсеннән Виктор Китаев белән Рафат Юсупов һәм башка берничә кеше керделәр. Интернациональ бригада 2200 метр тирәнлектәге скважинаны билгеләнгән вакытыннан җиде көн алда бораулап бетерде. Бригададан берничә кеше бөтен дөнья фестивалена делегат итеп сайланды. Алар арасында Виктор Китаев белән Рафат Юсупов та бар иде.

Гаҗәп кызыклы сәяхәт була бу егетләр өчен. Самотлор — Әлмәт нефть үткәргече төзелеп бетеп, «Дуслык» нефть үткәргеченә тоташкан инде. Самотлор нефтьчеләре чыгарган кара алтын урман-сазлыклар аша үтеп, континентларны тоташтырып, дәүләт чикләрен кичеп, Германиягә барып җитә. Егетләр нефть үткән юлларны буеннан-буена кичәләр.

Мәңге онытылмаслык матур истәлекләр алып кайткан Рафат фестивальдән. Бигрәк тә фестивальнең ачылу һәм ябылу тантаналары нык тәэсир иткән аңа.

— Ә без Рафатның Берлинда йөргәнен телевизордан карап утырдык, — ди Рәйсә.

Митингларны, кичәләрне, мең дә бер төрле милләт яшьләре белән танышу-дуслашуны, төн урталары узгач та Берлинның шау-гөр килеп торган урамнарында йөргәннәрен сөйләп туя алмый Рафат.

Ә нефтьчеләргә анда игътибар һәм ихтирам аеруча зур булган. Аларны ГДРның геология буенча дәүләт секретаре (безнеңчә әйтсәк, министры) доктор Бохман кабул иткән.

— Ничек шул кадәр тиз бораулый аласыз икән сез, шуны үз күзләрең белән күрәсе иде,— дигән ул.

— Ничек бораулаганыбызны бәйнә-бәйнә сөйләп бирдек без аңа, — ди Рафат елмаеп.

Алар ГДРның буровойларына барганнар, бик тирән катламнардан газ чыгаручылар белән очрашканнар.

Әлбәттә инде, безнең егетләргә журналистлар тынгы бирмәгән. Уен-көлке яратучы Рафат аларның кайберсенә шаярып та җавап биргәләгән. Бер журналист:

— Самотлорда үзегез өчен иң истәлекле вакыйганы сөйләгез әле, — дип сорагач, Рафат:

— Интернациональ бригада члены Рөстәм Гудыковның безгә килеп төшүе, — дип җавап биргән. — Декабрь аенда ялтырап торган ботинкалар киеп, ялан баш килде ул. Ул яши торган Төркмәнстанда җылы икән, ә бездә кырык градус салкын. Киез итек, бүрек, тун, тире бияләйләр китергәнебезне көтеп өйдә утырды егет, шунсыз вахтага бару түгел, урамга да чыга алмады.

Менә шулай, бик шәп калаларда олы кунак булып йөргән Рафат.

— Кунагын кунак та, соңга таба Түбән Вартаны бик сагына башладым, — ди ул. — Кайчан кайтып шушы кечкенә бүлмәнең түренә менеп утырырмын да, кайчан Самотлорга барып дусларымны күрермен, дим. Бездән башка ничек эшлиләр икән, дип тә борчыласың бит. Йөкләмәләр бик зур бит безнең. Ел эчендә җитмеш мең метр бораууларга сүз бирдек. Кайда бар ул шул кадәр күп бораулый торган комсомол-яшьләр бригадасы? Андый бригада юк бүтән.

Ни хисабына арттырыла ул метрлар саны?

Техника елдан-ел яхшыра, әлбәттә, дип сөйли Рафат. Мондагы бораулау техникасы Татарстандагы ише генә түгел, төньяк шартларында эшләү өчен махсус яраклаштырып чыгарылган. Ләкин эш уңышлы барсын өчен төп шарт — бригаданың нык оешкан, берекkән булуында, бер ритмда эшли алуында, бер-берсен сүзсез аңлавында. Бораулау бригадасы — музыкаль ансамбль кебек ул. Ансамбльдәге төрле уен кораллары бер көй, бер моң булып яңгырарга тиеш булсалар, бораулау эшендә дә, һәркем эшнең гомуми агышын тоеп, башкаларның көен белеп эшләсә генә бригада уңышка ирешә ала. Ә андый бригаданы тиз арада гына төзеп булмый.

Өстәвенә, Самотлор шартларында эшләү яшьләргә аеруча кыен икән. Алар буын ныгыткан ирләргә караганда тизрәк ялыгалар. Бигрәк тә кышын авыр. Җәй көне буровойда дүрт кеше дә эшли ала, ә кышын бишәү дә әз кебек. Көчле җилләр искәндә вышка өстендә берәүнең генә көче җитми, чөнки «шәмнәр» — торбалар нык чайкала, шуңа күрә өскә икәүләп, хәтта өчәүләп менәргә туры килә.

Каты сынау аша үткәрә егетләрне Самотлор. Ләкин егетләр сынатмыйлар, торган саен бу якларга күңелләре белән берегә генә төшәләр.

— Бу бишьеллыкны шушында тәмамлыйбыз әле, — ди Рафат. — Бишьеллык планны комсомолга Ленин исеме бирелүгә илле ел тулган көнне төгәлләргә, дип йөкләмә алдык. Йөкләмәләрне үтик әле. Аннары... кузгалырга уйласак, безнең юл бер генә — тундрага табан гына булачак. Анда без аласы байлыкларның исәбе-хисабы юк бит әле.

* * *

Самотлор җир шарындагы иң зур нефть ятмаларының берсе булу белән бергә, ир-егетләренең көч сынашкан мәйданы да ул.

Күлнең бер ягында бораулау эшләрен 1 нче бораулау идарәсе алып бара. Әлеге Китаев бригадасы да шунда керә. Каршы ярда 2 нче бораулау бригадасы эшли. Ул идарәне үзара «татар-башкорт конто-

расы» дип атыйлар. Чөнки анда Әлмәттән, Азнакай, Октябрьск, Бөре шәһәрләреннән килгән нефтьчеләр күп. Идарәнең начальнигы — Афзалетдин Исәнголов.

Идарәләр арасында ярыш бара: кем кемне җиңәр дә кайсы өлкәдә кем кемне уздырыр. Бу ярыш-узыш моннан бер ел элек аеруча нык кызып китте, чөнки 2 нче идарә бирегә былтыр күчеп килде. Ә аңарчы идарә Шаим нефть ятмасын үзләштерде.

Бу коллектив 1964 елны оешты һәм Төмән өлкәсенең көнбатышында, Канда елгасы буенда бораулау эшләренә кереште.

Күз алдына китерик: Төмәннән мең чакрым ераклыктагы урман, сазлык, төтен кебек вак черки, кислород кытлыгы. Нефтьче егетләргә монда җитмеш төрле һөнәр дә әз булып чыкты. Сәгатен-минутын санамыйча, кирәк кадәр вахтада торалар, аннары кулларына балта алып, урман егарга, бура бурарга керешәләр. Яшәргә куыш кирәк, хатыннарны, бала-чагаларны алып килергә кирәк. Чөнки егетләр бирегә акча сугар өчен генә килмәгән, ныклап эшләр өчен, озаклап яшәр өчен килгән.

Төньяк шартларында җитәкчеләрдән нинди сыйфатлар таләп ителә? Нефть чыгаруны оештыруммы? Әлбәттә. Шәһәрләр салуммы? Әлбәттә. Юллар төзүме? Әлбәттә! Шулар өстенә кешеләргә кешечә яшәү мөмкинлеге тудыра белү дә кирәк әле. Сагышланганнарны юата белү, юлдан чыкканнарны эзгә кертә белү, күңеле төшкәннәрне илһамландыра, дәртләндерә белү дә кирәк. Шуның өстенә тирә-яктагы хант һәм манси авыллары турында кайгырту да алар җилкәсенә төшә. Тагын әле сөт тә сорыйлар алардан, кыш уртасында яшел кыяр да сорыйлар.

Ә бит бу бурычларның кайсын гына үти башласаң да, мең киртәгә очрыйсың. Нефть монда Идел — Урал бассейнындагы шикелле ятмый, ул җир астында катлы бәлеш кебек, таш, ком, су катламнары белән аралашып ята. Өстәге баткаклык трактор-машиналарны йотарга гына тора. Вышкалар кую өчен махсус нигез корырга туры килә. Җирнең байлыгын алу өчен монда рационализатор-галим булырга кирәк. Исәнголов сазлыкларда юлларны бозлап катырылган туфрак катламы өстенә салу ысулын уйлап тапкан. Вышкаларны «Һава мендәре»нә күтәреп, урыннан-урынга күчерү ысулын тәкъдим иткән. Төньяк шартларында нефть ятмаларын үзләштерүдә башкарган гыйльми эшләре өчен ул Дәүләт премиясенә лаек булды.

Шаим конторасында музыкаль ансамбль кебек төгәл һәм бердәм эшли торган бораулау бригадалары булдырылды. 1967 елдан алып алар тиз бораулау буенча яңадан-яңа рекордлар куя бардылар: елына 40 мең метр, 55, 60, 71 мең метр! 70 нче елдан бирле бу коллектив Коммунистик хезмәт коллективы исемен йөртә. Бораулау бригадасы бригадиры Анатолий Дмитриевич Шакшин һәм вышка монтажлау бригадасы бригадиры Ядкәр Ваһапов Социалистик Хезмәт Геройлары булдылар. Афзалетдин Исәнголов җидееллык планны уңышлы үтәве өчен Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, сигезенче бишьеллык планны уңышлы үтәве өчен Ленин ордены белән бүләкләнде.

Элегрәк кешеләр адашып йөри торган урманнар уртасында нефтьчеләр 20 мең кеше яши торган кала — Урайны торгыздылар. Аның клублары, профилакторийлары, пионер лагерьлары бар, кыш урталарында да кибетләреннән яшел суган, яңа гына сабагыннан алынган кыяр өзелми. Алар ерактан китерелми, Урайның үзендә үк, теплицаларда үстерелә.

Ә бит бу якларда теплица өчен туфрагын булдыру да олы бер мәсьәлә. Шуңа карамастан нефть шәһәрләрендә — Урайда, Сургутта, Нефтеюганскида, Түбән Вартада — теплицалар булдыру иң мөһим бурычларның берсе санала.

Бу уңайдан монда шундый бер вакыйга да сөйлиләр: Сургут бораулау конторасы директоры Жаворонков югарыдан рөхсәт сорамыйнитми генә теплица төзүгә шактый күп акча тоткан. Моның өчен аны Тәмәнгә чакырып «пешермәкче» булганнар. Начальник кабинетына килеп керүгә, Жаворонков:

— Минем белән бер кеше килгән иде, бер генә сүз әйтергә тели, рөхсәт итегез әле, — дигән.

Рөхсәт иткәннәр. Зәмһәрир суыктан бите бурлаттай кызарып чыккан кеше кереп, кулындагы зур төргәкне өстәлгә куйган да чишеп җибәргән. Аннан рәте-рәткә тезеп салынган... яшел суган килеп чыккан. Кеше бер генә сүз әйткән:

— Сургуттан.

Барысы да, күзләрен ала алмыйча, эре, сусыл, тере, куе-яшел кыякларга озак карап торганнар. Әйе, бу байлыкның кадерен, бәмен, чын бәясен бары Төньякта яшәүчеләр генә белә шул.

— Рәхмәт, — дигән начальник Жаворонковка. — Сиңа башка сүз әйтеп булмый инде.

Урайда теплицалар бөтен кешене тәэмин итәрлек — җан башына бер квадрат метр булдырылган.

Шулай да җитәкчеләрдән иң зур осталык таләп иткән эш — кешеләрнең күңелен таба белү, аларны эшкә рухландыра белү, аларны олы максатлар белән яшәргә өйрәтү. Яшерен-батырын түгел: Урай да, Түбән Варта да бик ерак бит, анда яшәүчеләр илне «Зур җир» дип атыйлар, үзләрен туган яклардан аерылган итеп хис итәләр. Сагынулар саргайтмасын өчен, һәркем күңеленә ачкыч табарга кирәк. Шул ук вакытта җитәкчегә артык беркатлы, йомшак күңелле булырга да ярамый. Төньяк кырыс, ул җебеп төшкәнне, артык нечкәргән күңелләрне, калтыраган кулларны кичерми. Исәнголовны беркем дә йомшак димәс. Ул ялкауларга, килде-китте эшләп акча суугу җаен гына караучыларга, эчкечеләргә каты, рәхимсез. Әмма беркайчан да гаделсезлек кылмый ул, мәсьәләнең төбенә төшми торып, кешене нахакка рәнҗетми. Аның игътибарлылыгы, аның ярдәмчеллеге турында кешеләр хәйран калып сөйлиләр. Ядкәр Ваһапов катлаулы операциядән соң Төмән больницасында ятканда, Исәнголов эшне шулай оештырган ки, хезмәттәшләре көннең-көнендә барып, авыруның хәлен белеп торганнар.

Исәнголов турында зур җитәкчеләр дә, гади нефтьчеләр дә, аларның хатыннары да сокланып сөйлиләр. Аның зирәк акылын, оештыру сәләтен, гаделлеген мактыйлар. Барыннан да бигрәк, кече күңелле, кешелекле булганы өчен яраталар аны.

— Исәнголов кебек җитәкчеләр булмаса, Төньяк болай күтәрелмәс иде, — диләр.

Мин барганда Түбән Вартада идарә өчен бина төзелеп бетмәгән, идарәнең конторасы вагоннарга урнашкан иде. Начальник кабинеты вагонның яртысын алып тора. Анда салкын, Исәнголов кара пальтосын иңенә салып утырган. Тулы, нык гәүдәле, киң йөзле, кара кашлы бу кеше өчен вагон кысан, тәбәнәк, ә язу өстәле бик кечкенә сыман тоела. Ул тыныч сөйли, куллары белән кирәк-кирәкмәс хәрәкәтләр ясамый, ләкин аның һәр сүзендә тыелган хис, көч сизелә.

Самотлорга килеп төшү белән, 2 нче идарә бораулаучылары 1 нче идарә куйган рекордларга һөҗүм ясаган, һәм нәкъ шул көннәрдә Григорий Кузьмич Петров бригадасы ел әйләнәсенә 80 мең метр бораулауны тәгәлләп килә иде.

Ике идарә үзара ярыша, шул ук вакытта алар бергәләшеп Татарстан нефтьчеләре белән ярышалар. Бу зур ярышта, билгеле инде, Төмән нефтьчеләре җиңеп чыгачак. 1974 елда ил буенча нефть чыга-

руны 30 млн тоннага арттыру күздә тотыла. Шуның 18 млн тоннасы Самотлор хисабына артачак.

Татарстаннан һәм Башкортстаннан килгән нефтьчеләр ярышларда туган якларда эшләүче дусларын җиңәләр.

Идарәнең социалистик йөкләмәләре бик зур. Алар арасында шундый пунктлар да бар: терлек азыгы әзерләү буенча «Нижневартовский» совхозын шефлыкка алырга; милли Ларьяк авылына шефлык ярдәме күрсәтергә; шәһәрне төзекләндерүдә 16 шар сәгать эшләргә.

Самотлор турында, Түбән Варта шәһәренең киләчәге турында сөйләгәндә, Исәнголовның дулкынланганы сизелә башлады, тавышы ук үзгәреп китте.

— Озакламас, бу шәһәр дә Әлмәт, Лениногорск, Октябрьск кебек матур кала булып үсеп җитәр, — диде ул. — Ә Самотлорда безгә эш күп әле, дистә елларга җитәрлек.

— Ә аннары? — дип сорадым мин.

— Ә аннары безне тундра көтә...

* * *

Түбән Варта каласының уртасындагы өч катлы бина түбәсендә кызыл флаг җилферди. Анда партиянең шәһәр комитеты һәм шәһәр башкарма комитеты урнашкан. Бина янында шушы як батырларының портретлары тезеп куелган. Мин алар арасында үзебезнең якташларны күрәм: Советлар Союзы Герое Мөхәммәтдин Гайнетдинов, Социалистик Хезмәт Герое Ядкәр Ваһапов...

Ай-һай, рәсемдә бик гаярь күренә Ядкәр: киң күкрәкле, баһадир гәүдәле, кырыс табигатьле ир булып төшкән.

Ә тормышта ул кечерәк кенә буйлы, ак йөзле кеше, гадилеген бик үк сиздермәскә тырышкандай, төртгеребрәк сөйләшә.

— Анысын да миннән сорап тормагыз инде, контор кенәгәләреннән генә карагыз, — дип куя.

Кенәгәләрдән карасаң, шаккатарлык саннар күрәсең: Ваһапов бригадасы план буенча аена 6 вышка корырга тиеш булган, ә корган уникене. Ул башка бригадалардан шул кадәр алда бара ки, кемнең дә булса аны куып җитүенә өмет тә күренми.

Мин аның бүләкләрен карыйм: Алтын Йолдыз, ике Ленин ордены, «Почет билгесе» ордены. Соңгысын ул 1957 елда, Татарстанда эшләгән чагында ук алган булган. Күп медальләр арасында Бөтен Союз халык хуҗалыгы күргәзмәсе медале. Ханты-манси милли округы Советы депутаты значогы.

Күренеп тора: күптән алдынгы, күптән данлы кеше Ядкәр.

Мин аңа сынап карыйм: холык-табигатендәге нинди сыйфатлар Герой иткән аны? Башкалардан нинди яклары белән аерылып тора герой Ваһапов?

Дөресен генә әйткәндә, язмыш Ядкәрнең башыннан сыйпап кына тормады, нык кына аяк та чалгалады бит.

Лениногорск егете Ядкәр Ваһапов Төньякка 1964 елда, Шаим нефть ятмасын үзләштерә башлауга килде һәм «кыен кыерчыгын» башкалар белән бертигез ашады.

1969 елның кышында, бригаданың эше гөрләп барганда, Ядкәргә зур бәла килде. Үзенең тынгысызлыгы, кызулыгы аркасында тарыды Ядкәр ул бәлагә. Вышкага электр станциясе куеп азапланалар иде. Урынына утырмый аптыратты бит шул каһәр төшкән нәмәрсә. Ядкәр кызуланып үзе өскә менеп китте дә кулына лом алды. Станциянең

шалт итеп урынына утыруы булды — Ядкәр баскан такта шуып китте. Күрә Ядкәр: дүрт метр түбән җирдә, нәкъ аяк астында, кадаклары тырпайган такталар ята. Ул бөтен көчен җыеп, гәүдәсен читкә, биек көрткә ыргытты. Чыныккан тәнле, төелгән йодрыктай җыйнак гәүдәле иргә 4 метрдан сикерү нәрсә ул! Ләкин бәла аяк астында дип юкка гына әйтмиләр шул. Ядкәр яны белән кар астындагы кантарга килеп бәрелде.

Сикереп аягына басып эшкә керешмәкче иде ул. Тик тайгада, авыл-шәһәрләрдән еракта эшләп, бер-берсенең хәлен бер карауда чамаларга өйрәнгән иптәшләре ирек бирмәделәр:

— Тыпырчынма, — диделәр. — Хәзер үк больницага илтәбез сине. Ай-ваена карамыйча, «ГАЗ-69» машинасына кертеп утырттылар да җан-фәрман шәһәргә таба чаптылар. Ә шәһәр — Урай — илле чакрымда.

— Миңа ни булганын безнең Литвинов шундук чамалады, — дип сөйли Ядкәр. — Бөерең шартлаган синең, ди. Шоферны ашыктыра. Шофер сигналын туктатмый кычкырта, пожарга чабамыни, алдагы машиналарның өстенә менәрдәй була. Мин авыртудан бөгелеп төштем, үзем егетләр өчен куркам. Кумагыз шул чаклы, дим, үзегез харап буласыз бит. Ә болай үлсәм дә үзем генә үләрмен. Дәшмә, диләр, хәлеңне бетерәсең.

Соңгы минутларында диярлек кайтарып җиткерәләр Ядкәрне. Больницадан өенә китеп барган хирургны капка төбеннән кире борып кертәләр. Ә больница төзелеп беткән генә әле, бөергә катлаулы операция ясау өчен анда тиешле шартлар да, тәҗрибәле врачлар да юк.

Ләкин бу якларда бөтен нәрсә беренче тапкыр эшләнә бит!

Коткаралар егетне үлемнән. Бераздан Төмәнгә күчерәләр, анда тагын ике тапкыр операция ясыйлар. Ниһаять, врачлар:

— Моннан соң ул эшеңне ташларга туры килер инде, — дип нәтиҗә чыгаралар. — Без сиңа инвалидлык бирербез.

Инвалидлыккамы? Кырык яшь тә тулмаган көе йомарланып түр башында утырыргамы? Ядкәр бит бер көн ял алып өендә утырганда да үзенә-үзе урын таба алмый торган тынгысыз кеше! Юк, ул тир түгеп, йөрәк җилкетеп эшләмичә яши алмый.

Аларның бригадасына дан тикмәгә генә килмәде. Армый-талмый эшләү бер нәрсә, алар эшкә күпме хисләрен бирделәр, күпме уйларын багышладылар! Вышкаларның сызымнары өстендә туктаусыз баш ваттылар, алар керткән тапкыр һәм акыллы тәкъдимнәр санап бетергесез. Иҗади эшнең газабын һәм ләззәтен бик яхшы белә Ядкәр, күп татыды ул аны. Үзең уйлап чыгарган һәр җайланма искиткеч зур канәгатьләнү хисе, горурлык хисе китерә бит. Менә бит ул ничек, дисең, берәүнең дә башына килмәгән нәрсәгә безнең баш җитте, беркем булдыра алмаганны без булдырдык, дип куанасың.

Электр станциясен югарыга, вышкага кую идеясен дә алар үзләре уйлап чыгарганнар иде.

Юк, тәнендә кайнар кан акканда ир-егет кул кушырып өйдә утыра алмас.

Төньякта эшләү өчен кешегә аттай сәламәтлек кирәк, диләр. Ядкәрнең тормышы бу кагыйдәгә сыеп бетми. Күрәсең, башка рухи сыйфатлары аның сәламәтлеге какшаган булуны бик үк сиздерми торгандыр. Алай да бер үзгәреш булды анда: элек ул утыз градус салкында да күлмәкчән эшли иде, хәзер тун сәдәфләрен каптырып куя. Эштә үҗәтлеге, дәрте, тынгысызлыгы исә тамчы да кимемәде. Аның бригадасы алдынгылыкны берәүгә дә бирмәде.

Герой исемен ул, авырудан терелеп ике ел эшләгәч, 1971 елда алды. Аның бригадасында эшләүче Шөгер егете Тәлгат Шәйдуллин шул ук елны Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.

Илнең асыл егетләре яшәешнең мәгънәсен эштән, иҗаттан, җиңүләрдән табалар. Алар лаеклы бүләкләрне дә башны югары тотып, горурлык белән кабул итә беләләр.

Тыгыз, мәгънәле тормышта яшәүнең шифасы зур, күрәсең. Ядкәр бик яшь күренә. Нәни оныгы Илдар янында бабай төсле түгел, яшь әти кебек кенә ул.

— Алда эшләр күп әле, — ди Ядкәр. — Картаерга вакыт юк. Монда эшне төгәлләгәч, тундрага барып вышкалар куясы бар.

* * *

Самотлор нефтьчеләре телендә сугышчан сүзләр еш очрый. Үзләре нииндидер атауда яшиләрмени, илне «Зур җир» дип атыйлар. «Зур җирдә яшәү һәм эшләү белән монда яшәү һәм эшләүнең аермасы зур», диләр.

«1964 елның язында бирегә, Обь елгасы буена десант ташладылар», — дип тә сөйлиләр. «Десантчылар» — нефтьчеләр һәм төзүчеләр — Обь буйлап килгән баржаларны бушатып, Сазлы яр буенда Түбән Варта шәһәренә нигез салганнар, «Десантчылар» арасында да Алабугадан килгән кешеләр — Имам Афзалов, Георгий Арнопольский һәм башкалар булган. Алар беренче урамны «Пионер урамы» дип атаганнар, икенчесенә Муса Җәлил исеме кушканнар.

Самотлорны «алгы сызык» дип атау телгә кереп киткән. «Бишьеллыкның удар фронты» да диләр.

— Тыныч төзелештә мондый сугышчан сүзләрне куллану дөресме? Арттырып җибәрү юкмы монда?

Бу сорауны мин Советлар Союзы Герое Мөхәммәтдин Гайнетдиновка бирдем. Мөхәммәтдин абый — могтәбәр ир, чал керә башлаган башын горур, сынын туры тота, сүзләрне бик төгәл, җиренә җиткереп сөйли, тавышы әкрен, урамнан машиналар үткәндә, мин аңа таба муенымны сузып, бик зур дикъкать белән тыңларга мәҗбүр булам.

— Әйе, фронт белән чагыштыралар шул,— ди ул.— Монда кешенең баш очында үлем куркынычы тормый торуын. Әмма җаваплылык алгы сызыктагыча.

Мондагы кыенлыклар турында ул җиңелчә көлемсерәп сөйли: «Монда хозурлык күп» ди. «Кышын урамга чыксаң — илле градус! Күтәрә күңелләрне». «Бу якларның черкие дә үзенчә — һаман тыгыз җиргә керергә чамалый». «Былтыр көз җир соң катты, бер трубоукладчикны сазлыкка батырып куйганнар иде».

Ирен читләре белән генә елмая ул. Бала-чага уенын күзәткән агай шикелле тыныч көлемсерәп утыра.

Ярый, дип уйлыйм мин, яшьләр монда көчен сынарга, үзенең нәрсәгә сәләтле икәнен исбат итәргә килә, дан эстәп килә, ниһаять. Ә соң бу кешене бирегә нинди теләк, нинди омтылыш китергән? Акчаны ул җылырак якларда, тынычрак урында да эшли ала. Данны инде ул күптән яулаган — Алтын Йолдызы түшендә. Сәламәтлеге дә корычтай дип әйтеп булмый, дүртенче катка менгәндә ике-өч тапкыр туктап ял итте.

Нигә килгән ул монда?

Әйе, сугыш турында сүз китте бит әле. Ул салмак кына итеп фронт хәлләрен искә ала башлады. Тавышы шулай ук әкрен, ләкин ирен читләрендә елмаю юк инде. Яңгырашы, аһәңе үзгәрде бу тавышның, анда сагыш, сызлану ишетелгәндәй булды.

— Мин генә түгел, барлык егетләр дә гомерен жәлләми сугышты,— дип сөйли ул.— Барыбыз бергә кердек утларга. Беркем чигенмәде, тайпылмады. Ә Герой исемен миңа Днепр елгасын кичкәндә, ар яктагы плацдарм белән элемтә тәэмин иткән өчен бирделәр. Без өчәү идек. Мин — командир.

— Туктагыз әле, — дим мин. — Ә бит шундый җаваплы бурычны нәкъ менә сезгә ышанып тапшыруларының сәбәбе булгандыр.

— Һәркем үз бурычын үтәде, — ди ул. — Мин исән калдым, шуңа күрә бурычымны ахырынача үти алдым.

Плацдармны өч көн буе ничек тотканнарын, дошман атакаларын ничек кире какканнарын сөйли ул. Сугышчан дусларын искә ала.

Минем өчен бу кешенең язмышы, холкы-табигате бераз гына булса да ачыклана башлый. Ул бит монда да нигез сала торган өлкәдә эшли. Ул эшли торган оешма «Союзпромэкскавация» трестының махсус идарәсе дип атала. Бу идарә биналар салу өчен субайлар кага, юллар сала, урамнарны төзекләндерә. Мөхәммәтдин абый шул идарәнең тәэминат бүлеге начальнигы урынбасары. Ул — идарәне техника белән, запас частьләр белән тәэмин итә.

Мөхәммәтдин Гайнетдинов күпме торак йортларга, балалар бакчаларына, мәктәпләргә нигез салганнарын санап күрсәтә. Еллык планны июнь аена тәгәлләгәннәрен әйтә. Аннары мине тәрәзә янына алып килә дә:

— Әнә күрәсезме? — дип, бишәр катлы йортлар арасында тау-тау өелеп торган ак комга ымлый. — Безнең эш бу. Иң элек берничә метр калынлыктагы сазлык пычрагын сыдырып алып түгәбез, аның урынына ком салабыз. Башта комны Обь елгасыннан земснаряд белән махсус урынга юдырып өябез, аннары машиналар белән шәһәргә ташыйбыз.

Ул шәһәрнең үткәне һәм киләчәге турында сөйли. Гайнетдинов монда килгәндә, 1968 елда, бу кварталлар берсе дә булмаган. Муса Җәлил урамы да ерып йөргесез булган. Хәзер аның уртасына бетон юл салганнар. Шул ук урамда идарәнең конторасы өчен яңа бина төзегәннәр. Бәйрәмнәрдә ул бинаны төрле төстәге утлар белән яктырталар, ул әллә каян балкып тора икән.

— Берничә елдан бик матур кала булачак бу, — ди Мөхәммәтдин абый. — Килсәгез, танымассыз әле.

Мин аңа текәлеп карыйм. Аның йөзендә көлемсерәүнең әсәре дә юк. Бу сүзләрне ул бик җитди итеп, зур ышаныч, эчке куаныч белән әйтә.

Ә бит тормышның нигезен шушындый кешеләр тәшкил итә дип уйлыйм мин. Алар һәркайда — яуда да, тыныч хезмәттә дә — иң авыр, иң җаваплы бурычны үз өсләренә алалар. Бүгенге көндә баш очларында үлем куркынычы булмау — аларның бәхете, ил бәхете. Әмма алар бөтен көчләрен, тормышларын илгә хезмәт итүгә багышлаганнар, кирәк булса, гомерләрен дә илгә бирергә әзерләр. Уйлап карасаң, сугышчан сүзләр бирелә бик урынлы һәм дөрес кулланыла икән бит.

* * *

Шәһәр башкарма комитеты залына яшелле-кызыллы буяулар белән ясалган эскизлар куелган, идәндә төрле төстәге катыргылардан ясалган макетлар ята. Шәһәр җитәкчеләре, төзүчеләре яңа төзелә торган микрорайонның проектын тикшерәләр. Проектны Новосибирск художниклары эшләгән.

Бүгенге көндә йортлар арасына керсәң, тиздән сазга батасың. Ә менә бу проект тормышка ашкач, ишегалды оҗмахка әвереләчәк икән. Нәрсә генә юк анда! Спорт мәйданнары, балалар өчен комлыклар, концерт карар өчен эскәмияләр, гөл түтәлләре, күкрәп үскән агачлар, карт-коры утырып ял итсен өчен уңайлы диваннар, кер элеп киптерер өчен колгалар. Электр лампалары асу өчен кәкре муенлы баганалар, өй стеналарында, ясле коймаларында хикмәтле сурәтләр.

Эскизлар күз явын алып тора. Әмма җыелган кешеләр «ах та вах» итмиләр, күрсәткеч таяк тотып уртада басып торган художникны тиргә батырып, сораулар яудыралар:

— Кер киптерү урыны кечкенә түгелме?

— Түбәләрне нинди төскә буярга киңәш итәсез?

— Нигә сез йорт стеналарын һаман-һаман куе кызыл төскә буярга тәкъдим итәсез? Бу якларда көннәр болай да караңгы, ул төс кеше күңелен изә бит. Күңелне күтәрерлек, ачыграк төсләр кулланырга кирәк.

Шәһәр башкарма комитеты председателе Наил Салихов дәшмитынмый кеше сөйләгәнне тыңлап тора. Кешеләр таралгач, мин аннан:

— Проект ошадымы соң? — дип сорадым.

— Ярыйсы, — диде ул. — Тик бер ягын уйлап җиткермәгәннәр, гашыйкларга икәүдән-икәү генә утырып торыр урын юк.

— Ә ник соң сез аны шунда ук әйтмәдегез?

— Мин бит монда яңа кеше әле. Элек башкалар фикерен тыңлап карарга кирәк.

Монда килгәнче Наил Урайда партиянең шәһәр комитеты секретаре булып эшләгән, ә аннан да элек Исәнголов кул астында цех начальнигы булган. Белеме буенча — нефтьче. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм «Почет билгесе» ордены кавалеры.

Монда эшнең күләме Урайдагыдан чагыштыргысыз зуррак. Урайда нибары 20 мең халык яши, ә Түбән Вартада бүген үк 50 мең кеше бар, киләчәктә ул 130 меңгә җитәчәк. Төзелеш кызу темплар белән бара, ләкин торак җитми. Бүген үк хәл итәлергә тиешле мәсьәләләр күп, ә председатель үзен шәһәр өчен генә түгел, бөтен тирә-як өчен җаваплы саный. Менә кичә генә әле ул Төмәндә булган, ханты авылында интернат, яңа мәктәп, балалар бакчасы салу өчен 380 мең сум акча алып кайткан.

Шәһәр яңа, кешеләр яңа, әмма Урайда алынган зур тәҗрибә председательгә һичшиксез ярдәм итәчәк. Монда яшәүчеләрнең борчуларын, шатлыкларын, күңелен яхшы аңлый ул. Монда тормышны җайга салуның үз серләре бар. Телевидениенең кешегә йогынтысын гына алыйк. Түбән Вартада телецентр төзелгәч, халыкның кәефе бөтенләй икенчеләнеп киткән. Кешеләр хәзер «Орбита» системасы буенча Мәскәү тапшыруларын карыйлар, үзләрен туган яклардан аерылган итеп сизмиләр.

Бәйрәмнәрне күңелле, кызыклы итеп үткәрү дә монда аеруча әһәмиятле икән.

— Без Урайда демонстрацияләрне шундый шәп үткәрә идек! — дип сөйли Наил.— Әллә ниләр кыландырып бизәлгән машиналар, ракеталар, луноходлар була иде. Демонстрация — зирәклекнең, осталыкның сынавы иде бездә. Клубта татар-башкорт ансамбле оештырган идек, ул башка шәһәрләргә барып та концертлар куя иде.

Кешеләрнең уен-фикерен даими белеп торса гына, җитәкче эшендә уңышка ирешә ала. Нефтьчеләр моны бик яхшы аңлыйлар. Һәр айның өченче атнасында эшчеләрнең эш урынына барып чыгыш

ясыйлар, сорауларга җавап бирәләр. Бу инде кабинетта очрашу түгел, монда сөйләшү ачыктан-ачык бара. Монда кешеләр эштә ут уйнаткан кебек, сөйләгәндә дә турысын курыкмыйча әйтә беләләр.

Самотлор кешеләре. Алар турында сокланып һәм чиксез горурланып сөйли Наил. Ә мин Виктор Китаевның күлгә ташлаган карашын күз алдына китерәм.

— Самотлорга барасым килә, — дим. — Күлне тагын бер кат күрәсем килә.

* * *

Бу юлы мин Самотлорга барып җиткәнче караңгы төште. Мин тагын күл уртасына килеп бастым. Һаман шул дымлы җил исә, өстән вак яңгыр сибәли иде.

Ләкин мин җилне дә, яңгырны да шунда ук оныттым. Нинди киң, нинди кырыс, нинди шомлы һәм сихри күренеш ачылды минем күземә! Күл буенда җилпенеп-җилпенеп биш факел яна, су өстенә алардан утлы юллар сузылган. Еракта, дегеттәй кара урманнар арасында, вышкаларның утлары җемелди. Утлар урман караңгылыгын җиңү, табигатьнең кырыслыгын киметү өчен, тирә-юньгә җан кертү өчен махсус кабызылган диярсең.

Бу күренештән күземне ала алмый озак басып тордым мин. Кайткан юл да миңа бөтенләй башкача күренде. Менә бер урында кран тора, кешеләр мәш килә: зур бетон плитаны янтайтып куйганнар, юлның нигезен ныгыталар. Әнә, ерак та түгел очкыннар чәчрәтеп сварка аппараты эшли. Юл кырыннан җир өстенә сузылып яткан кара торбалар факел утында ялтырый. «Самотлор — Әлмәт» нефть үткәргеченең башланган ноктасы бу.

Бихисап утлар белән балкыган шәһәргә кайтып кердем. Машинадан төшкәч, болытларга карадым да аһ иттем: анда биш утлы багана янып тора иде. Бары бераздан гына мин аларның Самотлор факелларының чагылышы икәнен аңладым.

Минем күңелемне менә шулай әсир итте Самотлор. Менә шулай сихерләде ул мине...

Саҗидә Сөләйманова

# ӘС-СӘЛЯМИ, СУФИЯТ!

БЕР СӘФӘР ХИКӘЯТЕ

## Чит илгә

Фирүзәдәй зәңгәр күк. Аста ак болытлар. Бик түбәндә куе яшел, ачык яшел, парчалы яшел җәймәләр. Без йөргән, без яшәгән җир бу. Нинди рәссамның кулы мозаика итеп бизәкләгән аны? Май ае, табигатьнең яшәргән чагы. Иген кырлары, бакчалар биектән шулай кояшка чыгарып җәйгән паласлар шикелле күренәләр.

— Карале, кара, Суфия, карта өстеннән очабыз!

Үсмерләрчә юка гәүдәле, кыяфәтенә караганда үсмерлектән күптән чыккан кызый самолет тәрәзәсеннән күзен алмый, әледән-әле юлдашының иңбашына җиңелчә суккалап, нидер күрсәтә, нидер әйтә. Суфия дигәне өлкәнрәк күренә. Иңнәренә төшеп торган коңгырт чәче аның хәрәкәтләренә салмаклык бирә төсле. Күз кабакларының читенә сизелер-сизелмәс йөгертелгән зәңгәр сөрмә күксел соры күзләрнең зәңгәр буяуларын яктырак итә, шул нәфис төскә хас моңсулык өсти. Юлдашлар, берберсенә сыенып, түбән карыйлар. Аста гүяки Көньякның зур картасы. Кара диңгезнең яр сызыклары. Яшел каймалы Кырым ярымутравы. Җете зәңгәр диңгез...

Самолет эчендә тынлык. Мотор гүләвен сизми башлаган сәфәрчеләр үз уйлары, үз кичерешләре белән мәшгульләр. Бу тынлыкка эче пошкандай, корыч кош, юлчыларны атынгычта атындырган сыман итеп, кинәт түбән төште, ак болытларны ерып оча башлады. Сәфәрчеләр чыннан да бераз җанландылар, сөйләшеп, көлешеп алдылар. Җирдән караганда мамык тауларына охшаган болытлар өстеннән очарга, мәтәлчек атып уйнарга иде дип сабый чагында кем хыялланмаган! Баксаң, ак төтен сыман сыек икән ул «мамык таулары». Ул да булмады, самолет яңадан болытлар өстенә элеккедән дә биегрәк күтәрелде. Зәңгәр диңгез артта калды. Аста соп-соры җир. Таш кыялар, салкын бозлар, көрәнсу томан — Төркия җире башланды. Бөтен нәрсә берьюлы үзгәрде, яшеллек заты күренми. Күршесе аркылы түбән карап барган Суфия, туңган сыман үзен-үзе кочып, кәнәфигә чумды.

Чит илгә сәяхәт! Мавыктыргыч та, шомлы да. Газеталардан гына укып белгән дөньяны үз күзең белән күрәсең. Әкиятләрдә генә ишеткән ерак сахра комнарына үз аякларың белән басасың. Культуралы дөньяның теленнән төшмәгән борынгы корылмаларга рәсем өстеннән шуышкан таяк очы белән түгел, үзең, тере гәүдәң белән барып кера-

сең. Чит ил. Кемнәр яши анда, ни уйлыйлар, ни сөйлиләр? Чит дигән сүз үзе үк читләштереп, шомландырып тора.

Сәяхәткә әзерләнгәндә Суфия сагаеп калгандай булды. Моңарчы башына килмәгән ниндидер яңалык ачылыр шикелле тоелды аңа. Самолетта очканда киеренкелек арта төште. Күз күрмәгән ят җирләр күге. Салкынрак та булып китте. Күршесе Матураның исә дулкынлануы йөзенә, хәрәкәтләренә чыга, һич җитди була белми дип уйлап куя Суфия аның турында. Берсе Әлмәттә, берсе Казанда яшәсәләр дә, уртак эшләре — журналистика буенча алар электән танышлар. Иделдән, Урал яКларыннан җыелган туристларны Мәскәүдә чакта ук дүртәр кешелек төркемнәргә бүлделәр. Суфия белән Матураны, әлбәттә, аермадылар. Коллективның калган икесе дә Казанныкылар, әнә, сул як кәнәфидә утыралар. Озын буйлы, мәһабәт гәүдәле галим кеше Габделбәр Хановны Суфия беренче күрә. Газета-журналларда чыга торган тәнкыйть мәкаләләре буенча ул аны, ни өчендер, тәбәнәк буйлы итеп күз алдына китерә иде. Төркемнең җитәкчесе — өлкә газетасында бүлек мөдире Риянов Фәрит. Кысынкы күзләренең үткен карашы, сүзне өздереп әйтә белүе белән ул бүтәннәрне үз ихтыярына буйсындырмаслык егет түгел. Башкалар арасында Риянов төркеме иң оешканы булып чыкты, ахрысы: коллегалар.

«Ил-18» Кипр утравына кунып ял итеп ала. Эче-тышы пыяла аэровокзал. Күккә күтәрелгән самолетлар артыннан ул да кузгалыр кебек, җип-җиңел. Тышта кояш кыздыра, ә эчтә салкынча. Күзгә күренмәгән җилләткечләр һаваны сафландырып торалар. Туристларга бинадан читкә китәргә ярамый. Диңгез уртасында утырган утрауның самолетлар оча-төшә торган кояшлы яланыннан гайре бер нәрсә дә күренми.

— Кара күзлек алдыңмы?

— Ах, онытканмын.

— Ярый, тегендә алырбыз.

— Җайлырак аяк киемең бармы?

— Шушы босоножки.

— Ком-таш арасында босоножки киялә рмени? Менә, минеке ише нәрсә кирәк,— дип, Суфия үз аягындагы чүәгенә күрсәтеп алды.

Сувенирлар тирәсендә әйләнгән юлдашлары янына киттеләр. Сәфәрчеләрдә әле чит ил акчасы юк, этикеткалар карап йөрүдән узып булмый.

— Әйбер күрмәгәндәй йөрмәгез инде,— дип, Матура ирләрне шелтәләп тә алды.

Утраудагы бер сәгать ял Суфия өчен соңгы ике-өч атнада бердәнбер буш сәгать иде. Тукталып, уйланып торырга да вакыт булмаган икән. Сәяхәткә барачагы ачыклангач, гарәпчә дәреслек белән сүзлек алган иде, ләкин әллә ни зур уңышка ирешелмәде. Китәр алдыннан редакциядә дә эш күбәйде. Үзе барачак Сүрия белән Ливан турында вакытлы матбугатта укыган-белгәннәре белән юлга чыкты. Суфияның яңа нәрсәгә үҗәтләнеп тотына торган гадәте бар. Әлеге бер сәгать тәнәфестә чигеш сыман язуның серенә төшенергә тырышып, кулына гарәп сүзлеге алды. Аерым хәрефләрне өйрәнгән инде, кушып уку кыенрак. Язуын танысаң, сүзләрен ятлау берни тормас иде кебек. Таныш сүзләр очрап, күңелне күтәреп җибәрә. Китабун — китап, кәлиматүн — сүз. «Бер кәлимә сүз әйтмәде» диләр бит. Кәбирун — зур. Татар исемнәре гел гарәптән икән. Күпме исем белсәң, шул чаклы сүз беләсең. Рәфикун — иптәш. Хәсәнун — матур, күркәм.

— Матура, синең исемең гарәпчә Хәсәнә була.

— Ә синеке?

— Мин начар эшләрдән тыелган изгелекле кеше, белдеңме?

— Сизелә, сизелә, ата-анаң ышанычын аклыйсың.

«ИЛ-18» күккә күтәрелде. Җир белән диңгез тоташкан сызык югарыдан бик матур күренә, бормаланып-бормаланып киткән авыл инеше сыман. Инеш аръягы тоташ яшькелт зәңгәрлек. Урта диңгез. Юк микән анда давыл алып киткән ялгыз көймәләр, бер йотым суга тилмергән кешеләр? Шуларны күрергә теләгәндәй, сәфәрчеләр дәшми-тынмый түбән карап бардылар. Сагышлы бертөрлелек күпкә бармый, күңелне сөендереп, яшел ярлар күренә. Монысы инде Гарәбстан ярлары. Кылган гөнаһларын җуяр өчен борынгылар елларын сарыф итеп барган юлны безнең сәяхәтчеләр берничә сәгатьтә үттеләр.

Самолеттан төшкәч, җан өшеткеч ямансу булып китте. Тирә-як шыр дала. Сарык көтүләре утлап йөри. Таш араларыннан кысылып чыккан сирәк-мирәк үлән бик кадерледер мәхлукларга.

Сәфәр йомшак автобуста дәвам итә. Шоферлар бөтен җирдә бер төрле була икән: баш очларына мәзәгрәк кыяфәтле курчак эләләр, каршыларына популяр киноактриса рәсемен ябыштырып куялар. Гарәп шоферының исә бу өлкәдә мавыгулары көчлерәктер — ике-өч курчак элгән, бизәкле журналдан ертып, ике-өч актрисаның рәсемен ябыштырган. Шулар арасында Татьяна Самойлова да бар.

Бетон юл чүл өстеннән үткәрелгән сызык төсле туп-туры сузыла. Аның очы күз алдында кинәт пәйда булган яшел бакчага барып керә. Сүриянең башкаласы Дәмәшкъ. Борынгыча әйтсәк, Шам-Шәриф.

Шам-Шәрифкәй дигән, ай, шәһәрдә
Кич ахшамсыз капка ябылмас.
Үткән гомер белән калган хәтер
Сатып алыйм дисәң табылмас...

Суфияның дәү әние шулай җырлый иде. Айбалталы сакчылары, озын чылбырлы олы йозаклары белән күз алдына килгән тимер капка кайда соң? Җимерек биналарның баганалары тырпаеп тора... Җиргә иңгән балчык өйләр, өй тирәсендә мәш килүче ярым-ялангач бала-чага... Көл белән аралашкан көн борынгы легендада түгел, менә ул, күз алдында. Ачык капкаларны җимереп, баскынчылар кергән монда.

Автобус үзәккә якынлаша. Айураклы манаралар, сырлап-бизәкләп эшләнгән колонналы таш диварлар. Бер яки ике катлы йортлар бакча эчендә утыралар. Гүя аларның яшеллектән аерыласылары, биеккә үрлиселәре килми. Әфлисун, лимон өлгергән чак. Дәү-дәү җимеш агачларының яфраклары яшел лакка буяган төсле. Әйтерсең чын агачлар түгел, ә пластмасс уенчык элгән декорация.

Таш җәелгән тар урамнарда халык та, машина да күп. Озын автобусларның маңгайлары төрле төсле пыяла белән бизәкләнгән, уенчыкчуклар белән чуарланган. Ике фара уртасында гудок кычкырткычлары сыңар мөгез кебек тырпаеп тора. Гудокларның нинди генә юк: кайсы сызгырта, кайсы улый, кайсы чиный — берсеннән-берсе уздырырга тырышалар.

Урам шау-шуын күмеп, итальян җырчыларында гына очрый торган тенор белән азан әйтәләр.

Килеп төшкән кичне бар да бик ашыгыч булды. Кичке аш әзер икән, әйберләрне бүлмәләрдә калдырып, тиз генә кире чыгарга куштылар. Кунак өе өчен гадәти булмаган иркен бүлмәгә килеп кергәч, кызлар ашыгырга кирәклеген онытып, беравык тукталып тордылар. Спорт залыныкы кебек биек түшәм. Дүртәр кеше сыярлык ике карават-тахта. Мәчет тәрәзәсе кебек өстән түгәрәкләнеп килгән вак рамлы олы тәрәзә. Суфия ашык-пошык кына чүәген туфлига, чалбарын

юбкага алыштырды. Үтүкләү урынына су бөркеп, кулы белән сыпырды да — вәссәләм. Юлга чыкканда ук кичке кием киясе калган аны, бер кәнәфидән икенчесенә күчеп утыру өчен ниемә юл киеме? Юлчылар шулай сукранып та алдылар.

Ресторан дигәч, Суфия шәрык музыкасы уйнап торган күп халыклы залны күз алдына китергән иде. Кеше сирәк йөргән музейдагы сыман буп-буш, тып-тын. Совет туристларыннан башка беркем юк. Имәндәй юан аяклы өстәлләргә ак ашъяулык җәелгән, галәмәт авыр урындыклары кызыл бәрхет белән тышланган.

Иң башта өстәлгә пыяла чүлмәк белән су китереп куйдылар. Гарәбстанда су элек-электән иң кыйммәтле сый булып исәпләнә. Аннары кыстыбый камырына охшатып пешерелгән икмәк. Ят һәм тәмле ризыклар белән сыйладылар. Ахырдан әфлисун, банан, алма бирделәр. Алдагы ризыкның һәммәсен тәмләп ашыйм дисәң, ике сәгать вакыт кирәк булыр иде. Ләкин артык мавыгырга мөмкинлек юк. Кичке җыйдегә каядыр барырга икән, ашыгырга куштылар. Һотель янында машина көтә, имеш.

Суфиялар, холлга бүтәннәрдән соңлабрак төшкәнлектән, кая барасыларын ишетми калганнар иде, төпченеп тормадылар, утырдылар да киттеләр. Габделбәр абыйларыннан сораштылар, ул да белми икән:

— Монда үзеңне чүлдә без күргән сарык көтүе итеп фараз кылудан да яхшысы булмас, кая куалар, шунда бар,— диде ул, уенынчынын бергә кушып.— Үзебездә программа бар бит, шуны карыйсы булыр,— дип өстәде.

Зал шыгрым, җыелыш башланган. Кунакларга арттагырак рәтләрдән урын калдырганнар, иелә төшеп кереп утырдылар. Трибуна янында ак йөзле, аксыл сары чәчле ир-ат сөйли иде, гарәпчә. Аны кара мыеклы, кара чәчле икенче оратор алыштырды. Алкышлап каршы алдылар. Мыеклы гарәп кәгазьгә-мазарга карамый, сүзләре агылып тора. Залдагылар аны тын да алмый тыңлыйлар. Безнең сәфәрчеләр сөйләүчеләрнең телен аңламасалар да, гомуми тәэсиргә бирелеп, тып-тын утырдылар. Гарәпнең сөйләвендә Суфия сабый чактан таныш аһәңнәр тоя. Кайчандыр колакка чалынган сүзләр ишетелеп китә: «Инкыйлаби» [1], «Шуралар җөмһүрияте» [2], шунда ук «Иншалла» [3]...

Озын кышкы кичләрдә, Суфия бик бәләкәй чакта, дәү әнисе саргаеп беткән калын китаплар укый иде. Көйләп, җырлап укый иде. Мыеклы гарәпнең сөйләвендә шул аһәңнәр кабатлангандай була. Бик музыкаль сөйләшәләр икән гарәпләр. Зал сәгать буе «эһ» тә итми тыңлады. Ахырга таба оратор Суфияларга бик таныш сүзләр кыстырып җибәрде. Ленин. Коммунист. Әл рәфикъ Брежнев, әл рәфикъ Косыгин...

Зал гөрләтеп кул чапты. Җыелыш тәмам. Тыңлаучылар Суфияга оратор кебек үк сөйкемле, чибәр булып күренделәр. Күбесендә килешле генә кара мыек, кара бөдрә чәч. Негрларныкы сыман бөтергәч түгел, ә диңгез дулкыннарыдай кабарып торган бөдрә. Йөзләре дә Суфия күз алдына китергәнчә кара-кучкыл түгел, ә нәкъ безнең Идел буе татарларыныкы сыман. Залда күбесе яшьләр, сирәк кенә хатынкыз күренә.

Митингтан соң сәфәрчеләрне Совет илчелегенә чакырдылар.

Дәрәҗәле даирәләрдә кабул итү мәҗлесләре кызык була икән. Зал уртасында озын өстәл, өстәл тулы оҗмах сые, кунаклар аяк

[1] Инкыйлаби — революцион.
[2] Шуралар җөмһүрияте — Советлар дәүләте.
[3] Иншалла — алла теләсә.

өсте сыйлана. Поднослар белән эчемлек тәкъдим итеп йөриләр, нәни чынаяклар белән кара кофе тараталар. Журналист ханымнар көнбатыш әсәрләреннән укып белгән виски татып карарга булдылар. Кызыгырлык әллә ние юк, сыек-сары төстәге әчкелтем-төчкелтем эчемлек. Боз салып, су белән сыеклап бирәләр үзен. Аяк өсте мәҗлеснең уңай ягы да бар икән: янәшәңдәге белән генә түгел, теләгән кешең белән сөйләшеп йөрергә мөмкин. Парлашып йөрүчеләр дә, өчәр-дүртәр кеше җыелып кофе эчеп торучылар да бар. Культура үзәге тәрҗемәчесе гарәп Фаруктан Суфия кайбер нәрсәләр турында сорашты. Фарук бер кәлимә рус сүзе белмәгән, Мәскәүдә ике ел укып әйбәт кенә русча сөйләшергә өйрәнгән. Культура үзәгенең бурычы — гарәпләрне Советлар Союзы белән таныштыру. Клубта очрашулар, әңгәмәләр уздырыла, совет кинофильмнары күрсәтелә, илчелектә эшләүчеләр һәм мондагы совет белгечләре көче белән концертлар куела. Рус телен өйрәнү түгәрәге эшли. Кемнәр йөри? Төрле халык. Эшчеләр, студентлар, интеллигенция, күбесе яшьләр.

Суфия ничектер бермәлгә ялгызы калган иде, поднос белән эчемлек китерделәр: коньяк, виски, кофе — теләсәң кайсын сайла. Суфия кофелы чынаякка сузылмакчы иде, янында торган гарәп гаҗәеп өлгерлек белән аның теләген үтәде. Суфия үз телендә рәхмәт әйтте.

— Сезнең халык гаҗәп культуралы,— диде шулай ук татарчалап. Рәхмәт әйтерлек кенә гарәп сүзләре белә иде белүен, әллә нишләп исенә төшерергә өлгерми калды. Гарәп утыз яшьләр тирәсендә. Сәфәрчә ханым белән аның бик сөйләшәсе килә, әмма нинди телдә сүз катарга аптырап тора. «Мадам, фрэнш, инглиш»? дип, уртак тел табарга тырыша.

— Нәү, нәү [1],— ди Суфия инглизчәләп, «белмим» дигән сүзнең гарәпчәсен һич хәтеренә төшерә алмый.— Лә фи-ллөгати инҗилизияти вә лә фи-ллөгати фарансийати [2].

«Лөгать»не хәтерләргә Тукай ярдәмгә килде. Шагыйрьнең шундый юллары бар бит: «Рус белән тормыш кичердек сайрашып, тел, лөгать, гадәт вә ахлак алмашып». Калган сүзләрен Суфия татарчалап бетерде.

— Француз, инглиз белән кунакка йөрешмәгәч, аларча белмибез. Мәктәптә инглизчә өйрәнгән идек, кирәге чыкмагач, онытылган,— ди.

Гарәп исә чит телнең яңгырашына соклангандай тыңлый. Үз чиратында ул гарәпчә нидер әйтә.

— Шөкран, шөкран,— ди Суфия, «рәхмәт» сүзен, ниһаять, исенә төшереп. Гарәп тагын җанланып китә, Суфияның бик аңлап бетермәвен сизеп, янында торган тәрҗемәчене ярдәмгә чакыра.

— Зәңгәр күзле рус кызын беренче тапкыр якыннан күрәм.

— Ә-ә, рус түгел мин, татар мин, Суфия.

«Суфият», «татар», «кәсир» дигән сүзләрне аера Суфия, татарларның күпме икәнлеген беләсе килә бугай гарәпнең.

— Кәсирун [3],— ди Суфия. Алты миллион икәнлеге аңлаешлырак булсын өчен, бармаклары белән дә күрсәтә. Аңлашу ысуллары табылганга икесе дә көлешәләр. «О-о» дип куя гарәп, чөнки бөтен Сүрия халкы шул чама.

— Шу исмак? [4]

Гарәп Зәкәрия атлы икән. Кирәкле сүзләрнең телгә килеп торуына сөенеп, Суфия тагын сораша:

— Ма шөглука? [5]

---

[1] Юк, юк (ингл.).
[2] Инглизчә дә, французча да сөйләшмим (гар.).
[3] Кәсирун — күп (гар.).
[4] Шу исмак — исемең ничек? (гар.)
[5] Ма шөглука? — шөгылегез?

— Актубу шигран, ягъни эна шагирун [1].

Каты «г» авазын гарәпләр тамак төбенә бик җиткермичә, апострофка ошатыбрак әйтәләр икән. Шагыйрь булып чыкты мыеклы.

Ул да Суфияның шөгыле белән кызыксына. Бер сүз белән генә җавап бирергә кирәк тә бит, белми Суфия сүзне. Хәзер тырыш инде, аңлат.

— Эна... җаридатан [2].

Шагыйрьнең йөзе тагын да яктырып китә:

— Ягъни нәхну зумалау фи-әл-амали! [3]

Коллегасының һәр сүзен аңлаган сыман, Суфия күкрәгендәге значокка ымлый:

— «Социалистик Татарстан» — минем ватан.

— Ватан?

Бер-берсен аңлауларына сөенешеп елмаештылар. «Ватан» ике тел өчен дә уртак сүз.

Суфия тәрҗемәче аша шагыйрьнең иҗаты белән кызыксына. Зәкәрия әле үз исеме белән китап чыгармаган, уртак җыентыкларга гына катнашкан. Сүрия язучысына китап чыгару ифрат кыйммәткә төшә: хәреф җыючыларга да, кәгазь өчен дә үзе түли икән. Төп темасы? Тынычлык. Ә моңа ирешү өчен дошманны җиңәргә кирәк.

Язучы белән кызыклы әңгәмәне Суфияның бик дәвам итәсе килсә дә, китәргә вакыт җиткән. Күмәк сәяхәтнең үз кагыйдәләре бар, аларга буйсынмый булмый.

Моңарчы күңелен биләп торган шик-шөбһәләрнең таралуын тойды Суфия. Шомлану Мәскәүдән кайткан ораторның дулкын-дулкын булып аккан таныш аһәңле сүзләре белән агып китте. Сагаю мыеклы шагыйрьнең сабыйларча елмаюында эреде. Аның сугыш һәм җиңү турындагы сүзләре күңел түрендә ышаныч тудырды. Аңлашылмас телләр, аңлаша алмас кешеләр юк икән дөньяда.

## Сәләхетдин һәм алтын йөзек

Кара чәчле, чем-кара күзле яшь кенә гид килеш-килбәте белән күптән күреп йөргән кешегә охшаган. Исеме Хәсән икән. Сөйкемле егетнең сүзләре дә аңлаешлы булыр төсле иде, французча сөйли башлады. Борынгы легендаларның чынлыгына шик тотмагандай сөйли ул.

Оҗмахтан сөрелгәч, Адәм белән Һава Дәмәшкъ янындагы менә шушы Сәрәндин тавына килгәннәр. Ул чакта, әлбәттә, шәһәр булмаган әле. Эссе таш та кайнар ком. Күз ачар әмәл юк, бөтен дөнья көйдергеч кояш нуры белән тулган. Алар икәүләп кипшенгән иреннәрен чылатырга су эзләп китәләр. Су бар җирдә тереклек бар, яшеллек бар, яшәү бар. Шәрә тәннәрен бер-береннән каплар өчен яфрак өзәләр...

Хәсән туристларны су юлына түгел, ә гөнаһ җимешеннән авыз ителгән урынга, ягъни борынгы «оҗмах»ка алып китте. Дәмәшкътән бик ерак та түгел, автобус белән бер сәгатьләп кенә барасы.

Ярым кыргый бакча. Бакча тирәли челтерәп чишмә ага. Шушында оҗмах булган. Оҗмахны җирдә ясап булмый дип әйтеп карасыннар! Җирдә гөнаһ кубәйгәч, кеше хыялы аны соңыннан гына күккә мендергән, күрәсең.

Легендаларның чынлыгына гид үзе әллә ышана, әллә юк, гаҗәпләнми, сокланмый, әйтерсең көн дә булып торган хәлләр турында

[1] Актубу шигран, ягъни эна шагирун — шигырь язам, ягъни мин шагыйрь.
[2] Эна... җаридатан — мин... газета.
[3] Ягъни нәхну зумалау фи-әл-амали! — Без, алайса, коллегалар!

белешмә бирә. Туристлар җитәкчесе Вероника Сергеевна аны русчага әйләндерә.

Кеше дигән затны сынар өчен ходай тәгалә оҗмахка Иблис җибәрә. Иблис котыртуы буенча Адәм белән Һава тыелган татлы җимештән авыз итәләр. Һава җимешне йотып җибәрә, ә Адәм капкан җимешнең төше дөньяга киләчәк бөтен ирләрнең тамагына мәңгелеккә төер булып утыра...

Гид сөйләп бетергәч, ирләрдән берәү тынлыкны бозды:

— Егетләр, гөнаһ төерләрегез барыгызның да үз урынындамы?

Бу сорау бирелгәнче үк ирләр тамакларын капшап, Адәмнән калган төерне барлый башлаганнар иде.

— Димәк, гөнаһ эшләмәгән ир юк,— диде берсе.

Икенчесе болай дип аңлатып бирде:

— Алла бәндәсе, гөнаһ эшләгән өчен утырмаган бу төер, ә ходай тәгалә Адәм галиәссәләм бугазында җимешне тотып, гөнаһ ясаудан тыеп калган өчен.

Гид, ерактагы биек тауга таба кулын сузып сөйли-сөйли, сәфәрчеләрне шул якка алып китте.

Кешене бөек һәм изге хисләр югары күтәрә. Кеше булган җирдә түбән көнчелекләр, үчлекләр дә була. Дөньяга яралу белән кешеләр бер-беренә капма-каршы хисләр өермәсендә бөтерелә башлыйлар. Атабыз Адәм һәм анабыз Һаваның угыллары Кабил белән Һабил икесе бер кыз өчен ызгышып киткәннәр. Көнчел Кабилнең хәнҗәреннән хыянәт белмәс Һабил һәлак булган.

Әнә ул, кыя тау башындагы ялгыз кабер. Мәхәббәт өчен шәһит киткән иң беренче корбан. Күк томан эчендә ак чардуган... Беренчеләргә бит һәр вакыт һәйкәл куялар.

Табигать үзе биргән гомерләрне үзенә ала барган, аларны кояш күзеннән, дөнья йөзеннән яшерә торган. Һәм менә күз камаштыргыч кояшлы көн, чылтырап аккан чишмәләр, гөлгә күмелгән бакчалар... Бу сафлыкны бернинди гөнаһ пычрата алмас, бу яктылыкны бернинди болыт каплый алмас сыман. Мәһабәт таш сарайлар, алтын-көмеш бизәкле заллар, зал уртасындагы сихри фонтаннар...

Бер әкияттән икенче әкияткә күчеп йөрде туристлар. Әкият эчендә әкият... Ләкин берсеннән икенчесенә күчкәндә бүгенге аша узарга туры килә иде.

Дәмәшкъ урамнарында халык күп. Туктаусыз машиналар агыла, җәяүлеләр мыжлап тора. Йөзләренә кара пәрәнҗә япкан сылу сынлы хатыннар үтеп китә. Иң олысы бот буе биш-алты бала иярткән аналар урамда пәрәнҗәсез дә күренәләр. Ирләр чуклы яулык очларын җилбәгәй җибәреп, баш тирәли бау урап куялар. Яулык гадәттә соры, божра-бау кара төстә. Ак яулык өстеннән кызыл божра кигән ирләр дә очраштыра. Монысы, күрәсең, шатлыклы вакыйга уңае белән, бәйрәмчә киенү билгесе. Күпчелек ирләр, бигрәк тә яшьләр, европача киенә икән.

Үзәктән аз гына читкәрәк китсәң, атлы-арбалылар, велосипедка атланганнар — барысы бер юлда. Шунда ук вак-төяк сатучылар, шылдыр-былдырларын шылтыратып, узып баручыларның юлына төшәләр. Су, җимеш сатучылар товарларын кычкырып мактыйлар. Сеңер сагыз каплары тоткан малайлар, юылмаган нәни кулларын сузып, туристлар төркеме артыннан ияреләр. Бәрелми-сугылмый үтим дисәң, бер нәрсәгә дә игътибарыңны юнәлтмичә, туп-туры алга карап барырга кирәк. Шуңа күп кенә кызыклы әйберләрне күрми каласың.

Туристларны урам аркылы чыгарганда гид Хәсән ике кулын җәеп машиналар агымын туктата. Шәһәр урамнары тар, халык күплеге шуңа да нык сизелә.

Борынгы биналарның берсе булган Гомайядлар мәчетенә туристларның һәммәсе аяк киемнәрен салып, хатын-кызлар кара бөркәнчек ябынып керделәр. Мәчет ислам диненең чәчәк аткан чорында, сигезенче гасыр башында салынган. Гомайядлар берләштергән Гарәбстан чикләре ул вакытта Бохара, Сәмаркандтан алып Каһирәгә чаклы җиткән. Өч манаралы, бер гөмбәзле мәһабәт мәчет солтаннар династиясенә лаеклы һәйкәл итеп төзелгән. Уртада фонтанлы бассейннары белән ул бөтен бер кварталны биләп тора.

Гарәп гидның французчасын русчага тәрҗемә иткәч, куян шулпасының шулпасы килеп чыга, тыңлау бик кызык түгел. Суфия да, бүтәннәр дә үз күзәтүләренә ныграк ышанып, күбрәк үз тәэсирләренә бирелеп йөриләр. Мәйдан чаклы зур зал. Төрле ташлар белән бизәкләнгән стеналар күк гөмбәзенә тоташалардыр сыман. Идәндә чәчәкле болындай зур келәмнәр. Келәмгә аякларын бөкләп утырган бала-чага сабак укый. Туристларга берсенең дә исләре китмәгән булып кыланалар. Урамда бит шушы ук бала-чага чит ил кешеләрен тамаша кылып артларыннан калмый йөри. Изге урынны ихтирам итүме бу? Яз ахыры, имтиханнар чоры, сабакка бирелгәнлек шул чаклы көчлеме? Китап өстенә иелеп төшкән бер малайның җилкәсендәге кара миңен кытыклау теләге туды Суфияда. Тынлыкны бозудан куркып, якын килмәде. Яңа Сүриядә мәктәпләр дәүләт кулына күчсә дә, дин укыту, элеккечә, үзәк урында тора. Халык күп булуга карамастан, мәчет эчендә бер хәрәкәт юк. Картлар мәрткә киткәндәй күзләрен йомып, иреннәрен кыймылдатып утыралар.

Мәчет эчендәге ишекләрнең берсе өйалды сыман урынга алып чыга. Соры таш стеналы чолан кебек бүлмәдә шундый ук таштан ясалган ике табут. Гарәпләр өчен изге көрәшче Сәләхетдин белән аның ярдәмчесе Имаметдин җирләнгән монда.

XII гасыр. Ярлы гаиләдән чыккан көрд Сәләхетдин үзенең куркусызлыгы, батырлыгы аркасында гаскәр башлыгы дәрәҗәсенә ирешә. Хәрбиләр ярдәмендә фатимидлар династиясен алып ташлый, үзе тәхеткә килә. Илнең бәйсезлеген кайтару өчен Көнбатыш баскынчыларына — тәре йөртүчеләргә каршы көрәш башлап җибәрә. Сәләхетдиннең батырлыгы турында җырлар чыга, әкиятләр сөйләнә, аның үзен күрер өчен генә әллә ни бирерлек булалар. Изге сугышка күтәрелмәгән авыл-шәһәр калмый.

Дәүләт башлыгы, юлбашчы турындагы гомер-гомердән килгән теләк-хыялларын кушып, гади халык Сәләхетдинне изелгәннәр өчен көрәшче итеп таный. Гид та аны нәкъ шулай сурәтли.

Бәйсезлеккә омтылган халык баһадир Сәләхетдинне үз солтаны итеп таный: батыр солтан Сүрияне, Фәластин, Мисырны берләштерә. Ә үзе зиннәттән баш тарта, суфилыкны алга сөрә. Пәһлеванлыгы белән генә түгел, гадилеге белән дә бөек кешенең тормышын хәзер дә әкият итеп сөйлиләр, аның таш табутына табыналар. Чөнки азатлык һәм бердәмлек өчен көрәш әкият дөньясына китеп бетмәгән әле. Бигрәк тә гарәпләрдә бу бүген дә беренче чираттагы мәсьәлә. Дәмәшкъка кергәндә күргән җимерек кварталлар, яртысы җиргә сеңгән кечкенә балчык өйләр — һаман тукталмаган сугыш тамгалары.

Холлга кайткач, туристларны төшке ашка чакырдылар.

Ак күлмәк, кара костюм, кара галстуклы официант егетләр өстәл-урындыклар арасында балериннар сыман йөриләр. Хәрәкәтләре җиңел, төгәл, өстәлгә куйган әйберләре һәммәсе үз урынында. Кашык, чәнечке ише әйберләрне алар куйган урыннан ике сантиметрга күчерсәң дә, өстәлдә тәртип югалыр төсле. Җикән сабагыдай зифа буйлы официант ике кашыкны бер-берсенә каплатып алып, Суфия тәлинкәсенә ят ризык сала.

— Җитәр... Һалас! — Суфия һәр вакыттагыча сүзне башта татарча әйтеп, шуннан гына гарәпчәсен исенә төшерде.

— Җитәр? Төрекчә беләмсез?

— Сез әллә төрекме?

— Бәнд — көрд. Төрек белән сүләшә беләмез.

— Алайса, без дә төрек белән сөйләшә белербез.— Суфия көрдне якын итеп, ихлас елмайды. Көрд тә шундый ук җавап кайтарды, нәзакәтле баш иеп, бүтәннәргә сый-хөрмәт өләшергә китте. Эш вакытында сөйләшү аларның гадәтендә юк. Үз урыннарын, үз бәяләрен белеп кенә йөриләр. Туристлар туенганда официантлар бер читтә басып, гыныч кына карап торалар. Аштан бушаган тәлинкәне өстәлдә бер минут та тотмыйлар, шундук чистасы белән алмаштыралар. Бушаган савытларны җыеп алганда кашык шалтыравын да ишетмәссең. Үз эшләренең матурлыгын күрә beләләр. Дөресрәге, шактый кызыксыз тоелган эшкә гүзәллек бирәләр. Һәрхәлдә, Суфия «Аккош күле»ндәге салмак биюләр тәэсирендә бирелеп утыргандай хис итте үзен. Ашханә кебек җирдә мондый нечкә осталыкны ул беренче очрата иде.

Төшке аштан соң ирексездән ике-өч сәгать ял итәргә туры килә. Көн кызуында шәһәрдәге бөтен учреждениеләр ябыла, кибетләрнең ишек-тәрәзәләре эчкә кояш төшмәслек итеп каплана. Урамнар бушап кала. Сәгать кичке бишкә чаклы шәһәр ял итә. Биштән җидегә чаклы ике сәгать — туристларның шәхси вакытлары. Бу вакыт шәһәр карау, сувенирлар алуга багышлана. Әллә ни алмасаң да, сату-алу мәзәкләрен тамаша кылу үзе бер кызык, музей караудан һич ким түгел.

Туристлар җитәкчесе Вероника Сергеевна шәһәргә ялгыз чыкмаска куша, чит-ят җир, төрле хәл булуы мөмкин, ди. Суфия белән Матура бер-ике кибеткә кереп чыктылар. Матураның күзе төшкән бер күлмәк бәясе белән кызыксынганнар иде, моңа үкенеп бетә алмадылар: әйбернең бәясен киметә-киметә алырга кыстау китте. Чат ябышкан кибетчеләрдән гаҗиз булып, безнең дамалар витриналарга гына карап уза башладылар. Суфияның Гарәбстан якларына гына хас истәлекле әйбер аласы килә иде. Хрусталь, фарфор савытларга соклангып уздылар. Саплары төрлечә бизәкләнгән хәнҗәр-кылычлар янында тукталып тордылар. Борын заманнарда Дәмәшкъ кылычлары бөтен дөньяда дан тоткан. Суфияның күңеленә кайчандыр укылган юллар килде:

Шаң-шаң иткән шам кылыч —
Ир-егетнең кылычы...

Шам-кылыч — Дәмәшкъ кылычы дигән сүз. Утта кыздырылган яңа кылыч кол тәнендә сыналган. Кол канында чыныктырылган, имеш...

Җиргә чапса — су чыгар,
Ташка чапса — ут чыгар,
Тәнгә чапса — кан чыгар,
Канга чапса — җан чыгар...

Сугыш — һөнәр, үтереш — кәсеп булган заманнарда Дәмәшкъ кылычын мактап җырлар чыгарганнар. Хәзер аларны тарих истәлеге итеп келәмле стенага элеп куялар.

Юлчылар фәлсәфи уйларга бирелеп бер урында озак тора алмыйлар. Узган-барган бик игътибар итә, сәфәрчеләр үзләре тамаша үзәгенә әверелә. Ир-ат күзгә керердәй булып чекерәеп карый. Чөнки урамда йөзе ачык хатын-кыз юк дәрәҗәсендә. Безнең сәфәрчеләр дә йөзләрен пәрәнҗә белән каплардай булдылар. Кай якка барырга белмичәрәк бер читтә басып торганда, тылсымлы ишектән чыккандай, официант көрд пәйда булды. Сәфәрчеләр аны күрүгә кара

урманда таныш кеше очраткан сыман сөенделәр. Көрднең янында иптәше дә бар. Күкрәкләренә ымлап, таныштылар. Официантның исеме Рәшид, иптәшенеке — Тарикъ. Кызлар татарча, Рәшид көрдчә — ярыйсы гына аңлашалар. Авазларның әйтелешенә генә игътибарлы булырга кирәк, сүзләр шул ук диярлек. Базарга юл тоталар икән. Дамалар теләсә, бергә барырлар. Дамалар икеләнеп торуны яхшысынмадылар, киттеләр. Базарны да күрергә кирәк. Гадәттә ул шәһәрнең иң кайнап торган урыны була. Суфияның күңеленә бермәл «бу көрд арттан күзәтеп килгәнме әллә?» дигән шик төште. Югыйсә, һотельдән ерак бер җирдә ничек очрашырлар иде? Нәкъ аптырашта калган чакны туры китереп, каршыларына килеп бастылар. Тарикъ дигәне бер сүз дәшми, сәфәрчеләр белгән телнең берсен дә белми икән. Әллә белеп тә телсез шикелле барамы? Матура да шундый шикле уйлар кичерә бугай, тирә-якка сагаеп карый. Әллә ничаклы лабиринтлар үтеп, электр уты белән яктыртылган аралыкка килеп керделәр. Тар гына коридорның ике ягында газета киоскаларына охшаш такта кабиналар. Тәрәзәләрнең эчке ягына алтын алка, балдаклар, җем-җем ташлы муенсалар эленгән. Суфияның эченә шом йөгерде, бу аралыктан аның тизрәк чыгасы килде. Ә Рәшид ике кулын артына куйган да җай гына атлый. Әнә ул таныш сәүдәгәрен очратты бугай.

— Мәрхабә!

— Мәрхабә.

Танышлар бер-берсенә сәлам бирделәр, гарәпчә нидер сөйләшеп алдылар. Әрмәнгә охшаганрак сатучы затлы әйберләренә ымлады, карагыз, сайлагыз, янәсе.

Кызлар йөзек карый башладылар. Фирүзә кашлар бик гади, зәңгәр төймәгә охшаган. Энҗе ташның исеме кызыктыргыч булса да, төсе әллә ни искитәрлек түгел, ак перламутр буялган мәрҗән төсле. Суфия кызгылт кашлы бер йөзеккә тукталды. Ташы александрит дип атала икән. Алмаз, якут белән янәшә тора торган таш ди. Көн яктысында аның төсе яшел булырга тиеш, ә ясалма яктылыкта — чия кызыл. Караңгыракта шәмәхә-зәңгәр төскә керә. Суфия шушы балдакны алырга булды. Ил эчендә туристик походларда йөргәне бар, кая барса шуннан таш алып кайта. Кавказ, Урал, Алтай ташлары... Сарман янында Петр I дәверендә казылган бакыр базыннан таш кисәкләре, Идел буендагы Болгар хәрабәләре истәлеге. Менә Гарәбстаннан да бер истәлек. Икәүләп карап та, бер әйбер алмый китү килешмәс төсле.

Рәшид кызларны каядыр чакырып маташты, буза эчәргә дип сөйләнде, кызлар баш тарткач, кәефсез генә саубуллашып, иптәше белән китеп барды.

Якты һавага чыккач, бөтен шикләр таралды. Официант көрд сәүдәгәр дустының әйберләрен үткәзергә ярдәм итеп йөри, күрәсең, килгән туристларга шунда юл күрсәтә.

Аллы-гөлле хәтфә келәмнәр, елкылдавыклы парчалар бүлеме лаклы сумкалар, елтыр башмаклар рәте белән алмашына. Аннан ары — ал, яшел, сары пластмасстан савыт-саба, табак, кәстрүл, кәрзин... Тау-тау әфлисун, банан... Шау-шу, этеш-төртеш. Велосипед, ишәк, дөя... Мөсафирларыбызның башлары әйләнде, күңелләре болганды, бу «җәннәт»не бер күрмәскә әллә ни бирерлек хәлгә килделәр. «Кавалерлары» да хәтәр әйбәт булып чыкты, чакыруларын кабул итмәгәч, эзләреннән җил исте.

Дамалар исә Хәмдия базарыннан чыгу юлын тапмый йөдәп беттеләр. Чит ил кешеләре икәнлекләрен белеп, һәр җирдән сатучылар кычкыра: «мадам» да, «товарищи» да калмый. Бер алга, бер артка төшеп, кибетләренә чакыралар, җитәкләп алып кермәкче булалар. Бу илдә кустарьчылык алга киткән, вак-төяк әйбер күп. Халыкның

сатып алу мөмкинчелеге түбән. Товарны сату-сатмау яшәү белән үлемне хәл итә торган мәсьәлә. Аннары мөсафирның күңелен күрү дигән нәрсә элек-электән гарәпнең канына сеңгән. Сатып алучыларга игътибарлы булу шул әйбәт гадәттән дә киләдер. Кустарьлар бит күбесе гарәпләр. Ә менә алтын сатучылар — тәкәббер. Ул товарын кыстап тагарга тырышмый, артык сатулашмый. Беренче сораган хакыннан азрак төшсә дә, йөзенә «ярый, сезнең белән вакланмыйм инде» дигән мәгънә чыгара.

Кичен Суфиялар бүлмәсенә Фәрит керде.

— Кая, кызлар, сезне бездән качып китеп, асыл әйберләр алган диләр, күрсәтегез әле.

Суфия ачык тәрәзә борысына сөялеп, урамны күзәтә иде, баскан урыныннан кузгалмый гына йөзекле кулын Фәриткә таба сузды. Фәрит кызның озын нәфис бармакларын үз учына алды, икенче кулы белән сак кына йөзек кашын сыйпады. Йөзекле кулны озак кына җибәрмичә, әйләндереп-әйләндереп карады. Бу якынлык гүя үткән вакыт арасын алып ташлады, Суфияның күңеле күзгә урманга күчте. Алтынсу сары шәл бөркәнгән каеннар... Беренче тапкыр кулны кулга орындыру...

Үткән көз яшь нефтьчеләр слетына килгән кунакларны Суфия, хуҗа кеше буларак, аэропортка озата барган иде. Көн аяз булуга карамастан, самолет ике-өч сәгатькә тоткарланды, күтәргә туры килде.

— Әйдәгез, йөреп киләбез,— диде Фәрит Суфияга, иптәш егетенә дәшкәндәй гади генә итеп.

Көз сарысы кунган каеннарга карап, сүзсез генә йөрделәр.

Самолет очканда Суфия кул болгап калды. Бөтен танышлык шул. Көткәнгәме, Казаннан Фәритнең шалтыратуын Суфия әллә кайдан танып ала иде. Фәрит сораган газета мәкаләләрен мәхәббәт хаты язгандай яза. Үзен җитәкләп баручыга мохтаҗ микән әллә Суфия? Сабый чагыннан ул әбисе тәрбиясендә үсте. Бөтен тормышны ялгызы алып баручы авыл карчыгының игътибары кызчыкка җитеп бетмәде. Ятимәне карчык я бик иркәләде, я бик каты куллы булырга тырышты. Шуңадыр, Суфия бер караганда басынкы, буйсынучан, икенче караганда башбирмәс, чая булды. Мөстәкыйльлеккә омтылып, үзенә ярны да бик иртә тапты. Ләкин ул яр ничек тиз табылса, шулай ук тиз юкка да чыкты...

Аэропортта Казан кунаклары белән хушлашканнан соң аның күңелен нindидер юксыну, тынгысыз омтылу хисе биләп алды. Менә бүген тагын Суфияның бәләкәй генә нәфис кулы Фәритнең көчле кулы белән очрашты. Йөрәк эшеме бу, ми эшеме — тән буйлап кайнар кан йөгерә. Буйсынмаска иде бу башбаштак хискә... Соңыннан аңардан арынуы кыен. Суфия көчле булырга тиеш.

Кызның карарын бармак очындагы сизгер кыл-тамырлар Фәриткә җиткерде бугай, егет кинәт турайды. Үз карарын ныгытыр өченме, Суфия әйтеп куйды:

— Официант Рәшид сайлашты...

Фәрит йөзекне Суфияның урта бармагыннан салдырып, атсыз бармагына кидерә-кидерә сүз катты:

— Бер үк вакытта Сәләхетдингә һәм алтынга табыну логикага сыямы соң? Нәрсә диләр әле: суфи суган сөймәс...

Солтан Сәләхетдин турындагы бүгенге сөйләшүне искә алып маташа икән Фәрит. Суфия корт чаккандай кулын аңардан тартып алды. Тартып алуы булды, бармакка киелеп бетмәгән йөзек ачык тәрәзәдән урамга очты. Күтәрелгән кулына карап, Суфия «аһ» итеп куйды, ләкин баскан урыныннан кузгалмады. Йөзекне ул юри тышка ыргыткан төсле тоелды Фәриткә.

— Мондый кыю эшкә сәләтле икәнлегегезне белми идем әле,— диде Фәрит, салкын тынычлык белән. Ләкин ул тыныч булырга тырыша гына, әнә яңак сеңерләре тартышкалый.

Фәрит белән Суфияның сүзләренә катышмаган Матура өченче каттан йөзек ыргытуга кысылмый кала алмады.

— Әй, очынчык та инде! Хәзер ничек табасың аны? — Матура әрләшә-әрләшә урамга чыгып китте.

Буламы соң мондый урамнан алтын йөзек табып? Халык мыжгып тора. Үзләре яшәгән бүлмә турысын табу гына да кыен. Йөзләгән тәрәзә бит монда, йөзләгән... Суфияның кыланышына чын күңелдән рәнҗеп, урам як тротуарда арлы-бирле йөренгәндә, гостиницадан бер гарәп чыкты.

— Мадам, мадам...

Кулы белән ымлап, ул Матураны чакыра икән. Гарәп артыннан Матура холлга керде. Ачкыччы янына килделәр. Ачкыччы гарәп Матурага үтә ягымлы елмаеп, французча дәште:

— Мадам, бу әйбер сезнеке булырга тиеш, сез нидер эзли идегез?

Ачкыччы кулында Матура таныш йөзек күрде.

— Уи, уи! — Сөенгәнен бик күрсәтмәскә тырышып, йөзекне алды.— Мерси, мөсье! [1]

Ачкыччы, әйбернең иясе табылганга сөенгәндәй ачылып китеп, аңлатмалар өстәде. Йөзекне урамнан баручы берәү кертеп биргән, тәрәзәдән төшкәнен күргән...

— Мерси, мөсье...

Француз телен мәктәптә өйрәнү өстенә Матураның аз гына сөйләшү тәҗрибәсе дә бар. Казанга француз яшьләре делегациясе килгәч, газета вәкиле буларак, алар тирәсендә йөргәләгән иде. Үзе чатнатып сөйли алмаса да, кешенекен ярыйсы гына аңлый.

Табышын учына йомарлаган Матура бүлмәгә кергәндә Фәрит инде юк, Суфия юрганын бөркәнеп йокларга яткан. Имеш, аны берни дә борчымый, имеш, аның күңеле тыныч...

Суфияның уйлары исә аерылган ире Фуатка барып тоташты. Теге чакта Фуатның хаксызлыгын дәлилләрлек сүз таба алмады Суфия. Тормышта турылыклы юлдаш булырга тиеш кешенең бүтәнчә уйлавына кабат-кабат ачынды. Аңарчы Суфия үзе кебегрәк фикер йөрткән кешеләр белән аралашты. Нилектән Фуат шундый? Һәм нигә әле ул менә хәзер генә Суфияның исенә төште? Бүгенге тәэсирләргә ниндидер кагылышы бар сыман. Сәләхетдин табуты... Солтанның зиннәттән баш тартуы. Алтын йөзек... «Суфи суган сөймәс...» Мещанка дип уйлагандыр Суфия турында Фәрит. Үткәннәр — вөҗдан көзгесе. Кайтып-кайтып, синең чагылышыңны күрсәтә ул көзге. Суфияның чагылышы нинди анда? Үзенә аңлашылмаган кешеләр белән ике араны ул кырт өзде түгелме?

Бер ялгышлык эшләсәң, гомер буе өрәк кебек артыңнан йөрер, ди. Бармак канатып салган балдак турында тагын бер тапкыр Суфияның исенә төшерүче табылды. Чит илдә, чит-ят кеше. Алтын балдакка ниндидер бәйләнеше бар кеше. Ярый әле, Суфия аның белән сәяхәт ахырында, туган илгә кайтып китәр алдыннан гына очрашты. Югыйсә, искиткеч сәфәр тәэсирләре шыксыз хатирәләр белән аралашып, төссезләнеп калыр иде. Ә хәзергә сәяхәтче тауларга менде, коймалары белән дәһшәтле, корбаннары белән шомлы кирмәннәргә [2] керде. Хәрабә шәһәрләрдә борынгы сәнгатькә сокланды. Походларда, юлларда яңа Сүрия белән танышты, аның шатлыгына шатланды, аның кайгысына кайгырды.

---

[1] Уи, уи! Мерси, мөсье! — Әйе, әйе! Рәхмәт, әфәндем! (Фр.)
[2] Кирмән — крепость.

Тарих бөеклек һәм түбәнлекләрдән тора. Җиңү дә җиңелүләр, төзү дә җимерүләр... Тарих дигән илдә мәгърур шәхесләр, аларның мәңгелек эшләре яши. Дәмәшкъ музее. Безнең эрага чаклы күп йөз еллар элек ташка язылган серле язмалар. Шул заман казылмаларыннан табылган бизәкле балчык чүлмәкләр, алтын-көмеш беләзекләр. Бу борынгы Мисыр һәм Месопотамия... Белгечләр генә укый алырдай тарихи истәлекләр белән аралашкан пәйгамбәр сурәтләре төшерелгән стена китекләре, таш бизәкле колонна ватыклары. Сүриядә Рим һәм Византия хакимлек иткән гасырлар аша атлап, музейның бер бүлмәсеннән икенчесенә чыгасың. Җиденче-сигезенче гасырлар, ислам дине белән берләшкән Гарәбстанның куәтле чагы. Дөя тиресеннән шомартып эшләнгән төрле зурлыктагы китаплар... Барысы да кулдан язылган. Дин юлына күпме күз нуры түгелгән! Күпме акыл яктырткан ул юлны! Кайсы караеп, кителеп беткән, кайсы һаман да елкылдап торган кылычлар, хәнҗәрләр. Ничә гомернең башына җиткәннәр дә кемнәр исеменә дан яулаганнар алар? Тимер алкалардан ясалган хәрби киемнәр... Ләкин тимер киемнәр дә, корыч калканнар да илне яңа яулардан саклап кала алмаган — Сүрия дүрт гасыр буе Төркия хакимлеге астында җәфа чиккән.

Мәңгелек дигән илнең борылмалы юлларыннан йөрисең-йөрисең дә үзең дә сизмичә бүгенгегә кайтасың. Безнең гасыр башы — Сүриядә көнбатыш капиталы хакимлек иткән чор. Бигрәк тә французлар өстенлек тота. «Кара алтын» диңгез аша көнбатышка озатыла, җирне торбалар сузу өчен файдаланалар. Банклар, сәүдә конторалары, портлар — бары да французныкы. Гарәпләр элеккечә һөнәрчеләр, терлекчеләр, игенчеләр булып калалар. Бу шөгыльләрдә борынгы ата-баба ысуллары хөкем сөрә. Әйе, тарих иле биеклек һәм түбәнлекләрдән тора.

Бүлмәләрдә экспонатлар тәртип белән тезелмәгән, гүя буталчык тарихка ачыклык кертүне кирәк тапмаганнар. Борынгы культура истәлекләренә илтифатсызрак карау сизелә. Гарәпләр үз бәһаләрен үзләре белеп бетерми. Гид Хәсән дә әйберләргә кирәксә-кирәкмәсә кулы белән кагыла. Матураның моңа эче поша. «Кагылырга ярамый» дип язып куясы иде. Бизәнү-ясану әйберләре яныннан Хәсән тыныч кына үтеп китә алмый. Гасыр катламнары астыннан табылган асыл ташлы муенсалар, алтын-көмеш беләзекләр янына килгән саен:

— Безне, ирләрне, бөлдерә торган әйберләр менә шулар инде, — дип кабатлый.

Гарәп хатыны ирдән аерылганда язылмаган закон буенча үзенең кием-салымын һәм бизәнү әйберләрен генә алырга хаклы икән. Бүтән барлык мал-мөлкәткә ир хуҗа. Шуңа да бизәнү-ясану әйберләрен күбрәк җыеп калу гарәп хатынының канына сеңгән. Өйдә бикләнеп, урамда битен каплап йөргән хатын-кызның юанычы да шул асыл ташлар, күрәсең.

Бүлмәдән бүлмәгә — «империядән республикага», «азатлыктан коллыкка» күчеп йөреп, тәмам талчыккан туристлар иң ахырдан солтанның киңәшмә залына керделәр. Музейдагы иң матур бүлмә бу. Сигезенче гасыр казылмаларыннан галимнәр шундый ук зал тапканнар. Музей залы нәкъ шул хәрабә залга охшатып эшләнгән.

Төсле пыялалар, төрле ташлар белән бизәкләнгән стеналар. Күк гөмбәзе шикелле ярымшар түшәм. Идәндә сабан туй мәйданы кебек аллы-гөлле зур келәм. Олы түгәрәк өстәл тирәсендә йомшак кәнәфи-

ләр. Музей залларында йөреп арган экскурсантлар кәнәфиләргә утырып ял итәләр.

Хәсән үзе утырды, бүтәннәргә дә шуны ук тәкъдим итте. Бу эшкә Матураның тагын ачуы килде. Нигә урындыкларга бездәге кебек «утырырга ярамый» дип язып куймаска инде! Туза бит алар. Өсләренә хәтта япма да ябылмаган. Ишегалдына чыгып, агач күләгәсендәге эскәмияләрдә ял итәргә була.

Юк, моның үз сере бар икән. Туристлар утырышкач, музей хуҗасы электр кабызгандагы кебек итеп бер төймәгә басты. Каршы як стенаны иңләп, югарыдан түбәнгә терекөмештәй су ага башлады. Стена бизәкләре су астында сай елга төбендәге ташлар сыман җемелдиләр. Ә гаҗәеп елга ага да ага... Шарлавыксыз, тын гына ага. Агымсу сулышны киңәйтә, күзгә рәхәтлек бирә. Бу гүзәллекне арыган килеш аяк өсте торып кына тоеп буламы соң!

Зал уртасында таш астыннан ургылып чыккан чишмә төсле фонтан. Бер-берсе өстенә утыртылган эреле-ваклы өч таш касә. Чишмә суы касәдән касәгә агып төшә дә каядыр җир астына китеп югала.

Шушы суга карап утырсаң, дөнья кайгылары, борчулар онытыла, Хәтта мәхәббәт тә...

Суга карап гид шулай дип сөйли.

Сәфәрчеләр дә суга карыйлар. Күз яшедәй саф су бер касәгә тула да аның тышыннан тын гына икенчесенә агып төшә, өченчесенә.... Челтерәгән тавыш та ишетелми, тып-тын.

Габделбәр кыска җиңле саргылт күлмәгенең сәдәфләрен ычкындырып җибәргән дә түшәм-стеналарны җентекләп карый. Яши белгәннәр солтаннар. Тышта 38 градус эсселек, монда җиләс. Гарәбстанда эссе дип куркыткан иде, тирләп-пешеп йөргән юк әле. Бина эчләрендәге күзгә күренмәс җилләткечләр гөжләп тормыйлар, һава алышынуын гына сизәсез. Ә бу агымсу сулышны җәңеләйтә, җанга ял бирә. Урамда тавыш, шау-шу, монда тып-тын. Гидның сүзләре хак: сәнгать белән чынлап ләззәтләнү өчен борчулардан арынган булу кирәк. Шул ук вакытта чын сәнгать кешене вак-төяк борчулардан арындырып, үз дөньясына алып керә. Күкрәккә иркенлек, теләккә омтылыш бирә. Дөньяны матурлау, аны чүп-чардан арындыру теләге көчәя.

Фәрит терсәге белән тезенә таянып, уйга талган. Кысынкы коңгырт күзләре тагы да кысыла төшкән. Тынычланып калган киң маңгаеның гадәттәге җыерчыклары җуелган. Нишә солтан бу тылсымлы агымга карап, дөньясын онытып утыргандыр... Һәркайсы «Мин барысына ирештем» дип уйлагандыр. Вәзирләр аның күз карашын аулаган. Кешеләр аның янына тезләнгән килеш, башларын җиргә ора-ора кергән. Ул баскан җирдә чишмә ургылып чыккан. Су — шөһрәт ачкычы. Ансыз бар нәрсә корый. Чөнки тирә-якта көйдергеч кояш, ком-сахра, бер йотым суга тилмергән бәндәләр...

Ходайдан мәрхәмәт сорап, күккә сузылган арык кулларның калтыравын, кибешкән иреннәрнең пышылдавын оныттыра алдымы икән соң бу тылсымлы агым?

Суфия чишмә янындагы колоннага сөялгән. Чокырдан чокырга су агып төшә. Чишмә таш астыннан ургылып чыкса да, тыштан тыныч.

Гасырлар эчендә сәяхәт кылып, сәфәрчеләр Дәмәшкътә инде атнага якын яшиләр. Йөзләрдә төньяктан килгән аклык югалды, бар да бериш кара-кучкылга әйләнделәр. Шуңадырмы, урам халкы хәзер туристларга сәер итеп карамый. Карасалар да, туристлар моңа игътибар итмиләр, күнектеләр. Ханымнар киеп алган кара күзлек күз камаштыргыч кояш нурыннан гына түгел, артык кызыксынучыларның үтәли карашыннан да саклый иде.

Матура сәяхәт истәлеге булырдай сувенир эзли. Аңа юлдаш бу-

лып, Суфия сату-алу хәлләрен тамаша кылып йөри. Урамда, базарда, кибет алларында бала-чага кайнаша. Күбрәк ир балалар. Иртә таңнан алар урам себерәләр, тротуар юалар, йомышка чабалар. Җидесигез яшьлек малайлар аяк киеме чистарталар, сәүдә итәләр. Алты класска чаклы гомуми уку законы кертелсә дә, бу закон тормышка ашырылмый, күрәсең. Кырмыска кебек мәш килеп, үз тамакларын үзләре туйдыручы малай-шалай укырга кайчан өлгерсен?

Җиргә чүгәләп утырган гарәп карты җиз комганнар сата. Тау кызлары сыман нечкә билле, озын муенлылары бар. Нишләп Суфия бу комганнарны тау кызларына охшатты әле? Әһә, шундый савытларны җилкәләренә утыртып, кинода тау кызлары суга бара. Монда гарәп кызлары үзләре кебек үк зифа савытларны башларына куеп йөриләр, кулларына белән тотмыйлар да. Үзе бер сынлы сәнгать!

— Матура, ал әле шул нечкә билле бәләкәй комганны ирең бүләк итеп!..

Базар урамының бер очында ирләр асфальт җәя. Башларына барысы бер төсле шакмаклы яулык бөркәнгәннәр. Киң штан төпләре асылынып, тезләренә үк җитеп тора. Театрда борынгы картларны шулай күрсәтәләр. Крестьянның иске модасыннан тамашачы рәхәтләнеп көлә. Ә монда көләсе килми. Урамда көлү килешмәгәннән дә түгел. Яулыклы ирләр таш чыгырларны кул белән әйләндереп, асфальт тигезлиләр. Йөзләреннән кара тирләр агып төшә. Чуклы яулыкларының очлары белән битләрен сөртеп алалар. Бәлки шул максат белән ирләр яулык бөркәнәдер?

Витриналарның берсендә Суфия дәфтәр битләренә ябыштырылган иске почта маркалары күрде. Филателия белән мавыгучы күрше малаен сөендерергә уйлады ул. Тротуарга аягын бөкләп утырган чалмалы карт алдына иелеп, Матура төрле формадагы трубкалар сайлап маташа иде (ире тәмәкече дә түгел ләбаса). Шуннан аерыласы килмәде, Суфияны марка сатучы белән французча сөйләшергә өйрәтеп кертте.

— Мөсье, монтре...[1]

Башлаган сүзен әйтеп бетерә алмыйча, Суфия тукталып калды: марканың хакын сорар, кибетче әйтер, аның французча әйткән бәясен Суфия аңламас бит.

Маркаларны ул шулай да французча сорап алды, калганын гарәпчә-татарча аңлаштылар.

— Бәһасе?

Гарәп язып күрсәтте. Саннар бит бер үк!

Маркалар белән эш бетүгә, Матура да килеп керде. Тотылган әйберләр җыя-сата торган урын бу, күрәсең. Бизәкле термос, җиз шәмдәл, көмеш кашык ише әйберләр бар, өр-яңа түгел икәнлекләре күренеп тора. Ханымнар музейдагы сыман фарфор чынаяк белән кызыксынасы иттеләр.

— Комме биан куттэ? [2]

— Пятьдесят рублей.

Бәй, французча сорауга русча җавап ишетелде. Үзара сөйләшкәндә мөсафирлар, гадәтләре буенча, русча сүз кыстырдылар бугай. Күзеннән ут чәчеп торган кибетче егет мөсафирларның кайсы илдән икәнлеген чамалап алды:

— Терешкова? Гагарин?

Таныш исемнәр ишетеп, ханымнар җанланып киттеләр. Әле генә игътибар үзәгендә торган чынаяк тонықланып калды, кибетченең үзе белән кызыксыну көчлерәк иде.

---

[1] Мөсье, монтре...— әфәндем, күрсәтегез... (Фр.)
[2] Комме биан куттэ? — Бу ни хак тора? (Фр.)

— Русча кайдан беләсез?

— Сәүдәдә өйрәндем. Миңа бөтен телләрне белергә кирәк. Миңа сатарга кирәк. Миңа табыш китерергә кирәк.

— Исемең ничек?

— Мин мөсье Монтре, — ди кибетче, хәйләкәр елмаеп, үзе читтәрәк торган Суфияга керфек астыннан карап ала.

Исеме Мәхмүт икәнен соңыннан белсәләр дә, ханымнар аны шулай «мөсье Монтре» дип кенә йөрттеләр.

— Җаның ни тели, мадам, шуны табабыз.

— Миңа ирләр әйберсе кирәк иде.

— Менә моннан да яхшысын таба алмыйсың. — Әллә кайдан гына укалы башмаклар килеп чыкты. Бусы Суфияга ошамады.

— Ука дигәне чыршыга элә торган елкылдавык кына бит аның, бер кисәң, сынып бетәчәк. Ыбыр-чыбырга кызыкма әле, дустым.

Гарәп боларның сүзләрен аңлап тора икән.

— Ыбыр-чыбыр түгел, мадам, чын ука. — Сатучы очлы башлы аяк киемен кулында уйнатып алды. Кибетченең татарча аңлавына ханымнар гаҗәпләнгәннәр иде, соңыннан исләренә төште: егет төрекчә белә, күрәсең. Сувенир алучылар нигездә туристлар, аларның телен аңласаң гына уңышлы сәүдә итеп була.

Теленә салынып торган кибетчегә теге баштан кемдер усал гына дәште.

— Гафу, мине чакыралар.

Егет ялт кына китеп барды. Сәфәрчеләрнең һаман китми торуларын күргәч, бер ара табып, тагын килде. Клиентлар өчен үзе астан әйбер алган була, үзе Матураның иңендә асылган фотоаппаратка карый.

— Сатасыңмы?

Матура башын селки. Мәхмүтнең русча бик сөйләшәсе килә, ләкин бушка вакыт үткәргәнгә хуҗасы ачулана. Туристларның кайсы һотельгә тукталганнарын белеп, егет өченче тапкыр яшен ташыдай ялт итеп китеп барды.

Культура үзәгендә үткәрелә торган берәр очрашуга яисә киного бармасалар, кичке сәгатьләренә туристлар үзләре хуҗа. Кайберсенең шәхси танышлары барлыкка килде, кунакка йөриләр. Кайберләренең танышлары һотельгә килә. Кунакларны холлда гына кабул итәләр, бүлмәгә алып керү әдәпсезлек санала. Холлда тәбәнәк өстәлләр, кәнәфиләр. Теләсәң, рестораннан шәраб һәм рюмкалар чыгарт, иң яхшы официант хезмәт күрсәтәчәк. Ләкин бу кыйммәткә төшә, үз илең түгел, артык мавыгып китсәң, күршеңнән акча алып булмый.

Кичке якта, һава җиләсләнгәч, Суфия белән Матура урамда йөреп керү нияте белән холлга төштеләр.

Бүлмәдәшенең беләгенә кагылып, Суфия ишеккә ымлады. Ике үсмер егет ачык ишектән эчкә узарга кыймый торалар иде. Берсе таныш кибетче Мәхмүт. Көндезге ак ситсы күлмәктән. Үтүкләнмәгән соры чалбары тез турысыннан самавар трубасы кебек бөгелеп тора. Икенчесе Мәхмүттән кечерәк кара-кучкыл йөзле үсмер малай. Сәфәрче ханымнар кунакларны каршы алырга кузгалдылар.

— Ә-ә, «мөсье Монтре»! Әйдәгез, рәхим итегез!

Һотель алдына чыгып, җиңел өстәлләр тирәсенә тезелгән үрмә урындыкларга утырдылар. Унбиш яшьләрдәге үсмер малай Мәхмүтнең энесе булып чыкты. Кәбир атлы икән. Абыйсы янында сәүдәдә эшли. Әңгәмәчеләр янына официант килде:

— Кө десир месдам, э мөсье? [1]

[1] Кө десир месдам, э мөсье? — Дамалар һәм әфәнделәр ни тели? (Фр.)

Туристлар үзләре генә утырганда мондый тәкъдим булмый иде, «дамалар» югалыбрак калдылар. Мөсье «Монтре» исә егетлеген күрсәтәсе итте, дүртесенә дә «оранж» дип аталган әфлисун суы сорады. Эчемлекне сыра эчә торган кружкаларга охшаш саплы балчык савытларда китерделәр. Алда шөгыль булганда әңгәмә дә җиңел бара. Сөйләшмәсәң, эчемлек белән мавыгып утырырга мөмкин. Безнең ханымнар сүз тапмый аптыраучылардан түгел. Мәхмүтләрнең тормыш шартлары белән кызыксыналар. Мәхмүтнең агасы, үзе, Кәбир, аннан кече энесе сәүдәдә эшлиләр икән. Агасы өйләнгән, үз тормышы. Апалары, сеңелләре күп. Илле биш яшьтәге атасы баш авыруыннан интегә. Гаиләне өч ир бала карый. Гарәпләрдә хатын-кыз эшләми, андый гадәт юк. Өй эшләре дә җитәрлек. Егетләр алты сыйныф укып туктаганнар, сәүдә итәргә шуннан артыгы кирәкми дә.

— Гадәттә ничә яшьтә өйләнәләр?

— Кем ничек? Ундүрттән дә, унсигездән дә, егерме биштән дә. Яшьтән өйләндергәндә олы кәләш алып бирәләр. Баеса, ул үзенә тагын яшь кәләш ала. Дүрткә чаклы өйләнергә хакы бар.

— Әтиең сине өйләндермиме соң әле?

— Өйләнергә акча күп кирәк. Башта апаны кияүгә бирәсе бар, аңа бирнә кирәк.

— Культура үзәгендә рус теле өйрәнү түгәрәге эшли, шунда йөрегез, укыгыз, тәрҗемәче булырсыз, гид булырсыз, акчагыз күп булыр.

Андый җиргә йөрергә егетләрнең вакытлары юк. Кибет ябылгач та кич буе урамда йөреп сәүдә итәләр.

Кәбир дә русча аз-маз сөйләшә. Ул абыйсы мөрәҗәгать итсә генә сүзгә кушыла. Гарәпләрдә олылардан узып сөйләшү юк. Җавапны да, сорауны да Мәхмүт кенә бирә.

— Ханымнар ничә сыйныф бетергәннәр? Эшлиләрме?

Институт, университетларда укыган өчен студент бер тиен дә түләми, киресенчә, дәүләт стипендия түләп укыта дигәч, Мәхмүт гаҗәпләнүеннән сызгырып җибәрде. Бу хакта аның элек тә ишеткәне бар, ләкин әле һаман ышанып җитми. Аларда югары белем алу өчен зур капитал кирәк, андый кеше Мәхмүтләрнең нәселендә юк.

— Мадамнарның ирләре бармы?

— Бар, бар. — Матура дәшми утырган Суфия өчен дә җавап бирде, — минем ирем врач, Суфиянеке журналист.

— Синең ирең бик байдыр, врачлар бик күп акча эшли.

— Бай, бай.

Матура студентлыктан чыгып бетмәгән Камилне күз алдына китерде. Җитәкчесе белән психотерапия буенча фәнни тикшеренүләр алып бара ул, сәяхәт кылырга да вакыт таба алмады. Матура журналист кеше, аңа йөрү кирәгрәк дип уйлагандыр.

— Ирең сине ничек ялгызыңны чит ирләр белән чыгарып җибәрде?

Мәхмүт Матурага син дип кенә җибәрә, гарәпләрдә бер кешегә күплектә эндәшү юк икән.

— Без бер-беребезгә ышанабыз.

— Хатынга ышансаң да, алар тирәсендәге ирләргә ышанырга ярамый. Гүзәл заттан ирләр баш тартмыйлар.

И хәсрәт, ничек сөйләшә бит, күпне күргән ир уртасы диярсең. Матура укучы балага сөйләгәндәй аңлата:

— Ир кеше хатын-кызга рөхсәтсез кагыла алмый. Култыкларга теләсә дә, рөхсәт белән генә. Хатының булгач, аңа ышан, ул синең ышанычыңны аклар.

— Юк, мин хатынымның йөзен чит кешеләргә күрсәтмәм, — диде Мәхмүт, әле генә укылган лекцияне нәтиҗәсезгә чыгарып.

Матура елмаеп утыручы Суфияга карап башын чайкый: һай, авыр булыр мондый егетләр белән социализм төзүе. Әнә бит ни сөйли бу хәсрәте:

— Хатын күп бала китерергә тиеш. Югыйсә, аның башы шухыр-мухыр белән тула.

— Күп баланы карарга акча күп кирәк булачак бит.

— Ирнең эше — акча табу. Тапкан акча бетеп бармаса, шайтан булып котырта башлый.

— Балалар колы булып гомереңне уздырасың инде, алайса?

Балалыктан иртә чыккан гарәп егетен тыңлап, Матура таң калып утыра.

— Без барыбыз да коллар. Минем менә хуҗа өстенә хуҗа. Ике катлы хуҗа. Аннары ата-анама хезмәт итәм, апама, сеңелләремә. Ә син беркемгә дә хезмәт итмисеңме? Ирекле?

Бу сорау менә-менә бирелергә тиеш иде. «Ирекле» сүзен әнә ничек аңлый кибетче. Ни рәвешчәрәк төшендерергә?

— Ата-анага мин дә хезмәт итәм. Кеше өчен бу аз. Мин халыкка хезмәт итәм. Ләкин кол булып түгел, дус булып, туган булып. Безнең ил халкы барысы да бер-берсенә хезмәт итә, коммунизмга. Коммунизм турында ишеткәнең бармы?

— Ленин?

Матура егетнең бераз хәбәрдар икәнен аңлап, сөенеп куйды. Сумкасыннан Ленин рәсемле значоклар эзли башлады, таба алмады. Таратып бетергән. Суфияда ике значок калган икән, кунакларның түшенә кадады. Матура аңлатуын дәвам итте:

— Коммунизмда бөтен кеше белемле, аңлы булырга тиеш. Талау, алдау булмый, мохтаҗлык булмый. Һәркем җәмгыятькә сәләтенчә хезмәт итә.

— Мохтаҗ булмагач, кем аны хезмәт итәргә мәҗбүрли?

— Ата-анаңа, сеңелләреңә хезмәт итәргә сине кем мәҗбүрли соң?

Мәхмүт аңлаганлыгын белдереп көлеп куйды.

Матура егетнең фотоаппаратка күзе төшкәнлеген сизеп, бүләк итмәкче дә булган иде, кире уйлады: кибетче аны барыбер сатачак.

«Мадам Матура» бүлмәгә кереп, төрле дарулар тутырылган кап алып чыкты. Гарәбстанда дару кыйммәт, сәфәрдә төрле хәл була дип, Камил биреп җибәргән иде. Мәхмүт әтисен сәламәт түгел, диде бит.

Бүләккә фотоаппарат алса да, Мәхмүт болай сөенмәс иде. Латин хәрефе белән язылган кулланмаларын укып, һәр кап даруга алтын бәясе куйды. Кәбиргә Суфия гарәп-рус сүзлеге бүләк итте.

Иртә белән ханымнарны холлда сюрприз көтә иде: Матурага Хоттабычныкы кебек очлы борыны өскә күтәрелгән читүле чүәк. Суфияга сырлы, бизәкле агач шкатулка. Капкачын ачсаң, скрипкада уйнаган кебек гаҗәеп моңлы көй сызыла. Кызыл бәрхет эчле шкатулкада куен дәфтәреннән ертып алынган кәгазь, кәгазьдә русча язу: «Хәерле сәфәр теләп, Мәхмүт белән Кәбирдән бүләк».

Нинди изгелекләре өчен бу бүләкләр? Университет тәмамлаган укымышлы «дамалар»ның гади егетләрне үз күреп, ихлас сөйләшүләре өчен рәхмәт белдерүме? Терешкова, Гагарин иленнән килгән кунакларга аерым хөрмәт билгесеме? Сувенир сайлаганда кибетчене тинтерәтүен исенә төшереп, Матура уңайсызланып китте. Гарәпләр кунакчыл, әдәпле халык. Урамда исерек кеше күрмәссең, гади халык арасында чит кеше әйберенә тию гадәте юк. Дин басымчагыннан, пәрәнҗәдән арыну исә Терешкова заманында тормышка ашмас нәрсә түгел, колониализмнан арынган халык анысын булдырыр.

*Ахыры бар.*

Локман Бадыйкшан

# ЕРАК ДИҢГЕЗДӘ

*Диңгезче язмалары*



1941 ел. Владивосток.

Командирларның ерак атаулардан эвакуацияләнүче семьяларын каршы алырга киттек. Аларны «Гоголь» пароходы китергән иде. Сахалин, Николаевск, Куриль якларыннан кайтучыларны дәүләт вәкилләре Себернең ерак шәһәрләренә озата киттеләр. Күрәсең, Япония белән иртәме-соңмы бәрелеш көтелә. Японнар инде күптәннән безнең чикләребезгә хәрби көчләрен туплыйлар. Алар Хасан, Халхин-гол сабакларын онытканнар.

Корабыбыз докта ремонтта булганлыктан, ул-бу була калса дип, безне коры җирдә сугышырга да өйрәтә башладылар. Тактика занятиеләренә йөрибез. Ә көнбатышта безнең кебек егетләр немец фашистлары белән сугыша.

*
* *

Сикәлтәле юлдан хәтсез баргач, Уссури тайгасына килеп кердек. Тау елгасы янында туктадык. Безнең полигон шушында икән. Винтовкалардан ату күнегүләре үтә башладык.

Буш арада без якын-тирәдәге куаклыклардан кура җиләге, кызыл карлыган җыеп ашадык. Аннан соң парашюттан төшкән «десант»ны каршылау башланды. Пластунча үрмәләп барып, «күктән төшкән дошман»ны камап алдык. «Ура» кычкырып, аңа ташландык. Өйрәнүләребезгә яхшы бәя бирделәр.

Төшке аш вакытында Казан егете, дустым Миргали Монасыйпов белән кәрзин үреп, елгада балык тоттык. Сай гына суда ярыйсы гына зур балыклар йөзә. Тик аларны тотучылар гына юк. Уссури крае миңа бик ошый, суы тәмле, табигате матур. Туган авылым Әлмәткә, ямьле Зәй буена кайткандай булдым.

*
* *

Радиодан татар концерты тыңладым. Мәрьям Рахманкулова, Халидә Зәбирова, Разия Тимерханова, Гөлсем Сөләйманова һәм Асия Измайловалар җырлады. «Кара урман», «Галиябану», «Зиләйлүк», «Сагыну» көйләре безне дулкынландырды.

Канатланып яшәр чакта, кешеләрне сугыш, шушы рәхимсез сугыш туган җирләреннән аерды.

*
* *

Кичкә таба яңгыр сибәләп китте. Минем тормышымда бернинди дә үзгәреш юк әле. Төштән соң докка бардык. Ремонтны тәмамлап килләр. Кораб палубасында Миргали белән очраштык.

Инструментальныйда Фәһимәне күрдем. Аның күзләрендә сөйкемле караш сизелә. Кем белә, бәлки ялгыша да торганмындыр. Кызның күңеле күтәренке. Бүгенге көнгә кадәр аның егете бармы, юкмы икәнен дә әйткәне юк. Иптәшләр күрмәгән арада гына аның янынннан үтеп китмәкче идем дә, Миргали сизде.

*
* *

Төшкә кадәр киемнәребезнең пөхтәлеген тикшерделәр. Аннары мин сәгать бишләргә кадәр ял иттем. Тревогалар еш булганлыктан, болай рәхәтләнеп йоклау безгә бик аз эләгә. Сугышчан һәм политик белемне отличнога үзләштерүчеләрне бүген паркка культпоход белән алып баралар. Анда «Пограничниклар» исемле спектакль күрсәтәчәкләр. Бөтен уй, фикер театр караудa түгел, «кара күз»не күрергә өметләнүдә. Нарядка баручылар аша инструментальныйга записка җибәрдем инде. Бакчада кызны очратсам иде.

Сәгать алтылар тирәсендә строй белән паркка юнәлдек. «Альбатрос» җыры бик матур яңгырый. Җырлаган саен күкрәк киңәя, күңел күтәрелә бара. Паркка да килеп җиттек. Безгә таралырга команда булды. Прожектор белән яктыртылган түгәрәкне үткәндә Фәһимәне күрдем. Аның янына ашыктым. Ни күрим, кыз янына бер матрос килеп баскан. Күрәсең, кызның танышы булырга тиеш. Нишләргә? Матроска да комачауларга ярамый, сабыр итим. Тизрәк агачлар арасына шылдым. Егет кызны үзенә карата ала икән, анысы аның үз булдыклылыгы. Фәһимә бүген кара костюмнан. Күзләре шундый матур, ягымлы җылы карашы җанга рәхәт бирә. Менә «кара күз» мине күреп алды. Матросны калдырып, яныма килде. Мине көтеп торган икән. Без аның белән бик озак сөйләшеп йөрдек.

*
* *

Тагын бер якташым бар. Аның исеме Моталлап. Ул да безнең яктан, Әлмәт районының Бишмунча авылыннан. Ул бүген минем янымда булып китте. Күзләремә туп-туры карап:

— Беләсеңме, Локман? — диде.

— Бер нәрсә дә белмим.

— Син оныт Фәһимәне...

— Ни өчен?

— Соңыннан үзең аңларсың.

Якташымның болай сөйләшүе бик сәер тоелды. Башта аптырап калдым. Күрәсең, ул Фәһимә белән миннән алданрак танышып өлгергән.

*
* *

Кич кубрикта дневальный булып тордым. Нарядка китүчеләр таралгач, өлкән лейтенант Афзал Низаметдинов килеп керде. Устав буенча аңа рапорт бирдем. Ул бүлмәне тикшерә башлады. Бер тумбочканы ачты, анда тәртипсез аунап яткан кәгазь кисәкләренә күрсәтеп:

— Бу чүп нишләп монда? — диде.

Мин җавап бирмәдем. Бер читтә сөялеп куелган винтовканы күреп алды:

— Хуҗасы кем? — дип сорады. Мин дәшмәдем.

— Нигә анда калдырырга рөхсәт бирдең?

— Хуҗасы хәзер килеп җитәчәк, — дидем.

Дежурный өлкән лейтенант Низаметдинов мине шелтәләде. Аның алдында шәм кебек басып тордым.

— Старшинаң кайда?

Ул арада булмады, кубрикка старшина да килеп керде.

— Чиратсыз ике наряд языгыз дневальныйга, — дип боерып, өлкән лейтенант чыгып китте.

Бүлмәгә винтовка хуҗасы Моталлап кайтты. Мин аңа: «Синең өчен шелтә алдым», — дидем. Мине шелтәләтер өчен әллә юри эшләгән инде. Югыйсә, посттан кайту белән, винтовкасын чистартып, тапшырырга тиеш иде ул.

*
* *

Көнбатышта сугыш көннән-көн кискенләшә. Фашистлар, зур югалтуларга дучар булуга карамастан, һаман алга омтылалар. Ленинградны дошман чолгап алган. Анда зур сугышлар бара. Казакъ акыны Җамбулның «Ленинградлылар, балаларым минем» дигән җырын радиодан бирделәр.

Кичә чик буендагы Краскино поселогы тирәсендә егермедән артык япон солдаты чигебезне бозды. Бәрелеш нәтиҗәсендә ике яктан да яралanучылар булды. Шайтан тавында булып узган бу хәлне «Боевая вахта» газетасында да язып чыктылар. Ә Америка газеталары зур бәрелеш булган дип күрсәтергә тырышканнар.

*
* *

Көчле тайфун башланды. Җилнең тизлеге секундына 26 метрга җитә. Таң белән торып, походка әзерләндек. Диңгез шауласа да, яр буенда чатлама суык иде. Сәгать сигездә походка чыктык. Башта командирыбыз Алексей Васильевич Волков сөйләде:

— Бу сезнең өчен чыныгу булыр. Сугышта мондый походлар еш булачак. Диңгезчеләр дошманга өермәдәй ташланырга тиеш.

Ул Балтика диңгезчеләренең немецларны ничек кыйнаулары турында мисаллар китерде.

Аннары старт бирелде. Чаңгылар белән диңгез култыгының көнчыгыш ягына таба киттек. Суык. Урап кайтканда музыка белән каршыладылар. Музыка тавышы тәнгә рәхәтлек, йөрәккә дәрт бирде. Безнең взводтан өч кенә кеше артта калды. Дүрт сәгать егерме минут эчендә илле километр араны үткәнбез.

*
* *

Занятиедән кайткач, мине старшина чакырып алды:

— Сиңа сугышчан бурыч тапшырыла.

— Үтәргә әзер! — дидем мин.

Үзебез яшәгән казармалардан шактый еракларак диңгез буенда секрет посты бар. Шунда нарядка киткән бер диңгезче иптәшебез каты авырган. Дустым Миргали белән шул диңгезчене носилкага салып алып кайтырга тиешбез.

Караңгы төшеп килгәндә, юлга чыктык. Буран. Карга бата-бата атлыйбыз. Диңгез шаулаганы аермачык ишетелә башлады. Юлсыз җирдән бару бик тә авыр. Үргә күтәрелеп түбән төшкәндә, чәнечкеле тимер чыбык корылмаларына килеп төртелдек. Күп уйлап тормадык, кулыбыздагы носилканы чыбык өстенә салып чыктык. Дулкыннарның яр ташларына бәрелеп шаулаганы безнең күңелләрне күтәрә. Ни әйтсәң дә яр буенда яктырак. Көмеш су тамчыларының сибелүе безгә аермачык күренә. Көч-хәл белән «Яшен» постына килеп җиттек. Авыруны алып кайтырга туры килмәде. Хәле яхшырган. Бераз җылынгач, каравыл начальнигы безгә кайтырга рөхсәт итте.

*
* *

Тормышымда артык куанырлык вакыйгалар булмаса да, һәр көн күңел дәртле уйлар белән тулы тора. Дусларым да янымда. Бергәләп сугыш белемен өйрәнәбез. Кораб ремонтланып бетеп килә. Хәзер безне эшчеләргә булышырга бик сирәк алып бара башладылар. Шулай да кичен, докка баргач, инструментальныйда булдым, Фәһимәне күрдем. Ул һаман шат, көләч, мине күрүгә сөйкемле генә карап алды да:

— Хәтсез вакыт күренмәдең, — диде.

Мин инде хәзер, беренче танышкандагы кебек, кыюсыз түгел. Сүзләремне уйлап, үземә кирәк җавапны алырлык итеп сөйләшәм.

Кич белән «Бөек Британия» дигән киножурнал күрсәттеләр. Дөньяның зур су дәүләте Англия — ул безнең союздашыбыз.

Мин инглизчәдән тәрҗемә ителгән китаплар белән шактый ук таныш. Әле күптән түгел генә хәрби диңгез журналындагы гади матрос — Дэррикның язмаларын укыдым. Ул ун елга якын король флотында хезмәт итә. Бөтен яшьлеген флотта үткәрә. Шулай да соңыннан үзенең офицеры аны «хезмәткә яраксыз» дип, политик яктан гаепләп, флоттан куыра.

*
* *

Кинәт шәһәр караңгылыкка чумды. Озак та үтмәде, радио безнең союздашларыбызга Япониянең һөҗүм башлавын хәбәр итте. Сингапур, Гонконг, Пирл-Харбор кебек Ерак Көнчыгыштагы диңгез базаларына япон самолетлары һөҗүм иткән. Күп кенә сугыш кораблары батырылган.

Ерак Көнчыгышта да сугыш давылы кабынып киткәч, безнең уяулыгыбыз икеләтә арттырылды. Частьларда, корабларда митинглар булды. Шәһәргә чыгып йөрүләр туктатылды. Флот сугышчан хәзерлеккә күчте.

Иптәшләрем дә җитдиләнделәр. Диңгездә, сирәк кенә булса да, безнең сәүдә корабларын билгесез су асты көймәләре батыра башлады. Бу бары тик япон самурайларының эше. «Билгесез» сүзе нигәдер миңа бик сәер тоела. Күңелем ышанмый моңа. Без бу сүзне «самурай» сүзе белән алыштырабыз.

31 декабрьда флот экипажы яңа елны каршыларга хәзерләнде. Командаларның үзешчән сәнгать түгәрәге көче белән концерт та бире-

ләчәк. Клубка ашыктык. Концерт башланды. Матрослар биюләр, декламацияләр тагын бик күп төрле номерлар башкардылар. Концерт беткәч, дежур офицер: кем танцыга калырга тели — зур залга, теләүчеләр — киногә, диде. Мин танцыга һәвәс кеше түгел, киногә киттем. Озакламады, экранда геройлар күренә башладылар. Сәгать уникедә залда ут сүнде. Радиодан «Интернационал» агыла. Бастык. Ирексездән флотка китәсе елда каршылаган яңа ел искә төште. Әгъзәм Камал дигән яшь шагыйрь дустым бар иде. Ул безне яңа ел кичәсенә чакырды. Минем белән янәшә шагыйрь Шәрәф Мөдәррис утырды.

Менә хәзер шагыйрь дустымның:

> Моңсу булма, туган, көрәшербез,
> Вакыт житми жиргә аумасак,
> Җәйге гөлләр белән күмелербез,
> Язгы ташкын белән акмасак, —

дигән куплеты искә төште.

Ә бүген якташым Солтан Ибраһимов белән янәшә утырабыз.

— Киләсе яңа елны без кайда каршыларбыз икән? — ди ул.

— «Вакыт житми жиргә аумасак», каршыларбыз, — дим мин.

*
* *

Ниһаять, без корабка күчтек. Тормыш элеккедән күңеллерәк кайный башлады. Яңа кешеләр килде. Миңа яшь кызыл флотчыларның бер төркеменә туп механизмнарын өйрәтүне тапшырдылар. Шунда бер егет: бу кораб турында авылга кайтып сөйләсәм, миңа ышанмаслар да. Суда йөзүче бер завод икән ләбаса, диде.

*
* *

Март ае жылы башланды. Кояшка карау белән күзеңне кысасың, гәүдә җиңел, атлавы рәхәт. Бүген, дүрт сәгатьлек вахтадан соң, салкын су белән юынып, кубрикка кайттым да, әйбәтләп ял итәргә булдым. Яңадан төнге вахтага басасым бар. Татлы уйларга бирелеп, йоклар-йокламас ятам.

— Син йокламыйсыңмы? — ди бер тавыш. Башымны күтәрсәм, янымда Миргали басып тора. Эче пошып килгән икән. Аның белән тормыш турында, сугыш хәлләрен еш кына сөйләшә идек. Менә хәзер дә шуңа өметләнеп килгән ул. Аның теләге — бу хәтәр елларның герое булып калу. Мин инде моны күптән беләм.

— Безне дә сугышка җибәрәчәкләр икән, — диде ул.

— Каян белдең?

— Матрослар сөйли.

— Әй, дустым, имеш-мимешләргә син ышанма. Менә стройга тезерләр, приказ укырлар, шунда гына теләгеңнең тормышка ашырылуына ышанырга була.

*
* *

Рейдта торабыз. Безнең кораб белән янәшә берничә миноносец килеп туктады. Озакламый киң култыкта көймәләр ярышы башланачак. Мин ярышта ишкәкче булып катнашам. Моның өчен без күп кенә күнегүләр үттек. Иң яхшы ишкәкчеләрне генә ярышка билгеләгәннәр иде.

Яр әллә ни ерак түгел. Зәңгәр офыкка сузылган кыялар беленербеленмәс кенә булып күренә. Сигнал булуга без — ишкәкчеләр — югары палубаның алгы өлешенә тезелдек. Суга карасам, безнең кораб ти-

рәсенә утыздан артык көймә җыелып та өлгергән. Алар стартка тезеләләр. Бер миль (1852 м) ишкәкләр белән, аннан өч миль җилкән күтәреп үтәргә тиеш идек. Көймәгә тиз генә төшеп утырдык та сигнал булуга кузгалып та киттек. Әйләнәбездә дистәләрчә көймәләр алга ыргыла. Бирелеп, көчебезне кызганмыйча ишәбез. Боцманыбыз — тәҗрибәле диңгезче. Мондый гына ярышларны күп күргән. Шулай да ул бүген нигәдер борчыла сыман. Йөзендә бер генә дә елмаю әсәре юк. Вакыт-вакыт команда биреп куя. Тырышабыз. Бөтен тән манма су булды. Сынатмадык. Кораб командиры Алексей Васильевич та безнең көймәдән канәгать калды. Ул ярышны югары палубада бинокльдән күзәтеп торган икән.

Моталлаплар көймәсе иң соңгылардан берсе булып килде. Аларны «Чижик-пыжик, син кайда булдың?» көен уйнап каршыладылар. Үзе белән очрашкач:

— Сезнең көймәнең җитәкчесе тәҗрибәле карт диңгез бүресе шул, шуңа күрә дә алга чыктыгыз,— диде Моталлап.

*
* *

«Кызыл Татарстан» газетасы сотрудницы Мәрьям Дибаева апа шагыйрь Шәрәф Мөдәррнснең фронттагы адресын соратып алдырдым. Озакламады, Тын океанга 2 нче Белоруссия фронтыннан бер төргәк (ун данә) «Фронт хакыйкате» газетасы белән хат килеп төште. Әйе, бу Тын океан флоты корабына татар телендә килгән беренче газеталар иде. Шагыйрь дустым җибәргән газеталарны II ранг капитаны Почуйпайлога күрсәттем.

— Бик әйбәт булган, бу газеталарны политзанятие вакытында якташларыгызга укырсыз. Үзегез укыганнан соң, газеталарны башка кораблардагы татар яшьләренә дә җибәрергә кирәк булыр, — диде ул.

Икенче көнне корабта политзанятие сәгатендә Солтан Ибраһимов, артиллеристлардан Миргали Монасыйпов, зенитчылардан башкорт егете Хөрмәт Гыйльфанов, Җиһангир Мостафин, Салих Шакиров, кораб электрикларыннан ике бертуган Казан егетләре Сабир һәм Галимҗан Мөхәмматҗановлар, Нәшһәт Киреевләр белән бергә фронт газеталарын укыдык. Шул көннән башлап, Шәрәф Мөдәррис фронт газеталарын флотка гел җибәреп торды.

*
* *

Кораб күптән ачык диңгездә. Вахтага басар алдыннан палубага чыгып, диңгезгә карап тордым. Безне берничә эскадра миноносецы озатып бара. Мин аларның дулкыннарны ярып үтүләрен күрәм. Безнең корабка дулкын алай ук тәэсир итми. Бу тирәләрдән тайфун инде үткән, шулай да диңгез әле һаман тынычланып бетә алмый.

Еракта диңгез өстенә кара төтен тасмасы сузылган. Без аңа якынайган саен ул зурая бара. Бераздан аларның сугыш кораблары икәне беленде. Яңа гына вахтадан бушаган зенитчылар старшинасы урта буйлы, яшь имәндәй нык гәүдәле башкорт егете Хөрмәт Гыйльфанов янына килеп:

— Япон эскадрасы, Хоккайдога бара, нейтраль суда. Безнең маневрларны күзәтергә чыкканнар, — диде.

— Бәрелешү булырга мөмкинме?

— Самурайның холкын белмәссең...

Шторм көчәйде, күңел болгана башлады, баш авырайды. Югыйсә, җиде-сигез баллы штормнарга гына бирешә торган кеше түгел идем. Янымнан үтеп киткән матросларның да йөзләре агарган. Күрәм, алар да диңгез авыруы белән җәфалана...

Бу поход өч көннән артык дәвам итте. Татар бугазын үтеп, Камчаткага якынаюыбызны офицерлардан гына белдем. Диңгез бу тирәдә кара-кучкыл булып тора. Материк ярлары, дөя сырты сыман булып, төньякка таба сузылган. Ярдан әллә ни ерак булмаганлыктан, мин барысын да аермачык күрәм. Менә нинди икән ул Охот диңгезе ярлары.

Тревога. Сигнал тавышын ишетеп, диңгезчеләр шундук сугышчан урыннарына килеп бастылар. Пулеметлар, туплар, торпедалар тизлек белән хәрәкәткә килде. Диңгездә дулкыннар шаулашып тәгәри. Җил дулкын тауларын ак күбеккә әйләндереп корабка сибә.

Озак та үтмәде, еракта зур гына бер шхуна күренде.

Сугышчан рубкадан:

— Тикшерү партиясе матросларына әзерләнергә! — дигән боерык алынды.

Мин дә тикшерү партиясенең члены.

Ашкынып көтә башладык. Шхуна белән безнең корабның арасы барган саен кыскарды.

— Нәрсә дип безнең суларга керде икән ул?

— Төрлечә булгалый... Шторм курстан да яздыра. Усал нийт белән дә су чикләрен бозалар, — диде старшина.

— Тукталырга!

Бу сигналга суднода игътибар итмәделәр. Ул үз юлы белән йөзүен дәвам итте. Шхуна ничек кенә тиз бармасын, без аны янадан куып җиттек.

— Тукталырга!

Шхунадан монысына да җавап булмады.

— Кыланалар, ачуым килмәгәе...

— Нептун патшалыгына китәселәре килгәндер...

Сигналга буйсынмагач, кисәтеп дежур туптан аттык. Шхуна янында су өстендә ак томан барлыкка килде. Шартлау яңгырады.

— Әрсез мал шушы була икән инде, — дип көлештек.

Шхуна, кача алмагач, маневр ясарга керешге. Кечкенәлегеннән файдаланып, бөтен тизлегенә нейтраль суга омтылды ул.

Без, якын ук килеп, аның белән янәшә бара башладык. Бортына терәлдек тә шхуна палубасына төштек.

Башларына киң эшләпә, өсләренә су үткәрми торган җиңел киемнәр кигән кешеләр, бер-берсенә сыенып, палубада хәрәкәтсез торалар иде.

Тикшерүләр вакытында шхуна капитаны:

— Без — япон балыкчылары, көчле су агымына эләгеп, курстан яздык. Гафу итегез, — диде.

Япон шхунасының тикшермәгән җирен калдырмадык. Штурман рубкасында СССРның Хәрби Диңгез базалары билгеләнгән топографик карталар, шушы тирәдә Ватаныбызның иминлеген саклап йөзүче сугыш корабларыбыз төшерелгән фотопленкалар таптык. Тикшерү партиясе җитәкчесе өлкән лейтенант Афзал Низаметдинов бу дәлилләрнең барысын да күрсәтеп акт язды. Аннары, кораб командиры Алексей Васильевич боерыгы буенча, шхунаны якындагы бер портыбызга борылырга мәҗбүр иттек.

*
* *

Ерактан килеп туктаган сәүдә корабын бушатырга крейсердан кешеләр билгеләнде. Алар арасында мин дә бар. Без Америкадан яңа гына кайткан йөк корабына бардык. Палубага аяк басуыма, уйламаган җирдән, әле моннан алты гына ай элек безнең корабтан киткән Куйбышев өлкәсе егете дустым Салих Шакиров очрады. Без кочаклашып

күрештек. Ул озынча буйлы, аксыл йөзле матур кеше. Япон диңгезендә хезмәтне бергә башлап җибәргән идек. Салих эш беткәч, безнең старшинадан рөхсәт алып, мине каютасына алып керде. Кунак итте. Шунда өстәл янында ашыкмыйча гына башыннан үткәннәрен сөйләп алды.

— Корабыбыз Архангельск портыннан ике сугыш корабы сагы астында Америкага юл тоткан иде. Баренц диңгезен үтүгә, безне инглиз кораблары каршы алды. Зур бер кәрван булып, Атлантика океанына чыктык. Көтелмәгән җирдән фашист самолетлары һөҗүм итте. Озатучы сугыш кораблары һава пиратларына ут ачсалар да, кайбер судноларга бомбалар эләкте. Анда-санда ут көлтәләре күтәрелде, безнекенә дә бомба эләкте. Машинабыз сафтан чыкты. Палубадагы зенит пушкасы кубарылып диңгезгә ауды. Үлүчеләр, яраланучылар булды. Ут астында пробоинаны рәтләдек. Самолетларны куып җибәргәч, үзебезне буксирга алдылар. Көч-хәл белән генә Нью-Йорк портына барып җиттек. Анда докка ремонтка керттеләр.

— Ничек кайттыгыз? — дип сорадым мин аңардан.

— Өч ай дигәндә Панама каналы аша Сан-Францискога килдек. Анда йөкләр кабул итеп, туган ил ягына юл тоттык.

Салихның башыннан күп нәрсәләр үткән, ул барысын да кичергән. Мин аны элек яхшы белгәнгә, сораулар биреп аптыратып бетердем. Үзе белән элемтәне югалтмаска булып аерылыштык. Менә бит ул дөнья. Берәүләр ерак илләр гизә, ә мин сугыш корабында сугыш күрмичә гомер үткәрәм. Тикмәгә генә: «Өлешеңә төшкән көмешең», — дип әйтмиләр. Диңгез тормышы катгый, анда кешеләр зур чыныгу үтә. Хәрби тормыш авыр булса да, аның үзенә күрә матур яклары да бар. Хезмәткә эләкмәгән булсам, Япон диңгезен кайчан гизгән булыр идем әле мин.

Иртән диңгез култыгына сөт сыман аксыл томан җәелгән иде. Кояш, табигатьне ямьләндереп, томанны бик тиз тарата башлады. Җыештыру эшләренә катнашырга югары палубага чыктым. Эшләрне бетергәч, барыбыз да, механизмнарны тикшереп карарга дип, сугышчан урыннарыбызга бастык. Кичә, диңгезгә чыгып, эре калибрлы туплардан ату күнегүләре үткәргән идек. Хәзер тупларны чистартабыз. Мине, Миргалине, Хөрмәтне ярга такта алырга чыгардылар. Безнең кораб яр буеннан, читтән аеруча мәһабәт булып күренә. Диңгез култыгының уртасына кадәр сузылган. Ачык диңгезгә чыгып китәргә әзер булып тора...

*

* *

Корабны кояшның алтын нурлары яктырта. Тирәбездә берничә эскадра миноносецлары да бар. Каршыбызда яшел бәрхеткә төренгән сыман булып, Рус атавы күренә. Кояш баерга хәтсез вакыт бар әле. Берничә ишкәкче матрос белән мине шлюпкага төшерделәр. Корабның поход вакытында дулкыннар ашаган ала-кола җирләрен буярга кирәк.

Кич белән миңа ют палубасында постта торырга туры килде. Өлкән диңгезчеләрнең әйтүләренә караганда, моннан кырык еллар элек бу култыкта «Рюрик», «Искольд» һәм «Алмаз» кебек зур кораблар якорьда торган.

*

* *

Яңгыр болытлары йөзә. Без иртәдән алып кичкә кадәр янибызга килеп туктаган тимер баржадан снаряд бушаттык.

Мин палубаны юа торган швабраны бик искергән дип диңгезгә ыргыткан идем. Боцман моның өчен чираттан тыш өч наряд бирдерде.

Шәһәр борын төбендә генә булса да, теләгән вакытта чыгып булмый. Культпоходлар туктатылды. Палубада яңа кешеләр күренгәли башлады. Мондый хәл сугышчан хәзерлек кертелгән вакытта гына була торган иде. Япон диңгезендә дә сугыш давылы кубарга тора, ахрысы.

*
* *

Әниемнән бик яшьли калганмын. Аның йомшак чәч толымнары әле хәзер дә йөземә кагыла сыман. Аның «Бәхетле булып үс, улым» дигән сүзләре бүген дә колак төбемдә яңгырый әле. Әйе, бәхетле яшәү өчен тынычлык кирәк. Җирдә сугышлар булмасын. Ә хәзер нинди еллар! Кешеләр язмышы гына түгел, илләр язмышы хәл кылына.

Габделбарый абыем күптән инде фронтта. Сталинград фронтында. Ул хатларында туганнарын бик сагынуын яза, сугыш беткәч барыбыз да бергә җыелып, күгәрченнәрдәй гөрләшеп яшәрбез дип хыяллана. Нык ихтыярлы, коммунист кеше ул.

*
* *

Кичке эшләр беткәч, дустым Миргали янына килдем. Ул альбомын ачкан да ерак Татарстандагы сөйгән кызы Мөршидәсенең рәсеменә карап утыра. Мине күргәч, үпкәләгән сыман:

— Рәсемеңне нигә бирмисең инде, күрмисеңмени альбомымның бер бите буш тора. Бирмәсәң, альбомыма керми калырсың, — диде.

Аның бу сүзләре миңа сәер булып тоелды.

Кичен корабта чын мәгънәсендә бәйрәм булды. Безгә бөтен илгә данлыклы артистка Тамара ханым килде. Күкрәгендә депутат значогы. Хөрмәт йөзеннән корабыбызда депутат флагы күтәреп, каршы алдык. Вахтадан бушагач, барыбыз да концертка бардык. Тамара ханым СССР халыклары телләрендә: русча, үзбәкчә, әзербайҗанча, әрмәнчә, казакъча, татарча җырлады. Кул чабулардан кораб клубы гөрләп торды. Тамара ханымның сугыш шартларында хәрби диңгез корабына килүе күңелләребездә онытылмаслык матур хатирә булып калды.

*
* *

Боцман Семиликов безнең артиллеристлар бүлекчәсенә корабның чылбыры белән запас якорен чистартуны йөкләде. Мавыгып кына эшләгәндә, рассыльный:

— Комендорлар, тизрәк булыгыз, кубрикка җыелыгыз, — диде.

— Тикмәгә генә эш бүлдереп чакырмаслар, нәрсә булса да бардыр,— диде Миргали, мине ашыктырып. Без кубрикка килеп кергәндә, анда басар урын да калмаган иде. Түрдә озынча өстәл янына баскан артиллеристлар командиры безгә мөрәҗәгать итте:

— Эшегездән аерып сезне монда җыю миңа да күңелле түгел. Шулай да мин моны кирәкле таптым. Ярты гына сәгать элек безнең башняда хезмәт итүче Моталлап... приказ үтәүдән баш тарткан. Аны зенитчылар белән эшкә җибәргән идек. Ул бармаган. «Мин үзебезнең зур калибр башнясы кешеләре белән генә барам», — дигән.

Командир Николай Герман янында Моталлап басып тора. Мин командирның сүзләрен тыңлаганда якташым Моталлап өчен кызарынып тордым. Аның күзләрен, хәрәкәтен күзәттем. Ул бер агара, бер кызара, күзләрен түшәмдәге электр лампасы калфакларына текәп, тынын да алмый тора иде.

Моталлапның йөрәге тупасланганын, иптәшләренә һич тә ачылып бетмәвен, үз җаена гына карап яшәргә тырышуын мин моңарчы аңлап җиткерми идем әле. Менә хәзер болар бары да ачылды. Аның бу хәлгә төшүенә кызганып та, нәфрәтләнеп тә карыйм. Информациядә Моталлапны комсомол җыелышында тикшерергә һәм иптәшләр судына бирергә кирәклеге әйтелде. Мин аның нинди приказ үтәүдән баш тартуын соңыннан гына белдем. Аңа кыргыч белән палубаны кырырга кушылган булган. Ул шуны үтәмәгән. Аның бу эше өчен нинди җәза бирелер, хәзергә әйтүе кыен. Бик зур ахмаклык, уйламыйча эшләнгән тәкәбберлек дип карадым мин моны. Дустым Миргали да моның белән килеште.

— Әтисе булсам, каеш белән ярыр идем мин аны,— диде ул.

*
* *

Дөньям караңгыланды. Мөнирә апа соңгы хатында бертуган абыемның Сталинград фронтында һәлак булуын хәбәр иткән. Хаттагы кыска гына юлларны укыгач, нишләргә дә белмәдем. Тын океан флотына китәсе көзне абыем белән үрдәккә барган идек. Хыялга бирелеп торганда, яныма дустым Миргали килеп җитте. Аңа кайгымны әйттем. Ул миңа: «Чыдам бул», — диде.

*
* *

Көз килеп җитте. Әле күптән түгел генә яшеллеккә төренгән табигать алтын төсенә манчылды. Кочак-кочак яфрак коела. Әйтерсең лә дөньяның матурлыгы коелган яфраклар сыман кими.

*
* *

Яңалык. Әйе, зур яңалык. Корабка бүгенге почта берничә номер «Тревога» газетасын алып кайтты. Ерак Көнчыгыш политидарәсе Хабаровск шәһәрендә татар телендә газета чыгара башлаган. Газетаның редакторы журналист Бари Корбанов. Әле моңарчы ана телендә Көнбатыш фронтларындагы газеталарны гына укый идек. Үзебезнең газетабыз булуга барыбыз да сөендек. Аның битләрендә авиациядә, диңгез флотларында хезмәт итүче якташларыбызның парчалары, репортажлары, мәкаләләре урын алган.

Мөнир Мазунов, Әдип Маликов, Хәниф Кәрим, М. Сабельев шигырьләре номер саен дип әйтерлек басылганнар. Атна үтмәде, редакциягә үзебезнең корабта хезмәт итүче татар яшьләренең хәрби белемне ничек үзләштерүләре турында очерк язып җибәрдем.

*
* *

Диңгез өстенә аксыл куе томан җәелгән. Кораб, вак шадра дулкыннарны борыны белән ярып, билгеләнгән якка юл тота.

Диңгезчеләр һәрберсе үз эше белән мәшгуль. Механизмнар янында тулы сугышчан хәзерлектә торабыз.

Эре калибрлы туп башнясында без утыздан артык кеше. Мин югарыга снарядлар биреп торам. Янымда берничә булышчы да бар. Алар команда гына көтеп торалар.

— Каушамаска! — дип куям мин аларга. Снарядларны бәрдермисуктырмый гына божра ялгашына урнаштырып, югары озату — безнең төп эшебез. Моның өчен күпме генә көнегүләр, өйрәнүләр үтмәдек.

*

* *

Сугышчан походта без. Туган ил ярлары еракта калды. Крейсерны эсминецлар озата. Диңгез давыллап тора, чал дулкыннар палубага ыргылалар да аннан, көчләре бетеп, кире чигенәләр.

Төшке ашны да постларыбызда ашарга туры килә.

Диңгездә кем беренче булып ут ача — шул җиңүче. Сугышны минутлар түгел, секундлар хәл итә. Моны барыбыз да бик яхшы аңлыйбыз.

— Беләсеңме, Локман, — ди башня электригы Нәшһәт Киреев. — Әле генә мин югары палубада булдым. Эскадраны диңгез авиациясе саклап бара икән. Бик күп самолетлар күрдем...

— Бу минем өчен зур яңалык.

— Кая таба юл тотабыз икән?

— Куриль атаулары ягына булса кирәк.

Шул вакыт югарыдан команда бирелде. Башня механизмнары дәррәү хәрәкәткә килде. Мин житәкчелек иткән божра яшен тизлеге белән бер әйләнеп алды. Берничә снаряд укталй югарыга менеп тә китте. Минут үтмәгәндер, саңгырау гына шартлау тавышы башняны калтыратып алды. Егетләр стеллажлардан снарядларны яңадан әйләндерү божрасы ялгашына тәгәрәттеләр.

Берничә залптан соң отбой командасы яңгырады. Шулай да сугышчан постларны ташламаска боерылды. Матрослар башня эчендә калдылар.

Башня наводчигы Геннадий Очелков, буш вакыт булды исә, мине үз янына чакырып ала да өйрәтергә керешә. Бу юлы да мин аның янына ашыктым.

Штурвалга кулымны куярга өлгермәдем, башня командиры өлкән лейтенант Николай Герман телефон трубкасын тоткан килеш:

— Бадыйкшанов, сине корабль командиры сугышчан рубкага чакыра, тиз бул, — диде.

Артиллеристлар игътибарларын миңа юнәлдерделәр. Ышанырга да, ышанмаска да белмәдем.

— Сиңа әйтәләр бит, — дип, яңадан фамилиямне кабатлагач кына броня ишеккә килдем. Аны кыенлык белән генә ачтым.

Салкынча дымлы җил йөземә бәрелде. Кораб әле бер якка, әле икенче якка авышкалап, күбекле дулкыннарны икегә яра. Аның ике ягында да эскадра миноносецлары чайкалалар. Күктә эскадрилья оча, самолетлар корабтан шактый ерак. Берсе артка калган безнең кораб өстеннән үтеп бара.

Мин палуба буенча сугышчан рубка ягына таба тарттырылган баугa тотына-тотына ашыгам. Шкафутны үткәндә зур гына дулкын борткa сикереп, үземне юып алып китә язды.

Палубада күзәтүче матрослар гына постта тора. Мин югарыга күтәрелә башладым. Башка уй килә: «Командир ник чакырды икән?»

Рубкада — хәрби диңгез штабыннан килгән югары чинлы офицерлар. Мин командир янына килеп:

— Сезнең чакыру буенча, өченче башня кызыл флотчысы...— дип рапорт бирдем.

— Күктә сезнең кемегез бар? — диде командир.
— Беркемем дә юк. Илаһи көчләргә ышанмыйм, — дидем кыю гына.
— Сезгә очучы Батталовтан радиограмма, ул кемегез була?
— Салих Батталовмы? Ул күренекле татар шагыйре, — дидем мин.
Элемтә офицеры кулыма радиограмманы тоттырды.
Бу шагыйрь белән моннан өч ай элек Владивостокта, Давыллар борыны урамында, Җамал апа йортында энесе Фоат Батталов белән бергә очрашкан идек. Ул минем кайда, ничек, кем булып хезмәт итүемне сораштырган иде. Аның дингез авиациясендә хезмәт итүе исемә төште. Мөлаем йөзле, коңгырт күзле, зур гәүдәле Салих абый күз алдыма килеп басты.
Командир миңа башняга кайтырга рөхсәт бирде.
Егетләрнең шагыйрьне күрәселәре бик килә иде. Алтын мөгез култыгына кайтып якорь салгач, командирдан шагыйрь Салих Батталны крейсерга кунакка чакырырга рөхсәт сорадым.
Ул теләгебезне үтәргә вәгъдә бирде...

*
* *

Ике көн үтүгә, кораб палубасына зур гәүдәле, киң җилкәле хәрби дингез очучысы Салих Баттал күтәрелде.
— Командирыгыз чакыруы буенча килдем, — диде ул.
Салих Баттал башта кораб белән танышып йөрде. Кичен дингезчеләр клубында аның белән очрашу үткәрелде.
Унике яшь тулар-тулмастан Тигәнәле авылы кырына ат сакларга йөрүләрен искә алды, авиациядә хезмәт итүе, иптәшләре турында сөйләде.
«Тын океан ярларында» исемле шигырьләрен яратып тыңладык. Ул сугышчан походларда безнең эскадраны озата баруларын да әйтте.

*
* *

Салих ага Баттал моны үзе хәтерлиме икән? — сорашканым юк. Аның авиациядә хезмәт итүе турында күренекле поляр очучысы Михаил Каминскийның «В небе Чукотки» исемле китабында язылган.
«...Татар Салих Батталовның характеры үзенә бер төрле. Эре гәүдәле, әлегә юанаерга өлгермәгән, шулай да тыгыз тәнле һәм яшь имән кебек нык, хәрәкәтләргә саран, киң, яссы йөзле бу кеше бик аз елмая, шуңа күрә ул үз эченә бикләнгән булып тоела һәм аның интеллектуальлеге бик үк сизелми иде. Әммә беренче тәэсир алдаучан булып чыкты. Озакламый мин Батталовны күп укыган һәм без яшәгән мөхиттә грамотасы ягыннан гомумән югары торуына ышандым. Кайберәүләр: ул хикәяләр һәм шигырьләр язгалый икән, дип сөйли иде, әмма үзенең мактанганы булмады. Шулай да аның әдәбиятка мөнәсәбәте барлыгы дуслары белән сөйләшкәндә сизелә иде. Кайберәүләр аны борын күтәрә дип саныйлар иде. Әмма ул алай түгел иде. Биредә башка нәрсә иде. Тик ул үзе турындагы фикерләрнең ялгыш икәнен аңлатырга ашыкмады, очу эшен белә һәм ярата иде, ләкин парашютта сикерүләр белән мавыгып китмәде. Мин ул чакта аның авиация белән мавыгуы очраклы нәрсә генә, яшьлек романтикасына хөрмәте генә дип исәпли идем.
Хатын-кызлар турында ирләрнең ачыктан-ачык бер сөйләшүендә ул Энгельсның «Семьяның килеп чыгуы...» исемле китабыннан яттан өзек

китереп, мине бик гаҗәпләндерде. Анда хатын-кызның ничек итеп бер иргә хокук яулавы турында әйтелгән иде. Батталов аны бик җидти һәм, гаҗәпләнүебезгә каршы, үтә урынлы китерде. Күпләр аны аңламадылар, ләкин әңгәмә шунда ук юнәлешен үзгәртте һәм бу темага Батталов алдында яңадан беркайчан да сүз куертучы булмады.

Батталовка интеллектуальлек каян килүен мин ул чакта аңлый алмый калдым.

Батталов яхшы иптәш иде. Гәрчә аның бу сыйфатына тиз генә төшенү читен иде. Ул гаиләсе булган хезмәттәшләренең берәрсе урынына якшәмбе көнне дежур торырга теләп ризалаша, кем турында булса да башка кешенең фикерен хәтта шаярып та әйтүдән тыела иде. Һәр мәсьәлә буенча һәм һәр кеше турында аның үз фикере бар һәм бу фикерен ул бер кешегә дә көчләп тагарга тырышмый иде. Без аның салкын канлылыгын һәм ашыкмаучанлыгын экспансив мөхитебезгә каршы кую ысулы итеп тоя идек, һәм аның тыштан караганда юри олы сымак булып күренүе кайчакта бездә пошыну уята иде. Барыбызны гаҗәпләндереп, 1935 елда Батталов безнең бюроның конструкторы Ольга Яковлевнага өйләнде. Бу хатын үзенең кечкенә буен ташып торган энергия, кайнар темперамент һәм батыр парашютчы булуы белән тутыра иде. Группа белән биектән сикерүдә катнашып рекорд куйганнары өчен ул, башка хатын-кыз парашютчылар белән бергә, хәтта Кызыл Йолдыз ордены да алды.

Бу никах боз белән утны аралаштыру кебек булды. Ләкин бу мисал кешенең характеры турында аның тышкы билгеләренә һәм кайбер чыгышларына карап кына фикер туплауның нигезсез икәнен раслый иде шикелле.

Сынау эшләрендә Батталов, гадәттә, бер нәрсәдән дә баш тартмады һәм бер нәрсәгә дә үзе атылып тормады. Башкалар эшне командир кулыннан «йолкып» диярлек алганда, аңа түземлелек һәм системалылык таләп итә торган эшләр кала иде. Ул «Р-5» самолетыннан ташлана торган объектларны эшкәртеп бетерергә барыбыздан да күбрәк очты, бу, башлыча, күп төрле десант капчыклары һәм әрҗәләр ташлау иде. Ул икенче пилот булып авыр машиналарда да очты, шулай ук «У-2»дә парашютчыларны кабаттан сикерүгә алып чыга иде.

Гомумән, очучы Батталов күп файда китерде һәм безнең гомуми эшебездә эз калдырды. Хәзер кайда ул, исәнме-юкмы, белмим, ә бу үзенчәлекле кешенең характерының алдагы үсешен күрәсе иде»...

*
* *

Сугышчан поход иде бу. Эскадра Япон диңгезенең көньяк ягына зур поход белән чыкты. Безне вак кораблар, миноносецлар, су асты көймәләре озата. Әллә нидә бер генә материк ягыннан авиация дә күренеп китә. Кышкы штормнар вакыты булганлыктан, җиле дә бик усал. Өстебездә кыска тун, башыбызда малахай бүрек булса да, вахтада торганда, суык тәнгә үтеп керә. Зенитчыларга бигрәк тә читен. Алар салкын җилдә дә минуты белән ут ачарга әзер торалар. Безнең башня турбиналар нык эшләүдән калтырый. Атуын атмадык әле, шулай да авиация һәм торпеда атакаларын каршыларга әзер торабыз... Мин Сормово шәһәреннән килгән дустым Оленькин белән янәшә наводка постында утырам. Ул да «параваннар»[1] кую командасына билгеләнгән. Сигнал бирүләрен көтеп кенә торабыз.

---

[1] параван — минага каршы корал.

Тревога. Барыбыз да дәррәү аякка бастык. Параваннар куярга башнядан атылып чыгып киттек.

Диңгез өстендә иләмсез җил. Дулкыннар палубага ыргылып кына торалар. Без, тарттырылган корыч бауга тотына-тотына, корабның урталык өлешенә йөгерәбез. Бик тиз генә үз урыннарыбызга җиттек. Оленькин тимер чыбыктан үрелгән бауны ыргагыннан ычкындыра башлады. Без дә койрык бауларын чишәбез. Тиз ычкындырып өлгердек. Оленькин генә нишләптер озаклады. Шул чак кинәт көтелмәгән хәл булды. Ычкынып киткән парван Оленькинны диңгезгә екты. Бу шундый тиз булды, без абайлап өлгергәнче, дустыбыз диңгезгә барып та төште. Зур тизлек белән йөзгән кораб Оленькиннан ераклаша барды.

«Борт артында кеше» сигналы бирелде. Дежур пушкадан да аттылар. «Харап кына булмаса ярар иде», дип уйлап, тиз генә борт кырыена килдем дә, коткару кругын йолкып алып, диңгезгә ыргыттым. Ләкин Оленькинга минем круг барып җитмәде.

Моторлы көймәне диңгезгә төшерделәр. Бу эш белән боцман Семиликов җитәкчелек итте. Кораб батучыга таба чигенде. Оленькинның башы әле һаман күренә. Бозлы дулкыннар аны капларга тырыша. Бер коткару кругы аның янына ук төште. Әмма ул монысын да тота алмады, җебеп авырайган киеме комачаулады. Моторлы көймә якынайганда гына Оленькинның башы күмелде. Матрослар багорлар белән тирәюньне айкасалар да, егетне таба алмадылар.

Без кораб мачтасында төшерелгән флаг белән базага соң гына кайттык. Мин үзем белән ничәмә еллар хезмәт иткән Оленькинның һәлак булуына ышанырга да, ышанмаска да белми йөрдем. Ләкин хакыйкатьтән качып буламы соң? Бик авыр булды дусны югалту. Үзенең саксызлыгы нәтиҗәсендә параван ыргагын командир өйрәткәнчә ычкындыра алмады шул. Өйрәнүләр вакытында бу эшкә нык игътибар бирмәве аны һәлакәткә китерде. Командир кушуы буенча аның флот киемнәрен, козырексыз фуражкасын кораб исеме язылган тасмасы белән бергә посылкага салып әнисенә җибәрдек.

Илбарис Надиров

# ТАТАР СОВЕТ ФОЛЬКЛОРИСТИКАСЫНЫҢ АКСАКАЛЫ

Халыкның яшәеш дөньясын, олы тарихына һәм көндәлек көнкүрешенә хас аерым хәл-вакыйгаларны, шуларга бәйле хис-тойгыларны, эчке кичерешләрне шагыйрәнә хыяллары белән сугарып сүз сурәтләре ярдәмендә мәңгеләштерә килгән поэтик иҗаты бар. Шул иҗатны — дастан һәм әкиятләрне, бәет һәм җырларны, мәкаль һәм табышмакларны бөртекләп җыйган һәм кадерле хәзинә буларак яңа буыннар өчен саклап калган кешеләр бар. Әгәр без татар фольклористика тарихының ике гасырга якын вакытны иңләгән сәхифәләрен актарсак, анда халык иҗатын җыю-өйрәнүгә өлеш керткән күп исемнәр белән очрашырбыз. Ул исемнәрне хезмәтләренә һәм тоткан урыннарына карап төркемнәргә бүләргә, дәрәҗәләргә аерырга мөмкин булыр иде. Әмма бу эш эшләнгән. Аны үзе шул исемлектә лаеклы урын тотучы фольклорчыларның берсе Хәмит Ярмөхәммәтов (Хәмит Ярми) башкарган. 1948 елда ул татар фольклористикасы тарихы турындагы диссертациясен яклый һәм шул тармакта беренче буларак фәннәр кандидаты дигән дәрәҗә ала. Гомумән, Хәмит ага Ярмигә карата беренче дигән сүзне куллану байтак очракларда хакыйкатькә туры киләчәк. Ул татар фольклорын фәнни өйрәнүгә өлеш керткән беренче монография авторы, Тел, әдәбият һәм тарих институтындагы фольклор секторының беренче мөдире, шул секторда һәм башка урыннарда эшләүче бер төркем фольклорчыларның беренче фәнни җитәкчесе, беренче булып шушы өлкәдә фәннәр докторы исеме алган галим. Татар фольклорын өйрәнү һәм бу өлкәдә фәнни кадрлар хәзерләү буенча алып барган күп еллык уңышлы хезмәтләре өчен моннан ун ел элек Хәмит Ярмөхәммәтовка Татарстанның атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде.

Хәмит ага Ярмигә май аенда 70 яшь тулды. Бу озын гомеренең яртысыннан артыгы татар халык иҗатын җыюга, өйрәнүгә багышланган.

Хәмит Хөснетдин улы Ярмөхәммәтов Түмән өлкәсенең Казарова дигән кечкенә авылында туа. Аның дөньяны таный башлаган үсмер чагы Россия империясен тетрәткән данлы революция чорына туры килә. Бүген җитмешкә җиткән агайлар язмышына тирән эз салган исталекле, тарихи борылыш еллары. Иске белән яңа арасындагы рәхимсез көрәш куәтләнеп кабынган заман. Көрәш ялкыны гасырлар буе йокымсырап, йомылып яшәгән меңнәрчә авылларга да яктылык сибә, халыкны уята. Большевиклар партиясенең алдынгы идеяләрен халыкка җиткерүдә, хезмәт иялəре

арасында аң-белем таратуда яшьләр, комсомоллар зур эш башкаралар. Шулар арасында Хәмит тә була. Ул үз авылларында яңа гына оешкан китапханәдә эшли, балалар укыта, авыл Советы председателе урынбасары була. Аннары аны техникумга укытучы итеп чакыралар, соңрак ул облоно инспекторы хезмәтләрен үти. 1930 елда Хәмит Ярмөхәммәтов Коммунистлар партиясе сафына кабул ителә һәм үз районнарында партия комитетының инструкторы булып эшли.

Гомернең дәртле эш белән үрелгән яшьлек еллары шулай үтә. Әмма Хәмит күңелендә күптән инде бер хыял яши. Укырга кирәк, төпле, нигезле белем алырга кирәк. Шул теләген тормышка ашырыр өчен ул 1930 елда Казанга килә һәм педагогия институтының татар тел-әдәбият бүлегенә керә, аны уңышлы тәмамлагач, аспирантурада калдырыла. Шуннан соң Хәмит Ярминең хезмәт биографиясенә яңа юллар өстәлә. Ул журналист, Татарстан язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре, марксизм-ленинизм классикларын татарчага тәрҗемә итүче редакторларның берсе. Ә 1939 елда Тел, әдәбият һәм тарих институты оештырылгач, шунда татар фольклоры буенча тикшеренүләр алып баручы өлкән фәнни сотрудник.

Менә гомернең штрихлар белән генә билгеләп үтелгән беренче яртысы. Ул ерак елларда баштан кичкән кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләр, гомер юлында очраган күренекле шәхесләр, бигрәк тә замандаш язучылар турында Хәмит аганың сагынып һәм сурәтле итеп сөйли торган кадерле истәлекләре шактый күп. Аларның бер өлешен аерым китап рәвешендә дөньяга чыгару хакында дәрте барлыгын да әйткәне бар. Бу хыял чынга әйләнсә бик яхшы булыр иде.

Тел, әдәбият һәм тарих институтында вакытта Хәмит Ярми халык иҗаты белгече булудан тыш фәнни оештыру эшләрендә сәләте барлыгын күрсәтте. Сугыш чорында ул берничә ел буе шул институтның директоры булып тора, ә фольклор секторы оештырылганнан соң ун елдан артык шуңа җитәкчелек итә, күп төрле җәмәгать эшләрендә катнашуга көчен кызганмый.

Татар фольклорын өйрәнү эше Институтта билгеле бер план нигезендә алып барыла. 1941 елда зур антология хәзерләнә башлый. Ләкин, сугыш башланып киткәч, ул дөнья күрә алмый кала. Бирердә безнең фольклористика тарихына хас бер күркәм үзенчәлекне билгеләп үтәсе килә. Татар халык иҗатын җыю, өйрәнү өлкәсендә, галимнәрдән тыш, язучылар да актив катнашалар. Бөек Тукай традицияләрен дәвам итеп, бу эшкә егерменче елларда Г. Ибраһимов зур игътибар күрсәтә, ә утызынчы елларда А. Шамов һәм Г. Толымбай, Н. Исәнбәт һәм Г. Бәширов төзегән җыр, бәет, табышмак һәм әкият җыентыклары дөнья күрәләр. Хәмит Ярми исә язучы Абдулла Әхмәт белән бергә 1938 елда «Халык иҗаты» дигән җыентык чыгара. Язучылар белән иҗади дуслык сугыштан соң да дәвам итә. «Татар халык иҗаты» исемендәге мәгълүм антология шуның матур мисалы (1951). Аны төзеп китап хәленә җиткерү өчен Х. Ярми белән бергә Г. Бәширов, Х. Госман, А. Шамов күп хезмәт куялар.

Фольклорчы һөнәре бер-берсенә тыгыз бәйләнгән өч тармактан тора. Беренчедән, аңа халык белән тыгыз бәйләнештә торырга (кабинетта утырып кына фольклор турында фикер йөртү бик кыен), халык күңелендәге шигъри иҗат байлыгын эзләргә, табарга, язып ала белергә кирәк. Тәҗрибә һәм осталык сорый торган эш бу. Бер кеше дә кинәт кенә «җыр капчыгын» ачып салмый, бәетләрен әйтеп бирми, әкиятләрен сөйләми. Аларны сөйләтер өчен «тел ачкычы» таба белергә, кешенең ышанычын казанырга кирәк. Моңа ирешү җиңел түгел, әмма халык белән даими аралашып торган фольклорчы үзенә кирәк кешеләр белән уртак тел таба ала. Хәмит ага Ярми бу осталык серләрен яхшы үзләштергән фольклорчыларның берсе. Үз гомерендә ул татарлар яшәгән уннарча өлкәләрне урап чыга, йөзләрчә авылларда меңләгән кешеләр белән очраша. Ул язып алган борынгы һәм хәзерге заман халык иҗаты үрнәкләре Институтның фольклор фондында күләмле генә урын алып торалар. Шул материалларны Х. Ярми үзенең докторлык диссертациясенә өстәмә итеп биргән иде. Алар ике калын томны тәшкил иттеләр.

Икенчедән, фольклорчы халыктан язып алган байлыкны халыкка кайтарып бирүче дә. Моның өчен җыелган материалны фәнни яктан бәяләп сайлый, барлый белү, тәртипкә салу сорала. Популяр җыентыклар төзү артык кыен түгел, ә фәнни җыен-

тык өчен мәгънәле, тыгыз кереш мәкалә язасы, кергән әсәрләргә һәм вариантларына карата искәрмә-аңлатмалар бирәсе бар. Бусы фольклорчыдан җыелган хәзинәне тирән белүне, эстетик критерийларның югары булуын таләп итә. Хәмит ага Ярми әнә шул таләпләргә җавап бирерлек берничә фәнни җыентык төзеп дөньяга чыгарды. Шул исәптән иң элек «Татар халык әкиятләре»нең ике томлык басмасын (I том — 1946 ел, II том — 1956 ел) искә алыйк. Алар әкият дөньясын яхшы белүче күренекле әдип Гомәр Бәширов белән бергә төзеләләр, ә сүз башын һәм искәрмәләрне Х. Ярми яза. Боларга өстәп безнең фольклорда үзенчәлекле жанр саналган «Бәетләр» җыентыгын (1960 ел) төзүче, эчтәлекле кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы да Хәмит Ярми булуын әйтергә кирәк. Шул ук вакытта ул татар әкиятләренең популяр басма буларак рус телендә чыккан ике җыентыгын һәм мәкаләләр китабын төзүче дә. Хәзерге вакытта Ярми ага башка фольклорчылар белән бергә «Татар халык поэтик иҗаты»ның унике томлык фәнни басмасын төзүдә катнаша һәм Мәскәүдә «СССР халыклары эпосы» сериясендә чыгарга тиеш «Бәетләр» китабын хәзерләү өстендә эш алып бара.

Фольклорчы эшчәнлегенең өченче тармагы — халык поэзиясен тарихи һәм теоретик юнәлештә өйрәнү, монографик хезмәтләр һәм фәнни мәкаләләр язу белән бәйле. Фольклор турында, аның аерым төрләре һәм жанрлары, үткәне һәм бүгенгесе турында тикшеренү язу халыкның эстетик карашлары үсешен тирәннән өйрәнмичә мөмкин түгел. Моңа ирешү өчен, халык иҗатында гәүдәләнгән социаль фикерләрне, иҗтимагый тормышка һәм көнкүрешкә караган уй-тойгыларны гади сөйләп чыгу белән мавыкмыйча, халыкның поэтик фикерләү дөньясына, шигъри сүз белән эш итә алу осталыгына үтеп керергә кирәк. Бу авыр эш фольклорчыдан анализ һәм синтез берлеген генә түгел, халыкның тарихын һәм этнографиясен яхшы белүне дә сорый. Яшерми әйткәндә, мондый хезмәтләр әлегә бездә бик аз. Ләкин аларны язар өчен хәзер ныклы гына нигез салынган. Илнең төрле төбәкләрендә яшәүче этник төркемнәр (Казан татарлары, мишәрләр, Урал, Себер татарлары һ. б.) фольклорын күзалларга мөмкинлек биргән бай фонд тупланды, аерым җыентыклар басылды һәм яшь белгечләр үсеп чыкты. Илленче еллар ахырына кадәр, татар фольклорын өйрәнү өлкәсендә исемнәре телгә алынган язучыларны искә алмаганда, Хәмит ага Ярми берүзе эшли иде. Хәзер аның фән кандидаты дәрәҗәсе алган биш шәкерте бар. Халык иҗаты секторында сигез белгеч фәнни эш алып баралар.

Хәмит Ярми — иллидән артык хезмәт авторы. Шулар арасында «Татар халкының поэтик иҗаты» дигән (1967 ел) зур монография үзенә аерым урын тота. Анда татар фольклорының төп жанрлары турында бай мәгълүмат бирелгән. Китапның уңышлы яклары, аерым кимчелекләре хакында үз вакытында матбугатта сүзләр булды. Шуларга өстәп бер фикер әйтәсе килә. Бу хезмәт аның авторының гына түгел, гомумән, билгеле бер этапта татар фольклор белеменә хас казанышларны һәм йомшак якларны шактый тулы чагылдыра. Поэтик географиясенең киңлеге һәм этник яктан чуарлыгы белән аерылып торган татар халык иҗатының барлык жанрларына хас идея-эстетик байлыкны бер китапта гына ачып бирү гаять авыр эш. Хәмит Ярми бу эшкә алынып фидакарьлек һәм тәвәккәллек күрсәтте. Ул бер кеше колачына гына сыймаслык тарихи чорлар һәм материаллар белән эш итте. Бу өлкәдә аның ачышлары булды, шуның белән бергә куелган проблемаларның кайберләре тиешле фәнни тирәнлектә чишелә алмый калдылар (мәсәлән, сүз сәнгате буларак халык иҗатының поэтика дөньясы). Х. Ярми монографиясен без татар фольклористикасы тарихында тәкъдир ителергә лаек хезмәт дип саныйбыз. Хәзерге вакытта аерым жанрларның тарихын, теориясен, поэтикасын мөстәкыйль өйрәнү өлкәсендә эш алып барган фольклорчылар өчен Хәмит ага Ярми язган фәнни хезмәтләр ышанычлы бер чыганак булып торалар.

Хәмит Ярминең фольклор белән бәйле эшчәнлеге турында сөйләгәндә искә алынырга тиеш тагын бер тармак бар. Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбият бүлегә ачылганнан соң (1944 ел), ул анда байтак еллар буе татар фольклоры буенча дәресләр бирә. Әле дә хәтердә, без — төрле авыллардан килгән студентлар аның лекцияләрен кызыксынып тыңлый идек, чөнки ул, бу фәннең теориясенә караган төшенчәләрдән тыш, үзе катнашкан экспедицияләр, оста әкиятчеләр, җырчылар

турында җанлы итеп, тасвирлап сөйли белә, мавыктыра, тыңлаучыларны халык поэзиясен яратырга, җыярга, сакларга өнди, дәртләндерә. Шул студентларның кайберләре Х. Ярми җитәкчелек иткән күп кенә экспедицияләрдә катнашты, ә берничәсе фольклористика буенча фәнни эшче булып китте.

Хәмит Ярми татар мәктәпләре өчен илленче елларда чыккан әдәбият дәреслекләренең бер авторы да иде. Анда ул татар халык поэтик иҗатына багышланган бүлекләрне яза, бу предмет буенча программалар төзи, шуның белән мәктәп эшенә, мәгариф өлкәсенә үзеннән зур гына өлеш кертә.

Хәмит ага Ярмине якыннан белүчеләр аның киң күңелле һәм игътибарлы кеше булуын таныйлар. Аксакал дигән сүзне кулланганда без аның бай һәм гыйбрәтле тормыш тәҗрибәсенә таянып әйтелгән акыллы киңәшләрен һәм тормышка, эшкә мәхәббәт уятучан кешелек сыйфатларын да күз алдында тотабыз.

Н. Г. Чернышевский бер хезмәтендә: «Галимнәргә булган ихтирам нигезендә нәрсә ята соң?» — дигән сорау куя һәм аңа шулай дип җавап бирә: «Бу ихтирам фән-гыйлем дөньясын ихтирам итүнең, аң-белем һәм хакыйкатькә мәхәббәтнең үзенчәлекле бер күренеше». Хак сүзләр. Татар фольклорының атказанган галиме Хәмит ага Ярми эшчәнлеген ихтирам белән телгә алганда без бер үк вакытта халкыбызның үлемсез поэтик иҗатына, күп гасырлык олы әдәбияты һәм чәчәк аткан сәнгать тармаклары үсешендә нигез ташларының берсен тәшкил иткән бай фольклорына тирән мәхәббәтебезне белдерәбез.

# ОЛЫ ФӘН ЮЛЫНДА

Галимнәрнең һәм хәкимнәрнең үзәк штабы — СССР Фәннәр академиясенә 250 ел тулды. Күп меңләгән совет галимнәре, киң совет җәмәгатьчелеге бу датаны лаеклы төстә билгеләп үтәләр. СССР Фәннәр академиясенең 250 еллык юбилее ул — үтелгән зур һәм данлы юлга күз ташлап, ирешелгән уңышларны билгеләү генә дә түгел, ул — алдагы үсеш перспективасын ачыклау да, киләчәккә юллар сызу, эшләнәсе эшләрне барлау һәм галимнәрнең, хәкимнәрнең көчен һәм акылын шул эшләргә туплау һәм юнәлтү дә.

1924 елда Академиянең 200 еллыгын уздыру тантанасына Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты каршындагы Академик Үзәкнең җитәкчесе атаклы язучы Галимҗан Ибраһимов та чакырыла. Тантанага килгән башка кунаклар белән бергә, ул да Мәскәүдә һәм Ленинградта була, Академиянең эшчәнлеге белән якыннан таныша, Академиянең ул вакыттагы Президенты академик А. Карпинский, Академиянең Баш гыйльми секретаре академик С. Ольденбург тарафыннан кабул ителә. Соңыннан язучы тантанада алган тәэсирләре белән уртаклашып матбугатта чыгыш ясый («Академия бәйрәменнән кайткач». «Мәгариф» журналы. 1925 ел. 9 сан). Әлеге мәкаләсендә ул Татарстанда фән үсеше турындагы фикерләрен яза, теләкләрен белдерә. Әлбәттә, әдипнең иң зур теләкләреннән берсе — безнең республикада да фән һәм техниканы академик юнәлешләрдә үстерү эшен юлга салу була.

Классик язучы һәм күренекле җәмәгать эшлеклесенең планнары Бөек Ватан сугышыннан соңгы чорда ныклап тормышка ашырыла башлады. 1945 елда Казанда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы оештырылды. Шуннан бирле ул уңышлы эшләп килә. Хәзерге вакытта Казан филиалы академик Арбузов исемендәге органик һәм физик химия институтын, Казан физика-техника һәм биология институтларын, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтын берләштерә. Монда 1 академик, СССР Фәннәр академиясенең 2 член-корреспонденты, берничә дистә фән докторы, ике йөзгә якын фән кандидаты фәнни-тикшеренү эшләре алып баралар.

Фәннәр академиясе төзелүнең данлы юбилеен Казан галимнәре дә җитди уңышлар белән каршылыйлар. Аерым алганда, Тел, әдәбият һәм тарих институтының да телгә алып сөйләрлек казанышлары бар.

Татар филологиясенә һәм тарихына зур өлеш керткән Л. Җәләй, М. Гали, Н. Калинин, В. Хангильдин, Н. Воробьев, Х. Гыймади, һ. Йосыпов, Х. Ярми, Х. Хәйри, Х. Хисмәтуллин, Г. Хисаметдинов, Р. Газизов кебек өлкән буын галимнәр үзләренең күпчелек тикшеренүләрен шушында яздылар. Институт оешканда монда гыйльми дәрәҗәле хезмәткәрләр булмаган, хәзер исә 5 фәннәр докторы һәм 51 фәннәр кандидаты эшли. Бүген биредә эшләүче галимнәрдән М. Гайнуллин, М. Мөхәррәмов, Г. Халит, Х. Хәсәнов, А. Халиков, Л. Мәхмүтова, Н. Юзиев, И. Надиров, Б. Гыйззәт, Җ. Гыйльманов, Я. Абдуллин, Х. Курбатов, Н. Борһанова, Ф. Фасеев, Ш. Абилов, Ә. Кәримуллин исемнәре Татарстанда гына түгел, бүтән тугандаш республикалар галимнәренә дә яхшы таныш. Инде фәндә кыю төстә үз сүзләрен әйткән К. Сабиров, Ш. Ханбикова, Ф. Ганиев, И. Абдуллин, М. Мөхәммәдиев, Н. Гыйззәтуллин, Р. Гайнанов, Ф. Мусин, Х. Мәхмүтов, И. Илялова, М. Нигъмәтҗанов, М. Сәйдәшева, С. Алишев, Ю. Смыков, А. Җәләлев, Р. Мөхәммәдова, Р. Фәхретдинов,

П. Старостин h. б. татар филологиясен hәм тарихын, сәнгатен өйрәнүгә үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр.

Институтның яшәве дәверендә 200 гә якын фәнни хезмәт иҗат ителде, аларның гомуми күләме өч мең басма табактан арта. Болар арасында культурабыз тарихына казаныш булып керерлек дистәләрчә хезмәтләр бар. Галимнәребез элек-электән төрле методик кулланмалар, мәктәпләр өчен дәреслекләр хәзерләү эшендә дә нәтиҗәле катнашып киләләр, шуның белән халык мәгарифе эшенә турыдан-туры ярдәм күрсәтәләр.

Институт хезмәткәрләре соңгы биш-алты ел эчендә генә дә 40 тан артык әһәмиятле китаплар хәзерләп бастырдылар. Күпчелек хезмәтләрдә татар теленең, әдәбиятының, халык авыз иҗатының, сәнгатенең, тарихының, археология hәм этнографиясенең кызыклы hәм мөhим яклары яктыртыла. Бигрәк тә зур даталарны: Бөек Октябрьның 50 еллыгына, В. И. Ленинның 100 еллыгына, Татарстан төзелүгә 50 ел тулуга багышланган юбилейларны галимнәребез җитди хезмәтләр белән билгеләп уздылар. Шулар арасыннан, мәсәлән, тарихчыларыбызның 1968 елда басылып чыккан «Татарстан АССР тарихы» дигән хезмәтен күрсәтеп була. Узган елны авторлар аның яңартылган hәм беркадәр кыскартылган вариантын бастырдылар. Бу китапларда татар халкының тарихы, аның күпчелек проблемалары яңа фәнни яктыртылыш тапты. Шул елда ук «Татарстанда ленинчыл милли политиканың тантанасы» дигән тематик җыентык та дөнья күрде. Ул Бөек Октябрьның 50 еллыгы хөрмәтенә партиянең өлкә комитеты белән безнең институт бергәләп уздырган фәнни-теоретик конференция материалларыннан төзелгән иде.

Профессор М. Мөхәррәмовның «Октябрь hәм Татарстанда милли-дәүләт төзелеше», «Татарстанда гражданнар сугышы» дигән монографияләре, тарих фәннәре кандидаты М. Сәйдәшеваның «В. И. Ленин hәм Татарстанда социалистик төзелеш» дигән хезмәте, «Ленин hәм Татарстан» исемле документлар hәм материаллар җыентыгы турыдан-туры данлы юбилейларга багышлап чыгарылдылар. Калган китаплар да, тегеләйме-болаймы, татар халкының революциягә килү юлын, аның олы вакыйгаларга катнашуын күрсәтүләре белән шул ук юбилейлар рухына җавап бирә торган булдылар. Шундыйлардан тарих фәннәре докторы Х. Хәсәновның «Большевистик «Урал» газетасы» (1967) hәм «Революционер-интернационалист» (1971) дип аталган, С. Алишевнең «Урта Идел татарлары Пугачев восстаниесендә», Ю. Смыковның «Урта Идел татарлары җир hәм ирек өчен көрәштә» дигән, профессор А. Халиковның «Урта Иделнең борынгы тарихы», Р. Мөхәммәдованың «Татарлар-мишәрләр» исемле, коллектив язган «Урта Идел hәм Урал буе татарлары» h. б. китапларны күрсәтергә мөмкин. Аларның күпчелеге тарихчы, археолог hәм этнографчыларыбызның фәндә яңа сүзләре булды, җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршыланды.

Филолог-галимнәр дә нәтиҗәле эшлиләр. Татар теле hәм әдәбиятының үзенчәлекләрен, еракларга киткән тарихын hәм күп гасырлык байлыгын өйрәнүдә алар Г. Ибраhимов, Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Газиз, В. Богородицкий, Х. Бәдигый, Г. Рәхим, М. Корбангалиев, Җ. Вәлиди, Л. Җәләй, М. Гали h. б. галимнәрнең, танылган тюркологларның традицияләрен уңышлы төстә дәвам иттерәләр.

Филология буенча эшләнгән hәм институт грифы белән басылган китапларның күпчелегенә карата «беренче» дигән сүзне әйтергә туры килә. Чөнки алар, чыннан да, татар әдәбияты hәм теле фәнендә беренче мәртәбә дөнья күрәләр. Мәсәлән, шундыйлардан 1969 елда Мәскәүдә «Наука» нәшриятында рус телендә «Хәзерге татар әдәби теле» дигән хезмәт басылды. Авторлар коллективы язган бу китапта фонетикага, графикага, орфографиягә, орфоэпиягә, морфологиягә hәм лексикологиягә багышланган бүлекләр бар. Анда шулай ук диалектология, стилистика hәм татар теле тарихы мәсьәләләре дә чагылыш таба. 1971 елда хезмәтнең икенче кисәге дә шундый ук исем белән дөнья күрде. Татар теленең синтаксисына багышланган бу китапны професор М. Зәкиев язды, аны хәзерләшүдә шулай ук филология фәннәре кандидаты Х. Курбатов та катнашты. Шулай итеп, бу ике китап ярдәмендә телчеләребез башка милләт укучыларын беренче мәртәбә тулы рәвештә татар теленең байлыклары белән таныштырдылар.

Тел белгечләре төрле типтагы hәм билгеләмәсе төрле булган сүзлекләр төзүгә дә тиешле игътибар бирәләр. 1966 елда

«Энциклопедия» нәшриятында зур күләмле «Татарча-русча сүзлек» чыкты. Ә 1969 елда беренче мәртәбә тулы итеп «Татар теленең диалектологик сүзлеге» басылды. Инде сүзлекче галимнәребез «Хәзерге татар әдәби теленең аңлатмалы сүзлеге»н бастыруга хәзерләү эше белән мәшгульләр. Ул зур күләмдә: якынча 300 басма табакта булып, өч томнан торачак. Бу сүзлекләр татар халкының тел байлыгын чагылдыралар, халыкның сөйләм культурасын күтәрүгә ярдәм итәләр.

Бездә әдәбият гыйлеменең академик юнәлешләрен өйрәнү, татар әдәбиятының тарихын эшкәртү, аның үткәндәге һәм бүгенге мөһим мәсьәләләрен хәл итү алгы планда тора. 1965 елда русча «Татар совет әдәбияты тарихы»н бастырып чыгарып, галимнәребез татар әдәбиятын бөтен союз мәйданына чыгаруга үзләреннән өлеш керттеләр.

Татар әдәбиятының күп гасырлы бай үсеш юлын тулы чагылдырган берничә томлы тарих язу эше — инде күптән көн тәртибенә куелган мәсьәләләрнең берсе. Бу җаваплы эшкә хәзерлек йөзеннән әдәбиятчы галимнәребез соңгы елларда әдәбият тарихының аерым чорлары һәм аерым жанрлары буенча тикшеренүләр алып бардылар. Мондый хезмәтләрнең, әлбәттә, мөстәкыйль әһәмиятләре дә бар, шуңа күрә алар басылып чыга килделәр. Бу җәһәттән күренекле галим һәм тәнкыйтьче Гали Халит нәтиҗәле эшли. Ул, мәсәлән, «Революция тудырган геройлар» (1967) дип аталган китабында яшь татар совет әдәбиятындагы яңа әдәби геройлар, аларның идея-эстетик сыйфатлары, рухи байлык чыганаклары, социалистик җәмгыятьнең асылына тәңгәл килерлек эчке дөньялары турында сүз алып бара. Монографиядә Г. Ибраһимов иҗатын анализлауга аеруча зур урын бирелгән. Г. Халит XX йөз башында татар поэзиясенең үсеш юлларын, үзенчәлекләрен тикшергән яңа хезмәтен хәзерләп матбугатка тапшырды.

Өлкән галимнәребездән берсе М. Гайнуллин үзенең күп еллык хезмәтен 1966 елда бастырып чыгарды. «XX йөз башында татар әдәбияты һәм публицистикасы» дигән исем белән русча язылган бу китап материалга байлыгы, Беренче рус революциясе тәэсире астында көчәеп үсеп киткән татар әдәбияты һәм журналистикасының шактый тулы картинасын күз алдына бастыруы белән әһәмиятле. 1968 елда галимнең югары уку йортлары өчен «XIX йөз татар әдәбияты» дигән тагын бер китабы дөнья күрде. Ә узган елда ул аның русча эшләнгән вариантын нәшриятка тапшырды.

Әдәбиятчы галимнәр тагын да «М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре» дигән, XVI йөз шагыйре Мөхәммәдьяр, совет язучылары Ф. Бурнаш, Г. Кутуй, Ф. Хөсни, Г. Әпсәләмовлар иҗаты турында һ. б. китаплар бастырып чыгардылар. Болар арасыннан тагын да ике китапка аерым тукталып үтәсе килә. 1968 елда «Габдулла Тукай» исемле тематик җыентык дөньяга чыкты. Татар халык шагыйренең тууына 80 ел тулуга багышлап төзелгән бу китаптагы мәкаләләрдә Г. Тукайның иҗат мирасы, андагы проблемалар яңача яктыртылалар. Бу мәкаләләрнең авторлары — Мәскәү, Казан, төрки телендәге союздаш һәм кардәш республикалар язучылары һәм галимнәре С. Муканов, Г. Голәм, А. Шәриф, М. Вәлиев, Т. Нуртазин, Л. Каюмов, Х. Госман, С. Сафуанов һ. б. — бөек шагыйрьнең татар поэзиясен үстерүгә керткән өлеше һәм аның тугандаш халыклар әдәбиятларына ясаган йогынтысы хакында сүз алып баралар.

1972 елда Татарстан китап нәшриятында «Герой, стиль, осталык» дигән җыентык чыкты. Аны галимнәребез КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарына җавап төсендә хәзерләгәннәр иде. Җыентыкта бүгенге җанлы әдәби процессыбызның кайбер өлгергән мәсьәләләренә багышланган, шулай ук бүгенге язучыларыбызның тел-стиль үзенчәлекләрен җентекләп тикшергән мәкаләләр урын алды. Инде институтта шундый рухтагы икенче җыентык хәзерләнә, ул «Метод, стиль, жанр» дип аталачак.

Халык авыз иҗатын өйрәнүче галимнәребезнең дә уңышлары байтак. Татар фольклоры турындагы хезмәтләре белән танылган Хәмит Ярминең «Татар халкының поэтик иҗаты» исемендәге китабы басылып чыкты. Фольклорчылар чыгарган «Халык әйтсә — хак әйтер», «Татар халкының җырлы-биюле уеннары» дигән җыентыклар, И. Надировның «Татар халык җырлары» дигән китабы укучылар тарафыннан яратып каршы алындылар. Ф. Вәлиевнең «Казан татарлары орнаменты» (1969) исемле сәнгатькә багышланган китабы да тиз арада таралып бетте.

Өлгергән фәнни проблемаларны хәл итүдә төрле дискуссияләр, фәнни конференцияләр һәм киңәшмәләр дә мөһим

роль уйный. Шуңа күрә дә институтта бу эшләргә тиешле игътибар бирелә. Мәсәлән, соңгы 5—6 ел эчендә генә дә шундый уннарча чаралар үткәрелде. Алар арасыннан татар халкының иҗтимагый-политик фикере һәм культурасы тарихының өлгергән проблемаларына багышланган дискуссияне (1969), В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга, Татарстан АССРның 50 еллыгына карата уздырылган конференцияләрне (1970), СССР төзелүнең 50 еллыгы уңае белән үткәрелгән ике конференцияне (1972) аерым алып күрсәтергә кирәк. 1973 елда иҗат Союзлары белән берлектә социалистик җәмгыятьтә (Идел һәм Урал буе автономияле республикалар материаллары җирлегендә) милли әдәбиятлар һәм сәнгатьләрнең үзара бәйләнеше мәсьәләләренә багышланган зур фәнни-теоретик конференция оештырылды. Аның материаллары Л. И. Брежневның «СССРның 50 еллыгы турында» дигән докладында куелган теоретик проблемаларны хәл итешүгә билгеле бер өлеш булып керерләр дип уйлыйбыз.

Тормыш безнең алга да көннән-көн югарырак таләпләр куя. Г. Ибраһимов исемендәге институт галимнәренең бурычы — татар халкының тарихын, археологиясен, этнографиясен, тел һәм әдәбиятын, фольклорын һәм сәнгатен бүгенге фән югарылыгыннан торып, академик юнәлешләр таләп иткән тирәнлектә өйрәнү һәм аларны аерым китаплар, җыентыклар, сүзлекләр һәм материаллар рәвешендә дөньяга чыгару. Шуңар лаеклы төстә җавап бирү өчен, институт галимнәре якындагы елларда түбәндәге хезмәтләрне иҗат итәчәкләр. Телчеләр бишьеллык ахырына аерым күренекле язучыларның стилен өйрәнеп язган зур монография тәмамлаячаклар. Шулай ук халкыбызның көндәлек сөйләм телен, бу өлкәдәге үсешне һәм аерым кимчелекләрне яктырткан хезмәт тә, рус һәм татар телләре арасындагы бәйләнешләрне тикшергән монография дә әзер булачак. Тел тарихы буенча эшләүче галимнәр XV—XVI йөз язма истәлекләрен, шулай ук татар һәм чуваш телләрен чагыштырмалы өйрәнү өлкәсендә ныклы эш алып баралар. Диалектологлар татар теленең атласын төзиләр. Бу атлас 2 томнан булачак. Шулай ук аерым диалектлар буенча, татар телендә сүз ясалу, полисемия, синонимия һәм омонимия турында махсус хезмәтләр языла.

Әдәбият галимнәре үзләренең төп иҗат көчләрен татар әдәбиятының тулы тарихын тудыру эшенә багышлыйлар. 5 томнан торачак дип исәпләнгән бу тарихта әдәбиятыбызның XII гасырдан алып хәзерге көнгә кадәр булган үсеш юлы тулы яктыртылачак. Моннан тыш Г. Ибраһимовның 8 томлык әсәрләре (аның I томы шушы көннәрдә укучылар кулына керәчәк), К. Насыйриның 2 томлык «Хезмәтләр»е дөнья күрәчәк, Г. Тукайның, М. Җәлилнең 4 томлык басмалары хәзерләнә.

Халкыбызның авыз иҗатын тикшерүчеләр татар фольклорының 12 томлык җыентыгын төзү, Идел буе һәм Себер татарларының фольклор үзенчәлекләрен өйрәнү буенча эш җәелдерделәр. Музыкаль фольклор буенча да хезмәтләр булачак. Себердә һәм Урал буенда яшәүче татарларның музыкаль иҗаты буенча монографияләр дә языла, җыр һәм көйләрен үз эченә алган альбомнар да төзелә. Театр белгечләре «Татар совет театры тарихы (очерклар)» исемле хезмәтне басарга хәзерләп тапшырдылар. Сәнгать буенча тагын «Хәзерге татар композиторлары иҗатында музыкаль фольклор традицияләре», «Татар совет сынлы сәнгате тарихы (очерк)», «Татар театры бүгенге көндә», «Революциягә кадәрге татар театры» дигән һ. б. хезмәтләр дә языла.

Җәмгыятебезнең төп көче — эшче сыйныф. Аның данлы үткәне, революцион көрәше, тарихи җиңүләре җентекләп өйрәнүне таләп итә. Шуны истә тотып, тарихчылар Татарстанда промышленностьның һәм эшче сыйныфның тарихын тикшергән китап язалар. Бу зур һәм җитди монографик хезмәт булачак, анда XVIII гасырның урталарыннан, ягъни бездәге беренче эшче отрядлары оешу, тәүге промышленность учаклары барлыкка килү вакытларыннан алып бүгенге көнгә кадәрге вакыйгалар күз алдыннан үтәчәк, совет чорында Татарстан эшче сыйныфы ирешкән гүзәл казанышлар тулы яктыртылачак. «Татарстанда культура революциясе» дигән 2 томлык зур хезмәт тә үзенең фәнни әһәмияте белән аерылып торачак. Тарихчылар шулай ук Казан шәһәре тарихы турында да китап язалар.

Этнографлар һәм археологлар экспедицияләрне елдан-ел киңәйтә баралар. Киләсе бишьеллыкта татар халкының этнографик атласы төзелә башлый, «Идел буе Болгариясе һәм Казан ханлыгының куль-

турасы һәм этник составы» диган ике томлык хезмәт язылачак, Татарстанның күп томлык археологик картасын төзү эше дәвам иттереләчәк.

Татарстандагы иҗтимагый-политик фикернең үсеше проблемалары галимнәрне күптән кызыксындыра һәм аларны ныклап өйрәнү актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Хәзер бездә бу өлкәдә дә эшләр җанланачак. Шуның беренче чагылышы буларак, якын елларда татар мәгърифәтчелеге турында зур хезмәт дөнья күрәчәк.

...Г. Ибраһимов югарыда искә алынган мәкаләсендә, академик С. Ольденбург алдында үзен нык кызыксындырган бер мәсьәләне куюы турында әйтеп, мондый юлларны яза:

«...Сөйләшкәндә Татарстанны өйрәнү эшендә академия белән баглану мәсьәләсе кузгалган иде. Академик Ольденбург, бу эшнең кирәклеген Совнарком белән аңлашканның соңында, Союздагы өлкәләр эчендә аерымрак тип сыйфаты белән Татарстан өчен экспедиция төзүнең мөмкинлеген әйтте. Моның өчен, әлбәттә, урыннан башлау кирәк. (...) Татарстанның үзендә дә гыйльми көчләр булганга, бу эшне башкаруда Академиянең төп хезмәте юлбашчылыкта булып, урындагы куәтләр нык катнашу кирәклеген аңлатты».

Әдип язган бу юлларны укып, аны моннан 50 ел элек билгән планнарның һәм теләкләрнең берсе турында уйланасың да, күңелне горурлык һәм куаныч били. Шушы кыска гына тарихи вакыт эчендә Г. Ибраһимовның татар халкын академик фән нигезләрендә өйрәнә башлау теләге тормышка ашты гына түгел, артыгы белән үтәлеп бара. Әйе, бездә хәзер татар халкын, аның культура һәм гражданлык тарихын махсус өйрәнүче академик оешма бар. Бу оешма — Г. Ибраһимов исемендәге институт үзе генә дә республикага һәм Союзның татарлар яши торган башка районнарына ел саен уннарча экспедицияләр чыгара. Аның галимнәре ел саен уртача 8—10 китап, йөзләгән мәкалә бастырып чыгаралар, төрле шәһәрләрдә йөзләрчә фәнни докладлар ясыйлар. СССР Фәннәр академиясенең 250 еллыгын алар да зур күтәренкелек белән билгеләп үтәләр. Чөнки Советлар илендә фәннең киләчәге якты һәм өметле.

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН,**
**филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты директорының фәнни эшләр буенча урынбасары.**

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ БЕР ХИКӘЯСЕ ТУРЫНДА

Галимҗан Ибраһимовның 1913 елда язылган «Көтүчеләр» хикәясе укучыларга мәгълүм әсәр. Язучы анда революциягә кадәрге авыл тормышының онытылмаслык картиналарын бирә, ярлы крестьяннарның авыр язмышын зур осталык белән сурәтли. Хикәянең төп герое — көтүче малае Вахит. Укучы бөтен вакыйгаларны аның күзе белән күрә, аның нечкә күңеле аша кичерә. Вахит кечкенәдән үк әтисе белән көтүгә ялланган, шуңа күрә аңа күп кимсетелүләр күтәрергә туры килә. Вахит әле монысына да түзгән булыр иде, ләкин көннәрдән бер көнне аның әтисе авырып китә. Авыл кешеләре авыру картны чиратлап, өйдән-өйгә йөртеп карый башлыйлар. Тик Вахит бу хурлыкны күтәрә алмый — ул авылдан чыгып китә. Ләкин авылдан читтә дә аңа бәхет елмаймый: ул чак кына үлмичә кала һәм бәхетле очраклылык аркасында гына больницага килеп эләгә. Анда ул Сара белән таныша. Хикәя ахырында без Вахитның гаилә тормышы корып җибәрүен күрәбез.

Ләкин рәхәт тормышка ирешкән Вахитның күңелен инде хәзер әтисе турындагы уйлар тынгысызлый. Ул аны кызгана, тормышта ни өчен бик күпләрнең ярлылыкта газап чигүен аңларга тели. Вахитның әнә шул уйларын тагын да калкурак итеп бирү өчен язучы героен берничә мәртәбә бер картина белән очраштыра. Ул картинаны Вахит беренче тапкыр больницада күрә.

«Бер көнне күңелем ачылып, рәхәтләнеп, бакчадан бүлмәмә кереп килгәндә, күзем дивардагы сурәтләргә төште.

— Бу кем? — дип сорадым.

Сара уйлы тавыш белән:

— Хәзрәте Гыйса... Ай яктысында тирән уйга чумып утыра... Ул фәкыйрьләрне бик яраткан... Шулар турысында уйлый торгандыр, диде.

Мин бернәрсә дә аңламадым. Ләкин, китә алмыйча, бик озак карап тордым.

Фәкыйрьләр хакында уйлый, дигәч, өткәй искә төште: хәзрәте Гыйса ни эшләтер иде икән, дидем. Ләкин бертөрле дә бу уйның очына чыга алмадым».

Шуннан соң Вахит тагын ул картина белән очраша. Бусы инде икенче җирдә — картиналар галереясында.

«Аңардан ерак түгел хәзрәте Гыйса тора. Олы диңгез, шуның уң ягыннан зур таулар күккә күтәрелеп киткән; тын, рәхәт төн; диңгездән тулы ай күтәрелеп килә. Дөньяда бер «эһ» дигән дә тавыш юк. Шул вакыт хәзрәте Гыйса таяк таянып тау эченнән чыга да, зур бер ташка утырып, айга карап уйга бата. Аның аяклары ялангач, өстендә тубыкларына чаклы төшкән озын җөббә... үзе ялан баш. Ефәк кебек йомшак чәчләре ике кулбашыннан дулкынланып төшеп торалар. Йөзе артык җитди, күзләре тирән уй белән каядыр юнәлгәннәр...

Моның хакында ни әйтергә белмәсәм дә, сәгатьләрчә тукталып карый идем.


Бервакыт Сарадан:

— Ул нәрсә уйлый икән? — дип сораган идем.

Фиреште́м, җанланып, канатланып китте. Минем сәвальләрем аңа күп вакыт шулай тәэсир итәләр иде. Култыгымнан алды да, нур сибелеп торган күзләре белән элек Гыйсага, аннан соң миңа карап:

— Ул бәхетсез адәм балаларының рәхәте, сәгадәте хакында уйлый,— диде».

Шулай итеп, әлеге картинаны караган саен Вахитның уйлары, кичерешләре тирәнәя, үз алдына куйган сораулары җитдирәк була бара.



«Гыйса алдына килсәм, Сараның әйткән сүзләре һәр вакыт исемә төшә:
— Ул бәхетсез адәмнең рәхәте, сәгадәте хакында уйлый...
— Ул фәкыйрьләрне бик сөйгән...
Сөйлә, Гыйса! Син адәмнәрнең бәхетсезлеге, аларны рәхәтлеккә чыгару турында күп уйладың; әйт, нинди фикергә, нинди нәтиҗәгә килдең? Кан түгү бетәчәкме? Милләте, дине башка булганлык өчен дошманлашуларның бер чиге булачакмы? Әйт, боларга ирешүдә син күп уйлавыңның нәтиҗәсендә нинди юлны кыскарак таптың?»

Галимҗан Ибраһимовның яшь героен шул кадәр дулкынландырган бу картина кем әсәре соң?

Язучы үзе хикәясендә картинаның кемнеке булуын да, ничек аталуын да әйтми. Ләкин Вахитның сүзләренә карап, ул картина күренекле рус художнигы И. Н. Крамскойның «Христос чүлдә» исемле әсәре икәнлеген чамаларга мөмкин.

Крамской үзенең бу картинасын 1872 елда язып бетерә. Художникның Христос образына яңа эчтәлек салып, аны халык язмышы өчен борчылучы һәм аны авыр газаптан коткару юлларын эзләүче итеп сурәтләве илдәге бөтен прогрессив көчләрдә зур кызыксыну уята, аларда кайнар теләктәшлек таба. Крамскойның бер хатында: «Һәркемнең тормышында шундый минут була... ул уңга китәргәме, сулгамы, алла хакы өчен дип теләнергәме, әллә явызлык каршында бер адым да чигенмәскәме дип уйлана башлый. Шулай итеп, ул Христос түгел. Ягъни, мин аның кем икәнен белмим. Бу минем үз уйларымның чагылышы» дип язуы картинасының гаять тирән эчке мәгънәсенә тагын бер ишарә була. Л. Н. Толстой: «Крамскойның Христосы — мин белгән Христосларның иң әйбәте», дип яза.

Шулай итеп, сәнгатьнең башка төрләре, шул исәптән рәсем сәнгате белән дә нык кызыксынган һәм 1915 елда махсус «Рәсем сәнгате альбомы» бастырып чыгарган Галимҗан Ибраһимовның хикәясенә бу картинаның килеп керүе бик аңлашыла.

Язучы Крамской картинасында үзен иң борчыган сорауларның чагылышын тапкан, аның халык тормышы турындагы уйланулары бу әсәр тәэсирендә тагын да көчәйгән, тирәнәйгән.

Бу факт Галимҗан Ибраһимовның сәнгать дөньясында нечкә сиземләү сәләтле шәхес булганлыгына безне тагын бер тапкыр ышандыра.

**С. РӘИМОВА.**

Сәлим Шәйдуллин

# ХИКМӘТ ИНКАРЬ ИТҮДӘ ГЕНӘМЕ?

*XX йөз башы татар поэзиясендәге романтизмның кайбер үзенчәлекләре*

## 1

Унынчы еллар татар поэзиясендә Европа романтизмындагы төп билге һәм образларның күпчелеге урын алды. Моның үзен генә дә татар романтизмының әдәби юнәлеш буларак формалашып җиткәнлеген күрсәткән факт дип карарга мөмкин булыр иде. Болар нинди билге һәм образлар соң? Безнең поэзиядә алар ничек, ни рәвешле чагылдылар? Татар романтизмының үзенә генә хас билгеләре һәм образлары бармы? Бу сорауларга җавап эзләргә керешкәнче, романтизмны өйрәнүдә еш очрый торган бер җитешсезлек турында искәртеп үтү кирәк кебек.

Күпчелек хезмәтләрдә романтик билге һәм образлар гадәттә реаль тормышка каршы куелган, аны инкарь иткән билге һәм образлар сыйфатында гына аңлатыла. Мондый тенденция соңгы елларда чыккан аеруча зур һәм мөһим тикшеренүләрдән В. В. Ванслоқның «Эстетика романтизма» (Мәскәү. 1966) исемле хезмәтендә дә үзен нык кына сиздергән иде. Дөрес, чынбарлыкны инкарь итү, аңа каршы тору яисә аңардан качу — романтизмның төп билгеләреннән берсе. Әмма бу билгене артык күпертү, аны үзәккә куеп тикшерү һәр очракта да уңай нәтиҗә бирмәскә мөмкин. Чөнки чынбарлыкка каршы куелган билгеләре күп булган кебек, романтизмның чынбарлыктагы тәртипләргә авараш, тәңгәл китереп сурәтләнгән образлары да аз түгел. Икенчедән, романтик язучы, реаль тормыштагы бөтен әшәкелекне, явызлыкны инкарь итү белән бергә, чынбарлыкның матурлыгын, прогрессив якларын расгый, ә еш кына идеаллаштырып та сурәтли.

Әлбәттә, бу фикерне без уйлап чыгармадык. Ул соңгы вакытта язылган кайбер хезмәтләрдә чагылып үтте инде. Мәсәлән, моны без У. Р. Фохтның «романтик әдәбиятның гомум идеологик юнәлеше... бүтән, «булуы мөмкин булган» **чынбарлыкны раслау** белән дә характерлана»[1] дигән юлларыннан ачык күрәбез. Г. Халит та, Октябрь революциясеннән соңгы татар романтизмын күздә тотып, түбәндәге юлларны язган иде: «Әлбәттә, бу инде традицион мәгънәсендәге романтизм гына түгел. Аның төп өлеше яңа чынбарлыкның җанлы тамырларына бәйләнгән булып, шул **чынбарлыкны раслау көрәше** белән рухланды»[2].

---

[1] У. Р. Фохт. Некоторые вопросы теории романтизма. «Проблемы романтизма» исемле җыентык. Рус телендә. Мәскәү, 1967 ел. 87 бит. Ассызык безнеке — С. Ш.

[2] Гали Халит. Тизләтелгән әдәби үсеш һәм иҗат методлары. «Казан утлары» журналы. 1971 ел. 9 сан. 151 бит. Ассызык безнеке.— С. Ш.

Бу карашлар XX йөз башы татар поэзиясендәге романтизмның үзенчәлекләрен өйрәнүдә дә таяныч була алалар [1]. Чынлап та, романтизмны «раслау» төшенчәсеннән башка күз алдына китерүе кыен. Биредә «инкарь итү» һәм «раслау» төшенчәләре — философик категорияләр кебек — берсе икенчесеннән башка була алмый, ягъни романтизмда һәрбер инкарь итү матурлык идеалын (эстетик идеалны) раслау ихтыяҗыннан чыгып эшләнә. Әгәр «җир галәме»ндә раслар яки таяныр нәрсә таба алмаса, романтик язучы үзен иксез-чиксез хәят диңгезендә чайкалган йомычка хәлендә хис итә башлый һәм котылгысыз рәвештә, таяну ноктасы эзләп, «күк галәме»нә, дингә яисә фатализмга килә.

Шул рәвешчә, реаль тормыш белән романтик идеал һәр вакыт үсеш-үзгәрештә һәм диалектик мөнәсәбәттә булып, бу мөнәсәбәт бер чорда антагонистик, ә икенче чорда теге яисә бу дәрәҗәдә **гармоник** характер алырга да мөмкин. Романтизмның «билгеләр системасы» үзгәреп тору сәбәбе һәм образларны чынбарлыкка каршы яки параллель кую үзенчәлеге дә, беренче чиратта, әнә шул реаль тормыш белән романтик идеал арасындагы мөнәсәбәт үзенчәлекләренә бәйләнгән.

Чынбарлык белән романтик идеал арасындагы каршылык, мәсәлән, явыз көчләр өстенлек алган вакытларда тирәнәйсә, гармоник тенденция гадәттә демократик көчләр тантана иткән чакларда ачык күренә.

Соңгы тенденция, реакция чорында (1907—1910) «югалып» торганнан соң, мәсәлән, яңа революцион күтәрелеш елларындагы татар поэзиясендә (1911—1914) кабат алгы планга чыкты. Бу барыннан да элек бәйрәм, таң, йолдыз, кояш, яз, маяк, җил, шаулы диңгез, дулкын, яшен һ. б. ш. романтик-символик образларны туып килгән матурлыкка яисә булырга тиеш дип идеал ителгән тормышка параллель, янәшә куеп сурәтләүдә күренде.

Шундый сурәтләрне күп кулланган шагыйрьләрнең берсе — Сәгыйть Сүнчәләй булды. Мәгълүм булганча, поэзиягә Тукай һәм Гафурилар күтәргән гуманистик идеал яктылыгында килеп кергән бу шагыйрь таң образын изелгән халыкның якынлашып килгән иректе көне, тарихи бәйрәме итеп күз алдына китерде:

**Син күрәмсең! Әллә кайларда —**
**Еракта таң агара.**
**Ярлыларның сәгадәтле**
**Ул матур бәйрәм таңы.**
**Бер заман тәнвир итәр [2] ул**
**Таң бу фани дөньяны [3].**

С. Сүнчәләй поэзиясендә шагыйрь образы да әнә шул таңны каршылаучы һәм халыкны уятучы ролендә сурәтләнә:

**Мен манараң өстенә, хәсрәтле җырчы, әйт азан!**
**Моң белән яңрат, уят тизрәк татарлар дөньясын!**
**Үтте төн, бетте; кояш чыгышында инде атты таң;**
**Җитте йоклау! Һәммәсе торсын да тизрәк уйласын! [4]**

һәм шушы мотив С. Сүнчәләй поэзиясенең үзәгеннән кызыл җеп булып үтте. («Шагыйрь», «Шагыйрьгә», «Җырларым — күз нурларым», «Бер газетага», «Шагыйрь каргышы» һ. б.)

Әлбәттә, «азан әйтүче» шагыйрь образы романтизм өчен әр-яңа герой түгел иде. Безнеңчә, аны рус һәм Европа әдәбиятларыннан килгән пәйгамбәр-шагыйрь образының үзенчәлекле бер төре итеп карау дөресрәк булыр. Шул ук вакытта татар

---

[1] Бу урында шунысын искәртергә кирәк: югарыда куелган сорауларга җаваплар эзләү барышында төп игътибар теге яисә бу шагыйрьне «романтик шагыйрь» итеп күрсәтүгә түгел, бәлки XX йөз башы татар поэзиясендә реализм белән бергә урын алган романтизм хәрәкәтен күзәтүгә, аның кайсы шагыйрь иҗатында нинди билге-элементлары ни дәрәҗәдә һәм ни рәвешле чагылуын тикшерүгә биреләчәк.

[2] Тәнвир итәр — яктыртыр, нурландырыр.

[3] Сәгыйть Сүнчәләй. Сайланма әсәрләр. Казан, 1961 ел, 48 бит.

[4] С. Сүнчәләй шигырьләре. Казан, 1913 ел, 36 бит.

шагыйрьләренең рус поэзиясендәге пәйгамбәр образына мөнәсәбәтләрендә капма-каршы тенденцияләр чагылганлыгын да истә тотарга кирәк. Билгеле булганча, 1909 елда Г. Тукай Лермонтов «Пәйгамбәр»ен, ә С. Рәмиев Пушкин «Пәйгамбәр»ен татарчага тәрҗемә иттеләр. Ләкин алар Пушкин һәм Лермонтов иҗатындагы пәйгамбәр образына икесе ике ноктадан карап якын килделәр. Г. Тукай рус поэзиясендәге пәйгамбәр-шагыйрь образының, хакыйкать өчен көрәшкә чакырып, җәмгыятьне үзгәртергә омтылуын һәм трагик хәлгә дучар ителүен көчәйтеп сурәтләгән булса, С. Рәмиев тәрҗемәсендә ул образ җәмгыятьтән **үз ирке белән** читләшкән герой сыйфатында гәүдәләнде — аның индивидуалистик характеры калку итеп тасвирланды.

С. Сүнчәләй поэзиясендәге «азан әйтүче» шагыйрь образы исә нәкъ менә беренче тенденциягә тоташкан иде: бу геройның төп миссиясе (халыкның күзен ачу, аны уяту) белән Пушкин, Лермонтов һәм Тукай әсәрләрендәге пәйгамбәр-шагыйрь миссиясе арасында зур охшашлык, уртаклык бар.

Яңа күтәрелеш чоры татар поэзиясендә киләчәк тормыш матурлыгын раслаган элементлар куәт алганлыгына икенче дәлил итеп романтизмның актив сыйфатлары көчәю фактын китерергә мөмкин. Бу исә явыз тәртипләргә каршы актив көрәш алып барган геройларга йөз тотуда һәм ирке чикләнмәгән табигать стихиясенең фетнәле, җимерүле күренешләрен явыз чынбарлыкка каршы, ә хыялдагы тормышка параллель куеп сурәтләүдә ачык күренде. Мәсәлән, Г. Тукай поэзиясенә рус әдәбиятыннан кергән кояш, диңгез, җил һ. б. ш. кебек романтик-символик образлар «XX йөз башындагы революцион омтылышларны яктырту сызыгында файдаланылдылар» [1]. Мисал өчен, А. С. Пушкинның «Сказка о мертвой царевне и о семи богатырях» исемле әсәрендәге:

**Ветер, ветер! Ты могуч,**
**Ты гоняешь стаи туч.**
**Ты волнуешь сине море,**
**Всюду веешь на просторе,**
**Не боишься никого,**
**Кроме бога одного...—**

дигән юлларыннан файдаланып, Тукай тарафыннан язылган «Җил» (1911) шигырен карап үтик:

**Исәр җил! Көчлесең, син бик батырсың,**
**Ачулансаң, җиһанны кузгатырсың.**

**Бик иркенләп исәсең җир йөзендә,**
**Котыртып болгатасың диңгезен дә.**

**Көтү төсле болытларны куасың,**
**Теләсәң кайсы якларга борасың.**

**Ireклесең, исәсең дә исәсең,**
**Тузан, кар туздырып юллар кисәсең.**

**Ирекле син, исәр җил, әйдә ис, ис!**
**Сиңа баш юк, ходайдан башка һич, һич.**

Әгәр оригинал белән тәрҗемәнең юлын юлга, сүзен сүзгә чагыштырып, җентекләп күзәтсәк, соңгысында нәкъ менә актив романтизм сыйфатларының өстенлек алганын күрербез. Пушкин әсәрендә җилнең һәр яктан ирекле, һәртөрле тоткарлыклардан азат икәнлеге һәм теләгәнен эшли алу сәләте җырланган булса, тәрҗемәдә исә иң әүвәл әнә шул тенденциянең көчәйтелгәнлегенә күзгә ташлана. Тукай шигыренең һәр юлында диярлек «ирeклесең», «бик иркенләп исәсең» кебек тәгъбирләр кабатланып килүе үзе генә дә шуны раслау өчен җитәр кебек. Икенчедән, тәрҗемәдә җилнең фетнәлелек, дәһшәтлелек сыйфатлары калку тасвирлана. «Ачулансаң, җиһанны кузгатырсың», «котыртып болгатасың...», «тузан, кар туздырып юллар кисәсең» шикелле гыйбарәләрдә ачык күренә ул. Өченчедән, Тукай җил образына әлеге сыйфатларын-

[1] Р. Башкуров, Тукай һәм рус әдәбияты. Казан, 1958 ел, 115 бит.

нан киләчәктә дә аерылмаска, «бик иркенләп» исүдән туктамаска кушып чакыру да ташлый: «Иреклә син, исәр җил, әйдә ис, ис!»

Бу уңайдан Тукай әсәрендәге җил образын Дәрдмәнднең «Кораб» шигырендәге җил образы белән чагыштыру кызыклы. Романтик-символик образ буларак, җил бу әсәрләрнең икесендә дә ирке чикләнмәгән, һичкемгә буйсынмас стихия рәвешендә гәүдәләндерелә. Бусы — охшаш яклары. Әмма үзләренең төп бурычлары, вазифалары ягыннан алар бик нык аерылалар. Пушкин әсәрендә җилнең вазифасы күрсәтелми; биредә ул, барыннан да элек, ирекә тантана итеп йөргән бөек һәм гөнаһсыз бер көч, ирек символы буларак тасвирлана. Тукайда инде без анык «ачулана» торган гадәте барлыгын да күрәбез. Ирекен буарга, юлына аркылы төшәргә теләүчеләр булган очракта, Тукай әсәрендәге җилнең «җиһанны кузгату» ихтималы да юк түгел. Дәрдмәндтә исә бу образ гомумән тәкъдир җиле, язмыш символы итеп алына. Аның «Кораб»ындагы җилнең вазифасы, Тукай әсәрендәгедән аермалы буларак, үзен «ачуландырган» көчләрне генә түгел, ә юлында очраган һәр нәрсәне һәлакәткә дучар итүдән гыйбарәт. Шул рәвешчә, җил образы Дәрдмәнд «Кораб»ында гомумән язмыш мәрхәмәтсезлегенә аваздаш китереп сурәтләнгән булса, Тукайның яңа революцион күтәрелеш чорында иҗат ителгән шигырендә ул күтәрелеп килгән революцион хәрәкәткә параллель куеп тасвирланды.

2

Романтик идеал белән киләчәк тормыш матурлыгының үзара кушылуы, гармония хасил итүе турында сөйләгәндә, әлбәттә, заманның төп героен ни рәвешле күз алдына китерү мәсьәләсе үзәктә торырга тиеш. Яңа күтәрелеш елларында Тукай һәм Гафури кебек шагыйрьләр чорның төп герое итеп, әйткәнебезчә, нәкъ менә явызлыкка каршы актив көрәшүче геройны санадылар, ә еш кына реаль революционерларны (әйтик, Хөсәен Ямашевны) идеаллаштырып сурәтләделәр. Аларның игътибарын, барыннан да бигрәк, көчле ихтыярга ия булган, халык азатлыгы һәм бәхете өчен җанын да кызганмаган, гомум интересны үз интересларыннан һәр вакыт өстен куйган көрәшче-интеллигент һәм революционер — «әүлия» образы җәлеп итте. Мәсәлән, Г. Тукайның «Аң», «Татар яшьләре», «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре», «Даһига», М. Гафуриның «Ирек өчен көрәш» һәм «Хәят юлында» кебек шигырьләрен шуның җанлы үрнәкләре итеп карарга мөмкин.

Яңа революцион күтәрелеш еллары татар поэзиясендә туарга тиешле матурлыкка янәшә, параллель, ә явыз чынбарлыкка каршы куелган романтик образлар системасында тагын табигать гармониясе, эчкерсез мәхәббәт, чын дуслык, ирекле хезмәт, сабый күңеленең сафлыгы яисә лирик геройның балалык чоры турындагы мотивларны һәм башка шундыйларны күрсәтергә мөмкин. Бәйрәм һәм табигать образларын сурәтләүдә кайбер яңа тенденцияләр дә күренде.

Бәйрәм образының, беренчедән, социаль-иҗтимагый мәгънәсе ачыклана барып, югарыда әйткәнебезчә, изелгән халыкның якынлашып килгән ирекле, бәхетле көне итеп күз алдына бастырылды һәм, икенчедән, анык мәҗлес, җыен, туй, уен шикелле төрләре дә активлашты. (Мәсәлән, Г. Тукайның «Мәҗлес», С. Сүнчәләйнең «Җыен» кебек шигырьләре.)

Табигать күренешләре исә явыз чынбарлыкка каршы да, параллель дә куелды. Беренче очракта табигать гүзәллеге һәм гармониясе, 1905—1910 еллардагы кебек үк, тормыш шыксызлыгына каршы куеп сурәтләнде. Бу билге (шулай ук мәхәббәт һәм сәнгатьне илаһилаштыру билгеләре) бигрәк тә М. Гафури («Эңгер вакыты», «Түгелгән яшь», «Беренче мәхәббәт») белән М. Фәйзи («Табигать манзарасы», «Чәчәкләр җыры», «Хәйран булам», «Тәгъриф», «Матурлык кайда?») поэзиясендә көчле чагылды.

Икенче очракта табигать күренеше, әйткәнебезчә, ирке чикләнмәгән стихия рәвешендә, явыз тәкъдиргә, язмыш мәрхәмәтсезлегенә аваздаш итеп тасвирланды. Бу тенденция, Дәрдмәнд һәм аның йогынтысындагы шагыйрьләр иҗатыннан тыш, Н. Думави әсәрләрендә дә шактый сизелде. («Тормыш» һ. б.)

Беренче рус революциясе чорларында: «Егет булсаң, кабердән башка җир тап, башканы уйла!» дип, дөнья белән аяк терәп бәхәсләшкән һәм Иделгә: «Эшеңдә бул, бәреп ек һәм навозны, алып кит диңгезгә һәрбер явызны!» дип мөрәҗәгать иткән

Н. Думави яңа революцион күтәрелеш елларында кешене башлыча язмыш колы итеп күрсәтте. Чөнки реакция караңгылыгында югалткан иҗтимагый идеалын ул яңа күтәрелеш елларында да таба алмады. Идеалын югалту һәм үзен тормыш диңгезендә чайкалган йомычка хәлендә хис итә башлау аны котылгысыз рәвештә, таяну ноктасы эзләп, «күк галәме»нә, дингә килергә мәҗбүр итте. Моның чыннан да шулай икәнлеге турында «Үзгәрү» исемле шигырендә ул үзе үк язып чыкты:

**Кыскасы, чын мәгънәсе илә кайттым аллага хәзер,**
**Мин гаҗизгә күк назир [1], йолдыз назир, алла назир [2].**

Шулай да яңа революцион күтәрелеш чоры татар поэзиясендә мондый мотивлар түгел, бәлки, киресенчә, кешенең ролен зурайтып тасвирлау өстенлек итте. Г. Тукай һәм аның фикердәшләре иҗатында үзәктә «хөр кеше» образы торып, аларның көрәш байрагына да:

**Без яраткачтан ярар, дим, кем аны синнән сорар!**
**Хөр кеше алдында җирләр һәм дә күкләр калтырар! —**

дигән сүзләр язылган иде.

Моннан гади хезмәт кешесенә дан җырлау, аның намуслы һәм ирекле хезмәтен капитал коллыгына каршы куеп сурәтләү тенденциясе үсеп чыкты. Бу яктан С. Сүнчәләйнең «Ярлы җыры» дигән шигыре характерлы. Биредә, «табигать кешеләрен» шәһәр тормышына, буржуаз цивилизациягә абстракт каршы кую белән генә чикләнелмичә, ирек сөючән гади хезмәт кешесенең рухи байлыгын материаль байлыктан өстен куеп сурәтләүгә күбрәк басым ясала, лирик геройның капитал хакимлегенә буйсынмаганлыгы калкурак тасвирлана:

**Мин күрәм байлар сараен, зур нәфис бакчаларын,**
**Йөкләнеп эшкә үтәм мин, сызлана ачка карын.**
**Әмма ятсынмыйм! Минем бар хәсрәтем, бар сөенечем,**
**Бар минем иркем, туям, эшлим дә җиткәнче көчем.**
**Эшкә барганда кояш чыгышы белән ләззәт әнәм,**
**Якты көннәрдә, иректә — мин табам хезмәттә ямь [3].**

Инкарь ителә торган, ягъни явыз чынбарлыкка параллель, янәшә куеп сурәтләнгән романтик-символик образларга килик. Мондый образлар да, идеаль тормышка параллель куелган образлар кебек үк, башлыча реаль һәм фантастик төрләргә бүленәләр. Реаль төргә төрмә, читлек, караңгылык, төн, болытлы көн, көз, кыш, ә фантастик төргә «җир-сөрген», тәмуг, җәһәннәм, кыямәт һәм башка шундый образлар керә.

Билгеле булганча, төрмә һәм тоткын образлары, мәҗнүн яисә пәйгамбәр образлары кебек үк, борынгыдан килә. Ләкин прогрессив карашлы татар шагыйрьләре мондый образларның Көнчыгыштагы формаларын гына түгел, хәтта Көнбатыш яки рус шагыйрьләренең «иҗат казаны» аша үткәрелгән төрләрен дә турыдан-туры гына кабул итә алмадылар, бәлки XX йөз башындагы татар әдәбияты алдында торган бурычлар яктылыгында дәвам иттерергә һәм үстерергә тиеш булдылар. Мәсәлән, Тукайның 1907 елда Пушкиннан тәрҗемә иткән «Мәхбүс» шигырендә «тимер читлек»тәге тоткынның төрмәдәге газаплары һәм яшь каракошның «ирек иркендә» яшәү ләззәтләре (ягъни азатлыкка, яктылыкка омтылу идеалы белән караңгы чынбарлык арасындагы конфликт) көчәйтебрәк бирелгән иде.

Бу тенденцияне тагын да үстерү, яңа сыйфатларга баету ягыннан С. Сүнчәләйнең Байроннан тәрҗемә иткән «Шильон тоткыны» (1910) исемле әсәре аерым игътибарга лаек. Мәгълүм ки, Байрон поэмасында лирик геройның, озак еллар төрмәдә яту нәтиҗәсендә, төшенкелеккә бирелеп, дөньядан бизүе, бөтен нәрсәгә битараф карый башлавы һәм хәтта ирекккә чыгарылган чакта һичбер төрле шатлык кичермәве сурәтләнә. С. Сүнчәләй тәрҗемәсендә оригиналның төп идея эчтәлеге саклану белән бергә, кайбер үзенчәлекле мотивлар да кертелгән. Беренчедән, тәрҗемәдә әлеге «шат-

---

[1] Назир — баш булып, күзәтеп торучы.
[2] Нәҗип Думави. «Уйгану» һәм башка шигырьләр. Казан. 1918 ел. 17 бит.
[3] С. Сүнчәләй шигырьләре. 30 бит.

лык кичермәү» моментына күбрәк басым ясалып, аның сәбәбе дә үзенчәрәк аңлатылган булса, икенчедән, тоткынның горурлык сыйфатлары һәм тирәлеккә тискәре мөнәсәбәте калкурак итеп гәүдәләндерелгән. С. Сүнчәләй герое төрмә тышындагы «ирекле тормыш»ка ирония белән карый. Чөнки бу герой өчен төрмә эчендәге ирексез тормыш белән төрмә тышындагы «ирекле» тормыш арасында аерма юк: икесенең дә асылы — коллык. Шуңа күрә ул төрмәдән чыгарылуны бер төрмәдән икенче төрмәгә күчерелү шикелле генә хис итә.

Шул рәвешчә, Байрон поэмасында нечкә хисле, йомшак күңелле тоткынның таш күңелле кешегә әверелүе, ягъни буржуаз җәмгыятьтә шәхеснең һәм физик, һәм рухи яктан гарипләндерелүе үзәккә куелган булса, С. Сүнчәләй тәрҗемәсендә геройның социаль-иҗтимагый коллыкка тәнкыйтьле-ироник мөнәсәбәте алгарак куеп сурәтләнде. Мондый тенденция татар шагыйренең оригиналь әсәрләрендә дә урын алды.

**Тик ачылсын зинданым, салкын гүрем,**
**Тик кояш чәчсен минем гүргә нурын —**
**Чыкмамын бер дә кабахәт дөньяга —**
**Бәндәләргә чын кояш чыкмас борын!** [1]

Бу, һичшиксез, татар романтизмында явыз чынбарлыкка протест белдергән үзенчәлекле герой образларының берсе иде.

«Сөрген җир» образына мисал итеп М. Гафуриның дини легендадан файдаланып язылган «Адәм вә Иблис» исемле поэмасын күрсәтергә була. Биредә җир шары «күк галәме»ннән сөрелгән гөнаһлы бәндәләр өчен хәзерләнгән җәза урыны рәвешендә тасвирлана. Менә, мәсәлән, Иблис коткысына бирелеп, җәннәттә тыелган җимешне ашаган Адәмгә Алланың боерыгы:

**Бу җәннәткә керер-кермәс, я Адәм, зур хатаң булды,**
**Чык инде җәннәтемнән бар! Сиңа җирләр ватан булды.**
**Берегез-берегез берлән талашып гомерегез үтсен,**
**Синең балаларың җирдә шулай аз-маз яшен түксен** [2].

Шулай да яңа революцион күтәрелеш чоры татар поэзиясендә дини, фантастик образларны явыз чынбарлыкка параллель кую зур урын алмады. Мондый тенденция гадәттә романтик идеал белән реаль тормыш арасындагы мөнәсәбәтләр антагонистик характер алган чакларда активлаша.

### 3

Капитализмның бөтен вәхшәтен тагын да шәрәләндергән империалистик сугыш шагыйрьләрнең идея-эстетик карашларына тәэсир итте, аларның идеологик позицияләрен катлауландырды һәм романтизм хәрәкәтендә дә яңа төсмерләр китереп чыгарды. Бу төсмерләр яңа революцион күтәрелеш елларында куәт алган кайбер билгеләрнең пассивлашуында, яңа романтик-символик образлар формалашуда яисә элеккеләренең яңа сыйфатларга баетылуында күренде. Иң әүвәл, явызлык тантана итүенә һәм тормышның тоташ ямьсезлектән гыйбарәт булып күренә башлавына нисбәтән, бәйрәм, мәҗлес, җыен образларын чынбарлыкка параллель куеп сурәтләүнең пассивлашканлыгы сизелде: бәйрәм темасын шиксыз һәм күңелсез күренеш итеп тасвирлау алга чыкты. (Мәсәлән, М. Гафуриның «Күңелсез бәйрәм» шигыре һ. б.) Икенчедән, империалистик сугыш елларында Дәрдмәндтән килгән тенденция — котырынулы, фетнәле табигать стихиясен явыз чынбарлыкка аваздаш итеп сурәтләү активлашты. Моның сәбәбе, әлбәттә, язмыш, тәкъдир мәсьәләсенә игътибар көчәю белән дә бәйләнгән иде. Тормышта явызлыкның тантана итүе һәм шуның сәбәпләрен дөрес аңламау күп кенә шагыйрьләрне, бигрәк тә вак буржуаз карашларга якынрак торган авторларны, чыннан да, «язмыштан узмыш юк» икән дигән фикергә китерде. Поэзиядә «язмыш» төшенчәсе, символик характер алып, иң дәһшәтле, һәлакәтле һәм илаһи бер көч рәвешендә сурәтләнә башлады. Бу елларда чыккан дистәләрчә шигырь, бал-

---

[1] С. Сүнчәләй шигырьләре. 109 бит.
[2] Мәҗит Гафури. Адәм вә Иблис. Уфа. 1910 ел. 12 бит.

лада, нәсер һәм поэмаларның «язмыштан узмыш юк» дигән фикерне исбатларга тырышып язылган булулары шуны күрсәтә. Моның өчен Ф. Бурнашның 1916—17 елларда язылган һәм 1918 елда «Шәрык гөлләре» исеме белән аерым җыентык итеп басылган поэмаларын («Дулкыннар арасында», «Коркыт», «Казакъ кызы» һ. б.) искә төшерү дә җитә. «Дулкыннар арасында» исемле поэмада, мәсәлән, зур газаплар чигеп, үз бәхетен табарга омтылган егетнең ахыр чиктә көчле дулкыннар арасында югалып калуы сурәтләнә. Бу, әлбәттә, фетнәле табигать стихиясен «явыз тәкъдир»гә параллель куеп сурәтләүдән башка нәрсә түгел иде.

Безнең поэзиядә «артык кеше», «гаепсез җинаятьче», сукбай, качкын һәм теләнче шикелле образлар формалашу үзенчәлеге дә нәкъ әнә шул язмыш проблемасына игътибар көчәю белән тыгыз бәйләнгән. Европа романтизмында, мәсәлән, җинаятьче образының ике тибы барлыгы билгеле: «гаепсез җинаятьче» һәм «явыз җинаятьче». Беренчесе буржуаз чынбарлыкка каршы, ә икенчесе параллель куеп сурәтләнә. Татар поэзиясендә исә боларның һәр икесе дә үзенчәлекле рәвештә кулланылды.

Рус һәм Европа әдәбиятларында «гаепсез җинаятьче» тибына караган геройларның («артык кеше», сукбай, качкын һ. б. ш.) трагик хәлгә төшүләренә төп сәбәп итеп буржуаз җәмгыять, капиталистик тәртипләр алынган булса, татар поэзиясендә алар, беренче чиратта, язмыш корбаны буларак гәүдәләндерелде. Моңа мисал итеп Н. Исәнбәтнең «Артык кеше» шигырен, «Сукбай»[1], «Качкын»[2] исемле поэмаларын һәм Г. Шәрифинең «Теләнче»[3] дигән поэмасын китерергә мөмкин. Дөрес, Н. Исәнбәтнең әлеге әсәрләрендә капиталистик тәртипләргә билгеле бер дәрәҗәдә протест авазлары да ишетелеп китә кебек («Сукбай» һ. б.).

«Явыз җинаятьче» тибын куллану үзенчәлегенә килсәк, бу бигрәк тә дини легендалардан алынган Кабил образын сурәтләүдә сизелде. Европа романтизмында, әйтик, Байронның «Каин» исемле әсәрендә, бу образ җир һәм күк кануннарына каршы баш күтәргән горур бунтарь, титаник шәхес сыйфатында гәүдәләндерелгән булса, татар поэзиясендә ул, киресенчә, явыз җинаятьче, нахакка кан коючы рәвешендә тасвирланды. Татар шагыйрьләре Октябрь кояшы чыкканга кадәр Кабил образының аллага, дини кануннарга каршы тору кебек сыйфатына теләктәшлек белдерә алмадылар әле. Шуңа күрә бездә бу титаник геройның фәкать үз туганын үтергән, кан койган моментлары гына күпертеп сурәтләнгән булуы һич тә гаҗәп тоелмас. Әмма моңардан бу герой прогрессив, демократик сыйфатлардан бөтенләй мәхрүм иде дигән нәтиҗә чыкмый әле. Татар шагыйрьләре, Кабил образының явызлык сыйфатын калку итеп, аны җинаятьче рәвешендә сурәтләү белән, империалистик сугышка, гадел булмаган һәртөрле кан коюга кискен протест белдерергә теләделәр. Мәсәлән, С. Сүнчәләйнең «Вөҗдан күзе», «Кыйсса», Г. Харисның «Сугыш» һәм Н. Исәнбәтнең «Кабил-кан» исемле балладаларын шуның үрнәкләре итеп карарга мөмкин.

Беренче бөтен дөнья сугышы елларында татар шагыйрьләренең мәхәббәткә, сәнгатькә һәм үткән заманга мөнәсәбәтләрендә дә яңа тенденцияләр барлыкка килде. Шулардан берсе, мәсәлән, мәхәббәткә мөнәсәбәттә күренде. Кайчандыр акча хакимлегеннән өстен саналган мәхәббәт бу чорда үзе дә сатыла һәм сатып алына торган товарга әверелде. Борынгы шагыйрьләр иҗатында лирик герой үтә көчле сөюдән һәм сөелүдән мәҗнүн хәлендә калып җәфа чиккән булса, хәзер инде ул, киресенчә, сөяр кеше юклыктан газаплана. Ул сөюгә лаек кеше таба алмый: аны чолгап алган тирәлектә һәркем — вак, эгоист, акча колы! Бу герой ялгызлыкны нәфрәтли, әмма шул ук вакытта ялгыз яшәргә мәҗбүр! Аның трагизмы да шунда:

**Хәйләсез, чын, саф мәхәббәтне күңел эзләп оча,**
**Әйләнеп мәэюсь булып кайта, кунар җир тапмыйча.**

**(М. Гафури. Халәте тәэссердә. 1914.)**

Шул рәвешчә, империалистик сугыш елларында татар шагыйрьләре җирдәге мәхәббәттә раслардай нәрсә таба алмадылар. Ләкин бу гомумән кешеләр арасындагы мәхәббәтне идеаллаштырудан, аның бөеклегенә дан җырлаудан баш тарту дигән

---

[1] Н. Исәнбәт. Сайланма әсәрләр. I том, Казан, 1960 ел. 107, 220—226 битләр.
[2] «Аң» журналы. 1916 ел. 9 сан.
[3] Шунда ук, 24 сан.

сүз түгел иде әле. Энкерсез, саф мәхәббәткә иланы бер кодрәт, иҗтимагый гармония төзергә сәләтле көч итеп карау бу чорда да дәвам итте. Мәсәлән, М. Гафуриның шул ук үндүртенче елда язылган шигырьләре арасында түбәндәге юлларны очратабыз:

> **Ул мәхәббәт төрле җирдә, төрле төстә ялтырый,**
> **Ул тәҗәллә итте исә [1], таулар вә ташлар калтырый.**
> . . . . . . . . . . . . . . . . .
> **Чын мәхәббәт очраса дөньяда бер-бер бәндәгә,**
> **Һич тәрәтдетсез [2] аның алдында егылыр сәҗдәгә.**
>
> **[«Гыйлавә».]**

Мәхәббәтне идеаллаштыруда тагын ике характерлы тенденцияне әйтергә кирәк. Боларның берсе — бөтен дөньяны онытып, иланы мәхәббәт белән шашыну — акмеизмга, ә икенчесе — «шәрык кызын» үзәккә куеп идеаллаштыру — милли хисләрнең куерүына тоташкан иде. Беренче тенденциягә М. Хәнәфинең «Аң» журналында басылган «Сөю — җәллад», «Гөл бакчасында», Нәкыйнең шул ук журналда чыккан «Ай», «Мәхәббәт», «Мәхәббәт тәңресе алдында» шикелле нәсерләрен, икенче тенденциягә Н. Думавиның «Шәркыям», Н. Исәнбәтнең «Шәрык кызы» дигән шигырьләрен һәм Ф. Бурнашның 1916—17 елларда язылган «Айсылу», «Шәрык кызы» кебек поэмаларын мисал итеп китерергә мөмкин.

Милли хисләр белән сугарылган мондый әсәрләрнең күпләп мәйданга чыгуы шул ук вакытта чын матурлыкны үткән заманнардан, Урта гасыр экзотикасыннан эзләү көчәйгәнлеген дә күрсәтә иде. Милли тойгыларның һәм матурлык идеалын үткән чорлардан эзләүнең кабарып китүе үз чиратында яңадан идеаль идарәче образын мәйданга чыгарды. Тик инде ул хәзер, Колгали яисә Мөхәммәдьяр әсәрләрендәге кебек, прогрессив түгел, ә киресенчә, консерватив характер алды. Мәсәлән, Н. Думавиның «Шәрык даһие» [3] дигән поэмасында Урта гасыр ерткычы Чыңгыз-ханның идеаллаштырып тасвирлануы шуның бер күренеше иде.

Шәхси һәм иҗтимагый азатлык идеаллары белән бергә, милли азатлык идеалының алга чыгуы, үткәнне бүгенгегә каршы куюның куәт алуы тарихи темага һәм фольклорга игътибар артуына сәбәп булды. Татар шагыйрьләрен фольклорга еш мөрәҗәгать итүгә һәм тарихи легендаларны сюжет итеп алуга этәргән сәбәпләрдән тагын берсе — романтик хәрәкәтнең тизләтелеше, иҗтимагый-идеологик шартларның романтизм үсешен көчәйтә торган характерда булуы; икенчесе — халык иҗатының героик характерларга, романтик элементларга гаять байлыгы. Мәгълүм ки, А. М. Горький совет язучыларының Беренче бөтен Союз съездында сөйләгән докладында риваять һәм мифларның нигезендә романтизм ята дигән иде.

## 4

Җир һәм күк «галәмнәре»нә мөнәсәбәттә үзенчәлекле эволюция кичергән шагыйрьләр арасында С. Рәмиев поэзиясе күренекле урын алып тора. Мәгълүм ки, С. Рәмиев — беренчеләрдән булып татар поэзиясенә байронизм мотивларын, бунт күтәргән шәхес образын алып кергән шагыйрь. Аның лирик герое баштарак берникди дә чикләүләрне танымаучы, җир һәм күк кануннарын тоташ кире кагучы демоник шәхес сыйфатында чыкты («Мин» h. б.). Әмма революцияне шәхес иреге ноктасыннан гына торып аңлаганлыктан, С. Рәмиев герое тарихи оптимизм югарылыгына күтәрелә алмады. Реакция чорыннан башлап бу горур герой, «җир галәмен» тулаем кире кагуын дәвам итү белән бергә, «күк галәме» алдында ташламалар ясауга, аның белән килешүгә таба барды. Шагыйрьнең элек абсолют бәйсезлеккә омтылган һәм үзен хәтта алладан да югары санаган «мин»е белән алла арасына тигезлек билгесе куела башлады:

---

[1] Тәҗәллә итте исә — мәйданга чыкса, барлыгын күрсәтсә.
[2] Тәрәтдетсез — икеләнмичә, шикләнмичә.
[3] «Аң» журналы. 1915 ел. 7—8 саннар.

**Кем ул андый, сәгыйд[1] иткән**
**Мине һәм урынымы, белмим.**
**Беләм тик: бу җаным аннан**
**Яратылган, мин — ул, ул — мин[2].**

Ә империалистик сугыш елларында инде шагыйрь, «җир галәме»нә тагын да ярсыбрак һөҗүм иткән хәлдә, «күк галәме» алдында җиңелүен танырга мәҗбүр булды:

**Илаһым, әл мине! Талдым,**
**Юлыңда берүзем калдым;**
**Куям кылычым кире кынга...**
**Газаплый тик сиңа антым...[3]**

Менә шунда инде аның трагизмы да ята иде... Әмма моңа карап, без һич тә бу титаник шәхес явызлык каршында тез чүкте дияргә теләмибез. Ул, таяну ноктасы эзләп, «күк галәме»нә барырга мәҗбүр булса да, «җир галәме»ндәге явыз кануннарга буйсынмый, үзенең горурлык сыйфатларын югалтмый. («Күрәм гали»... һ. б.)

Гомумән, лирик геройның нинди генә хәлдә дә явыз чынбарлык белән килешмәве — унынчы еллар татар поэзиясенең мөһим бер үзенчәлеге ул. Мондый сыйфаттан хәтта Н. Думавиның аллага ышанучы геройлары да азат түгел иде:

**Син беләмсең синдә күпме көч барын, куәт барын!**
**Тип очыр бу дөньяның барлык кара куәтләрен!**
**Син — бөек! Салган ходай күктән сиңа үз орлыгын!**
**Бул гали! Таптатма, зинһар, шул «ходайлык» зурлыгын![4]**

Шул рәвешле, аерым шагыйрьләрнең империалистик сугыш чоры поэзиясендә шәхеснең роле «күк галәме»нә мөнәсәбәттә кечерәйтеп, ә «җир галәме»ндәге кара көчләргә мөнәсәбәттә, киресенчә, зурайтып тасвирланды. Шуңа күрә унынчы еллар татар поэзиясендәге шәхес-җәмгыять каршылыкларының әдәбият белемендә билгеләп кителгән төрләр белән генә чикләнмәве аңлашыла.

Мәгълүм булганча, әдәбият белемендә романтик герой белән явыз чынбарлык арасындагы каршылык гадәттә өч төргә бүлеп карала. Беренче каршылык геройның үз идеалларына турылыклы булып калуы сәбәпле, я физик, я рухи яктан һәлак булуы белән хәл ителә. Икенчесе геройның үз идеалын тормышка ашыру өчен актив көрәш алып баруы, халык көрәшенә кушылу юлларын эзләве һәм, ниһаять, шуңа ирешүе белән чишелә. Өченчесе исә геройның, хыял-идеаллардан ваз кичәргә һәм явыз тирәлек белән килешергә мәҗбүр булып, вак җанлы, эгоистик шәхескә әверелүе рәвешендә гәүдәләнә.

Шәхес һәм җәмгыять арасындагы конфликт чишелешенең әлеге төрләре XX йөз башы татар романтизмында да чагылыш алды, әлбәттә. Ләкин өченче төр, ягъни геройның явыз, эгоистик тирәлеккә яраклашуы, әйткәнебезчә, унынчы еллар татар поэзиясендәге романтизмда чагыштырмача азрак иде. Беришe татар шагыйрьләренең романтик геройлары, явыз чынбарлык белән килешүгә караганда, «җир галәме»н бөтенләй «ташлап», «күк галәме»нә сыенуны яисә үлемне артыграк күрделәр.

Явыз чынбарлыкка каршы куярдай матурлыкны эзләп, романтиклар, мәгълүм булганча, сәнгать өлкәсенә дә еш мөрәҗәгать иттеләр. XX йөз башы татар романтизмында исә сәнгатькә (бигрәк тә поэзиягә һәм музыкага) мөнәсәбәтнең рус һәм Европа романтизмнарында чагылган барлык төрләре дә диярлек урын алды. Биредә без, бу төрләрнең һәммәсенә дә тукталып тормастан, шушы мәсьәләгә кагылышлы кайбер үзенчәлекләрне генә искә алып үтәргә телибез.

Унынчы еллар татар поэзиясендә сәнгать культының куәт алуы, әлбәттә, барыннан да элек, эмоцияләр һәм милли хисләр көчәюгә бәйләнгән иде. Моның шулай икәнлеге бу чор татар поэзиясендә музыканы илаһилаштыруга игътибарның аеруча кө-

---

[1] Сәгыйд — бәхетле.
[2] С. Рәмиев шигырьләре. Казан. 1909 ел. 24 бит,
[3] С. Рәмиев шигырьләре. Уфа. 1918 ел. 44 бит.
[4] «Аң» журналы. 1916 ел. 11—12 саннар, 183 бит.

чаюе, музыка коралларына дан җырлауның активлашып китүе белән дә раслана. Мәсәлән, Ш. Бабич шигырьләрендә түбәндәге юллар белән очрашабыз:

**И сихерле, серле, илһамлы, гаҗәеп мандолин!..**
**Әйдә сыздыр, әйдә өздер, сафланыйм, иманланыйм!**

**(«Мандолин». 1914.)**

**Син генә иң нечкә хисләр, нечкә моңнар чишмәсе,**
**Син тавышлар казнасы һәм син үеннар патшасы.**

**(«Скрипка». 1915.)**

Шул рәвешчә, Ш. Бабич поэзиясендә музыка кеше рухын сафландыра торган илаһи бер көч, барлык «тавышлар», «моңнар» һәм «уеннар патшасы» итеп тасвирланды.

М. Фәйзинең «Көзге моңнар», Ф. Ибраһимовның «Гармун тавышы» һәм Н. Исәнбәтнең «Сазым кыллары» дигән әсәрләре турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

Икенче яктан, сәнгать культы, мәхәббәтне, табигатьне һәм үткәнне идеаллаштыру кебек үк, милли хисләр белән дә тыгыз бәйләнештә күренде. Милли тойгыларның көчәюе поэзиядә милли көй, милли культура, милли әдәбият төшенчәләрен идеаллаштыруга этәрми кала алмады. (Мәсәлән, С. Сүнчәләйнең «Уенчылар мәҗлесендә» исемле әсәре һ. б. ш.)

Шулай итеп, Европа романтизмындагы төп билге-элементларның күпчелеге урын алуы һәм аларның яңа сыйфатларга баетылуы, милли хисләр белән сугарылып бирелүе татар романтизмының стихияле әдәби агым хәленнән иҗат методы дәрәҗәсенә үсеп җиткәнлеген күрсәтте. Бу исә гомумән XX йөз башы татар поэзиясендә кешенең эчке дөньясына игътибар көчәюе, лирик психологизмның тирәнәюе дигән сүз иде.

Унҗиденче елда башланган революцион тетрәүләр татар романтизмында да тирән үзгәрешләр барлыкка китерде. Октябрь революциясе җиңгәннән соң романтизмның реаль тормыш матурлыгына, революцион хәрәкәткә авазлаш итеп сурәтләнә торган образлары (җил, давыл, дулкын, яз, таң, кояш, бәйрәм һ. б. ш.) алга чыкты, яңа сыйфатларга баетылды. Революцион сыйнфый көрәш идеяләре белән сугарылган һәм халыкның явызлыкны җиңүен раслаган романтизм чәчәк атты.

## Лев Юдкевич

# ТАТАРСТАНДА ЯШӘҮЧЕ РУС ЯЗУЧЫЛАРЫ ИҖАТЫ

Соңгы елларда Татарстанда яшәүче рус язучылары безнең чынбарлыкның төрле якларын, совет кешеләренең бай рухи дөньясын чагылдырган байтак яңа әсәрләр иҗат иттеләр. Ул әсәрләрнең күбесе — тормыштагы реаль вакыйгаларга нигезләнеп язылган документаль повестьлар һәм хикәяләр. Сүзне М. Скороходовның «Шелья»да сәяхәт» исемле повестеннан башлап китәсе килә. Әсәр рус әдәбиятында күптән формалашкан сәяхәтнамәләр жанрында, шул жанрның иң яхшы традицияләре рухында язылган.

Михаил Скороходов — борынгы поморлар юлы белән легендар Мангазея хәрабәләренә сәяхәттә катнашкан кеше. Укучылар хәтерлидер, үз вакытында матбугат бу хакта күп язды. Язучының яңа повесте шул сәяхәт нәтиҗәсендә туган әсәр. Автор безне сәяхәт барышында очраган кешеләр, аларның тормышы белән таныштыра; юл язмаларында сәяхәтченең шәхси күзәтүләре, уй-хисләре, башыннан үткән хәлләре тасвирлана. Повесть нигезда вакыйгаларның табигый агышы буенча үсеп бара. Ләкин әсәрнең кысалары сәяхәт маршруты белән генә чикләнми. Төньяк халыкларының тормыш-көнкүреше белән таныштырудан, алар турындагы шәхси тәэсирләре белән уртаклашудан тыш, автор төрле чыганаклардан эзләп тапкан фәнни мәгълүматларны файдалана, сәнгатьчә тасвир лирик чигенешләр, реаль вакыйгалар язучының публицистик фикерләре белән чиратлашып бара. Болар повестьның кысаларын, иҗтимагый яңгырашын киңәйтеп җибәрә: бүгенге вакыйгаларда үткән көннәр шәүләсе, аерым кешеләр язмышында бөтен бер халык язмышы чагыла.

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, М. Скороходов Архангельскидан алып Мангазея хәрабәләренә кадәр булган юлда үзе күргән бөтен нәрсәләр турында яза һәм, әйтергә кирәк, белеп яза. Ләкин бу якларга ул коры экзотика эзләп килмәгән. Аны, беренче чиратта, совет власте елларында төньяк халыклары тормышында барлыкка килгән зур үзгәрешләр кызыксындыра. М. Скороходов капитализм чорында үлемгә хөкем ителгән ненец халкының яңадан аякка басуын, социалистик җәмгыять шартларында ирешкән зур казанышларын конкрет мисаллар, аерым кешеләр язмышы аша ышандырырлык итеп күрсәтә.

Шул ук вакытта язучы, аерым бер җылылык белән, үзе туып-үскән якларны исенә төшерә. Грозный шәһәрендә яшәүче Лагейскийга Җиде башлы сопка итәгендәге җирләр ничек якын булса, аңа да үзенең яшьлек еллары узган Чистай шәһәре шул кадәр үк кадерле һәм якын. Озак еллар читтә йөреп, тундрага кунакка кайткан ненец белән сөйләшеп утырганда, автор «үз йөрәгенә коючы бердәнбер елга» Каманы, «куе әрәмәлекләр уртасындагы тонбоеклы күлләрне, яшеллеккә күмелгән туган шәһәрен, Мангазея кебек ерак Чистайны» сагынып искә ала. Әмма барлык нәрсәләрдән дә бигрәк, язучыны легендар Мангазея хәрабәләре, аның тарихы, андагы казу эшләре кызыксындыра.

«Шелья»да сәяхәт» повесте үзенең җыйнаклыгы, эмоциональ тәэсир көченең зурлыгы белән аерылып тора. Андагы һәр деталь, һәр фраза әсәрнең төп фикерен, гомуми идея юнәлешен һәм пафосын ачуга буйсындырылган. Тундра табигатен һәм анда яшәүче кешеләр тормышын сурәтләүгә багышланган бүлекләрнең берсендә әсәрнең гомуми рухын чагылдырырлык мөнә мондый табигать күренеше

китерелә: «Кызыл малица[1] кебек балкып, үзенең алтын чатырыннан кояш килеп чыкты һәм Объ култыгына иелде». Бу жыйнак рәсем шагыйрьләргә хас осталык белән ясалган.

«Шельяда сәяхәт» — төрле жанрларда эшләүче авторның бәхәссез уңышы. Әсәрне укыганда без үзебез дә язучының юлдашларына әйләнеп китәбез, сәяхәтчеләр белән бергә шатланабыз, алар белән бергә кайгырабыз. Кыскасы, повесть тормышны танып-белү ягыннан да, әдәби-эстетик яктан да зур әһәмияткә ия.

* * *

Ян Винецкий белән Юрий Белостоцкий хикәя-повестьларында һәм Николай Беляев шигырьләрендә документальлек бөтенләй башкача чагыла.

Казан — Ленинның яшьлек шәһәре. Кокушкино — аның беренче сөрген урыны. Безнең шәһәрдә А. С. Пушкин була. Казанда бөек пролетариат язучысы М. Горький яши. Татарстан күп кенә тарихи кешеләре, уллары һәм кызларының зур эшләре белән дан тота. Язучыларыбызның бөтен республикага һәм бөтен илгә мәгълүм шул кешеләрнең әдәби образларын иҗат итәргә алынулары — бик табигый һәм законлы күренеш. Бу яктан бигрәк тә Я. Винецкийның иҗат эшчәнлеге игътибарга лаек. Ул юлбашчыбыз В. И. Ленинның, шулай ук А. С. Пушкин, М. Горький кебек әдипләрнең Казан чорын сурәтләүгә багышланган әйбәт кенә әсәрләр бирде. Аның әсәрләрендә әлеге бөек шәхесләрнең тормыш юлына бәйле аеруча мөһим эпизодлар җанландырыла, ул үз әсәрләрен кирәкмәгән вак детальләр белән чуарламый, юк-бар фараз кылулар белән мавыкмый. Язучы әсәрләренең ышандыру көче шуннан килә.

Я. Винецкий тарихи шәхесләрне һәр вакыт диярлек гади халык арасына куеп сурәтли һәм хезмәт иясе массаларының аларга булган тирән мәхәббәтен күрсәтә. Әнә шулай В. И. Ленин турындагы әсәрләр тукымасына крестьян кызы Ксюша («Истоки»), бала чакта ук юлбашчыга хат язган авыл активисты Тихон Курков («Течет река Волга») образлары килеп керә. Йөк бушатучы Сафа («Баллада о блаженном») һәм ярлы кызы Марютка («Пушкин и Марютка») образлары да игътибарны җәлеп итәләр.

[1] Малица — төньяк халыклары кия торган эче-тышы мех кием.

Тарихи шәхесләр биографиясеннән алынган конкрет фактларга һәм алар әйтеп калдырган сүзләргә таянып, язучы үз геройларын тормышның төрле ситуацияләрендә күрсәтә, үзен кырыс сюжет кысалары белән чикләмичә, ирекле хикәяләү алымына таянып эш итә. Авторның нияте изге: ул геройлары турында мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат бирергә, аларга төрле яклап характеристика бирергә тели. Әмма авторның бу изге теләге еш кына прозаның, бигрәк тә кече формадагы прозаның, сюжет кысалары белән каршылыкка керә, мондый очракларда язучы кайбер вакыйгаларны һәм тормыш күренешләрен өстән-өстән санап чыгу белән чикләнергә мәҗбүр була. Әйтик, «Пушкин һәм Марютка» исемле әсәрендә язучы, шагыйрьнең почта начальнигы белән очрашуын сурәтләгән гаҗәеп матур күренештән соң, ашыгып кына «Мин хәтерлим гүзәл бер мизгелне» дигән шигырьнең язылу тарихын телгә алып уза. Ә бит бу — болай ашыгып, аяк өсте генә әйтеп уза торган факт түгел.

Сәнгатьчә тасвирны ничек, ни рәвешле сөйләп бару белән чиратлаштыру шактый четерекле мәсьәлә. Билгеле булганча, ул әсәрнең жанры һәм композициясе белән дә, шулай ук авторның әсәрдәге төп мәсьәләләргә игътибар юнәлтә белүе белән дә бәйләнгән. Әдәби әсәрне ныклы бер эзгә сала торган чараларның иң әһәмиятлесе — сюжет. Ирекле хикәяләү стиле уңышлы сюжет алымы табуны сорый, шулай булмаганда, бу стиль автордан үч алучан була.

Я. Винецкий җыентыгында «Идел ага» дигән бер хикәя бар. Алда бер әйтелгәнчә, сүз анда унөч яшьлек малай чагында ук В. И. Ленинга хат язган Тихон Курков турында бара. Бу факт күп кенә әдәби әсәрләрдә яктыртылды. Шуңа күрә, табигый, Я. Винецкий хикәясен шулар янына янәшә куеп, шулар белән чагыштырып карыйсы килә. Моннан берничә ел элек рус һәм татар телләрендә басылып чыккан «Мы из Казани, с Волги...» (татарчасы — «И кадерле туган як») исемле китапларында Г. Ахунов белән М. Зарипов та Курков образына мөрәҗәгать иткәннәр иде. Һәр ике әсәрнең үзәгеннән: Тихон Курков яшьлегендә В. И. Ленинга биргән вәгъдәсенә турылыклы булып кала, дигән фикер сузыла. Ике әсәрнең дә анык билгеләнгән сюжеты юк дияргә була. Әмма төп фикер һәр әсәрдә үзенчә ачыла.

Г. Ахунов белән М. Зарипов геройның портретын бер көн эчендә булып узган вакыйгалар фонында ачалар. Әмма ул вакыйгалар бик оста сайланганнар. Очерк ифрат җыйнак һәм төзек чыккан, бер көн эчендә булып узган вакыйгаларга нигезләнеп язылган әсәрдә узган тормыш та, бүгенге көннәр дә, киләчәк тә күз алдына баса.

Я. Винецкий Тихон Курковның (балалык елларыннан алып картлык көннәренә кадәрге) озын тормыш юлына караган аерым эпизодларны сурәтли. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, геройның гыйбрәтле вакыйгаларга бай бөтен тормыш юлын хикәя жанры кысаларына сыйдырып бетерү бик кыен эш. Шуңа күрә дә, әсәр таркау чыккан, аңа композицион төзеклек һәм бөтенлек җитми. Сүз уңаеннан шул кадәрлесен дә билгеләп үтәсе килә, әгәр Г. Ахунов белән М. Зарипов китабындагы кайбер очерклар новеллага тартым булса, Я. Винецкий хикәяләре очеркларга якынрак тора.

Я. Винецкийның иҗат тәҗрибәсе шуны күрсәтә: сюжет-композиция төзеклегенә ирешкән очракларда аның әсәрләре бөтен һәм камил чыга, табигый, андый әсәрләрнең тәэсир көче дә зуррак була. «Ишет мине, Мария!» — шундый әсәрләрнең берсе. Монда батырлык турындагы сүз үзе дә, романтик стильгә хас булганча, киеренке һәм сабыр тонда бара. Башка әсәрләрендә еш очрый торган купшылык һәм төчелек тә кими төшкән.

Я. Винецкий үз әсәрләрендә еш кына тасвирчылык шаукымына бирелеп китә. Ә бит тормыштагы реаль шәхесләргә һәм реаль вакыйгаларга нигезләнеп язылган әсәрләрдә дә фактларны сайлап ала белү, аларны төркемли һәм, мәгълүм бер проблема яктылыгыннан карап, сәнгатьчә аңлата белү сорала.

* * *

Безнең язучылар игътибарын, беренче чиратта, совет кешеләренең югары мораль сыйфатларын чагылдыра торган вакыйга һәм фактлар үзенә тарта. Тормыш үзе нәкъ менә шундый әсәрләр өчен бай материал бирә.

Татарстанда яшәүче рус язучыларының соңгы бер-ике ел эчендә дөнья күргән әсәрләрендә батырлык темасы күбрәк Бөек Ватан сугышы вакыйгалары мисалында сурәтләнә. Шул елларның бөтен авырлыгын үз җилкәләрендә кичергән язучылар өчен бу табигый күренеш. Татарстан китап нәшрияты Тихон Журавлевның «Хәрби повестьлар»ын бастырып чыгарды, алар арасында «Ут сызыгы», «Комбат» кебек укучыларга яхшы таныш әсәрләр бар. Ю. Белостоцкийның «Небо хранит тайну» повесте, Я. Винецкийның «Зори девичьи» повесте һәм «По ту сторону» дигән хикәясе совет очучыларының батырлыгына багышланган әсәр.

Совет әдәбиятында халкыбызның сугыш кырларында һәм тылда күрсәткән батырлыгы хакында күп язылды. Бик табигый хәл, чөнки бу — иксез-чиксез тема. Каләм осталары аңа кабат-кабат мөрәҗәгать итәләр, ул еллардагы вакыйгаларны бүгенге карашлардан чыгып, төрле аспектлардан карап яктырталар.

Я. Винецкий да, Ю. Белостоцкий да — элекке очучылар. Шуңа күрә аларны күбрәк хәрби очучылар тормышы кызыксындыра. Бу — алар иҗатының уртак ягы. Шуның белән бергә, алар язган әсәрләр бер-берләреннән нык кына аерылалар да. Я. Винецкийны гадәттән тыш вакыйгалар, романтик шәхесләр рухландыра. Аның палитрасында ачык буяулар, күпчелек очракта, ак һәм кара төсләр өстенлек итә.

Ю. Белостоцкий әсәрләренең төсләр палитрасы шактый катлаулы, ул ярым тоннарны да яратып куллана. «Небо хранит тайну» повестенең авторына сугышның фаҗигале күренешләре якынрак. Шул ук вакытта тормышның нәкъ үзендәге кебек үк, фаҗигале хәлләр көлке ситуацияләр белән чиратлашып килә, бу аңа чынбарлык күренешләрен бөтен катлаулылыгы һәм тирәнлеге белән тасвирларга, пластик образлар иҗат итәргә булыша. Автор хисләр диалектикасын сурәтләүгә нык игътибар итә.

Үз әсәрләрендә Ю. Белостоцкий төрле пландагы күп кенә югалтулар хакында сөйли, еш кына сүзне иң фаҗигале урыннарда өзеп калдырырга ярата. Без тикшерә торган повестьта яраткан геройларыбыздан штурман Бурноволоков һәлак була. Аның үлеме командирлары Доронин вөҗданында торып кала. Һавада булган серле фаҗига турында очучы Тамбовцев кына нәрсәдер белгән булырга тиеш, ләкин ул шик-шөбһәләрен сөйләргә өлгерми, икенче сугышта ук үзе һәлак була. Бурноволоковның ничек үлүе күк саклый торган сер булып кала... Ләкин яшерен нәрсәләр бер

ачылырга тиеш — повестьның бөтен пафосы шул фикерне куәтли.

Әгәр автор кеше характерларының ничек ачылуын күрсәтү белән генә чикләнмичә, аларның нинди шартларда формалашуын сурәтләүгә, социальлек сыйфатларын аныграк билгеләргә күбрәк игътибар иткән булса, әсәр тагын да зуррак яңгырәш алган булыр иде.

Ю. Белостоцкийның иң яхшы әсәрләре фикер тыгызлыгы, композицион яктан төгәлләнгән булулары һәм сәнгатьчә камиллекләре белән аерылып торалар. Авторның «Утлы өермә» («Огненная метель») исемле повесте да кызыксыну белән, яратып укыла. Бу әсәрендә язучы, реаль фактларга һәм архив материалларына таянып, партизаннарның эш һәм уйларын, сугышчан батырлыкларын сурәтли, геройларча һәлак булган батыр якташыбыз Борис Пахомовның җанлы образын иҗат итә. Киеренке сюжетка корылган «Батырлык» («Отвага») исемле хикәя дә совет очучысының ышандырырлык һәм тормышчан образы белән таныштыра.

Чын сәнгать әсәренең мәгънәсе аның идея эчтәлегеннән киңрәк була. Очучы Рапохинның искиткеч саф һәм фаҗигале мәхәббәтен сурәтләүгә багышланган «Кыска шырпы» («Короткая спичка») исемле хикәя — шуның бер мисалы. Әсәрдә романтик мәхәббәт хисләре җыйнак һәм ышандырырлык итеп бирелә. Хикәянең хәтта икенче-өченче дәрәҗәдәге персонажлары да җанлы кешеләр булып хәтердә кала.

...Юрий Белостоцкийның үзәк һәм җирле матбугат битләрендә уңай бәя алган бу китабы язучының зур иҗат мөмкинлекләре хакында сөйли.

* * *

Поэзиядә совет кешеләренең эчке дөньясы тулырак һәм киңрәк чагылган саен, шагыйрьләребез иҗаты зуррак яңгыраш ала бара. Шигырьләрдә чагылган тормыш күренешләре, хис һәм кичерешләр авторларның халык уйларына, халык теләкләренә якынлык һәм фикер дәрәҗәсен дә, алар язган әсәрләрнең сәнгатьчә кыйммәтен дә билгели. Ләкин тормыш турында һәр шагыйрь үзенчә сөйли, шигъри сүзнең көче дә шунда. Һәр шагыйрьнең үз позициясе, үз күрү ноктасы һәм үз бурычы була. В. Синев сугыш елларында формалашкан гражданлык позицияләренә һаман да турылыклы булып килә. 1972 елда Татарстан китап нәшрияты шагыйрьнең «Следы за рекой» исемле җыентыгын чыгарды. Җыентыкка авторның төрле елларда язылган иң яхшы әсәрләре тупланган.

В. Синев шигырьләрендә иҗат бәхете һәм югалтулар авырлыгы, сугышчан традицияләрнең яшәү көче һәм совет кешеләренең патриотик хисләре турында сүз бара. Әмма, ул нәрсә хакында гына язмасын, узакта — үткән сугыш, аның йөрәген яралаган, аңа тормышның кадерен аңларга өйрәткән рәхимсез сугыш. В. Синев шигырьләренең гражданлык пафосы шагыйрьнең явызлык һәм яхшылык турында чын гуманизм позицияләреннән торып фикер йөртүендә чагыла. Шагыйрьнең эстетик кредосын чагылдыра торган шигырьләренең берсендә, узган сугыш темасына мөнәсәбәтен белдереп, автор болай ди:

> Тереләр үлгәннәрнең күзен яба,
> Үлгәннәр тереләрнең күзен ача!
> (Сүзгә-сүз тәрҗемә.)

И. Кәлимуллинның «Море синее, пой!» исемле китабы да безнең игътибарны көчле гражданлык хисләре белән үзенә тарта.

Габдулла Тукай һәйкәленә карап торган тәрәзәләр аша шагыйрь зур тормышка күз сала. Ул үзен борчыган күп нәрсәләр, беренче чиратта, кыен чакларда ярдәм кулы сузган дуслары турында яза. Сезнең иңнәргә тотынып, бәхет үрләренә күтәреләм, ди ул бер әсәрендә. Дуслыкны ул зур бәхет дип саный. Чынбарлык күренешләренә сизгер шагыйрьнең иҗат диапазоны шактый киң, кичерешләр даирәсе бик бай. Аның шигъри хыял дөньясы чынбарлыкның үзеннән көч ала. Тормышны ул барлык төсләре, барлык яклары белән ярата.

Җыентыклары буенча фикер йөрткәндә, Николай Беляев ифрат үзенчәлекле һәм оригиналь шагыйрь булып формалашып килә. Ул гадәти нәрсәләрнең гадәттән тыш якларын, гадәттән тыш күренешләрнең гадәти якларын тотып ала белә. Иң яхшы шигырьләрендә тормыш матурлыгын җырлый, кимчелекләр өчен борчыла. Бу яктан аның «Нарат» исемле шигыре аеруча характерлы. Шартлы алымнар ярдәмендә, шагыйрь хатыннар кер баулары бәйләп, кысып бетергән наратка тар ишек алдыннан иркен, киң дөньяга күчеп китәргә киңәш итә.

Авторның шигъри ачышлары күп. Әнисенә багышланган шигыре лирик җылылыгы белән аерылып тора. «Герцен» исемле шигыре гражданлык пафосының зур-

лыгы белән игътибарны җәлеп итә. Башка китапларыннан аермалы буларак, «Юллар чаты» исемле яңа җыентыкта мәхәббәт шигырьләренә дә күп урын бирелгән, аларның иң яхшыларына җылы лиризм, хисләр тирәнлеге хас. «Не знаю — дано ли в изменчивом слове...» дип башланган шигырь — шундый әсәрләрнең берсе. Мәхәббәт кебек мәңгелек теманы автор яңача, үзенчә ача алган.

Н. Беляев шигырьләре үткен фикерле, шагыйрь күңеле кебек үк тиз җәрәхәтләнүчән булулары белән аерылып торалар. Ләкин шагыйрь әдәби зәвык һәм чама хисен югалтып җибәргән очракларда, авторның оригинальлеккә омтылуы да, дөньяны бөтен катлаулы яклары белән сурәтләргә тырышуы да теләгән нәтиҗәләрне бирми. Пародия язучыларга табыш булырлык аерым фразаларга тукталып тормыйбыз. Безне башка нәрсәләр күбрәк борчый.

Безнең уебызча, шагыйрьне ике төрле куркыныч сагалый. Геологны адаштырган ватык компас кебек, аны шулар адаштыра. Аларның һәр икесе артык оригиналь булып күренергә тырышудан килеп чыга. Бер яктан, бу аны литературщинага өстери, икенчедән, мәгънә бозуга китерә. «Представьте альбом семейный» дигән шигырьдә, мәсәлән, ясалма каршылыклар белән мавыгу ясалма идеяләргә алып килә. Бик үк төгәл һәм анык булмаган чагыштырулар авторның «Ветер», «Отчего-то припомнилась Саратовская толкучка» һәм кайбер башка шигырьләрендә дә очрый.

Без Н. Беляевның иҗат көченә, үз әсәрләрендәге кимчелекләрдән арына алачагына нык ышанабыз, шуңа күрә аның иҗатының кимчелекле якларына күбрәк тукталдык.

* * *

Бу мәкаләдә без соңгы елларда басылып чыккан барлык китапларга да тулы күзәтү ясый алмадык. Г. Паушкин, Р. Кутуй, М. Зарипов, П. Смольников кебек язучыларның яңа китапларын әдәби җәмәгатьчелек җылы каршылады. Мәктәп укучыларына адресланган китаплар турында да киңрәк сөйләргә мөмкин булыр иде. Мин өлкән язучыларыбыздан С. Радзиевскаяның «Сайланма әсәрләре»н һәм В. Байдеринның «Леська» исемле китабын күздә тотам. Бу китапларның беренчесенә яшь укучыларга электән таныш өч повесть («Болотные Робинзоны», «Рау и Гау» һәм «Остров мужества») һәм овчарка эт турындагы «Джумбо» исемле хикәя кергән. Табигатькә, андагы кошлар, җәнлекләр дөньясына гашыйк В. Байдерин да үзен сәләтле хикәяче итеп танытты. М. Горький музее каршындагы әдәби берләшмә членнарының чираттагы җыентыгы чыкты. Аңа, яшьләр язган хикәяләрдән, шигырьләрдән тыш, әдәби тәнкыйть мәкаләләре дә кергән. Сүз дә юк, мондый җыентыкларның басылып чыгуы һәртөрле хуплауга, ә андагы әсәрләр җентекләп бәяләнергә лаек.

Каләмдәш татар язучыларының әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү буенча башкарылган эшләрне дә уңай яктан телгә алып узарга кирәк. Бу өлкәдә бигрәк тә Н. Беляев нәтиҗәле эшләп килә. Тәрҗемә эшен тагын да җанландыра һәм активлаштыра төшәсе бар. Бу татар әдәбиятын киң массаларга җиткерү ягыннан гына түгел, тәрҗемәчеләрнең үзләре өчен дә файдалы эш булыр иде.

Күзәтүләрдән чыгып, гомуми характердагы кайбер нәтиҗәләр ясарга мөмкин. Сүз дә юк, Татарстанда яшәүче рус язучылары иҗаты нигездә уңышлы үсеп килә. Алар бүгенге чынбарлыкны, совет халкының бүгенге тормышын дөрес чагылдырырлык байтак әсәрләр иҗат иттеләр. Ләкин алар игътибарыннан тормышның күп яклары, бигрәк тә бүгенге көн вакыйгалары һаман читтә калып килә. Рус язучылары Әлмәт нефтьчеләре, КамАЗ төзүчеләре, Түбән Кама химиклары алдында зур бурычлы. Промышленность һәм авыл хуҗалыгы эшчеләре, галимнәр, барлык интеллигенция вәкилләре тарафыннан көн дә башкарылып килгән зур эшләр иҗат өчен бай материал бирә, сәнгать әсәрләрендә үзенең лаеклы гәүдәләнешен көтә. Әйтик, Кама автомобиль комплексын төзүче коллективлар тормышында художник бүгенге тормышның төрле характерлы якларын, өлгергән проблемаларын күрсәтү өчен дә, заманның уңай образын иҗат итү өчен дә ифрат бай материал таба ала.

«Кара алтын» чыгаручылар, автогигант төзүчеләр турындагы беренче әсәрләр, табигый, очерк жанрында язылды. Аларның авторлары журналистлар һәм язучылар иде. Очерк жанры киләчәктә дә әдәбиятның алгы сафында барырга тиеш.

Киләчәктә яңа бишьеллыкның зур төзелешләренә багышланган яңа әсәрләр языла. Ул әсәрләр арасында Татарстанда яшәүче рус язучыларының китаплары да булыр дип ышанасы килә. Халык бездән үзе башкарган зур эшләргә лаек яңа әсәрләр көтә.

Тәлгат Галиуллин

# БУЫННАР һӘМ ЯЗМЫШЛАР

*Хәзерге татар поэзиясе турында уйланулар*

Еллар, дистә еллар узар. Бүген чыгып килгән газета-журналларның битләре саргаеп бетәр, шигырь китаплары библиографик байлыкка әйләнер. Ул вакытта безнең көннәр поэзиясе турында да: «Фәлән чор шигърияте», «фәлән әдипләр поэзиясе» дип телгә алырлар. Туар көннәр укучысы бүгенге шигырь китаплары буенча безнең «чорның олы адымнарын», «көчле җилләрен» тояр, Татарстанның эре индустриаль үзәк булып үсү дәвере белән танышыр. Ул чагында бүгенге әдәбиятыбызга бәя дә, бәлки башкачарак булыр, хәзер безгә әһәмиятсез күренгән тенденцияләр алгы нәүбәткәрәк чыгар яисә, киресенчә, безне дулкынландырган әсәрләрнең эстетик кыйммәтләре күпмедер дәрәҗәдә искерә, кими төшәр. Вакытны иң олы һәм иң гадел хаким диләр.

Әмма ни генә булмасын, хәзерге поэзия алдына куела килгән югары таләпләрнең күбесе киләчәктә дә үз кыйммәтен җуймас дип ышанасы килә. Безнең чор шигъриятенең төп бәясен һәм асылын ил, халык язмышына якынлык, заман идеалларына турылык, революцион гуманизм һәм сәнгатьчә нәфислек кебек сыйфатлар билгели. Совет шагыйре, дәвернең фәлсәфи һәм әхлакый эчтәлегенә тирән үтеп кереп, алдынгы тенденцияләрне аларга бәрабәр форма, шигъри калып һәм шәхеснең мең төрле катлаулы кичерешләре аша укучыга җиткерергә омтыла. Шул сыйфатларга ия булган шигъри әсәрләр, гасырлар, еллар сынавын үтеп, безнең чорга килеп җиткән һәм гомум интернациональ байлыкка кушылган милли хәзинәбез шикелле, туачак еллар укучысын да уйландырыр һәм рухландырыр, дип ышанасы килә. Бүгенгенең һәм киләчәкнең диалектик бердәмлеге шунда.

Чор сулышы һәм кеше хисләре соңгы еллар татар поэзиясендә нинди көч һәм сәнгатьчә тулылык белән гәүдәләнде? Татар поэзиясенең тарихи казанышлары югарылыгында иҗат ителгән әсәрләребез күпме? Тукайлар кабызган утның ялкыны сүрелмиме?

Иң әүвәл шул кадәресен искәртеп үтик: җитмешенче еллар башы татар поэзиясе бер урында таптанмады. Ул, эстетик активлыгын тагын да арттыра барып, дәверебезнең шигъри һәйкәлен салуга үзеннән җитди өлеш кертте. Соңгы елларда язылган шигырьләрне укудан туган беренче тәэсир шул: тышкы эффектка корылган ялтыравык эстрада әсәрләре һәм риторик шаблоннардан торган тезмәләр бермә-бер кими төшкән. Тормыш һәм кеше турында тәпле итеп уйлану, фикер йөртү рәвешендә язылган шигырьләр күбрәк урын алган. Форма өлкәсендәге шәкли тәҗрибәләрне, бер чиктән икенче чиккә сугылуларны сүзнең эчке мәгънәсенә, эчке җегәренә, күп мәгънәлелегенә таяну алыштыра бара. Әхлак проблемаларын, фән-техниканың тиз күтәрелеше чорында кеше белән табигать арасындагы мөнәсәбәтләрне һәм шәхес язмышын, аның шатлыгын һәм сагышын, янып-көюен һәм бәхетле мәхәббәтен сурәт-

ләүгә омтылыш — хәзерге татар поэзиясендә үзәк бер тенденция буларак яши. Коры санап чыгуларга, рационализмга һәм ясалма сюжетка корылган шигырьләрнең дә кими баруы сизелә. Ул төр әсәрләрне хис муллыгын, фикер җылылыгын укучыга җиткерү максаты белән язылган лирик шигырьләр кысрыклый. Эмоциональ башлангыч — хәзерге поэзиянең йөрәк тибешен, гомуми үсеш рухын билгеләп торган төп фактор. Шигырь тукымасында барлыкка килгән менә шул җитди үзгәрешләр шигъри сүзнең абруен күтәрде, поэзиянең иҗтимагый тормыштагы ролен үстерде.

Хәзерге татар поэзиясе турында сүз чыкканда, беренче чиратта, шагыйрьләрнең яшьләрен истә тотып, аларны буыннарга бүлеп өйрәнәләр. Бер караганда, бу дөрес тә кебек. Чыннан да, сугыштан соңгы елларда әдәбиятка килгән һәр буынның үз тормыш тәҗрибәсе, үз язмышы, хәтта үз темасы бар. Ләкин бүгенге шагыйрьләрне бер-берсеннән аера, берсен икенчесенә каршы куя торган сыйфатларга караганда, аларны үзара якынайта торган яклар күбрәк тә, көчлерәк тә. Әйтик, С. Хәким белән Н. Арсланов, иҗат рухлары һәм кыю эзләнүләре белән, үз буыннарына караганда, яшьләргә якынрак торалар. Яшь шагыйрь М. Әгъләмовка, чордашлары иҗатыннан бигрәк, Х. Туфанның шигъри күреме якынрак. Рәшит Әхмәтҗанов, төрле буын татар шагыйрьләренең иҗади ачышларына таянып, халык лирикасы җәүһәрләренә килеп чыга. Роберт Әхмәтҗанов мәрхүм Ә. Давыдовның киеренке эзләнүләрен дәвам иттерә. И. Юзеев һ. Такташ, Ә. Фәйзи һәм М. Җәлилләрнең романтик-фәлсәфи эзләнүләрен бөтен совет поэзиясе казанышлары белән синтезлый, Ш. Галиев, С. Хәкимнең иҗат тәҗрибәсенә таянып, Тукайга кул бирә...

Ясисә менә иҗади активлык мәсьәләсен алыйк. Г. Афзал, Ш. Галиев, И. Юзеев, Х. Камалов, Ә. Баянов, М. Шабаев, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхим, М. Әгъләмов, Рәшит Әхмәтҗанов, Зөлфәт шикелле урта һәм яшь буын шагыйрьләрнең кыю эзләнүләре һәм шигъри ачышлары һәммәбезгә мәгълүм. Ләкин бит өлкән буын да үзенең элеккеге казанышы һәм шөһрәте белән тынычланып, кул кушырып кына утырмый. Нури Арсланов сүзләре белән әйткәндә, яшьлекне дәрт бизәсә, картлыкны хикмәт данлый. Х. Туфан, С. Хәким, Ә. Исхак, Ш. Маннур, Н. Арсланов, Н. Дәүли, З. Нуриларның заманча рухлы һәм сәнгатьчә камил әсәрләре шуңа мисал була ала. Кыскасы, ил һәм халык тормышында һәр көнне, һәр сәгатьтә туа килгән иҗтимагый һәм эстетик яңалыкларның көзгесе, совет поэзиясенең бер сугышчан отряды буларак, хәзерге татар шигърияте бер бөтен җанлы организмны хәтерләтә. Төрле буын шагыйрьләрен якынлаштыра торган нигез: социалистик чынбарлык һәм уртак иҗат методы.

Хәзерге татар поэзиясенең колачы шактый киң, тавышы да, тормышның үзе шикелле, төсмерләргә һәм нәкышларга гаҗәп бай. Темалар мәсьәләсен генә алыйк. Татар поэзиясенең борын-борыннан үстерелә килгән традицион темаларына — туган илне, җирне, табигатьне олылау, игенче хезмәтен данлау — яңалары өстәлә тора. Кара алтын табучыларның, химикларның, төзүчеләрнең фидакарь эшләре, уй-хисләре, идеаллары белән рухлану үз вакытында татар поэзиясенең офыгын, сурәтле фикерләү хәзинәсен баетып җибәргән иде. Материаль һәм рухи кыйммәт тудыручылар арасындагы якынлык елдан-ел ныгый, көчәя бара. Хәзер шагыйрьләрнең илһамын һәм зиһенен Чаллы пәһлеваны үзенә тарта. Олы теманы үзләштерү юлында ясалган тәүге тәҗрибәләр укучыга таныш булса кирәк. Бөек төзелешкә багышлап Р. Мингалимов «Күз карасы» исемле поэма язды. Р. Харис «Яр-Чаллыда яңару», «Тузан», «Чаллыда уйлану» кебек шигырьләрендә шул ук тема белән илһамлана. Чаллыда җәелеп киткән төзелешнең тарихи һәм сәяси әһәмиятен күрсәтү, социалистик җәмгыятьнең башка иҗтимагый-экономик формацияләрдән өстенлеген ассызымлау нияте белән, шагыйрь халык мифологиясе үрнәкләренә мөрәҗәгать итә, бүгенге батырлыкны легенда каһарманнарының шөһрәтенә тиңли:

**Кәвешеннән үр-үр туфрак коеп,**
**Тарихларда калган Алыпка**
**Дәвамчысы килгән —**
**Рәт-рәт булып,**
**Үрдән биек йортлар калыккан...**

*(«Яр-Чаллыда яңару».)*

С. Хәким дә шул ук темага килеп чыга. Әмма Алыпның кылган батырлыкларына да, гигант төзелешнең хыял җитмәстәй колачына да өлкән әдипнең карашы башкачарак:

> **Дошманнарын үзенең көнләштереп**
> **Үсте Ватан, үсте халыклар...**
> **КамАЗлар юк чакта гына җирдә**
> **Яшәгәннәр икән алыплар.**
>
> *(«Үткәнемә, узганыма бүген...»)*

«Бар нигезләр бергә буталганда...», «Атка күпме өмет багладым...», «Үз ягы үзенең йөзендә...» кебек лирик парчаларында С. Хәким ил гигантының шигъри сынын тудыру юлында кызыклы эскизлар ясый, бөек эшләр тудырган тәэсирләре белән уртаклаша.

Тулаем алганда, Чаллы төзелеше әлегә үзенең бай палитрасы, кабатланмас язмышлы кешеләре белән шигырьгә кереп кенә бара. КамАЗ белән шигъри соклану һәм тәэсирләнүдән югарырак күтәрелеп, аның проблемаларын һәм кешеләрен ачу юнәлешендә хәрәкәт итәргә, кыскасы, микъдар үсешеннән сыйфат үсешенә сикереш ясарга вакыт җитте. Хезмәт батырлыгы шигъри каһарманлык таләп итә.

Югарыда китерелгән мисаллар С. Хәкимнең заман сулышын, аның эстетик таләпләрен тирәнтен сиземләп, яшьләрчә дәрт һәм ашкыну белән туктаусыз алга, яңа шигъри үрләргә таба хәрәкәт итүе турында сөйлиләр. Шагыйрьнең «Үлгәннәргә хәтта моң кирәк», «Кырларда давыл...» шикелле цикларын һәм «Сибелә чәчәк» китабын укучылар ифрат җылы каршылады. Соңгы җыентыкка кергән шигырьләрнең күбесе газета-журналлар аша таныш иде. Шулай да, бергә туплангач, аларга башка күзлектән карыйсың, аларны яңа шигырьләр кебек укыйсың. Беренчедән, әдип аерым шигырьләрен яңарткан, аларга стилистик төзәтмәләр керткән. Икенчедән, төрле җирдә сибелгән әсәрләрне тоташтан укыгач, алар арасындагы эчке якынлык, лирик геройның рухи дөньясы, фәлсәфәсе тулырак күзаллана. Менә шул эчке бәйләнеш андагы шигырь-поэмаларны бер җепкә тезә, уртак ояга туплый.

Сугышта ирлек, илеңә турылык сынала. Сугышта халыкның характеры, аның әхлагы һәм рухы чыныга. Шуңар да сугыш михнәтләрен үз җилкәсендә татыган шагыйрьнең бу теманы кайта-кайта эшкәртүе — табигый күренеш. Әмма әдип кабатланмый. Сугыш хатирәсе хәзер аңарда күбрәк фәлсәфи уйланулар, гомумиләштерүләр рәвешендәрәк яши, чор каршылыкларын аңларга ачкыч бирә. «Үлгәннәргә хәтта моң кирәк» дигән шигырьләр келтәсендә ул, мәсәлән, сугышның немец халкына биргән сабакларын телгә ала да алга таба кеше язмышы, илнең матур киләчәге һәм шул туачак гармониядә поэзиянең роле, иҗтимагый функциясе турында фикерләүгә күчә. «Гете эчкән чыганактан эчәм, кайда да бер безнең чыганак» дип, шагыйрь поэзиянең демократик һәм гуманистик башлангычына басым ясый. Гете белән бергә, Блок, Тукташ, Җәлил, Кәрим образлары калка. Шагыйрьләр тавышы... Һәркайсы үзенчә яңгырый. Гете үзенчә, Тукай үзенчә. Унбер шигырьдән торган «Тукай дәфтәреннән» бәйләмендә С. Хәким шул идеяне уздыра.

С. Хәкимнең яңа әсәрләренә киңрәк тукталуның сәбәбе шунда, аларда хәзерге татар поэзиясенә хас яңа сыйфатлар аеруча калку чагыла. Әдипнең поэмалары да, шигырьләре дә күләмнәре буенча кыскара, тыгызлана бара. Шагыйрь тар мәйданда да тулы бер хакыйкатьне ачып салуга ирешә:

> **Тау өстендә тора, зур, мәһабәт,**
> **Шуңа, ахры, исме «Империал»,**
> **Җимерелгән империяләр, чорлар**
> **Җилкәсенә басып иттем ял.**
>
> *(«Тау өстендә тора...»)*

> **Ике куллап кабул итте бу җан**
> **Пушкин, Тукай эстафетасын.**
> **Туктата да сорый юлда заман:**
> **Үзең нәрсә өстәп илтәсең!**
>
> *(«Ике куллап кабул итте бу җан...»)*

Фикер ачык, җете бирелгән. Берише шигырьләрендә өлкән әдипләргә хас кискенлек тә бар. Әйтик, «Мәҗлесләрдә шагыйрьләр аз түгел...» шигырендә кискенлек кырыслыкка алып чыга. «Мәҗлесләрдә шагыйрьләр аз түгел, тыштан — иптәш, тыштан — дус алар. Киңәш итим дисәң — Кутуйлар юк, таянырга — Фатих, Мусалар»,— кебек юллар Сибгат аганың киң күңелле характерына ятышып бетми шикелле. «Төнге ике...» шигырендә әдип үзе үк: «сөенәм әле Пушкиннардан тыш Тукайлы бу дөнья, Туфанлы»,— дип яза, сәер исемле татар авылларыннан килгән Гамил Афзал, Мөдәррис Әгъләмовларны котлап кул чаба. («Кайдан татар шагыйрьләре...»)

С. Хәким шигырьләренең икенче төп сыйфаты — лирик эчкерсезлек. Аңарда сюжетлы, объективлашкан геройлы шигырьләр юк диярлек. Лирик стихия тулы хуҗа. Фәлсәфи-лирик уйланулар вакыйга сюжетын алыштыра. Шагыйрь заман проблемаларына кайнар хисләре аша килә:

**Чылтырыйлар... Кызыгуым түгел**
**Я шөһрәткә, данга, я малга,**
**Җырлар шунда, заман — зәңгәр тартма,**
**Ачкыч эзлим һаман заманга!**

*(«Бар иде бер тапкан зәңгәр тартмам...»)*

Шигырьләренең композицион пөхтәлегендә, ритмик төгәллегендә, һәр сүзнең үз урынында, иң кирәкле җирендә кулланышында олы мастер — С. Хәким кулы сизелеп тора. С. Хәким поэзиясенең шул рәвешчә үсә баруы бүгенге укучыларның фикерләү дәрәҗәсеннән артта калмыйча, аның белән бергә атларга һәм, иң мөһиме, аның рухи эзләнүләренә таяныч, маяк булып янарга омтылу белән аңлатыла булса кирәк. Кыскасы, С. Хәким әдәбият мәҗлесендә Тукай, Такташ, Җәлилләр поэзиясенең «йөзенә кызыллык» китермәслек шигырьләре белән катнашты.

Х. Туфанның соңгы елларда язылган кайбер шигырьләре бәхәс уята. Аны искечәрәк, «кадимчәрәк» язуда гаеплиләр. Чыннан да, йөз юлдан артык урын алган «Кайтмый калган дуска» шигыре озынрак тоелырга мөмкин. Информациясе дә яңа түгел. Ләкин «Кайтмый калган дуска» шигыре ике сыйфаты белән күңелне били. Беренчедән, өлкән әдип, хәтер канатында үткәннәргә әйләнеп кайтып, арабыздан вакытсыз киткән шәхесләргә игътибарын юнәлтә. Икенчедән, ул иҗтимагый юнәлешле, гражданлык пафосын үзәккә алган шигырьдә дә балаларча самимилеген, эчкерсезлеген саклый алган. Бу — шагыйрь өчен кыйммәтле сыйфат.

Х. Туфан хәзер аз яза, сирәк басыла. Ләкин уңышлы шигырьләрендә ул үзенең иҗат рухына, электәге казанышларына турылыклы кала. Туфан шигырьләре нинди сыйфатлары белән күңелне җәлеп итәләр соң? Революцион традицияләргә, халык идеалларына турылыклы булулары беләнме? Әллә дөньяны һәм кешене үзенчәлекле итеп күрә һәм сурәтли алулары беләнме? Шагыйрьнең «Ак каен», «Алга барышлый», «Каеннар сары иде», «Гөлләр инде яфрак яралар», «Иртәләр җитте исә», «Овидий Назон», «Агыла да болыт агыла», «Ромашкалар» шикелле назлы һәм кырыс, мәгънәле һәм горур яңгырашлы мәгълүм шигырьләрен искә төшерик. Аларның һәрберсе — поэзия тарихы, аларның һәрберсе үзенә бер шигъри үр. Аның җыентыкларын алып, теге яки бу шигырен укый башласаң, алардан аерылуы кыен, алар сине алга әйди, олы кешеләр, дәртле һәм моңлы хисләр даирәсенә алып керә. Геройлары белән бергә, үтә намуслы, идеалына, шигъриятькә турылыклы шагыйрь үзе атлый, сине дә үзе белән бергә тормыш турында уйланырга чакыра. Тормышка мәхәббәте, тирән оптимизмы, үзен олы дөньяның «җанлы материясе» итеп сиземләве һәм алга ашкынуы белән Х. Туфан күпләр өчен үрнәк була ала:

**Якын да соң тормыш йөрәккә,**
**Тыныч кичләр җиткәнгә микән!**
**Әллә юллар илткәнгә микән**
**Күңелледән күңеллерәккә!**
**Якын да соң тормыш йөрәккә!**

*(«Көнбатышта кояш кызара».)*

Х. Туфанның билгеле бер дата, бәйрәм уңае белән язылган әсәрләре, тарихи парчалары лирик киеренкелекләре һәм тәэсир көчләре буенча югарыда телгә алын-

ган шигырьләрдән түбәнрәк торалар. Соңгы елларда шагыйрь андый әсәрләрне дә аз язмады. Бу шулай ук аңлашыла торган нәрсә. Дөньяда бер шагыйрь дә тоташ шедеврлар гына биреп бармаган.

Н. Арслановның соңгы еллардагы шигъри үсешен һәммәбез күреп-белеп торабыз. Аның иҗаты фәлсәфи-лирик уйлануларга баеды. Чор язмышы өчен борчылу, кеше бәхете өчен янып-көеп яшәү, замандашының фидакарь хезмәте алдында баш ию, үзен дөньяда барган һәр вакыйга өчен җаваплы итеп сизү хисе шигырь юлларында кабатланмас сәнгатьчә гәүдәләнешен тапты. («Дантон әйткән диләр», «Асау атым», «Күкчәтау» һ. б.) Кыскасы, шагыйрьнең сулыш юлы иркенәеп китте, ул икенче яшьләреген тапты.

Халык характерын, аның үткәнен һәм бүгенгесен, киләчәген һәм хыялын, көен һәм вәзенен тирәнрәк аңларга омтылу, халыкның рухи олылыгына дан җырлау — соңгы еллар татар поэзиясенең үзәк мотивларыннан берсе булды.

Р. Вәлиев «Игенчеләр нәселе» исемле шигырендә түбәндәгечә яза:

**Вакыт җитте инде галәм иңләп**
**«Карурман»ны җырлап үтәргә...**
**Тик һаман да туган җирне сөю**
**Җитеп бетми әле күпләргә.**

И. Юзеевның «Карурман» поэмасы да элекке мирасны җилгә таратучы нигилизмга һәм ваемсызлыкка каршы юнәлтелгән. Туган табигать, шагыйрь уенча, матурлык, нәзакәтлек һәм мәхәббәт чыганагы. Табигать матурлыгы белән соклана белү кешене күтәрә, үстерә, аның рухын баета, әхлагын камилләштерә. Бу әлемтә югалса, кеше ваклана, үзенең характерын, холкын бизәүче сыйфатларын, табигый гүзәллекне аңлау сәләтен җуя. Поэмада «техницизмны» культка әверелдерүгә каршы көрәш авазы да үзен сиздерә. һәр эштә табигый гармония, иплелек, пропорция булырга тиеш, ди шагыйрь. Соңрак поэмада сурәтләнгән геройны да бабасының үлем алдыннан әйткән өч сүзе — «Сандугачлар... Чишмә... Карурман...» — уйландыра башлый. И. Юзеев егет күңелендә барган эволюцияне психологик әзлеклелек, үзенә бер иплелек һәм нечкәлек белән тасвирлый. Табигать — яшьлекнең кайнап торган татлы чишмәсе. Үзе яңа матурлыклар иҗат итүче буларак, кеше табигатьсез яши алмаячак:

**Юк, югалмас җирдә карурманың,**
**Өзелерлек түгел тамырлар,**
**Ерак-ерак киләчәктән килеп**
**Оныкларың сине табырлар.**

Әлбәттә, биредә сүз, милли традиция төшенчәсен артык тар мәгънәдә кабул итеп, аны көйгә һәм моңга гына кайтарып калдыру турында бармый. Туган җирне һәм батырлыкны олылау, азатлыкка, бәйсезлеккә омтылу һәм башка халыкларны хөрмәтләү, халыклар арасындагы елдан-ел ныгый барган дуслыкны данлау — безнең интернациональ һәм милли традициябез.

Яшь шагыйрь Әхмәт Рәшитов тарихи ассоциацияләр аша бүгенге көн, туачак көн проблемаларына килеп чыга:

**Эзләмим мин аннан канлы эзләр,**
**Кынысыннан чыккан кылычны.**
**Бүгенгегә карыйм:**
**Уртак Ватан —**
**Советларның күге тынычмы!!**

*(«Россия».)*

И. Юзеев «Карурман» поэмасында, «Табыну», «Уфтану», «Борчылу» кебек шигырьләрендә табигать һәм кеше проблемасын калкытып куя, цивилизация белән табигать арасындагы каршылыкларның уйдырма һәм шартлы икәнлеген расларга тырыша, диген идек. Әйтергә кирәк, бу проблема бик күпләрне үзенә җәлеп итә. Татарстанның табигатен яңадан үзгәртеп кору чорында әлеге проблеманың игътибар үзәгенә алынуы гаҗәп түгел. Әлеге темага мөрәҗәгать итүнең, минемчә, тагын бер сәбәбе бар.

Алтмышынчы еллар уртасында татар поэзиясе, тормышта барган үзгәрешләрдән һәм интеллектуаль әзерлекле, югары белемле укучылардан калышмаска омтылып, шигъри телескобын йолдызстанга, ясалма юлдашларга, биосферага, кыскасы, могҗизалар дөньясына юнәлтте. Ә. Давыдов, Г. Афзал, Роберт Әхмәтҗанов, И. Юзеев, Р. Фәйзуллиннарның бу юнәлештә ясаган уңай тәҗрибәләре поэзия белән даими кызыксынып баручыларга яхшы таныш. Халык хыялы тудырган үзйөрешле итекне реактив самолетлар, оча торган серле паласларны ясалма юлдашлар алыштырды. Фәнни-техник революция казанышларын шигъриләштерү шагыйрьләребезнең заман белән бер аяктан атларга омтылулары турында сөйли. Яңа темалар традицион образлар системасын тагын да баета төште, поэзиянең фикерләү рәвешен киңәйтеп җибәрде, аның лексиконына яңа сүзләр өстәде. Бу фикергә ышану өчен Роберт Әхмәтҗановның «Йолдызстан», «Кояш блокноты» кебек әсәрләренә мөрәҗәгать итү дә җитә.

Әмма техник прогресс белән артык мавыгуның күләгәле яклары да булмады түгел. Ул поэзиянең үз йолдызстанын — кешене, аның табигый хисләрен, уй һәм эшләрен арткы нәүбәткәрәк этәрде. Могҗизаларның иҗатчысын — кешенең үзен дә бер юнәлештәге поэзия генә канәгатьләндерә алмый, билгеле. Шигырьдән ул информация янсә коры ләззәт кенә эзләми, ә үзен борчыган яки хәвефләндергән катлаулы мәсьәләләргә җавап та эзли, тормышында рухи таяныч, көндәлек эшенең, борчуларының эчке мәгънәсенә нур сирпегән ачыклык эзли, шуларны таләп итә.

Киләчәктә табигый матурлык, табигать белән кеше тормышы арасындагы мәңгелек гармония югалмасмы? «Техницизм» поэзиянең җанын үтермәсме?.. Җитмешенче еллар башы поэзиясе йөз белән менә шул проблемаларга борылды. Әле кайчан гына кояш блокнотын «тутырып», ерак Галактика белән илһамланып йөргән Роберт Әхмәтҗанов та, тирә-ягына, җир тормышына күз салып, «Табигатькә дүрт җыр» исемле күләмле әсәрен бастырып чыгарды. Нәби Дәүли табигать исеменнән (цикл да «Табигать исеменнән» дип атала) махсус чыгыш ясады. Н. Арсланов фәлсәфи моң, сагыш белән Күкчәтауны сагынып җырлый. Фаил Шәфигуллинны ерак Аляска һәм төньякның төрле төсләр белән җем-җем итеп торган сихри балкышы үзенә тарта («Аляска», «Төньяк балкышы»). С. Хәким бөек КамАЗ янында крестьянның гади бер атын сагына, табигать символы булган шул атны саклап калу турында хыяллана:

**Күзеңдә моң: тизрәк дагала,**
**Үткәнемә озат, далага!**
**Мин ялынам: басып кал шунда,**
**Тимерчелек цехы каршыда.**

*(«Атка күпме өмет багъладым...»)*

Мондый мисалларны Г. Афзал, Ш. Галиев, Р. Харис, Р. Фәйзуллиннар иҗатларыннан да күпләп китереп булыр иде. Табигать хәзерге поэзиядә бутафория булып кына түгел, ә ак каеннары, салкын чишмәләре, җылы җилләре, төнбоеклары белән ачыла. Поэзия бакый чынбарлыкның реаль күренешләре аша туган ил образына юл ала. Шул хәрәкәтнең бер үзенчәлекле күренеше төсендә М. Шабаевның «Җикән камыш» дип аталган яңа китабына тукталырга мөмкин. Заманында Шәйхи Маннур шагыйрьнең берише әсәрләрен тәнкыйтьләп чыккан иде. «Проблемасыз» һәм вак темалы шигырьләр бу китапка да үтеп кергән. Шулай да «Җикән камыш» — соңгы еллар поэзиясендә барган эзләнү-тенденцияләрне үзәккә алуы, табигать һәм кеше проблемасына үзенчә килүе белән игътибар лаеклы җыентык. Китапны укып чыгып, соңгы битен япкач, күз алдына ике лирик герой килеп баса. Беренчесе балалык һәм яшьлек хатирәләре белән яши, чынбарлыкны самими һәм эмпирик төстә кабул итә. «Ра-ра-о-ом», «Ак каеннар йөгерә», «Июнь карлары» — шундыйлар. Чәчләре агарган икенче лирик герой табигатьтән эчке мәгънә һәм якынлык эзли, тирә-юнен гамәли һәм гыйльми күзлектән карый. Шигырь табигать турында язылган шикелле тоелса да, чынында ул кеше һәм аның эше турында булып чыга. Мәсәлән, шагыйрь тургайлар җырында «тøзелеш шавы, чыңы» ишетә, халык лирикасы сурәтен күчерелмә мәгънәдә үстереп, ялгыз тургай белән яңа төзелеш кранын янәшә куя («Тургайлар»). «Яшелләнеп уҗым шыткан» шигырендә яшь герой хисләре белән ир уртасы кешенең уй-фикерләре аралашып, кушылып китә. Туган табигать — арадашчы:

**Уйлыймын: «Ашыктым... Мин дә**
**Уҗымдай яшел идем.**
**Буыным катмаган көйгә**
**Серкә очырып йөрдем...**
**Газаплар гына күрдем!»**
**Уйлыймын: «Ашыктым... Иртә**
**Баш кыскан арыш идем.**
**Чәчләрем агарды бит, ә!**
**Агарсын, карышмыймын —**
**Балавыз Марс идем...»**
**Арышлы басуларыма**
**Яңадан барыш минем...**

Р. Харис игътибарын шул ук проблеманың бөтенләй башка ягына юнәлтә. «Җитмеш икенче ел икмәге» поэмасы табигатьнең әле кешегә буйсынмаган, баш бирмәгән кыргый көчләренә, бу очракта, корылыкка каршы көрәшне үзәккә ала. Ахыр чиктә акыллы зат, сәламәт башлангыч, совет кешесе җиңүче булып чыга, егерме беренче ел фаҗигасе кабатланмый. Шартлы алым һәм символик ситуацияләргә таянып, тарихи ассоциацияләрне «эшкә җигеп» (егерме беренче ел ачлыгының караңгы шәүләсе, фашизмга һәм ачлыкка каршы көрәшүче камалган шәһәр), шагыйрь һәр нәрсәдән өстен булган икмәкне һәм игенченең фидакарь хезмәтен зурлый:

**Икмәк ул — олы көч!**
**Икмәкнең мәгънәсе бик тирән...**
. . . . . . . . . . . . . . . . .
**Бакчалар салдык без, калалар —**
**Тарихлар күрсә шаккатырлык...**
**Барыбер, күрәсең, икмәксез**
**Көр булмас, тук булмас матурлык!**

Бу, әлбәттә, яңа фикер түгел. Ләкин аны искә төшереп, игенче хезмәтенең әһәмиятен һәм шигърияттен күрсәтеп үтүнең зарары юк. «Җитмеш икенче ел икмәге» поэмасы бер хакыйкатьне раслый: шагыйрь көндәлек вакыйга-хәлләргә дә игътибарлы булырга, тормышның «прозаик» проблемаларыннан да «язарына азык» таба белергә тиеш.

Ш. Галиев «Чынлык» исемле яңа китабында да элегрәк елларда тапкан һәм халык иҗаты белән тыгыз бәйләнгән эстетик зәвыгына турылыклы калган. Шагыйрь кеше характеры һәм кеше хисләренең нинди дә булса берәр чагылышын үзәккә алган, җыйнак композицияле ике, дүрт, сигез юллык шигырьләргә өстенлек бирә. Бер караганда, артык тыныч, салмак агышлы шигырьләр. Лирик герое да шундый: «...күз алдында эшләнми батырлыклар», «батырлыклар эшләнәләр үз вөҗданың алдында»,— ди ул. «Ник шул кадәр салкын син?» — дисең, яшерен ялкынны, димәк, сизмисең». Ш. Галиев шигырьләренең көче «эчке ялкынында», психологик һәм хисси тирәнлектә. Аның шигырьләренә гадилек һәм ачыклык хас. Вакыты белән бу гадилек куркытып та куя. Шигырьнең кичереш дулкыны бер урында өзелер, шагыйрь примитивлыкка урын бирер дип куркып, сулышыңны да алмыйча укыйсың. Ләкин шигырь, киресенчә, ныгый бара. Сәбәбе нәрсәдә? Шагыйрь нәрсә турында гына язмасын, ул һәр вакыт күренешнең эчке мәгънәсен һәм эчке җегәрен ачу турында уйлана. Шуңар да шигырьләренең композициясе, бетеме еш кына көтелмәгәнчә була.

**Ул фронтка бәхилләшеп китте,**
**«Кайтып булмас, диеп, туганнар...»**
**Күз яшьләре белән озаттык без...**
**Ә районнан кире борганнар.**
**Өч көннән соң кабат чакырдылар.**
**«Бәхил» сүзен ул да катмады.**
**«Кайтасың!» — дип көлеп озаттык без.**
**Китте... Ләкин кире кайтмады.**

Ш. Галиев бик күп парчаларын тормыш ваклыкларын җыеп, бөтенлеккә, табигыйлеккә омтылган камил кешене сурәтләүгә багышлый. «Чынлык» җыентыгында гомумән поэзиябезгә хас бер сыйфат ачык чагыла. Җитмешенче еллар лирикасында биографик элементлар әһәмиятле урын били. Шагыйрь үз шәхси тәҗрибәсен, интим хисләрен укучысына ышанып тапшыра, аның белән ачыктан-ачык әңгәмә алып бара:

**...Сабый чагым. Менеп читәнгә**
**Кыр казларын карап озатам.**
**Киләчәккә алар оча күк —**
**Серле, татлы уйлар кузгата!..**

**Киләчәктә йөрим мин хәзер —**
**Күпме казлар канат кагынган...**
**Кыр казлары инде язларын**
**Кайтадыр күк сабый чагымнан...**

Поэзиясенә нур бөркеп торган җирлектән, гади илаһилыктан аерылганда, Ш. Галиевнең илһамы тоныкланып, төссезләнеп кала. «Сугыш вакыты» парчасында ул күптән мәгълүм нәрсәләрне кабатлый. «Шактый еллар...», «Ах, син кояш кыйпылчыгы...» исемле сигез юллыкларында вак, әһәмиятсез фикерне матур формага төреп бирүгә көчен сарыф итә.

Хәзерге татар поэзиясендә эзләнүләр төрле юнәлештә алып барыла. Берәүләр дилбегәне тулысынча хискә, аның иркен агышына ышанып тапшыралар, икенчеләре фикергә таяналар, өченчеләре катлаулы метафора аша чорның ашкынулы романтикасын, фәлсәфи тирәнлеген аңларга омтылалар... Ш. Галиев «хис белән ега алмасаң, син безгә фикер китер» дип, лирик стихиягә каршы көрәшә. Р. Фәйзуллин «бар дөньяны үчлый алмый, салкын хисапчан акыл» дип, хискә урын даулый. Роберт Әхмәтҗанов исә үзенчә шаулый. Соңгысының поэзиясен, шигъри күремен тулырак күз алдына бастыру өчен, «Идел-йорт» исемле яңа китабына һәм «Казан утлары»нда, «Социалистик Татарстан»да басылган шигырьләренә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Ул — хәзерге поэзиядә актив эшләүче шагыйрьләребезнең берсе. «Идел-йорт» — әлегә аның иң тулы җыентыгы. Шагыйрьнең «унсигез язы», «утыз язы» үтеп, кырыгынчы язы килеп җиткән. Туган туфрак, батырлык, дөньяда яшәүнең яме һәм романтикасы турында ныклап уйланып, үзе әйтмешли, хыялларны тупсага утыртыр вакыт җиткән. Уңышлы шигырьләре — ачык мәгънәле, образлары катлаулы һәм ассоциатив. «Татарстан туфрагы» публицистик пафос һәм үзенчәлекле композициясе белән отышлы. «Туу хәбәре» шатлыкны, сөенечне табигать сурәтләре, лирик символлар аша сынландыруы белән хәтердә кала. «Җил белән килә еракта...» шигыре туган як өненең, ата-баба нигезенең, Идел-йорт төтененең изгелеген искә төшерүе белән күңелне били. Сугышны һәм кешегә каршы юнәлтелгән явызлыкны инкарь итеп язылган әсәрләре арасында да бүгенге поэзия югарылыгында торганнары аз түгел. Р. Әхмәтҗанов мәхәббәт һәм табигать турында үзенчә яза белә:

**Арыш исе аңкып торган яктан**
**Ачыграк күренә кыр юлы.**
**Учарланып таллар калка чаттан —**
**Башкайлары гына җыр тулы.**

*(«Яфрак шавы озата барды җәйне...»)*

Р. Әхмәтҗанов, кайбер шагыйрьләр кебек, тормышны гади кабатлау юлына басмый. Ул чынбарлыкка метафора һәм гипербола, кыскасы, сәнгатьчә образ аша килә. Аның лирик героена сөйгәненең йөрәге океан булып күренә, ул анда «тектоник тетрәүләр, яшеренеп яткан' бусагалар, рифлар» таба. Хәер, Р. Әхмәтҗанов «гадәти хисле» гашыйкларны да аңлый белә. «Каеннарны үт тә сугыл миңа...» шигырендә ул кырыс һәм табигый, кешелекле мөнәсәбәтне образлы итеп күз алдына бастырырга ирешкән.

Р. Әхмәтҗанов — контрастлар, көтелмәгән чагыштырулар һәм янәшәлекләр шагыйре. Шул юлда ул заманында омтылышлы һәм киеренке хисле романтик балладаларын иҗат иткән иде. Ләкин ачык буяу, контрастлы ситуация саклык белән эш итүне сорый. Шул таләпне истән чыгарганда, эстетик бөтенлекнең талымсызлыкка

урын бирүе дә мөмкин. Югарыда телгә алынган «Күктән репортаж» шигыре (элек «Кояш блокноты» дип атала иде) — шуның бер мисалы. Автор ерак сәяхәт романтикасын, үзенең галәм хуҗасы итеп тою шатлыгын җырларга ниятли. («Очабыз. Җитте! Алыгыз трапны кояштан!») Лирик герой сәфәр алдыннан үзенә якын кешеләр һәм әйберләр белән саубуллаша. Нинди кешеләр һәм нинди әйберләр соң алар? Лирик герой тәгәрмәчләргә, шассиларга, кассаларга һәм домуправ белән квитанцияләренә кул изи... Аптыраштa каласың. Квартира өчен түләүдән кача бит бу егет дип, шигырьне юмористик планда кабул итәр идең, тоны бик югары, лексикасы тантаналы. Төрле яссылыкта яткан төшенчәләрне янәшә кую, ничек кенә булса да шаккатырырга тырышу авторны ул үзе көтмәгән нәтиҗәләргә дә алып чыгарга мөмкин.

«Идел-йорт» китабының зур өлешен «Таш аргамак» исемле поэма алып тора. Әсәр Ватан азатлыгы өчен газиз башларын салган билгесез батырларга дан җырлауга багышланган. Мөстәкыйль шигырь буларак яшәргә хаклы «Исемсез таш» монологы тирән тәэсир итә:

**Мин үтәдем антны, иркәм,**
**хет бер ташыма сыен.**
**Үлеме дә берни түгел,**
**билгесезлек кыен.**

Шулай да, аны укып чыккач, поэма ахыргача уйланып җитмәгән дигән тәэсир кала. Үзе дә сизмәстән булса кирәк, шагыйрь әдәби традицияләрне кабатлый. «Таш аргамак»ны укыганда Ә. Фәйзинең «Кара таш ник дәшми?» балладасы хәтердә уяна. Р. Рождественскийның «Реквием»ына охшашлык та күңелне борчый. Шагыйрь үзе дә, Хиросима һәм Нагасаки шәһәрләренең фаҗигасен сурәтләгәндә, ташны бер «елаткан» иде инде («Таш елады» балладасы).

Р. Әхмәтҗанов каршылыклы хисле, үзен табып җитмәгән шәхесне сурәтләргә ярата. Менә аның герое күзгә каршына баскан да, сагышлы чыраен әйрәнә һәм бу «мин түгел бугай» дигән нәтиҗәгә килә. Ул үзен сирень чәчәк аткан бакчалардан, елгалардан, билгесез шәһәрләрдән, көздән эзли һәм башка берәүне таба:

**Сине таптым.**
**Инде, бар дөньяны бетереп,**
**Мин**
**Үземне эзлим.**

*(«Көзгеләргә киләм...»)*

Югары пафослы, романтик омтылышлы шигъри әсәрләр тудырырга сәләтле шагыйрьнең «Көзгеләргә киләм...» шикелле тезмәләргә җегәрен сарыф итүе кызганычрак, әлбәттә.

С. Хәким, М. Шабаев, И. Юзеев, Ш. Галиев, Роберт Әхмәтҗанов иҗатларыннан күренгәнчә, хәзерге поэзия, үзенчәлекле, кабатланмас кеше образларын тудыру белән берррәттән, шәхес психикасын гомумирәк һәм күләмлерәк итеп тасвирлау мөмкинлегеннән дә киң файдалана. Икенче юнәлеш бигрәк тә бер төркем яшь шагыйрьләр иҗатына хас. Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалимов һәм Зөлфәтләр өчен сүзне «без» янсә тулы бер буын исеменнән алып барган шигырьләр гадәти күренеш. Р. Мингалимов түбәндәгечә яза:

**Минем буын —**
**Бомба ярылганда,**
**Йортлар ауганда**
**аунап**
**елаган малайлар.**

**Безнең —**
**Җимерүчегә**
**үзебезнең караш,**
**үзебезнең —**
**үзгә —**
**ачуыбыз бар.**

Еш кына галәмне, дөньяны иңләгән масштаблы фикер гадәти төшенчәләргә, тормышчан күренешләргә алып чыга, шул рәвешле, кояш һәм ерак Галактика белән урам буйлап җил куып йөрткән гади бер яфрак, миллион еллар белән мизгел арасында якынлык, кардәшлек раслана. Шул тирәлектә кеше дә ничектер олырак, күләмлерәк булып күз алдына баса. Ул мещаннар фәлсәфәсенә каршы, тормыштагы башка төрле кимчелекләргә каршы көрәшә. Ул чордашларыннан янып яшәүне, сайлаган юлларына ахыргача турылыклы булуны таләп итә, үзе дә шуңа омтыла.

Р. Мингалимов каләменең соңгы еллар казанышы «Күз карасы» поэмасы булды. Лирик һәм публицистик фрагментлардан торган бу әсәр, алда бер тапкыр әйтелгәнчә, Чаллы шәһәренә һәм аны төзүчеләргә багышланган. «Яңа үсеп чыккан Чаллы ул сабый кебек әле — кайдадыр күке кычкыра, ул саный кебек әле». Шагыйрь үз бурычын дөрес аңлый:

**Миңа хәзер**
**Шигырьне —**
**Кирпеч, балчык, ком итәргә түгел,**
**Комны, балчыкны, кирпечне**
**шигырь итәргә кирәк.**
**Цехларны, машиналарны**
**шигырь итәргә кирәк.**

Шулай да поэзия өчен ул гына җитми. Аны матур һәм эшчән егетләр, кызлар бизәргә тиеш. Р. Мингалимов нинди дә булса үзәк геройны сайлап алмаган. Төзелешкә ул кинематограф күзе белән карый. Экранда «озын рус», «чандыр казакъ», «тәп кебек татар» шоферлары күренеп китә. Икенче кадрда алар янына Рәис, Умат Нурбиев, Карпенко кебек үз исем-фамилияләре сакланган шәхесләр өстәлә. Җырның дәвамы туйга, дәресрәге, туйларга килеп тоташа: «ә бер өйдә ял сәгатен туй итүче Нәсыйх белән Мәдинәгә текәлгәннәр», «ә бер өйдә ял вакытын туй иткәннәр, кияү кеше — дагстанлы сөйли басып».

Поэманың башында һәм ахырында шагыйрь масштаблырак образларны эшкә җигә, укучыны бомбалар белән өркетеп ала, «күз карасы кебек түгәрәк Җир»не сакларга, ятимнәрне кызганырга өнди:

**Җирдә бомба, бомба, бомбалар бар,**
**Янгын, янгын, янгын, янгыннар...**
**Ятим, ятим, ятим, ятимнәр бар.**
**Кайгы, кайгы, кайгы, кайгы бар.**
**Хәбәр, хәбәр, хәбәр, хәбәрләр бар.**
**Гел яралый шулар бәгырьне.**

Әлбәттә, шагыйрь әсәрне төрлечә башларга һәм тәмамларга хаклы. Аңа әзер рецептлар тәкъдим итеп булмый. Ләкин әсәр язган саен сугыш темасын телгә алу, укучының психикасы белән уйнау, егерменче еллар поэзиясе үрнәгендә, космик образлар белән мавыгу, бер гадәти нәтиҗә ясар өчен миллион елларга кизәнү һәр очракта да акланмый. Мондый хәл Р. Мингалимов поэмасы өчен генә характерлы нәрсә түгел. Тагын бер мисал китерик. «Табигать исеменнән» дигән циклының «Кереш сүз»ендә Нәби Дәүли түбәндәге нәтиҗәне ясый:

**Кеше,**
**Синең бабаң маймыл**
**булса да,**
**Синнән ләкин маймыл**
**тумасын.**

Шундый натуралистик хөкем ясаганчы, автор миллион елларны, галәмне аякка бастыра, диңгезләр, таулар барлыкка килү, вулканнар шартлау кебек вакыйгаларны телгә ала. Фәнни фикер шигырь юлларына куып кертелә, космик образлар белән мавыгу шигырьдән хисне, эмоцияне кысрыклап чыгара.

Совет шагыйре алдынгы идеяләргә, яңалыкка хезмәт итә, шуларның сәнгатьчә сынын эзли. Яңа матурлыкны һәркем үзенчә җырлый. Берәүләр шигърияткә лирик

җылылык алып килә, икенчеләре эпик киңлек һәм гомумиләштерү белән алдыра, өченчеләре публицистик ялкынны шигырь юлларына чыгара... Равил Фәйзуллин да поэзиягә үз юлы белән килде. Башлангыч чор иҗатында ул шәкли тәҗрибәләргә өлеш чыгарды, башваткычлар язу белән мавыгып алды. Шагыйрьнең ул чор иҗаты артта калды. Традицияләргә булган мөнәсәбәте дә үзгәрде. Хәзер ул гадирәк яза, фикер белән кичереш берлегенә омтыла, чынбарлыктагы иплелекне, нәзакәт һәм матурлыкны сиземли. Шәхеснең интеллектын калкытыбрак сурәтләгәндә дә, дилбегәнә рационализм кулына тапшырмыйча, фикерен тойгы, хис белән җылыту юлларын эзли. «Казан утлары»нда урын алган «Лирик шигырьләр» циклында мин шул юнәлештә алып барылган киеренке эзләнүләр ялкынын тоям.

Шагыйрь һәр яңа китабында характерның һәм шигъри күременең яңа бер сыйфатын һәм кыйбласын ачуга ирешә. Менә шул үзенчәлеген саклый алса, үз кыйбласын югалтмаса, Р. Фәйзуллинның шигъри офыгы тагы да киңәеп, ачылып китәргә мөмкин. Шуңа өметләнергә нигез бар.

«Гадиләргә гимн» китабы шагыйрьнең ярсулы һәм омтылышлы, кырыс һәм кешелекле, һәр очракта да актив, хәрәкәтчән позицияле гражданлык аһәңен укучыга ирештерде, аны егерменче еллар поэзиясенең сугышчан рухына тугрылыклы шагыйрь итеп таныттты. Р. Фәйзулинның лирик герое көрәшчеләр дөньясына килеп керә һәм көрәш, хезмәт мәйданының киңлегенә шакката. Бу мәйдан рухи һәм физик өлгергәнлекне таләп итә: «Мәйдан олы икән: буынның ныкмы дип сорап тормый икән». Анда җиңеп чыгу өчен иманының камиллеге, идеалының ачыклыгы, ышанычының ныклыгы кирәк икән. «Гадиләргә гимн», «Көрәшчеләр» поэмаларында шагыйрь мәйдан тотучы гади кешеләрне сурәтли. Сокланып һәм горурланып сурәтли. Буяуларны һәм метафораларны кызганмыйча сурәтли... Кешегә мәйдан тоту гына җитми икән әле. Ул үзенең рухи камиллеге, вөҗданы һәм ышанычы өчен туктаусыз көрәшергә тиеш:

**Янган-көенгән чакта,**
**башың иелгән чакта,**
**кайгың өелгән чакта,—**
**беттем! — дисең... Күзең ачсаң,**
**вөҗданың белән беррәттән**
**ышаныч тора сакта,**
**кешелегеңне саклап.**

*(«Нинди бетмәс ышаныч бу!»)*

Кешене тагын бер нәрсә борчый: дөнья фани, «яшьлек-картлык» аның ихтыярында түгел, гомер бик тиз үтә. («Ни генә җиккесез! Чапты заман — җиткесез», «Тавыш тизлеге таман — ыргылып чаба заман».) Вакыт агышы белән кеше ярыша аламы? Кешене табигатьнең биологик закончалыкларыннан өстен куярлык гали көчләр юкмы? Дөньяда вакыт тизлегенә баш бирми торган бер генә нәрсә бар икән. Ул — хезмәт.

**Яу-дауларны күргәннәр күп,**
**Көрәш-шауда җиңгәннәр күп.**
**Вакыт-яу — иң-иң яманы!**
**Җиңүчеләр сирәк аны!**
**Вакыт белән хезмәте тау**
**ирләр генә алыша ала.**
**Заман иелеп, җиңүченең**
**шанлы исемен алып кала.**

*(«Яу-дауларны күргәннәр күп...»)*

«Наз» җыентыгында лирик-интим интонация хакимлек итә. Әмма биредә дә шагыйрь гражданлык позицияләренә турылыклы кала. «Гадиләргә гимн»да аның герое ышанычын, вөҗданын, өметен, хыялын, сафлыгын көрәш мәйданында сынаса, мәкер, өметсезлекне, ялганны шунда җиңсә, хәзер бу тартыш башка яссылыкка күчерелә. Ул — кешене үстерә, баета, зурлый торган мәхәббәт өчен көрәш алып бара. «Син дә бөек идең ул мизгелдә», «Сөйдем аны...», «Сары ут капкан бу кырда...», «Бәлки...»

шигырьләре шундыйлардан. Шагыйрь бу темада үзен шактый иркен сизә. Лирик характерның бер сыйфатын рәсемләп бирү өчен аңа нибары дүрт юл да җитә:

**Чарам булса, горур йөрткән**
**башымны имәс идем.**
**...Бергә булсак, сине бәлки**
**бу кадәр сөймәс идем.**

(*«Бәлки...»*)

Тышкы дөнья белән шәхес кичерешләре арасындагы каршылыкны чагылдыру алымнары да төрле:

**Сөйдем аны.**
**Шаштым!**
**Җаным**
**күкләргә күкрәп менде!**
**Әйттеләр: бигрәк сүрән,**
**басынкы бала инде...**
**Бер заман, «гашыйк икән!» дип,**
**Илгә сүз чыккан иде.**
**...Ә мин инде ул вакытта**
**аны оныткан идем.**

(*«Сөйдем аны...»*)

«Наз» китабында шагыйрь татар поэзиясенең гүзәл традицияләренә кайтып төшә, халык иҗатының «яз», «аккош», «зәңгәр яулык», «таң җиле» шикелле традицион образларын яңарта, аларны тагын да баета.

Шулай да Р. Фәйзуллин без күнеккән мәгънәдәге традицион шагыйрь түгел. Ул ирекле формага өстенлек бирә, контрастлы образларга мәхәббәт тота. («Бай көз яхшы, тик шулай да ярлы яз күркәмрәк», «боз өстендә учак ага. Әй, төнге ялкын».) Шигъри ачышларына күләгә дә төшкәли. Тормыш ваклыклары белән артык мавыгып шигъри рухны югалткан очраклары да, кабатлануы да, прозаизмнарга күбрәк өлеш чыгаруы да күз алдында. Ләкин шунысы бәхәссез, хәзерге татар поэзиясен Р. Фәйзуллин тавышыннан башка күз алдына китерүе кыен.

Н. Дәүли Р. Фәйзуллин белән Р. Гатауллинны «поэзиядә игезәк туганнар» дип атаган иде [1]. Иҗатларының башлангыч чорын истә тотканда, бу фикердә бәлки дөреслек тә бардыр. Шулай да, мондый карашны әйткәндә, тәнкыйтьче өлеге шагыйрьләр иҗатында соңгы елларда барлыкка килгән җитди үзгәрешләрне исәпкә алмаган. Р. Гатауллин да яшьлегендә язганнардан кайтышрак язмый. Тик шул арада, тормыш белән бергә, поэзия бик нык үсте, алга китте, ә шагыйрь исә элеккеге үрендәрәк кала бирде. Кайнарлыгын югалта барган яшьлек хисләре белән генә хәзерге поэзия югарылыгында калып булмасын аңлап, ул тематик офыгын киңәйтергә омтылышлар ясап карады. Мәсәлән, ул, Хәсән Туфанның шигъри-мемуар жанрында ясаган тәҗрибәләренә таянып, татар мәдәнияте һәм аның мәшһүр кешеләре турында байтак шигырьләр язды. («Китапка хитап», «Сүнмәс утлар белән», «Сүнмәс йолдызларың», «Тукай урамында» һ. б.) Аларда Сәйфи Сараи, Мәүлә Колый, Утыз Имәни, Гали Чокрый, Акмулла, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская һ. б. бик күп тарихи исемнәр телгә алына. Шактый шома язылган, шигырь техникасын белеп язылган шигырьләр. «Сүнмәс утлар», «Сүнмәс йолдызлар» шикелле бер шигырьдән икенчесенә күчеп йөргән эпитетларны да тыныч кына «йотып» җибәрәсең. Тагын укыйсың. Ләкин шигырьләр сине борчымый, мәшһүр кешеләр турында белгәннәреңә яңалык өстәми. Чөнки аларның күбесе шигырь юлларын тутыру һәм рифмага бәгелү өчен генә килеп кергән икән:

**Ә йолдызлар... һәр кич алар калка,**
**Гүя Волжская, Камал, Карилар.**
**Тинчуриннар — биек тәрәзәдән**
**Үзе корган йортка карыйлар.**

(*«Сүнмәс йолдызлар».*)

---

[1] «Казан утлары». 1971 ел. 7 сан. 148 бит.

Икенче җитешсезлек тә күзгә ташлана. Шигырьләрнең байтагы озак уйланулар, иҗади газаплар нәтиҗәсендә түгел, ә юбилейлар, аерым даталар уңае белән генә язылган. Изге ният белән язылган әлеге шигырьләрнең эчке ялкынсыз һәм рухсыз килеп чыгуы укучыны шул чорга якынайта торган тарихилык һәм мәдәниятебезнең бөек әһелләрен безнең дәвергә бәйли торган фәлсәфи тирәнлек һәм эстетик яңалык җитмәү белән аңлатыла.

Тагын бер мисал. Гәрәй Рәхим поэзиягә Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллиннар белән бер чорда керде һәм шул шагыйрьләрнең күремен, интонациясенә якын юлдан атлаучы әдип булып саналып килде. Баксаң, ул үз юлы белән атлый, тормыш турында үз гипотезасын раслый, шигърият белән үзенчә «чирли» икән. Аның шигырьләренә киң мәгънәсендәге кешелеклелек хас. Ул тормыштан гармония, иплелек эзли. Г. Рәхим катлаулы метафоралар белән баш ватмый. Ул поэзиянең Г. Кандалый һәм Я. Емельяновлардан килә торган лирик сафлыгына, самимилегенә таяна һәм үзе яхшы белгән, башыннан кичергән темалар турында гына язарга тырыша. Кеше йөрәгенең берәр халәтен реалистларча чагылдыра белүе — Г. Рәхим турында «ул шагыйрь» дип әйтергә мөмкинлек бирә. Аның иҗатына җитдилек һәм тирәнтен уйлану хас:

**Мин еллардан әнә шундый**
**Бер челтәр үреп барам.**
**Бу төше ямьсез димәгез —**
**Үзем дә күреп барам.**
**Тик матур җире дә бар, дип**
**Шатланып көлеп барам.**

*(«Гомер челтәре».)*

Хәзерге шигырь культурасының һәм техникасының уңышлары гаять зур. Бу — сөенечле хәл. Ләкин аның бер уңайсыз ягы да бар. Шигырь техникасының нечкәлекләрен дәреслекләр буенча ныклап үзләштергән «рифмачыларның» шагыйрь түгелләрен тиз генә аңлавы, сизелмәве кыенлаша. Әмма табигый сәләте булган шагыйрьне шагыйрь итеп тану өчен бер шигырь дә җитә. Мәсәлән, Кадыйр Сибгатуллин күптәннән басыла. Ләкин мин аның язганнарының максатын, мәгънәсен аңламый, дөресрәге, үз почмагын, шигъри концепциясен тапмый идем. «Иргә чыкмый калган апалар» шигыре белән ул үзен шагыйрь итеп танытты.

Ә болай темасы һич кенә дә яңа түгел, күп тапкырлар колакка чалынган, кабатланган тема. Шигырь нинди сыйфаты белән алдыра соң? Беренчедән, автор татар хатын-кызларының характерына, холкына хас сабырлыкны, түземлелекне төгәл образларда чагылдыруга ирешкән. Икенчедән, ул кеше фаҗигасен йөрәккә үтеп керерлек итеп сурәтләрлек чаралар тапкан, вакыйга-хәлләргә үз эстетик һәм этик позициясеннән чыгып карый алган.

Шагыйрьләр һәм буыннар язмышы кызыклы да, гыйбрәтле дә. Алтмышынчы елларның икенче яртысында поэзиягә ике дистәгә якын яшь шагыйрь килде. Ләкин, ул буын турында сүз чыкканда, озак еллар буе биш исем кабатланды: Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхим, Р. Мингалимов һәм Р. Гатауллин. Чыннан да, алар поэзиягә шаулап, өермә шикелле, кинәт килеп керделәр, онытылыбрак торган традицияләрне яңарттылар, шигырьдә фәлсәфи уйлануларга киң урын бирделәр, әдәби форманың, композициянең функциясен киңәйттеләр. Традицион калыпта язучы бер төркем яшьләр күләгәдә, тәнкыйть игътибарыннан читтәрәк калды. Алдагы елларда әдәби тәнкыйть һәм җәмәгатьчелек игътибары Зөлфәт, М. Әгъләмов, К. Сибгатуллин, Рәшит Әхмәтҗановларга юнәлде. Поэзиягә алтмышынчы елларда ук аяк атлаган традицион стильле шагыйрьләр, үз сәгатьләрен көтеп, тыйнак һәм салмак кына алга хәрәкәт итләр. Биредә шул буынның өч шагыйре — К. Булатова, Ш. Маннапов, Т. Камалиев — турында берничә сүз әйтеп үтәсе килә.

К. Булатова поэзиягә үз темасы һәм үз образлары белән килде. Ул ачык һәм гади сюжетка таяна, тормыш-көнкүрештән алынган ситуацияне шәхси кичерешләре белән җылыта. Сүз җаенда шуны да искәртик, абстракт хисләр стихиясенә юлыкканда шагыйрәне уңышсызлык сагалап тора. Хикмәте табылмаган «Сабан туе иртәгә» шигыре — шуның ачык мисалы.

К. Булатова поэзиясенең әчтәлеген һәм аһәнен табигать һәм мәхәббәт темасы билгели. Ул табигатьнең барлык фасылларын да якын күрә, яратып сурәтли. Туктаусыз үзгәреш-яңарыш хәлендә яшәгән табигать катлаулы, ә кеше күңеле, аның рухи дөньясы һәм ихтыяҗлары тагын да катлаулырак. Шагыйрә шәхес кичерешләрен тирәнтен аңлап, эчке мәгънәсе, тибрәлеш-нюанслары аша тасвирларга омтыла. «Кабан күле өсләрендә...», «Кыз җыры», «Тын гына камышлар шаулаган урынга...» шигырьләре кешене күтәрә, үстерә торган мәхәббәтне олылаулары белән хәтердә калалар. Кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне шагыйрә саклык һәм нәзакәтлек белән тасвирлый:

**Тик ул чакта беребез дә:**
**«Миндә хата!» — димәдек.**
**Ни булса да гаепне тик**
**Каршы яктан эзләдек.**
**Нәтиҗәдә — уртак хата:**
**Икебез ике якта.**
**Син бер якта, мин бер якта,**
**Бергә чаклар — еракта.**
**Хәтер генә өзми юлны,**
**Һаман кайта үткәнгә.**
**Күңел генә урыныңны**
**Мәңге бирмәс бүтәнгә!**
(*«Рәнҗегән чаклар да булды...»*)

Интим лирика — поэзиянең катлаулы төре. Шагыйрь, үзенең артык вак шәхси кичерешләре эченә йомылып, иҗтимагый аһәңнән ераклашса, гражданлык хисен югалтса, интим лирика «альбом лирикасы» дәрәҗәсенә төшә. К. Булатова да вакыт-вакыт ике арадагы чикне югалта. Шигырьгә сентиментальлек һәм төшенкелек мотивлары үтеп керә. («Киткәнеңә бүген тәүлек тулды», «Тешләк дигән...» һ. б.) Билгесез дошман белән көрәшүгә, аны «фаш итүгә» дә шактый күп көч сарыф ителә:

**Төрле кеше йөри тирә-якта,**
**Ак дуслар бар, кара дошман бар.**
**Төс алышкан алдар төстән сакла,**
**Ак дошманнан, кара дуслардан.**
(*«Кашлар-күзләр...»*)

К. Булатованың халык лирикасыннан, халыклашкан җыр традицияләреннән үсеп чыккан «тыныч» һәм интим-хисси шигърияте татар поэзиясенең гомуми хорында үз урынын дәгъвалый.

Т. Камалиев кешенең тормыштагы урыны, яраткан һөнәре турында язарга ярата. Аның салмак һәм көйле үз тавышы, яраткан традициясе бар. «Осталар», «Ярыш», «Сукыр даны», «Балта остасы Закирҗан», «Язмыш ачысы» шигырьләре күңелдә җавап хисләре уятмый кала алмый. Сукыр Сөләйманның мичләре кешеләргә бәхет, шатлык алып килә. Ул эше белән дан казанган, «йөрәк кайнарлыгы» белән «кешеләрнең күңелен эреткән» герой. Кыскасы, Т. Камалиевның яхшы шигырьләре аз түгел. Ләкин аның иҗатына ниндидер уртак үзәк, проблема бөтенлеге җитенкерәми. Ул умырзая белән Җәлил турында яза да, монтерлар янына килә; шигырь язарга өйрәткән редакторына мәдхия яудыргач, «чишмәләрнең таныш моңын», «чүлпылар чыңлавын» тыңларга туган авылына юл тота. Фикер тарая, тема бүлмәгә бикләнә, ванна ләззәтен җырлауга алып чыга:

**И ванна, сиңа күпләрнең**
**Рәхмәте ява, ахры.**
**Суың да тынар су түгел,**
**Шифалы дәва, ахры.**
**Мендәргә башны салгандай,**
**Күз йомып, оеп ятам.**
**Мин шулай гомер күрмәгән**
**Рәхәтлек тоеп ятам...**
(*«Ванна».*)

Бер чиктән икенче чиккә сугылуның берәр сәбәбе бармы? Минемчә, бу житешсезлек үз-үзеңә һәм геройларыңа таләпчәнлек житешмәү, әдәбиятта үз урыныңны, позицияңне сиземмәү, сүзеңә, жестыңа игътибарсызлык белән аңлатыла. Бу инде шигъри культураның ярлы булуы хакында сөйли торган нәрсә.

Ш. Маннапов та бериш шигырьләрендә әһәмиятле вакыйга-хәлләр белән очраклы һәм типик булмаган күренеш-ситуацияләр арасындагы аермага игътибарсызлык күрсәтә икән аны сизмәми. Мәсәлән, ул лирик героеның яңа йортка күчүен («Кәтә яңа йортым, яңа тормыш мине чакыра»), анда иптәп урнашып, яңа дуслар табуын шигырьдән шигырьгә сузып килә («Күчену», «Яңа фатирга күчтек без...»). Аерым кеше тормышында бу вакыйга да әһәмияткә ия. Маяковскийның шул темага багышланган классик шигыре безне әле дә булса тәэсирләндерә («Рассказ литейщика Ивана Козырева о вселении в новую квартиру»). Ләкин яңа йортка күчү әле ул яңа тормышка аяк атлау дигән сүз түгел. Икенчедән, шагыйрь яңа фатирга ордер алырга килгән берәүнең кулын кысып утыручы регистратор дәрәжәсенә төшә алмый. Аны тормыш фәлсәфәсе һәм меңләгән гадәти вакыйга-күренешләр артыннан күтәрелгән мәңгелек хакыйкатьләр борчырга тиеш. Маяковский шул конкрет ситуация аша халык идеалларының гамәлгә ашуын гомумиләштереп күрсәтүгә ирешкән.

Ш. Маннапов, тулаем алганда, үз кыйбласын уңышлы эзләүче өметле яшьләрдән. Ул чордашы кылган изге эшләргә чын күңелдән шатлана белә, үзе «үлгәч тә күңелендә исән тота алырлык дуслар» эзли («Эзлим»), шигъри угын битарафлыкка каршы юнәлтә («Мин сиңа никадәр, никадәр»). Иң мөһиме шунда ки, ул чынбарлыкны чагыштыру-метафоралар аша күрә белә. Бу инде шагыйрьлек орлыгы бар дигән сүз.

Рәшит Әхмәтжанов — матур һәм үзенчә ачылып килүче яшьләребезнең берсе. «Ак канатлар» китабы — шуның ачык мисалы. Шагыйрьнең уңышлы әсәрләренә җыйнак, кыска композиция һәм халыкчан интонация хас. Ул вакыйгаларны үзенчә күрә һәм сиземли белә:

**Ятим бала...**
**Әгәр үги ана**
**Чакырмаса пешкән ашына,**
**Гомер буе сабый ялан аяк**
**Әнкәсенең йөгерә каршына.**

*(«Ятим»)*

Р. Әхмәтжанов халык җыры традицияләренә һәм Х. Туфан поэзиясе казанышларына киң таяна. «Карлар ява», «Нишләдең син, нишләттең син...», «Яшерен сөйсәң дә...», «Ай төшкән кое төбенә», «Йөрәкләр янар, сызлар...», «Кыр казы дәште тиңенә» шигырьләрендә Туфан иҗатының кырыгынчы-илленче еллар чорына хас образларның, рифма-кабатлауларның яңадан иҗатка кайтуы куанычлы. Традицияләрне һәм остазларны сайлый белүе, гади кабатлау юлына төшмичә, үзенчә януы белән Рәшит Әхмәтжанов иҗатының киләчәге өмет уята.

М. Әгъләмов та яңа шигырьләрендә үз тавышын расларга тырыша. «Каурый», «Бар иде заманалар», «Матчага элгән силә» шигырьләрендә күзәтүчәнлек һәм дөньяга философларча карый белү хас. Аны тарих белән мизгел, мәңгелек белән көндәлек арасындагы диалектика, якынлык һәм каршылык борчый.

**...Сез дигәнчә генә булса икән,**
**Барса икән сез дигәнчә генә...**
**Тимерченең чүкечедәй, бер көн**
**Килеп төшә вакыт, яньчә генә —**
**Барысы була ул дигәнчә генә.**

*(«Без дигәнчә генә барса икән...»)*

Кеше вакыт һәм мәңгелек алдында көчсез. Ләкин ул хыялы, эше, романтик омтылышы белән мәңгелек:

**Офыклардан ары бу киңлекләр...**
**Бу киңлекләр — безнең мөмкинлекләр.**

*(«Үзәннәрдә чәчәк бәйрәмнәре...»)*

Мәңгелекнең чыганагы, нигезе — туган ил: «Ул исән булса, беркайчан чормада ятмас бишек, ил исән-сау булса» («Матчага элгән сиде»). Күрәсең, шагыйрьне Р. Фәйзуллинны борчыган проблемалар уйландыра. Чишелеш тә якын. Ләкин аңа ирешү юллары, сурәтле фикерләү, материалны «шигърилаштеру» алымнары үзгә. М. Әгъләмовның барлык шигырьләре дә «бер тын» белән язылмаган. Кызганычка каршы, ул эшләнеп-уйланып бетмәгән шигырьләрен дә бастырып чыгарган. «Учак урыннары» шигыренең фәлсәфәсе каршылыклы һәм логикасыз. «Таулар күп ул» әсәре үзара бәйләнешләре артык шикле булган яисә тышкы, шәкли охшашлыкка корылган җөмләләр тезмәсеннән тора. Менә бер мисал:

**Көтә кебек мине Шәехзадә,**
**Юлым илтә сыман Акмуллага.**
**Өлкәннәргә «ага» диләр бездә —**
**Хөрмәт сүзе. Гомер дә бит ага.**

Соңгы китабында Х. Туфан поэзиясе йогынтысы нык сизелә. Кеше атына атланып ерак китеп булмый, ди халык. Беренче дебюты белән үк ышаныч һәм өмет уяткан М. Әгъләмовтан укучы күбрәкне дә көтәргә хаклы.

Соңгы елларда без поэзиянең тормышчан нигезләре турында күп сөйлибез. Вакыты белән әдәби традицияләрнең көче тормыш белән турыдан-туры бәйләнешкә караганда да куәтлерәк булып чыга, әдипне үзе артыннан ияртеп китә. Халык иҗаты мотивлары, образ һәм сюжетлары язучының хыялын уятып, яңа әсәр иҗат итүгә рухландыра.

Х. Камалов «Тормыш сабаклары» исемле олы бер шигъри бәйләм иҗат итте. Кеше әхлагының, характер-холкының төрле яссылыкларын, катламнарын үзәккә алган бу парчаларны турыдан-туры халык иҗаты сюжетларына кайтарып калдыру дөрес булмас иде. Әмма уңышлыларының халык акылы, халык тапкырлыгы, халык зиһене белән тыгыз бәйләнгән булуы бәхәссез. Сайлап-нитеп тормастан, берничә мисал китерик:

**ЯШЬЛЕК**

**Яшьлек башта күкне сөя,**
**Йолдызларны, айны,**
**Кояшны.**
**Шуларны сөеп туйгачтын —**
**Җирне сөя башлый!**

**ИСЕНДӘ ТОТМАС**

**Берәүгә бер сынык икмәк бирсәң —**
**Гомере буе шуны онытмас.**
**Ә берәүгә гомерең корбан ит син —**
**Ул онытыр, исендә тотмас.**

**ЖӘЛЛИМ ХӘЗЕР**

**Жәллим хәзер —**
**Бер адәмгә табынган чагым!**
**О, түбәнлек —**
**Эткә койрык булып**
**Тагылган чагым!**

Рационалистик фикер, тәрбияви дидактика урынына акыл сатуга нигезләнгән кайбер шигырьләр тешне камаштырып үтсә дә, тулаем алганда, «Тормыш сабаклары» — Х. Камаловның уңышы. Ул үзен ниндидер әзер өлгеләр, кануннар белән чикләмичә, халык хыялы тудырган сәнгатьчә алымнарга таянып, яңа сюжетлы, оригиналь композицияле әсәрләр иҗат итүгә ирешкән.

Хәзерге татар поэзиясе турында фикер йөрткәндә, эпик жанр хакында, дөресрәге, аның шигъри тукымасында барлыкка килгән кайбер тенденцияләр турында бер-ике сүз әйтми китү дөрес булмас иде. Шагыйрьләр поэманы әйләнеп үтмәсәләр дә, бу жанрда уңышларыбыз санаулы. Алдарак без Р. Фәйзуллинның «Гадиләргә гимн», «Көрәшчеләр», Р. Мингалимовның «Күз карасы», Роберт Әхмәтҗановның «Таш аргамак», Р. Харисның «Җитмеш икенче ел икмәге» кебек поэмаларына азмы-күпме тукталган идек. Бу поэмалар арасындагы мәгълүм якынлыкны инкарь итүе кыен: алар барысы да диярлек заман темасын үзәккә алып, публицистик хөкемгә өстенлек биреп, чор конфликтын шагыйрьнең үз шәхесе, үз хисләре аша сынландыру юнәлешендә язылган әсәрләр. Традицион поэма кануннары белән артык санашмыйча, тема таләп иткәнчә язылып, «үз киемнәрендә» туган поэмалар. Кыскасы, безнең каршыда иркен һәм күп сыйдырышлы форма белән иҗат ителгән лирик-публицистик поэмалар. Шунысы кызыклы: соңгы еллар татар поэмасы сюжетлы, эпик поэма үрнәген бөтенләй диярлек бирмәде.

Башка шагыйрьләрнең эзләнүләрен һәм тәҗрибәләрен дә инкарь итмәстән, хәзерге поэма, аның казанышлары турында сүз чыкканда, беренче нәүбәттә, ике фигураны атыйсы килә: Сибгат Хәким һәм Илдар Юзеев. Эпик поэзиянең бүгенге торышы, дәрәҗәсе, намусы һәм ил күләмендәге абруе шул ике әдип каләме һәм илһамы тудырган әсәрләр белән бәяләнә дисәк, шаять, зур күпертү булмастыр. С. Хәкимнең «Дуга», «Васыятьләр», «Кырыгынчы бүлмә» поэмалары турында матбугатта тәпле уңай фикер әйтелде.

И. Юзеев эзләнүләрен төрле юнәлешләрдә алып бара. Соңгы елларда ул үзен фәлсәфи-драматик поэма остасы итеп танытты, «Тынлык белән сөйләшү», «Соңгы сынау» поэмаларында жанр үсешенең принципиаль яңа мөмкинлекләрен ачты яисә онытылыбрак торган үзенчәлекләрен иҗатка кайтарды. Күптән түгел басылып чыккан «Таш диварлар авазы» поэмасы шул юнәлешне дәвам иттерә. Проблематикасы һәм жанр үзенчәлекләре буенча ул «Тынлык белән сөйләшү» поэмасының дәвамы кебек кабул ителә. Ләкин И. Юзеев яңа поэмасында кабатлана дигән тойгы калмасын берүк. Беренче поэмасында шагыйрь үзәккә XX гасыр конфликтын калкытып куйса, хәзер ул тарихны безгә килеп җиткән документлар буенча иңли алырдайераклыкка, дәверләр чатына юл ала, гасырлар һәм тарихи шәхесләр белән иҗтимагый-фәлсәфи диалог башлап җибәрә. Игътибар үзәгендә мәңгелек антогонистик конфликт: явызлык белән азатлык, вәхшилек белән гуманизм арасындагы көрәш тарихы ята. Халык азатлыгы һәм бәйсезлеге бик күп корбаннар сорый. Тарих юлы — канлы юл... Анда үз куллары белән төрмә торгызып шунда черегән коллар, билгесез Болгар чәчәне, акыл иясе Джордано Бруно, Пугачев полковнигы, лашманчы Мәсәгут Гомәров, Фучик, Җәлил... эзләре күренә. Халык олы уллары алдында баш ия. Исемнәрне — язмышларны сайлап алу принцибы бәхәс уятырга да мөмкин. (Бруно, Ленин кебек гигант, тарихи шәхесләр белән беррәттән, билгесез яисә галимнәргә генә мәгълүм исемнәр атала.) Ләкин хикмәт анда түгел. Поэма прогрессның җиңәчәген, караңгы көчләрдән өстенлеген раслый, гуманизмның көченә ышандыра. Эчке логикасы белән ул укучыны шул фикергә алып килә.

«Таш диварлар авазы» — масштаблы, колачлы поэма. Шартлы алымнарны, драма «серләрен» реалистик сәнгать таләпләренә буйсындырып, шагыйрь поэманың офыгын, мөмкинлекләрен киңәйтеп, яңа синтезга килә. «Таш диварлар авазы»на тулы бәя бирүне өстемә алмыйм. Поэма — махсус сөйләшүне таләп итә. Биредә И. Юзеевның яңа иҗади казанышы белән соклануымны әйтеп үтүне генә кирәк таптым. Бу поэма совет әдәбиятының шул жанрдагы югары үрләре дәрәҗәсендә иҗат ителгән әсәр. Хәзер барысы да аны пропагандалый белүгә бәйле.

Кызганычка каршы, поэма жанрында санаулы шагыйрьләр генә эшли. Заманында поэма һәм баллада жанрларында актив эшләп килгән Х. Камалов, М. Шабаев, Ә. Баянов, Ш. Галиев кебек поэзиянең төп көчләре бу авыр һәм катлаулы жанрдан читләштеләр. Хәлбуки, тормышны иңләбрәк сурәтләү, кеше характерын тулырак һәм гомумирәк ачу мөмкинлеге зур булган поэма жанрыннан башка поэзия үсә алмый. Романтик баллада бөтенләй югалып бара.

Уйлана, саный башласаң, поэма жанрында киң аренага чыгарлык шагыйрьләрнең барлыгына инанасың. Яшьрәк буынны алыйк, Р. Фәйзуллин, Зөлфәт, Р. Харис, Р. Мин-

галимовлар поэма жанрында эшләрлек колачлары барлыгын исбат иттеләр инде. Әхмәт Рәшитов «Минем шәҗәрәм» исемле поэмасы белән үзенә урын дауларга сәләте барлыгын күрсәтте. Кыскасы, потенциаль мөмкинлекләр, олы характерларны үзәккә алып, киң эпик полотно тудырырлык көчләр бар. Шагыйрьләребезгә иҗади батырлык һәм рухи кыюлык кына кирәк. Шунысын да искәртик, Э. Межелайтис, Ю. Марцинкявичюс, Д. Кугультинов, А. Кулешов кебек шагыйрьләр Союз аренасына поэма белән чыктылар. Бу мәсьәләдә махсус сөйләшер проблемалар бик күп.

Безнең поэзиягә, бик олы казанышлары булуга карамастан, чор алдында, укучысы каршында җаваплылык хисе җитенкерәп бетми. Шагыйрь еш кына, агымга бирелеп, күзенә нәрсә чагылса, шуны кәгазьгә төшерү юлына баса. Көньякка ялга барып кайттымы — Кырым, Грузия һәм магнолияләр турында цикл туа. Шагыйрьгә яңа квартира бирделәрме — берәр атнадан шул хакта бер бәйләм шигырьне көт тә тор. Әдипләребезнең күбесе авылда туып, югары уку йортларында белем алып, шәһәрдә урнашып калалар. Бирeдә искитмәле нәрсә юк. Тормыш диалектикасы шундый. Ләкин ни өчен бу аерылышуны фаҗига санап, туган авылына тугрылыгы, аны сагынуы турында томтом шигырь сырларга. Түзеп булмаслык дәрәҗәдә сагынасың икән, Шолохов шикелле, тот та авылыңа күчеп кит, шунда яз. Газета актарып утырганда, авыл хуҗалыгы һәм төзелеш алдынгыларының исемнәре күзенә чалынса, дөньяга яңа күләмле әсәр шытып чыга һ. б. Кыскасы, тема белән яну, шигырь белән яшәү, фикереңне, хисеңне метафора белән рифма кулына тапшырганчы чәчне агарту, кеше язмышы өчен сызлану һәм чын йөрәктән шатлану кебек олы төшенчәләр ничектер әйләнештән төшеп бара. Бу гамьсезлек үз чиратында уртачалыкка алып килә.

Сүзнең соңында яшьләр турында берничә фикер. Әдәби алмаш һәркемне борчый, һәр чыгышта, һәр мәкаләдә, һәр докладта диярлек бу хакта бәхәс уяна. «Казан утлары» узып киткән елларда яшьләр һәм башлап язучылар иҗатына урынны кызганыбрак бирә башлады. Мондый рационализмда бәлки дөреслек тә бардыр. Еш кына журнал ай саен төркем-төркем яңа исемнәр белән таныштыра, хәер-фатиха бирә, ә соңыннан аларның күбесе моны акламый, хәзерлексез, сәләтсез һәм яшьлек хисенә бирелеп, очраклы рәвештә генә каләмгә ябышкан кеше булып чыга. Яшьләрне тәкъдим иткәндә журнал-газета һәм нәшрият төркем-төркем чабаклар арасында берәр алтын балык килеп эләкмәсме дип эш итә торганнардыр. Күрәсең, алтын балыкны алай җиңел генә эләктереп булмый.

Татарстан китап нәшрияты үзенең күркәм традициясен үстереп, яшь шагыйрьләрнең коллектив җыентыкларын бастырып чыгару эшен дәвам иттерде. Шуларның берсенә тукталыйк. «Юл башы» китабы электән таныш, газета-журналларда һәм җыентыкларда берничә ел басылып килгән дүрт шагыйрьне тәкъдим итә: Рифгат Закиров, Флера Гыйззәтуллина, Фәннур Сафин, Кадыйр Сибгатуллин. Дүртесе дә, һичсүзсез, сәләтле һәм өметле яшьләр. Әмма китапта уйландыра, дулкынландыра алырлык шигырь күп түгел. Яшьләр күбрәк тә үз шәхесләре белән мәшгуль. Идиллия, үз-үзләреннән канәгать булу хисе өстенлек итә. Аларны тарих һәм чор сулышыннан бигрәк, мәхәббәт мәсьәләләре борчый. Бер үк тема тирәсендә әйләнә торгач, шигырь ваклана, тәэсири рухын югалта башлый. (Р. Закиров — «Лирик хат», «Көткәндә»; Ф. Гыйззәтуллина — «Кил бире»; Ф. Сафин — «Ак күлмәкле кызлар керә төшләргә...» һ. б.) Китапта романтик сурәт, чынбарлыкны иңләбрәк һәм хыял белән бизәп, идеал аша сурәтләү бөтенләй диярлек очрамый. Бу хәл яшьләр иҗатына гына карамый. Мәсәлән, С. Сөләйманова соңгы елларда шактый уңышлы эшләде. («Гомер», «Киткәннәрнең юллары озын...» шигырьләре уңай тәэсир калдыра.) Әмма берише шигырьләрендә лирик герой җегәрен әһәмиятсез һәм каршылыклы хисләре белән көрәшүгә сарыф итә:

**Вәгъдәләрем анда, өметләрем...**
**Син дә җирсез, илсез ир түгел.**
**Юк, карамыйм әле күзләреңә,**
**Җирдә үзем салган эзләрем бар,**
**Кош канаты — кашың-керфегең.**

*(«Аһ, ник түгел җилдәй җиңел чагым?»)*

Рифгат Закиров белән Әхмәт Гаделнең журналда басылган яңа шигырьләре дә артык гадәти, дулкынландырмый да, күңелдә дә калмый. Рашат Низамиевның шигърият рухы кунмаган «Привалда» әсәренең темасы өчен генә бастырылып чыгарылган булуы аяныч:

> **Пилоткамда — поход тузаннары,**
> **Ике битем бүйлап тир ага.**
> **Шушы хәлдә, сабый бала сыман,**
> **Карап торам менә дөньяга.**

Поэзия — кешеләр арасында аралашу чарасының үзенчәлекле төре. Шагыйрь илһамын ирекле шигырьгә тапшырамы, «ирексез» шигырьгә өстенлек бирәме, укучы өчен барыбер. Тик чорны, заман рухын шәхес кичереше аша чагылдыра алырлык шигырь генә булсын. Чынында исә дистәләгән әсәрләр поэзиягә эчтәлеге, пафосы һәм тормыш материалын үзенчә күрә белүеннән бигрәк, аңа тышкы киеме, тезмә белән язылуы буенча гына охшый. Ул төр әсәрләрдә шигъри яңу һәм кабатланмас интонация, көз айларындагы кояш шикелле, сирәк очрый.

Хәзерге поэзиядә үзгәреш-яңарыш процессы дәвам итә. Күз алдында рифманың әһәмияте кимеде, композиция һәм сүзне көтелмәгәнчә яңгырата белү гадәттә рифмага төшкән йөкне үзенә алды. «Әдәби форма, кеше фикерләве кебек үк, прогрессивлаша... Мәңгелек әдәби кануннар юк»,— дип яза Э. Межелайтис. Ләкин бу фикер гасырларга хезмәт иткән эстетик казанышларны читкә ыргытуга фатиха дигән сүз түгел. Яңалык буш урында һәм үзенә чаклы ирешелгәннәрне инкарь итү җирлегендә туа алмый. Шигырь үзенең яңалыгын, дәреслеген, маһирлыгын исбатлап, үзенә караганда йомшагракны җиңеп һәм аңа таянып дөньяга килә. Әдип элгәрләренең тәҗрибәсен исәпкә алмыйча, үзе белгәнчә, интуициясенә таянып кына эш кылса, ул иҗат итүдән туктый. Элгәрләренең эшчәнлегендә, милли формаларда бик күп буыннарның зиһен җегәре, фикерләү сәләте чагыла.

Сәнгатьнең башка төрләре шикелле үк, поэзия дә арадаш жанрларның үсешенә киң таяна, проза, драма ачышларын үзенә сеңдерә. Бу бәйләнеш бик катлаулы һәм четерекле. Башка жанрлардан үрнәк алганда да шигырь шигырь булып калырга тиеш.

Соңгы елларда поэзия дип тәкъдим ителеп тә, проза булып калган әсәрләр күбәйде. Бигрәк тә ирекле шигырь белән язылганнарында.

Һәр олы шагыйрь әсәренең эчтәлегенә тиң форманы таба. Ләкин әдәби форма үзе дә мәгълүм бер мөстәкыйльлеккә ия. Ул, тормышта барлыкка килгән үзгәрешләрнең чагылышы буларак, бу хәрәкәтне тизләтү омтылышыннан туа. Шул вакытта гына эчтәлек белән форма арасында гармония табыла.

## *КИТАП КҮЗӘТҮ*

# ПАУСТОВСКИЙНЫҢ ГУМАНИЗМЫ

Гадәттә, рецензияләрне укучыны яңа китап белән таныштырудан, тикшерелә торган китапның кереш өлешләрен бәяләүдән башлыйлар. Без исә башкарак юл сайладык. Күренекле совет язучысы Константин Паустовский иҗатын өйрәнү нигезендә монография авторы[1] нинди яңа фикерләр әйтә, нинди нәтиҗәләргә килә — сүзне әнә шул мәсьәләдән башларга булдык.

Хезмәтенең йомгак өлешендә Л. Ачкасова болай ди: «Һәр зур язучы иҗаты кебек, Паустовский иҗаты да — катлаулы һәм кабатланмас сәнгать күренеше. Икенче Гайдар, икенче Катаев яки икенче Пришвин булмаган кебек, икенче Паустовский да була алмый. Әдәбият тарихындагы урыннары һәм рольләре вакытлар узу белән генә, әдәби процессларга киң гомумиләштерүләр ясау, әдәбияттагы тарихи үсеш этапларының үзенчәлекләрен тирәнтен өйрәнү һәм шуларны художникның үз иҗат эшчәнлеге белән чагыштырып карау нигезендә генә ачыклана торган язучылар бар. Паустовский — шундый язучыларның берсе».

Бер караганда, бу фикерләр күп дәлилләр һәм фактлар ярдәмендә исбатланырга, расланырга тиешле декларация кебек янгырый. Әмма мондый декларация хезмәтнең йомгак өлешендә китерелгәч, аны алдагы фикер йөртүләрнең нәтиҗәсе кебегрәк кабул итәсең. Чөнки Паустовский гуманизмының социаль аспекты нигездә эстетик аспектлар аша чагыла. Хезмәттә Паустовский иҗатындагы гуманизмның социаль аспекты әзлекле рәвештә карала, алай гына да түгел, әдәби процесс белән, совет әдәбиятының иҗат практикасы белән тыгыз бәйләнештә өйрәнелә.

Паустовский иҗаты чынбарлык турында өзлексез уйланулар чылбырыннан тора. «Өзек-өзек берничә фикер» исемле мәкаләсендә язучы моны үз характерының төп сыйфаты дип саный. Монография авторы дөрес нәтиҗә ясый. Чыннан да, социальлек, тарихилык һәм социалистик халыкчанлыкны соңгы дәвер Паустовский иҗатындагы кеше концепциясенең төп сыйфаты дияргә була. Талантлы язучының иҗат методын билгеләү мәсьәләсендә дә, аны социалистик реализм методының төп принциплары белән бәйләнештә карау ягыннан да әлеге нәтиҗәләрнең принципиаль әһәмияте бар. Нәкъ әнә шул нәтиҗәләр аша Л. Ачкасова хезмәтендәге төп фикергә килә. Өлгергән Паустовский иҗаты социалистик реализм методының төп юлыннан барды, аның иҗатын, аның әсәрләрен социалистик реализм методының үзенчәлекле бер формасы итеп карарга кирәк, ди монография авторы.

Хезмәтнең йомгак өлешендә ясалган нәтиҗәләр белән таныштык. Хәзер инде андагы аерым бүлекләргә, ул бүлекләрдә күтәрелгән мәсьәләләргә күз ташлыйк.

Кереш бүлек гуманизм терминының мәгънәсен ачыклаудан башлана. Монография авторы бу мәсьәләгә багышланган хезмәтләргә төпле күзәтү ясый, алардагы төгәлсезлекләрне, хата фикерләрне күрсәтә. Теманың артык киң, ә монография күләменең чикләнгән булуын истә тотып, галим үзенең төп игътибарын Паустовский гуманизмының аеруча аз өйрәнелгән ягына, аның гуманизмының «социологик» аспектына юнәлтә.

«Совет әдәбиятының гуманизмы һәм Паустовский карашларының формалашуы» дигән беренче бүлек, исеменнән үк күренгәнчә, язучы иҗатының аерым этапларын тикшерүгә багышланган. Паустовский иҗатындагы үсеш баскычлары революцион гуманизм тудырган новаторлык — Бөек Октябрь революциясе казанышлары нәтиҗәсендә барлыкка килгән новаторлык фонында карала. Л. Ачкасова хаклы, революция ту-

[1] Л. С. Ачкасова. Гуманизм в творчестве Паустовского. Рус телендә. Казан дәүләт университеты нәшрияты, 1972 ел.

дырган әлеге новаторлыкның, социалистик (коммунистик) идеалның асылына төшенү барлык язучылар өчен дә бер дәрәҗәдә җиңел булмады. Филология фәннәре докторы Ю. Барабаш бу мәсьәләне тагын да ачыклый төшә. «Халыкчанлык турында» исемле китабында ул болай ди: «...язучының революциягә мөнәсәбәте, халәт булудан бигрәк, процесс иде, язучы революциягә акрынлык белән килгән очракта бу аерата шулай». М. Пришвин, Э. Багрицкий, И. Бабель һәм А. Грин да, 20 еллардагы башка романтик язучылар да катлаулы һәм каршылыклы иҗат юлы уздылар. Константин Паустовский хакында да шул ук сүзләрне кабатларга туры килә.

Билгеле булганча, яшь Паустовский иҗаты идеалист философ Бергсон карашлары тәэсирендә формалаша. Бу нәрсә язучының «Романтиклар» (1916—1923) исемле беренче зур повестенда аеруча нык сизелә. Монография авторы аның бу әсәрен «әлегә җаваплары табылмаган китап» дип атый. Һәм дөресе дә шулай, авторның теләге никадәр генә изге һәм яхшы булмасын, әсәрдә әледән-әле очрап торган идеалистик антропологизм әдәби иҗатны принципиаль төстә социологиядән аера, ахыр чиктә, язучының үз гуманистик омтылышларына да социаль аныксызлык кертә. Әсәр интеллигентлык иллюзияләреннән котылып җитмәгән Паустовскийның әдәби карашларындагы эклектизм һәм каршылыклар турында сөйли.

Өлгергән Паустовский бөтенләй башка кеше булып күз алдына килә. Бары аңа гына хас кайнарлык белән ул романтик сәнгатьнең үзенчәлекләре, художникның югары гражданлык бурычлары турында уйлана, совет сәнгатенең бөтен җир шарында башкарган бөек миссиясе белән горурлана. «Сайланма әсәрләр»енә язган кереш сүзендә художник болай ди: «Романтикада кешене яктырта, күтәрә торган көч бар. Киләчәк тормышыбыз өчен көрәштә, хәтта көндәлек гади тормышта да аннан ваз кичтерерлек берниндли акыллы дәлилләрнең булуы мөмкин түгел».

Игътибар иткәнсездер, «Романтиклар» повесте белән әлеге фикерләр арасында күпме аерма бар! Язучы аларга еллар буена сузылган газаплы эзләнүләр, сәнгать әсәрләренең социаль табигате турында өзлексез уйланулар аша килә. Шул эзләнү процессында акрынлап аның дөньяга карашы үзгәрә, ул идеализмнан материализмга килә, дөньяга марксистик-ленинчыл караш белән коралланa.

Бу нәрсә аның әдәби әсәрләрендә дә ачык чагыла. Яшь Паустовский романтик юнәлештәге художник булган, дидек. Әмма ул бервакытта да романтикларның реакцион канатына кушылмый. Беренче әсәрләренең геройлары арасында (шул ук «Романтиклар» повестендагы язучы Максимовны яки «Су өстендә» (1912) дип исемләнгән автобиографик хикәянең үзәк героен алып карагыз) иҗтимагый тормыштан читләшкән кешеләр бар. Хәтта шундый очракларда да моны, җир тормышына кул селтәүдән бигрәк, аларның яшәп килгән иске стройга протестлары дип бәяләү дөресрәк булачак. Шул рәвешчә, иҗат юлының беренче адымнарыннан ук Паустовскийның кешенең асылы турындагы уйланулары берничек тә социаль проблемаларга бөтенләй кагылмый уза алмый иде. Соңрак, Бөек Октябрь революциясе җиңгәч, ил каршына яңа социаль-политик мәсьәләләр килеп басты. Аларның күбесе социалистик стройны раслау белән бәйләнгән иде. Л. Ачкасова монографиясенең һәр бүлегендә Паустовскийның әлеге мәсьәләләрнең асылын иҗади үзләштерү юнәлешендә нихәтле катлаулы һәм каршылыклы юл узуын күзәтә. Язучының «Кара-Бугаз», «Колхида», «Алтын роза», «Тормыш турында повесть», «Иске шинельле карт», «Ерак сәяхәтләр шигърияте», «Ильин чоңгылы» кебек әсәрләрендә инде «социаль категория белән эстетик категория арасында ныклы күперләр салынган иде», ди галим. Бу әсәрләрдә тормышны романтик сәнгать алымнары ярдәмендә танып-белүнең методологиясе үк бик нык үзгәрә, художник дөньяга яңача, социалистик караш белән коралланып өлгерә.

Хезмәтнең «Социаль кеше» концепциясенең формалашуы» дип исемләнгән икенче бүлегендә язучы гуманизмының социологик аспектын өйрәнүгә караган мәсьәләләр күтәрелә. Л. Ачкасова бик дөрес яза, Паустовский иҗатының иң көчсез өлеше — социологик аспект. Хикмәт шунда, аның әсәрләре романтик сәнгать алымнарына нигезләнгән. Бу — аның иҗатын өйрәнгәндә өстәмә кыенлыклар тудыра. Аңлатудан, бәя бирүдән бигрәк, аның әсәрләрендәге социологик мәсьәләләрне тотып алуы, аерып күрсәтеп бирүе кыен. Менә шуңа күрә дә галимнәр һәм тәнкыйтьчеләр байтак еллар буе Паустовский иҗатының бу ягын читләтеп узарга тырыштылар. Алай гына да түгел, язучы әсәрләрендә социаль мотивлар булмауда гаепләделәр, аның иҗа-

тын башка совет язучылары иҗатына каршы куярга, хәтта социалистик реализм сәнгатеннән читләштерергә тырышып карадылар. Шуннан файдаланып, буржуаз галимнәр аны күкләргә чөйделәр, сәнгатьтәге экзистенциалистик агымнарга якынайтырга маташтылар.

Ул чорлар артта калды. Соңгы елларда-гы совет әдәбият фәнендә, бигрәк тә совет сәнгатендәге романтик мәсьәләләрне өйрәнүгә игътибарның көчәюе нәтиҗәсендә, Паустовский иҗатын өйрәнүгә багышланган күп кенә кызыклы хезмәтләр барлыкка килде. Биредә, мәсәлән, Н. Антипьев, В. Яценко, З. Крылова, Л. Саприна, Е. Алексанян һәм башкаларның хезмәтләрен телгә алып китәргә мөмкин. Аларның кайберләре Паустовский иҗатындагы «социаль кеше» концепциясен күрсәтеп үтү белән чикләнә, икенчеләре исә эчкәрәк керәләр. Әмма берсендә дә мәсьәләгә төрле яктан, төрле ноктадан карап төпле бәя бирү очрамый диярлек.

Л. Ачкасова хезмәтен асылда монографик типтагы беренче социаль хезмәт дияргә була. Монография төпле фәнни фикерләре, яңа, оригиналь күзәтүләре белән игътибарны җәлеп итә. Шул сыйфатлары аны конкрет бер язучы иҗатын өйрәнүгә багышланган чираттагы гадәти хезмәт итеп кенә түгел, ә социалистик реализм сәнгатендәге романтик юнәлешне өйрәнү юлында кулланма, методологик таяныч була ала торган хезмәт дип бәяләргә мөмкинлек бирә.

Монографиянең «Халыкчанлык проблемасы», «Кеше һәм тарих», «Социализм — «реаль гуманизм» дип исемләнгән бүлекләре дә кызыксыну белән укыла. Л. Ачкасова гуманизмның тарихи формалашкан төп структур аспектларын күзәтеп чыга, аларның реалистик сәнгать әсәрләрендә ничек чагылуларын аңлатып бара.

Билгеле, тикшерүче үз алдында торган барлык мәсьәләләрне дә бер дәрәҗәдә уңышлы хәл иткән, дип булмый. Әйтик, бүлектән-бүлеккә автор классик романтизмның бик үк анык булмаган идеалын яңа, социалистик романтизмның бик төгәл һәм анык иҗтимагый идеалы белән чагыштырып, янәшә куеп бара. Сүз дә юк, бик оста һәм уңышлы чагыштырып бара. Аны аңларга була. Паустовский, беренче чиратта, романтик язучы. Әмма, ни генә булмасын, безнең Паустовский иҗатына багышланган хезмәттә шундый сорауга да җавап табасыбыз килә: әйтик, социалистик гуманизмның «реаль» һәм «романтик» юнәлешләре арасында нинди структур аерма бар? Кызганычка каршы, китаптан бу сорауга җавап табып булмый. Хәлбуки, әлеге мәсьәлә нәкъ менә Паустовский хакында язылган хезмәттә хәл ителергә тиеш иде. Билгеле булганча, өлгергән Паустовский әсәрләрендә, «ул үз характерының органик сыйфатына һәм романтиклык талантына турылыклы булып калса да», тормышны сәнгатьчә гәүдәләндерә торган алым һәм чаралар ачыктан-ачык «реаль төс»ләрен югалталар. «Социаль кеше» концепциясенең формалашуы» дигән бүлектә Л. Ачкасова үзе дә шул хакта яза. Нәкъ менә шул урында мәсьәләне ачыклый төшәргә иде.

Прозада беренче совет шагыйрьләреннән саналган Паустовский беркайчан да көндәлекләр язмый, куен дәфтәрләре йөртми. Ул кеше хәтеренең кирәкле нәрсәләрне генә саклый алу сәләтенә ышана. Аның әсәрләренең башка бер генә язучыныкына да охшамаган үзенчәлекле сыйфатлары бар. Аның әсәрләренең стилен беркемнеке белән дә бутап булмый, ул һәрчак үзе булып кала белә. Менә шуңа күрә дә аның әсәрләрен тикшерү, аның әсәрләренә хас сыйфатларны сүтү, аерым кисәкләргә бүлгәләү — ифрат кыен эш. Әсәрләренең нәкъ шул сыйфатларын күздә тотып, В. Солоухин аның иҗатын «Константин Паустовский иле» дип атады, шунда ук «Паустовский иле — географик төшенчә түгел, ә эстетик, инде телисез икән, рухи төшенчә ул», дип тә өстәде.

Әгәр Л. Ачкасова язучы иҗатын сүтә, математика ярдәмендә тикшерә алган икән, бу — аның бәхәссез уңышы. Монография авторы ирешкән казанышлар совет сәнгатендәге романтик әсәрләрнең үзенчәлекле эстетик сыйфатларын өйрәнүче галимнәр өчен ныклы таяныч булачак.

Үзенең «30 ел эчендә» дигән китабында А. Фадеев романтик совет сәнгатен «романтик формаларда тормыш дөреслеген чагылдыручы» сәнгать дип атаган иде. Л. Ачкасова әлеге тезисны тагын да конкретлаштыра төшә, аңа фәлсәфи, тарихи-конкрет сыйфатлар өсти, шуның белән укучыларда үз китабына кызыксыну уята.

Социалистик реализм — тере, хәрәкәттәге метод, прогрессив кешелек җәмгыяте гасырлар буе тудырган культура казанышларын үзенә мирас итеп алган метод. «Паустовский иҗатында гуманизм» дигән китап тагын бер тапкыр әнә шул фикерне куәтли.

**И. АХУНҖАНОВ,**
**В. ЗЕЛЕНКОВ.**

# СИБЕЛӘ ЧӘЧӘК ҖИЛЛӘР ИСКӘНДӘ

Сибгат Хәкимнең «Сибелә чәчәк» исемле яңа җыентыгы[1] басылып чыкты. Аңа шагыйрьнең соңгы өч-дүрт ел эчендә иҗат иткән шигырьләре кергән. Бу яктан, ул — зур мираслы өлкән әдипнең чираттагы шигырь китабы, укучыга бүләк иткән нәүбәттәге шигырь бәйләме. Ләкин кабатлануны сөймәүче шагыйрь өчен яңа китап нәүбәт үткәрү генә түгел, билгеле. Һәм андагы шигырьләрне укыганда бу фикер тулысы белән раслана, әдипнең таланты яңа үзгәлекләр, яңа сыйфатлар белән ачылуын күрәсең:

Бар иде бер тапкан зәңгәр тартмам
(Сез уйлыйсыз: сабый сөенгән),
Ачкычы юк ләкин, ишетәм, тоям,
Чылтырыйлар төптә тиеннәр.

Чылтырыйлар... Кызыгуым түгел
Я шөһрәткә, данга, я малга,
Җырлар шунда, заман — зәңгәр тартма,
Ачкыч эзлим һаман заманга!

Заманның, төрле чорларның шигъри ачкычы хәтта зур шагыйрьгә дә җиңел генә бирелми. Шуңа да әдип әледән-әле үткән чорларга, узылган юлларга әйләнеп кайта. Аларны күңел күзеннән үткәрә, бүгенге тәҗрибәсе, бүгенге аң дәрәҗәсе югарылыгыннан торып бәяли. Болар бүгенге чорны тирәнрәк аңлау, аның рухын ачыграк тою өчен кирәк.

Шагыйрь ил белән, халык белән бергәләп, озын юллар кичте. Авыр сугыш, аннары хуҗалыкны аякка бастыру еллары, үсү, үзгәреш чорлары. Гел иҗатта, эзләнүдә шагыйрь.

Алтмышым, язмышың зурга
Сөенә-сөенә атлыйсың,—

ди шагыйрь бер шигырендә. Гомернең үтелгәне — мәгънәле дә, нәтиҗәле дә. Артта калган еллар — зур идеаллар өчен көрәш шаһитләре, алар үзләреннән-үзләре җырга керергә сорап торалар. Андый гомер — ул горурлык. Ләкин шагыйрьнең горурлыгы, тәрәзә пыяласындагыдай, бер яссылыкта гына чагылмый. Китаптагы кайбер шигырьләрне укыгач, Бакый Урманченың «Сагыш» дип аталган мәшһүр скульптурасы күз алдына килә.

Сезгә эндәшми мин кемгә
Эндәшим, өянкеләр?
Җитте минем дә сезнең күк
Картайдым дияр көннәр.

(«Сезгә эндәшми мин кемгә...»)

Бу да сагыш һәм без аны аңлыйбыз. Ләкин шагыйрьнең сагышы тик аның картлыгы өчен генәме? Юк, китаптагы шигырьләрдә бу хис тирәнрәк, баерак булып ачыла.

Мин торам, еллар күңелгә
Сагышын салып узган.
Ташулар аккан урында
Сары ком, сары эзләр...

(«Яз килә...»)

Гомер әнә шулай ташу булып аккан, ул ташуның инде үтеп баруы — сагыш хисен уята, ә шаулап-гөрләп аккан булуы горурлык хисләре тудыра. Әйе, бу — горур сагыш.

«Сибелә чәчәк» китабына кергән һәм аерым шигъри циклларда күтәрелгән темалар шактый күп. Авыл, игенче хезмәте, туган йорт — шуларның кайберләре. Нигезйорт хакында борыннан килгән мәгънәне шагыйрь нечкә тоя гына түгел, әлеге традицион образны үстерә һәм баета да:

Юк, бетми нигезләр, халкым
Давылы-җилләренә
Бирешми, яши, ышанам
Мәңгелек җегәренә,

(«Күпме моңайдым авылда...»)

Кырлар темасы Сибгат Хәким иҗатында бик күптәннән килә. Һәр вакыт әле бер, әле икенче ягы, яңа көе-моңы, яңа тәсмерләре белән ачыла. Бу китабында шагыйрь теманың тагын да киңрәк мәгънәләрен тап-

[1] С. Хаким. Сибелә чәчәк. Татарстан китап нәшрияты. 1973 ел.

кан. Үзендә күп буыннарның рухын сеңдергән дә тонык кына нидер көйли сыман кырлар. Бер генә жыр түгел анда, күңелеңне нечкәрт, күңелеңне тупла, җирнең өнен-авазларын ишет. Ул кырлар сиңа ялан җир булып түгел, тормыш кырлары булып ачылырлар. Шагыйрь җанлы, игенче һөнәрле халкыбыздан күчкән ул моңнар. Кырдагы карт игенче һәм басуларны әйләнүче шагыйрь образлары шигырьләрдә бергә килеп кушыла, җыр булып китә. Чөнки язмышлары, зур хыяллары уртак.

Якыннан торып күреп бетерелмәгән нәрсәне читкәрәк китеп карыйлар. Шагыйрь дә туган җиренең җылысын, аның суларының тәмен еракта йөргәндә ачыграк тоя. Китапның бер өлешен авторның Карловы Варыда дәваланганда кичергән уй-хисләре хакында сөйләүче шигырьләре алып тора.

Тоям артта бөек Идел барын,
Тоям артта Ватан, чик барын.
Телләреннән Фучик тавышын тыңлап
Арасында йөрим чехларның,

Телләреннән миңа рәхәт, шат тел,
Үзләренә тагы рәхәттер.
Яратамын: горур булсын халык,
Тик булмасын гына тәкәббер.

(«Тоям артта бөек Идел барын...»)

Тукай темасын Сибгат Хәким куптәннән нечкәләп эшли. Бу җыентыкта аңа аерым бүлек багышланган. Китапка кергән ике поэманың берсе — «Кырыгынчы бүлмә» — Тукай турында. Тукай темасы — чиксез тема. Һәм халкыбызның рухи тормышында Тукайның урынын иңләп бетерү — кыен мәсьәлә. Сибгат Хәким «Кырыгынчы бүлмә», «Шагыйрьнең бала чагы», «Пар ат» кебек поэмаларында, күп санлы шигырьләрендә әнә шул турыда уйлана.

Килде Тукай, килде шагыйрь җырлап
Хөр тойгыны, азат тойгыны...
Тукай, Тукай татар халкының ул
Бугазында газап төере...

Йөрәккә үтеп керерлек әнә шундый көчле, үткен образлылыкны туплаган шигырь юллары күп монда. Озак эзләнү, таләпчәнлек, илһам куәте белән туган юллар...

Чын шагыйрь иҗаты аша халык телгә килә, заман үзе сөйли. Бүгенге көнебезнең аһәңнәре китапның «Чорым, синең хисләр белән янам» дигән бүлегендә аеруча ачык яңгырый.

КамАЗ турындагы шигырьләрендә булсын, башкаларында булсын, шагыйрьнең сүзе саллы, чорның кыенлыгын җиңеләйтми, арзан буяуларга буямый, шигырьдә заманның үз төсен, яңгырашын табарга омтыла. Яңа төзелеш, яңа шәһәрләргә багышланган әсәрләрендә ул кичәгедән бүгенгегә күчүнең кискенлеген, тирәнлеген, каршылыклы булуын күрсәтергә тырыша:

Бөеклекләр — мин КамАЗлар аша
Барам һаман алга, алда — ялав,
Актарыла җирем, кайный ягам,
Янам мин дә, шунда бергә янам.
Чорым, синең хисләр белән янам.

(«Бар нигезләр бергә...»)

Өлкән шагыйребезнең бу китабын укып чыккач, үз-үзеңә: «Иң гүзәл чәчәк тә сибелмичә булмый, җилләр сибә икән чәчәкләрне», дисең. Хәер, сибелсен. Халык күңеленә сибелә бит ул гүзәл чәчәкләр!

**Рим ШИРИЯЗДАНОВ.**

## КАМИЛ ЯКУБОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Ялкынлы революционер, большевик-ленинчы К. Якубов 1894 елның 21 мартында Бөгелмә өязенең (хәзерге Куйбышев өлкәсе, Шонталы районы) Аптекай авылында туа. Башта Чистайда, аннары Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Үзлегеннән белем алып, укытучылыкка имтихан бирә.

1915—1917 елларда К. Якубов патша армиясендә хезмәт итә. Февраль революциясеннән соң большевиклар партиясе сафларына керә, солдатлар арасында агитация эше алып бара башлый.

Камил Якубов Казанда Октябрь кораллы восстаниесен хәзерләү һәм үткәрүдә турыдан-туры катнаша. Восстание җиңгәч, Вакытлы революцион комитет составына кертелә.

1918 елның январь аенда уздырылган Икенче бөтен Россия мөселманнар хәрби съездында К. Якубов башка большевиклар белән берлектә съездның реакцион делегатларына каршы кискен көрәш алып бара. Гомумән, ул бу чорда революцион эшкә бөтен көчен, энергиясен бирә. Шәһәр гарнизоны солдатлары һәм эшчеләр арасында чыгышлар ясый. Мөселман социалистлары комитеты эшенә актив катнаша.

К. Якубов Беренче бөтен Россия мөселман коммунистларының съездын (1918 ел, ноябрь) оештыручыларның берсе була, ленинчыл милли политиканы үткәрүдә Казан большевиклары оешмасына зур ярдәм күрсәтә.

1919 елны ул Үзәк мөселман хәрби коллегиясе члены буларак, Көнчыгыш фронтка бара. Хәрби коллегиянең К. Якубов җитәкләгән политбүлеге кызылармеецларга культура-тәрбия хезмәте күрсәтү, аларга Колчак бандаларының явыз ниятләрен аңлату буенча зур эш җәелдереп җибәрә.

25 яшьлек революционер К. Якубов 1919 елның җәендә милләтче контрреволюционерлар тарафыннан ерткычларча үтерелә.

Татарстан хезмәт ияләре большевиклар партиясенең турылыклы улы Камил Якубовның якты истәлеген хөрмәт белән саклыйлар. Республикабызның иң зур Матбугат комбинаты, Казанның бер урамы аның исеме белән йөртелә.

## «ЯЛКЫН» ЖУРНАЛЫНА 50 ЕЛ

Шушы елның март аенда «Ялкын» журналының чыга башлавына 50 ел тулды.

«Ялкын»ның шәҗәрәсе «Кечкенә иптәшләр» журналыннан башланып китә. Бу журналның беренче саны Мәскәүдә 1924 елның мартында дөнья күрә.

Ярты гасыр эчендә журналның исеме берничә мәртәбә үзгәртелә. 1929 елдан ул «Октябрь баласы» исеме белән Мәскәүдә, 1933 елдан «Пионер каләме» исеме белән

Казанда чыга. Бөек Ватан сугышыннан соң журнал «Пионер», ә 1957 елдан «Ялкын» дип аталып йөртелә башлый.

«Ялкын» журналының тарихы герой-шагыйрь Муса Җәлил һәм аның көрәштәше Абдулла Алиш исеме белән бәйләнгән. Муса Җәлил 1927 елдан 1933 елга кадәр журналның редакторы, ә Абдулла Алиш озак еллар җаваплы секретаре булып эшли.

Язучыларыбыз 50 ел буена балалар журналына әдәби әсәрләре белән катнашып килделәр. Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Рахман Ильяс, Салих Баттал, Абдулла Әхмәт, Әминә Бикчәнтәева, Гарәфи Хәсәнов, Җәвад Тәрҗеманов һәм башка бик күп язучыларның таланты нәкъ менә шушы журналда ачылды.

Филология фәннәре кандидаты, профессор Хатип Госман үзенең иҗат юлын «Кечкенә иптәшләр»дә шигырьләр бастырып башлый.

Сугыштан соң А. Әхмәт, Л. Ихсанова, И. Юзеев, Г. Мөхәммәтшин кебек күренекле язучылар, М. Җәлил, А. Алишлар башлаган күркәм традицияне дәвам иттерү белән беррәттән, журналның сыйфатын тагын да яхшыртуга күп көч куйдылар.

«Бүген «Ялкын» журналына иң актив язышучы өлкән әдипләрдән Н. Исәнбәт, Г. Галиев, А. Шамов, И. Туктар, Р. Ишморат, Г. Минский, Г. Әпсәләмов, А. Расих һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин. Н. Дәүли белән Җ. Тәрҗеманов — күп еллардан бирле журналның редколлегия членнары.

Соңгы елларда журналның тиражы да үсте. «Кечкенә иптәшләр», мәсәлән, 3 мең данә булып чыкса, бүгенге «Ялкын»ның тиражы 80 меңгә җитте. Бу журналны Татарстанда гына түгел, Советлар Союзының төрле почмакларында яшәүче татар балалары да алдыралар, яратып укыйлар.

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ СТЕНА ГАЗЕТАСЫ «ТЫНГЫСЫЗ КАЛӘМ» БЕЗДӘ КУНАКТА

## Тмин

## ЛИРИК АБЫНУЛАР

### ЛОГИКА

Син сөясең, мин дә сөям,
Мин ник сөям, син нигә?
Син белмисең, мин дә белмим,
Кайтышыйк мәллә өйгә?

### ТЬФҮ!

Урманнарда гөмбә эзлим,
Үз бакчамда — викторий.
Күтәрелеп караган юк —
Янымда кызлар йөри.

### ЮАНУ

Тышта кыш — буран котыра.
Карап торам тәрәзәдән:
Борын очын уа-уа
Егет бара бер кыз белән.
Үзе, бәгырь, көлгән була,
Кызга нидер әйткән була.
Карап торам тәрәзәдән —
Күңел йомшый, күңел тула.
Яшь егетләр нужа чигә,
Мин өемдә, мин җылыда.
Хатын коймак чыжылдата —
Кайчак ярый ир булу да.

### ВЕК ЖИВИ, ВЕК УЧИСЬ

Бакчада бер кызны күрдем,
Аның белән бергә йөрдем.
Төнлә күргән бу төшемне
Иртән сиңа сөйләп бирдем.

Ах, оятсыз! Азгын! дидең,
Йодрык белән сыртны төйдең,
Акланмадым, карышмадым,
Оятымнан башым идем.

Өнемдә бер кызны күрдем,
Кулларыннан тотып йөрдем.
Юк, монысын һич сөйләмәм,
Инде белдем — акыл бирдең.

## Гамил Афзал

### ЭПИГРАММАЛАР

#### МОСТАФА НОГМАНГА

Болын ямьле, сулар тәмле һәр авылда,
Кызлар матур, егетләр шәп һәр авылда.
Үзе тәти, йөзе тәти, күзе тәти,
Тигезләгәч тигез була икән тәки.

#### «АЗАТ ХАТЫН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ҖАВАПЛЫ СЕКРЕТАРЕ ГАБДУЛЛА ШӘРӘФЕТДИНОВ ҖЫРЛЫЙ

Әй, таң ата, таң ата шул,
Таң кайгыны тарата.
Безнең журналның кызлары:
Асиясе, Мәдинәсе, Диләрәсе, Саҗидәсе —
Бары да мине ярата.

#### ЗӨЛФӘТ

Юк безнең фамилиябез,
Булмаса, төкер әле.
Го́мер дә фамилиясез,
Аллага шөкер әле.

## Батулла Турай

### ТАЛАНТ АДЫМНАРЫ

#### БАЛИГЪ БУЛУ

Ут кабызгач кына
караңгыда утырганымны аңладым.

#### АФОРИЗМ

Ике йөзле булуга караганда
беркатлы булу яхшырак.

#### МӘРСИЯ

Мәрхүм Гапсаттар абзый әсәрләре сукыр бакырга да тормый иде, әмма алтын кеше иде үзе.

#### ДУАМАЛГА МӘДХИЯ

Җебегән ир
дуамал иргә караганда
гаиләсенә хәсрәтне күбрәк ташый.

# ЭШ ВАКЫТЫ

— Керергә ярыймы?
— Рәхим итегез.
— Фәрваз дигән егет сездә эшлиме?
— Бездә.
— Нуруллинмы?
— Юк, Миңнуллин Фәрваз.
— Ә миңа Нуруллин Фәрваз кирәк.
— Нурулин Вакыйф инде алай булгач.
— Юк, Нуруллин Фәрваз.
— Фәрвазның фамилиясе Миңнуллин бит.
— Ә миңа Нуруллин янына керергә куштылар.
— Вакыйф янынамы?
— Юк! Фәрваз янына.
— Фәрвазның фамилиясе Нуруллин түгел — Миңнуллин.
— Миңа Нуруллин Фәрваз кирәк.
— Нуруллин Фәрваз эшләми шул бездә.
— Миңнуллин — Вакыйфмыни ул?
— Нуруллин Вакыйф дидем бит инде.
— Миңа Фәрваз янына керергә куштылар.
— Алайса, Миңнуллингадыр?
— Миңнуллинга түгел, Нуруллинга.
— Вакыйфкамы?
— Фәрвазга.
— Гафу итегез, ләкин минем эш вакыты.
— Мин дә уйнап йөрмим. Эшемне бүлеп килдем. Фәрваз өстәле кайсысы?
— Әнә тегесе.
— Нуруллин Фәрваз өстәлеме?
— Әйе, Миңнуллин Фәрвазныкы.
— Нуруллин Фәрваз өстәле кайсы? дим.
— Нуруллин Фәрваз эшләми монда.
— Ә Нуруллин өстәле кайсысы?
— Тәрәзә янындагысы.
— Фәрваз эшлиме соң сездә?
— Эшли.
— Нуруллин да эшлиме?
— Ул да эшли.
— Миңа нәкъ менә Нуруллин Фәрваз кирәк тә инде.
— Соң алар икесе ике кеше ләбаса.
— Миңа Нурулин Фәрваз гына кирәк.
— Әбәткә киттеләр. Озакламый килерләр.
— Кемнәр?
— Нуруллин белән Миңнуллин.
— Миңа Нуруллин Фәрваз гына кирәк.
— Нуруллин Фәрваз бездә эшләми дидем ич инде мин сезгә.
— Җайлап кына аңлатырга буладыр ич... әле хәзер генә әбәткә китте дигән идегез.

— Бездә Миңнуллин Фәрваз гына эшли.
— Нуруллин эшләмиме?
— Эшли, ләкин аның исеме Вакыйф бит.
— Кайдан табарга инде Нуруллин Фәрвазны?
— Белмим шул.
— Сез Миңнуллин дисез, анысы Туфан буладыр инде аның.
— Туфан Миңнуллинмы? Әйе, андый кеше дә бар.
— Күптән шулай диләр аны. Югыйсә, аптыраттыгыз Фәрвазны Миңнуллин дип.
— Соң, ни бит... Фәрваз да Миңнуллин...
— Миңнуллин кем булып эшли соң ул?
— Журналда бүлек мөдире... тәнкыйтьче...
— Ә Туфан?
— Анысы шагыйрь аның.
— Ә миңа драматург дигәннәр иде.
— Анысы Миңнуллин.
— Әле генә шагыйрь дидегез.
— Хәсән Туфанны әйтәм бит мин.
— Миңнуллиннар ничәү соң, алайсам?
— Икәү.
— Ә Фәрвазлар?
— Берәү.
— Нуруллин?
— Берәү.
— Алайсам, шул үзе була инде Фәрваз Нуруллин.— Хушыгыз. Киттем. Шуны белергә генә кергән идем...

## М. Әпкәли

# СУДА БАЛЫК ЙӨЗӘДЕР

*Яңа романга рецензия*

Ниһаять, Хәсфиевнең «Суда балык йөзәдер» романы да дөнья күрде. Гаҗәеп кызык, үзенчәлекле чыккан Хәсфиевнең бу китабы. Калын гына, саллы гына. Чебен өстенә төшсә, һичшиксез, үтерәчәк. Бәясе бер сум илле ике тиен. Хәсфиев дигән сүзнең барлык хәрефләре дә эре итеп язылган. Укыган саен укыйсы килә ул сүзне. Ардырмый, ялыктырмый. Бәлки хәрефләрне ачык зәңгәргә буяганга да туа торгандыр әле бу дәртле хис. Романның исеме дә шулай ук игътибарны җәлеп итә. Шулай булмый хәле юк. Чөнки романның исеме Хәсфиев дигән сүз хәрефләренә караганда да эрерәк хәрефләр, урысчалап әйтсәк, чын мәгънәсендә БУКВАЛАР белән язылган. Бу хәрефләр инде Хәсфиев дигән сүз хәрефләренә контраст төскә буялган. Кыскасы, күзгә карап антитеза гудырган Хәсфиев. Ачык зәңгәр һәм ябык яшел...

Нур өстенә нур дигәндәй, түбәндә романның басылып чыккан елы да язып куелган. Бер сүз белән әйткәндә, тулы бер рәсем. Картина дип әйтсәк тә, авторыбыз уңышлардан башы әйләнеп егылмастыр, шәт. Чөнки Хәсфиев таза беләкле, киң җилкәле, егәрле егет.

Инде китапның төп сюжетына кайтып, «суда балык йөзәдер» җөмләсенә тулырак анализ ясыйк. «Йөзәдер суда балык» яисә «Балык суда йөзәдер» дип язмаган бит Хәсфиев. Кем әйтмешли, үгезне мөгезеннән эләктереп, «Суда балык йөзәдер», дип шартлатып әйткән. Биеп тора бу җөмлә. Суда балык йөзүен үз күзләрең белән күргәндәй буласың.

Тып-тын. Камышлар йоклый. Су чебеннәре оча... Ә балык йөзә дә йөзә. Элек тә шулай йөзгән, бүген дә йөзә. Бүгенге көн белән үткән заманны ничек оста бәйләгән Хәсфиев. Шул җөмлә аркасында роман эстетик тәрбия бирү белән бәррәттән күңелләрдә балык ашыйсы килү теләгән дә уята. Үзең дә сизмәсгән, хатыныңа «балык пешер» дип кычкырасың. Хатының тыңламый. Өйдә тавыш куба. Семья бозыла. Бу мәсьәләдә бераз сак булырга кирәк иде Хәсфиевкә. Анысы, дүрт аяклы ат та абына. Хәсфиев борынын төшермәсен. Тукай әйтмешли, тәнкыйть кирәкле шәйдер.

Роман кирпечтән аз гына югарак чыккан. Буе — ике, аркылысы — бер карыш. Алдан әйткәнемчә, китап артына бәясен дә язып яхшы иткәннәр. Бер сүз белән әйткәндә, молодчина! Кигап киштәләрен бизәп торырлык роман язган Хәсфиев.

# ТАБЫШ

*(Аңлатмалы сүзлек язуга тәҗрибә)*

*Табыш! Яңа табылдык! Әпкәлинең гаять бай архивыннан әдәбиятыбыз өчен бик тә кыйммәтле булган кулъязма — Әпкәли үзе исән чакта тәмамлый алмый калган аңлатмалы сүзлек табылды. Сүзлекнең төзелү принцибы кызыклы. Әпкәли беренче компонент итеп әдәбият белемендә, әдәби тәнкыйтьтә һәм язучыларның рәсми чыгышларында кулланыла торган сүзләрне һәм төшенчәләрне ала. Ә карасаң, шул ук сүзләрне һәм төшенчәләрне гадирәк, аңлаешлырак һәм кыскарак итеп тә әйтеп була икән. Әнә шундый гади һәм аңлаешлы сүзләрне Әпкәли икенче компонент итеп ала. Түбәндә без укучыларыбызга сүзлекнең Әпкәли эшләп калдырган кадәресен тәкъдим итәбез.*

1. Пөхтә киенгән, төз гәүдәле, йөзендә һәр вакыт елмаю балкып тора торган матур борынлы, зәңгәр күзле, кара кашлы, бөдрә чәчле кеше — **уңай герой**.

2. Иләмсез зур корсак үстергән, һәр вакыт караңгы чырайлы, тукмак кадәр күксел-кызыл борынлы, карлыккан тавышлы, җимерек кашлы, акай күзле пеләш кеше — **кире герой**.

3. Урта кул укучы — **урта белемле**.

4. Югары зәвыклы укучы — **вуз бетергән**.

5. Әдәбият һәм сәнгать кануннарына җавап бирми торган китап — **халтура (чүп, пүчтәк дигән вариантлары да бар)**.

6. Ритмик закончалыклар һәм рифма системасына җавап бирми торган поэзия әсәре — **телне сындыра торган шигырь**.

7. Югары зәвык һәм әдәбият-сәнгатьнең югары таләпләренә җавап бирә торган әсәрләр җыентыгы — **шәп китап**.

8. Артык нык сентиментализмга бирелеп, примитив хисләрне идеаллаштырырга тырышып, трагик пессимизмга бирелеп язылган шигъри әсәр — **елак шигырь**.

9. Дөреслекнең күзенә карап, сәнгатьчә дөреслек рухында тормышны купшыландырмыйча, бизәмичә язылган шигъри әсәр — **усал шигырь.**

10. Сюжет линиясе, образлар эзлеклелеге, логик бәйләнеше булмаган әсәр — **геройларны бер-берсенә төкерек белән генә ябыштырып кую.** (Монысы Ф. Хөсни терминологиясеннән алынды.)

11. Әдәби әсәрдә, тапталган, кулланылышта йөри-йөри шомарып беткән, төссез һәм хиссез сүзләр, фразалар гына кулланып язу — **гәҗит теле.**

12. Әдәби әсәрдә «ләбаса», «ласа», «ләсә» дигән сүзләрне кулланып язу — **Х. Туфанга ияру.**

13. Әсәрдәге җөмләләрдә бик күп тел бизәкләре куллану, җөмләне сыгылмалы итү, логик төзеклек булганда, хәтта грамматика, синтаксис кануннарын да исәпкә алмау, җор теллелек — **Ф. Хөснигә иярү.**

14. Җөмләне шигырь юлының уртасында тәгәлләп, бер үк җөмләнең дәвамын яки азагын икенче строфага үк чыгарып язу — **С. Хәкимгә иярү.**

15. Ярты ел вакыт эчендә берничә роман һәм повесть язу — **Мәхмүт Хәсәновка иярү.**

16. Язучының үзе белмәгән тормыш материалын үз иҗатында иң дөрес хәл итүе — **темага керешмәү.**

17. Теләсә нинди шартларда, теләсә кайсы урында шигырь язарга сәләте булган шагыйрь — **фатирсыз шагыйрь.**

Сүзлекне матбугатка яшь әпкәлиовед Г. РӘХИМ әзерләде.

## ЮБИЛЕЙ ТАНТАНАЛАРЫ

### Шәриф Камалның тууына 90 ел

Март аенда В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Хезмәт Кызыл Байрак орденлы Казан дәүләт университетының Актлар залына галимнәр, язучылар һәм студентлар җыелды. Биредә күренекле татар язучысы Шәриф Камалның тууына 90 ел тулу уңае белән фәнни-теоретик конференция барды. Казан дәүләт университеты, СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институты, Татарстан язучылар союзы тарафыннан үткәрелгән конференцияне Шәриф Камал турындагы кереш сүз белән филология фәннәре докторы профессор Хатип Госманов ачты. Әдәбият һәм тел белгечләре Һ. Мәхмутов «Шәриф Камал һәм татар театры», М. Мөхәммәдиев «Шәриф Камал әсәрләренең теле», М. Мәһдиев «Шәриф Камалның «Вакыт» газетасы битләрендә басылган фельетоннары», И. Башированың «Шәриф Камал әсәрләренең стиль үзенчәлеге» турындагы докладлары тыңланды. Татарстан дәүләт музее әдәби хезмәткәре Ә. Хәйруллинның «Шәриф Камал турында яңа материаллар» дигән чыгышы зур кызыксыну белән каршыланды. Ул Шәриф Камалның тәгәлләнми калган әсәрләре, каләмдәш дусларына язган хатлары, телеграммалары һ. б. кызыклы материаллар белән таныштырды.

Докладлардан соң фикер алышулар булды.

* * *

Татарстан язучылар союзы, ТАССРның Культура министрлыгы һәм Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге Шәриф Камалның тууына 90 ел тулуга багышлап, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында әдәби-музыкаль кичә үткәрде. Кичәне кереш сүз белән Фатих Хөсни ачты. Шәриф Камалның тормыш юлы һәм әдәби эшчәнлеге турында докладны Габдрахман Минский ясады. Әдипнең туган ягы Мордовия АССР язучылар союзы вәкиле Ф. К. Андрианов, Пешлә авыл Советы председателе Ү. З. Бикмурзин чыгыш ясадылар һәм Ш. Камалның Казандагы музеена истәлекле бүләкләр тапшырдылар.

Кичәдә шәһәребезнең хезмәт ияләре, партия, совет, профсоюз, комсомол работниклары, язучылар, артистлар, журналистлар һ. б. иҗат оешмалары вәкилләре катнашты.

Кичәнең тантаналы өлешеннән соң, Ш. Камалның «Акчарлаклар» әсәре буенча эшләнгән спектакль күрсәтелде.

* * *

Татар совет әдәбияты классигы Шәриф Камал Совет властеның беренче елларында Оренбург партия матбугатында эшли, Сакмар районының Түбән Чебенле авылында коммуна оештыруда катнаша (соңыннан шушы вакыйгалардан файдаланып «Матур туганда» романын яза). Оренбург шәһәренең Х. Ямашев исемендәге китапханәсендә мөдир була. Шуңа күрә биредә Шәриф Камалны яхшы беләләр һәм хөрмәт белән искә алалар.

Язучының тууына 90 ел тулган көннәрдә Х. Ямашев исемендәге шәһәр китапханәсендә зур әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кичәдә язучының тормышы һәм иҗаты турында доклад һәм 1921 елны коммуна төзүдә катнашкан беренче коммунарларның истәлекләре тыңланды. Тантанага килүчеләр Шәриф Камалга багышланган күргәзмәне зур кызыксыну белән карадылар.

### «Ялкын» журналының 50 еллыгы

Татар балалары өчен әдәби-художестволы журналның чыга башлавына 50 ел тулу уңае белән В. И. Ленин исемендәге Бөтен Союз пионер оешмасының Татарстан республика советы тантаналы пленум үткәрде.

«Ялкын» журналының 50 еллыгына багышлап, шәһәребезнең төзүчеләр Сараенда үткәрелгән бу пленумда «Ялкын» журналы редакциясенә Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Почет грамотасы тапшырылды, котлау адреслары бирелде. Тантанада язучылар, журналистлар, партия һәм комсомол работниклары, укучылар һәм укытучылар, Башкортстан, Үзбәкстан, Белоруссия, Грузиядән килгән кунаклар катнашты.

* * *

Совет матбугатында актив эшләүләре һәм «Ялкын» журналының 50 еллыгы уңае белән балалар язучысы Җәвад Тәрҗеманов һәм шагыйрь Нәби Дәүли КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советы Почет Грамотасы белән, художник Тавил Хаҗиәхмәтов Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Почет грамотасы белән бүләкләнделәр.

### Татарстанда кино сәнгате

Татарстанда кино эшләп чыгарыла башлауга быелның март аенда 50 ел тулды.

Шул уңай белән Казан киностудиясенең Зур залында иҗади конференция булып узды. Ике көн барган конференциядә Казан кинохроника студиясе директоры А. Н. Краев, студиянең баш редакторы Р. И. Копосов һәм Казан телестудиясе кино производствосының баш редакторы И. И. Ихсановның докладлары тыңланды.

Конференция эшендә РСФСР Госкино коллегиясе члены Т. И. Гваришвили, СССР

Кинематографистлары союзының Идел буе бүлеге секретаре В. А. Плотникова, КПСС-ның Татарстан, Чувашия, Мордовия, Мари өлкә комитетлары вәкилләре, Татарстанның иҗат оешмаларыннан килгән вәкилләр катнашты.

Конференциядә катнашучылар Казан кинохроника һәм Казан телевидение студияләрендә эшләнгән фильмнарны карадылар, соңыннан фикер алышулар булды.

* * *

Совет документаль кино сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм Татарстан АССР кинопроизводствосы оештырылуның 50 еллыгы уңае белән Казан кинохроника студиясе Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Почет грамотасы белән бүләкләнде.

## ӨЛКӘН РӘССАМНЫҢ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Республикабызда ТАССРның халык художнигы Кондрат Евдокимович Максимовның әсәрләрен яхшы беләләр һәм яратып карыйлар. Күптән түгел аңа 80 яшь тулды. Башкалабызның хезмәт ияләре яраткан рәссамнарын хөрмәтләп бу көнне Татарстанның сынлы сәнгать музеена җыелдылар. Биредә К. Е. Максимовның әсәрләре күргәзмәсен ачу тантанасы булды. Күргәзмәне ТАССР художниклар союзы идарәсе председателе урынбасары Әнәс Тумашев ачты. Сәнгать белгече Р. Г. Шаһиева художникның тормыш һәм иҗат юлы турында доклад ясады. ТАССР Культура министры урынбасары, шагыйрь Ренат Харисов, Социалистик Хезмәт Герое, академик Б. А. Арбузов, шәһәребезнең партия, комсомол оешмалары вәкилләре һ. б. юбилярны иҗат бәйрәме белән тәбрик иттеләр. К. Е. Максимовка РСФСР художниклар союзының Почет грамотасы тапшырылды.

Тантанага килүчеләр К. Е. Максимовның 150дән артык әсәрләре куелган күргәзмәне зур кызыксыну һәм канәгатьләнү белән карадылар.

## «ЙОСЫФ-ЗӨЛӘЙХА» ПОЭМАСЫНА 740 ЕЛ

Татар совет әдәбиятының елга башы булган «Йосыф-Зөләйха» поэмасының язылуына 740 ел тулды.

Бу күренекле датага багышлап, Татарстан Дәүләт музее әдәби кичә үткәрде.

Кичәдә филология фәннәре кандидаты Ш. Абиловның «Йосыф-Зөләйха» поэмасының татар әдәбияты тарихында тоткан урыны», филология фәннәре кандидаты Ф. С. Фасеевның «Әсәрнең кульъязмалары», КИЯЛИнең фәнни хезмәткәре Н. Хисамовның «Йосыф-Зөләйха» поэмасы һәм халык легендалары», скульптор Б. Урманченың «Кол Гали образы өстендә эшләвем» дигән чыгышлары тыңланды. Магнитофон язмаларында «Йосыф-Зөләйха» әсәренең халык иҗатындагы вариантлары бирелде. Артистлар башкаруында «Йосыф-Зөләйха» поэмасыннан аерым өзекләр укылды.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬЛӘР

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры язучы Нурихан Фәттахның «Кол Гали» трагедиясен сәхнәгә куйды. «Йосыф-Зөләйха» поэмасының авторы, борынгы Болгар шагыйре Кол Галинең фаҗигале язмышын сурәтләгән бу спектакльне Казан тамашачылары зур алкышлар белән каршылады. Шагыйрь Гали ролен Татарстанның халык артисты, Тукай премиясе лауреаты Ринат Таҗетдинов һәм артист Наил Әюпов, шагыйрьнең сөйгәне Чәчәк ролен Рәмзия Хисамова һәм Дания Нуруллина, Галинең агасы Хаҗи Бәк ролен Равил Шәрәфиев, аның хатыны Әнҗе бикәне ТАССРның атказанган артисткасы, Тукай премиясе лауреаты Наилә Гәрәева белән Гөлсем Исәнгулова, баш вәзир Актай ролен РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Габдулла Шамуков, ТАССРның халык артисты Дэллюс Ильясов, кыпчакларның ыру башлыгы Уразбәк ролен ТАССРның халык артисты Һидият Солтанов башкара. Спектакльдә ТАССРның атказанган артисты Наил Дунаев, артистлардан Бари Әшрәпов, Әнвәр Гобәйдуллин, Роберт Исхаков, Гаптелфәрт Шәрәфиев, Шамил Бариев, Сәлим Мифтахов, Роберт Әбүльмәмәтов, артистка Рауза Ахмеровалар да катнаша. «Кол Гали» трагедиясен сәхнәгә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты Марсель Сәлимҗанов куйды. Спектакльнең художнигы Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Тукай премиясе лауреаты Әнәс Тумашев. Костюмнар художник Тавил Хаҗиәхмәтов җитәкчелегендә әзерләнде. Трагедиягә музыканы композитор Ринат Еникеев язды.

* * *

Балалар өчен беренче татар операсы дөньяга туды. Һади Такташның «Тәүфыйклы песи» шигыре мотивлары буенча эшләнгән «Мәкерле песи» операсын яшь композитор Луиза Хәйретдинова язды. Либреттоның авторы шагыйрь Зөлфәт.

Мәкерле песи ролендә артистка Ә. Заһидуллина, Р. Мифтахова, ТАССРның атказанган артисткасы Ф. Тимерова, әби ролендә ТАССРның атказанган артисткасы Х. Гыйниятова, Р. Нуриева, Акбай ролен РСФСРның халык артисты А. Аббасов, К. Якупов, Актолым ролен З. Рәхимуллиналар башкаралар. Оркестр белән дирижер В. Васильев җитәкчелек итә. Әсәрне сәхнәгә режиссер И. Мәҗитов куйды.

Җиңел аңлаешлы матур музыка, кызыклы сюжет, художник Г. Павлов тарафыннан эшләнгән серле урман, авыл күренешләре, матур костюмнар нәни тамашачыларның күңелен бик тиз җәлеп итте. «Мәкерле песи» операсы язгы каникул көннәрендә Казан укучыларына күңелле бүләк булды.

## ГЫЙЛЬМИ УТЫРЫШ

СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының чираттагы гыйльми советы утырышы күренекле композитор Фәрит Яруллин истәлегенә багышланды. Композиторның мирасын өйрәнү мәсьәләләренә багышланган докладында аспирант А. Алмазова «Шүрәле» балетының совет музыка культурасында тоткан ролен сөйләде. Тарих фәннәре докторы Х. Хәсәнов,

Фиданлэр белэн бергэ яшэп, бергэ иҗат иткэн еллары, аерым кызыклы очрашулары турында истэлеклэр сөйлэделэр.

* * *

Америка-Совет яшьлэренең II форумына катнашкан Совет делегациясе составында яшь инженерлар, механизаторлар, Дагстанның атаклы «Лизгинка» ансамбле, шагыйрь Роберт Рождественский, белорус җырчысы И. Краснодубскийлар белэн бергэ республикабызның Муса Җэлил исемендэге опера һэм балет театры артисткасы Вафирэ Гыйззэтуллина да катнашкан иде. Март аенда ул «Казан утлары» редакциясенэ кунакка килде һэм СССР Яшьлэр оешмалары комитеты председателе Г. И. Янаев һэм БССР яшьлэр оешмалары комитеты председателе Б. Д. Егоров житэкчелегендэге бу делегациянең Америкада уткэргэн егерме көне, Америка яшьлэре белэн очрашулары, алар оештырган бэхэслэргэ, фикер алышуларга катнашулары, Америка халыкларының тормыш-көнкүрешлэре, гореф-гадэтлэре турында кызыклы истэлеклэр сөйлэде. Очрашуга килгэн язучылар, редакция хезмэткэрлэре җырчыга күп кенэ сораулар бирделэр.

* * *

Танылган композитор Хөснул Вэлиуллин Зеленодольск хезмэт иялэрендэ кунакта булды. Татарстанның атказанган культура работнигы, музыка белгече Зэйнэп Хэйруллина композиторның тормыш һэм иҗат юлы турында сөйлэп, очрашу кичэсен ачып җибэрде. Хөснул Вэлиуллин кичэгэ килүчелэрне иҗат планнары белэн таныштырды, яңа эсэрлэрен уйнап күрсэтте. Э композиторның иҗатташ дуслары — җырчылар ул язган көйлэрдэн концерт бирделэр.

## ТАТАР АРТИСТЛАРЫНЫҢ КОНЦЕРТЛАРЫ

* * *

Ленинград дэүлэт эстрада театры бинасында РСФСРның атказанган артисты, Г. Тукай премиясе лауреаты Илһам Шакиров концертлары булды. Концертны Татарстанның атказанган артисты Фэйзи Юсупов алып барды. Татар артистларының чыгышларын биш меңгэ якын ленинградлы карады.

* * *

Илһам Шакиров Г. Тукай исемендэге татар дэүлэт филармониясенең эстрада артистлары составында Чилэбе шэһэрендэге концертларда да чыгыш ясады.

* * *

Чилэбе шэһэренең спорт сараенда барган Татар дэүлэт филармониясенең эстрада артистлары концертында ТАССРның халык артисткасы Элфия Афзалова, ТАССРның атказанган артисты Габдулла Рэхимкулов, филармония солисткасы Флера Сөлэйманова һэм ТАССРның атказанган артисты Фэйзи Юсуповлар катнашып, тамашачылар алдында зур уңыш казандылар.

Өлкэ телевидениесе чакыруы буенча Флера Сөлэйманова белэн Габдулла Рэхимкулов зэңгэр экранда да чыгыш ясадылар.

## ДАГСТАН КУРЧАК ТЕАТРЫ КАЗАНДА

Казан шэһэр курчак театры бинасында «Җек малае Җек» (авторлары М. Тебиев, И. Гаев) исемле спектакль белэн Дагстан дэүлэт курчак театры үзенең гастрольлэрен башлап җибэрде.

Шэһэребезнең яшь тамашачылары рус һэм дагстан халык экиятлэре, илебезнең башка миллэт эсэрлэре буенча эшлэнгэн күңелле спектакльлэрне ике атна буе яратып карадылар.

## БАШКОРТ БИЮ АНСАМБЛЕ ЧЫГЫШЛАРЫ

Шэһэребезнең спорт сараенда Башкортстанның халык биюлэре дэүлэт ансамбле чыгышлары булып үтте.

Югары сэнгать осталыгына ия булган талантлы бу коллективны туган илебездэ генэ түгел, Европа, Азия һэм Африка иллэрендэ дэ яхшы белэлэр. Коллективта яшьлэрнең һэм студентларның Бөтен дөнья фестивальлэре лауреатлары Х. Зобэйдуллин, Э. Ишбердин, БАССРның атказанган артисткасы Р. Туйсина кебек күренекле артистлар күп.

Башкорт дуслар Казан тамашачыларына башкорт, татар, рус, украин һ. б. халык биюлэре һэм күп кенэ чит ил халыклары биюлэрен күрсэттелэр. Концертлар зур уңыш белэн барды.

## ХЕЗМЭТКЭ ХӨРМЭТ

Матбугат өлкэсендэ озак еллар эшлэве һэм «Ялкын» журналының 50 еллыгы уңае белэн журналның редакторы Роза Хафизовага ТАССРның атказанган культура работнигы дигэн мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет сынлы сэнгатен үстерүдэге хезмэтлэре өчен СССР Художниклар союзы члены Гайшэ Габдрахман кызы Рахманкуловага Татарстан АССРның атказанган сэнгать эшлеклесе дигэн мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет театры сэнгате өлкэсендэге хезмэтлэре өчен Г. Камал исемендэге татар дэүлэт академия театры артисты Эзһэр Шакировка, совет музыка сэнгате өлкэсендэге хезмэтлэре өчен Муса Җэлил исемендэге опера һэм балет театрының опера солисты Хэдичэ Гыйниятовага, совет хореография өлкэсендэге хезмэтлэре өчен шул ук театрның балет солисты Ирина Хэкимовага Татарстан АССРның атказанган артисты дигэн мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет театр сэнгате өлкэсендэге хезмэтлэре өчен Г. Камал исемендэге татар дэүлэт академия театры артисты Дэллюс Ильясовка Татарстан АССРның халык артисты дигэн мактаулы исем бирелде.

сәнгать фәннәре кандидаты Х. Гобәйдуллин Фәрит Яруллин турында истәлекләр сөйләделәр.

Утырышта чыгыш ясаучылар композиторның иҗатын өйрәнүдә булган аерым кимчелекләргә дә тукталдылар.

## АКТЕРЛАР ЙОРТЫНДА КИҢӘШМӘ

Март аенда Бөтен Союз театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге режиссерлар, драматурглар, театр тәнкыйтьчеләрен Актерлар йортына, түгәрәк өстәл янына чакырды. Киңәшмәдә драматург А. Гыйләҗев бүгенге татар театр сәнгате турындагы уйларын, теләкләрен әйтеп, кыскача кереш сүз сөйләде. Драматург Р. Батулла Курчак театры репертуары, «Казан утлары» журналының баш редакторы Г. Ахунов журналда бүгенге татар театр сәнгатенә багышланган мәкаләләрне тирәнрәк итеп эшләү, проблемалар кую турында, драматург Т. Миңнуллин режиссерлар белән драматургларның иҗади дуслыгын көчәйтү турында, драматург Р. Ишморат драма секциясен Актерлар йортына күчерү һәм аны чын мәгънәсендә әдәби осталык мәктәбенә әйләндерү турында, драматург Г. Минский өлкән драматургларның яшьләргә ярдәме турында сөйләделәр.

Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театрының баш режиссеры М. Сәлимҗанов, Республика күчмә театрының баш режиссеры Р. Тумашев, Минзәлә драма театрының баш режиссеры М. Мостафин үзләрен борчыган мәсьәләләр, репертуар әзерләүдәге кыенлыклар хакында сөйләделәр, драматургларны бүгенге көннең алдынгы кешесен пьесаларда зур итеп гәүдәләндерергә чакырдылар.

Киңәшмәдә шулай ук Бөтен Союз театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе Р. Җиһаншина, шушы бүлекнең җаваплы секретаре И. Гатова, режиссерлар П. Исәнбәт, Р. Хажиәхмәтов, Л. Садриев (Әлмәт театрының баш режиссеры), драматурглар И. Юзеев, Д. Вәлиев, рәссам Ә. Тумашев, театр тәнкыйтьчесе Д. Гыймранова катнаштылар.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Татарстан язучылар союзы каршындагы иҗат секцияләрендә отчет-сайлау җыелышлары башланды. Татарстанда яшәүче рус язучылары секциясе үткән эшләргә беренче булып йомгак ясады һәм секциянең яңа бюросына Ю. Белостоцкий, Г. Паушкин, М. Скороходов, В. Воздвиженскийларны сайлады. Секция җитәкчесе — Т. Журавлев.

* * *

Драматурглар да секция җитәкчесе Риза Ишморатның отчет докладын тыңлап, фикер алыштылар. Бюроның яңа составына Х. Вахит, А. Гыйләҗев, И. Юзеев, Р. Ишморат сайланды. Секциянең яңа җитәкчесе — Т. Миңнуллин.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ СУГЫШЧАН ЭЗЛӘРЕ

М. Горький исемендәге дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким күптән түгел Белгород һәм Калинин өлкәләреннән кызыклы хатлар алды. КПССның Белгород өлкә комитеты пропаганда һәм агитация бүлеге чыгарган «Политик агитация» журналы «Утлы поэма» дигән зур мәкалә бастырган. Анда Сибгат Хәкимнең егерме биш елдан соң Дугада булып, сугышчан эзләре буенча йөрүе, шул җирләрнең хезмәт иясләре белән очрашып сөйләшүе, нәтиҗәдә «Дуга» поэмасын иҗат итүе турында дулкынланып язылган.

Калинин өлкәсеннән килгән конвертта исә, «Калининская правда» газетасының соңгы көннәрдә чыгарылган бер саны салынган. Монда журналист И. Васильевның «Лейтенант Хакимов и писатель Эренбург» дигән мәкаләсе басылган. Ике язучы, ике сугышчы Грибеево авылы тирәсендә сугышканнар һәм иҗат иткәннәр. Араларын 5—6 чакрым гына аерып торса да, бер-берсеннән хәбәрдар булмаганнар, аларга очрашырга туры килмәгән. Тарих исә барын да ачыклый, тарих берсен дә онытмый.

## ЯҢА ТӘРҖЕМӘЛӘР

АПН тарафыннан хинди, бенгали, урду, пенджаби, орая, ассами, тамили, каннада, телугу, малаялам, гуджарати, маратхи телләрендә индиядә һәм непали телендә Непалда чыга торган «Совьет Ленд» журналында Мәҗит Рафиковның «Шарлама» хикәясе басылып чыгуы турында узган елда хәбәр иткән идек инде. Мәҗит Рафиков журнал редакциясеннән күптән түгел генә тагын хат алды. Анда шул ук журналда авторның «Сиңа ничә яшь» дигән хикәясе басылып чыгуы турында хәбәр иткәннәр һәм аның Индия — Совет дуслыгы темасына хикәяләр язып торуын үтенгәннәр.

* * *

Балалар язучысы Шамил Рәкыйповның «Таңнар һаман матурмы» дигән повесте Мәскәүдә «Детская литература» нәшриятында басылып чыкты. Советлар Союзы Геройлары Гыйльфан Батыршин һәм Иван Чернопятколарның дуслыклары һәм батырлыклары турындагы бу әсәрне русчага Эмил Амитов тәрҗемә иткән.

* * *

Драматург Диас Вәлиевнең «Дәвам» пьесасын Украинаның «Мистецтво» нәшрияты «Погода на завтра» исеме белән басып чыгарды. «Хәзерге заман драматургия китапханәсе» сериясенә кергән бу әсәрне В. Гончар тәрҗемә иткән.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

* * *

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында татар әдәбияты тарихы турында истәлекләр кичәсе булды. Үзенчәлекле һәм кызыклы бу кичәне Татарстан язучылар союзы идарәсе члены, өлкән язучы Афзал Шамов ачты. Татар әдәбиятының аксакаллары Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Риза Ишморат, Сәрвәр Әдһәмова, Гомәр Баширов, Габдрахман Минскийлар кичәгә килгән әдәбият сөючеләргә Риза Фәхретдинов, Фатих Кәрими, Шәриф Камал, Гомәр Гали, Һади Такташ, Муса Җәлил, Шамун

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210